ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.1999





# Сабан туе
# Сабан туе...



Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле...
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
—Бирмә билеңне!
—Бирмә-ә-ә...







Дошманнар таптаса җиреңне,
Сорамый: "Син батыр идеңме?"
Мәйдан күк кысыла бар халык:
—Бирмә илеңне!
—Бирмә!

**Казан утлары**
**Qazan utlarь**

*1999*

# 6

**(920)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Флүс ЛАТЫЙФИ. Ишелеп төшкән бәхет. *Роман* ... 5
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Шигырьләрем—яшәү хакында. *Шигырьләр* ... 69
Мәгъсум ХУЖИН. Ике хикәя ... 75
Клара БУЛАТОВА. Яңа шигырьләр ... 114

А. С. ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА 200 ЕЛ

Рәдиф ГАТАШ. «Хәзрәти Пушкин» ... 86
А. С. ПУШКИН. Шигырьләр. *Зөлфәт тәрҗемәсе* ... 87
Җәмил САФИУЛЛИН. А. С. Пушкин иҗатында Коръән ... 92

ДРАМАТУРГИЯ

Рәдиф СӘГЪДИ. Сынган беләзек. *Мелодрама* ... 100

ПУБЛИЦИСТИКА

Тәүфикъ ӘЙДИ. Үз җырыбыз—үзәктә ... 118

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рифат СВЕРИГИН. Туксанынчы еллар әдәбияты ... 126
Фатих УРМАНЧЕ. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь ... 129

СӘНГАТЬ

Гали АРСЛАНОВ. Халык җырчысы ... 142
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Нарасый хаким ... 145

ФӘН

Зоя КИРИЛЛОВА. Үткәннәрдән сабак алыйк ... 150
Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Мөбарәк тәсбихның бер буыны ... 158
Зөфәр РӘМИЕВ. Тукай энциклопедиясе төзелсәме!? ... 183

СӘЯХӘТНАМӘ

Галиәсгар КАМАЛ. Истанбул мәктүбләре ... 163

КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВКА 70 ЯШЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Дөньяда сүз җинәр ... 174

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ. Фатих Кәрими мирасына яңа сәхифәләр ... 177

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Ф. ЛАТИФИ «Свалившееся счастье»; рассказы М. ХУЗИНА; стихи Р. ИДИАТУЛЛИНА, К. БУЛАТОВОЙ.
«К 200- летию А. С. Пушкина»: предисловие Р. ГАТАША и стихи Пушкина в переводе Зульфата, статья Дж. САФИУЛЛИНА «Коран —в творчестве А. С. Пушкина ».
«Драматургия»: мелодрама Р. САГДИ «Сломанный браслет».
«Публицистика»: статья Т. АЙДИ «Всегда в нашем сердце».
«Литературная критика»: «Татарская литература 90-х годов»—статья Р. СВЕРИГИНА; статья Ф. УРМАНЧЕ «Древняя мифология и поэзия».
«Искусство»: статья Г. АРСЛАНОВА «Народный певец»; статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА о творчестве А. Фатхутдинова «Художник-мыслитель».
«Наука»: З. КИРИЛЛОВА. «Уроки прошлого».
«Память»: статья Н. ХИСАМОВА «Наставник» о профессоре Х. Усманове; статья З. РАМИЕВА «О необходимости энциклопедии Тукая».
«Заметки путешественника»: Г. КАМАЛ. «Письма из Стамбула».
«История литературы»: М. АХМЕТЗЯНОВ. «Новые тенденции в изучении творчества Ф. Карими».
«К 70 - летию переводчика К. Миннебаева»: статья Т. ГАЛИУЛЛИНА.
На наших обложках: фоторепродукция А. Фатхутдинова «Лошади военных лет»; ученый и поэт Нурмухамет Хисамов—работа А. Хисамова.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": F. LATIFI'S novel «The fallen down happiness»; M. KHUZIN'S stories; the verses of R. IDIATULLIN, K. BULATOVA.
"Commemorating the 200th anniversary of A. Pushkin": the preface of R. GATASH and PUSHKIN'S verses in translation of ZULFAT, D. SAFIULLIN'S article «Koran in A. Pushkin's creative works».
"Dramatics": R. SAGDI'S play «The broken bracelet».
"Publicism": T. AIDI'S article «Always in our heart».
"Literary criticism": "Tatar literature of 90 th years" article of SVERIGIN'S article; F. URMANCHI'S article «The ancient mythology and poetry».
"Art": ARSLANOV'S article «People's singer»; R. FAIZULLIN'S article about A. Fatkhutdinov's creativ works «The artist - the thinker».
"Science": Z. KIRILOVA «Lessons of the past».
"Memory": N. HISAMOV'S article «The mentor» about professor N. Usmanov; Z. RAMIEV'S article «About need of Tukai's encyclopaedia».
"Travelling notes": G. KAMAL «The letters from Istanbul».
"History of the literature": M. Akhmetzanov «The new tendencies in study of F. Karimi's creativ works».
The diary of social and cultural life.
In our covers:A. Fatkhutdinov's fotoreproduction; scientist and poet Nurmuhamet Khisamov - Hisamov's work.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.05.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9019 Заказ 3-234
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

---

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Флүс Латыйфи**

# ИШЕЛЕП ТӨШКӘН БӘХЕТ

РОМАН

**Икенче кисәк**

I

Оркыя ханым Илдарны алдына бастырып, әйләндерә-әйләндерә тикшерде. Энә-җептән яңа гына төшкән кием-салымда һәр җөйнең үз урынында икәнен белсә дә, барысын да кат-кат күздән кичерде. Пиджагының җыерылган җирләре юкмы, галстугының төене артык зур булып, чекрәеп күзгә кереп тормыймы? Күлмәге яхшылап үтүкләнгәнме? Аяк киемнәрендә тузан әсәре сизелмиме? Хәзерге моданы аңлап бетермәссең, ә югары даирәдәгеләр бу мәсьәләдә консервативрак була. Алар Парижданн яисә Лондоннан нинди мода җилләре исүгә бик үк карап тормый. Дипломатик даирәләрнең үз кануннары. Ә аларны исә Оркыя ханымга аңлатып торасы юк.

Шулай да тәэсирләрен кем белән дә булса уртаклашасы килде бугай, үзенә ярдәм итәргә дип күршедән кергәләп йөрүче кызга сораулы караш ташлады.

—Йә, әйт әле, мисс Марта, синең күзеңә берәр житмәгән жире чалынмыймы?—диде ул эчке горурлыгын сиздермәскә тырышып.

Мартаның йөзенә елмаю җәелде.

—О-о! Кияү егете кебек,—диде ул баш бармагын өскә тырпайтып.—Мондый егет янына бүген үк туй күлмәге киеп янәшә басарга әзермен...

—Һы,—дип куйды Оркыя ханым.

Һәм инде күптәннән кияүгә чыгарга хыялланып та, һаман тиңен таба алмыйча картаеп баручы кызга елмаеп бармак янады. Кара аны, янәсе. Күңеленнән генә уйлап куярга да өлгерде: «Һы, кызыкай, миңа ярдәм итәргә керәсең микән син, әллә кереп йөрүеннең сәбәбе Илдарда микән?»

Тизрәк чыгып китү җаен каерган Илдар гына каш җыерды:

—Әни, болай озаклап төпченсәң, минем гомердә өйдән чыгып китә аласым юк,—диде ул ризасызлыгын яшереп тә тормыйча.—Әллә мине анда көтеп торырлар дип беләсеңме?

Улының төз буй-сынына, чиста ак йөзендәге ирләрчә матурлыкка

---

Ахыры. Башы журналның 5 санында.

тагын бер ямь өстәп кыйгачланган кара кашларына, иягендә аз гына беленеп торучы чокырга, Әмирҗанның яшь чакларын хәтерләтүче хәрәкәтләренә карап горурлык хисләре кичергән ана кешегә аның сүзләре корт чаккандай тәэсир итте.

—Ничә тапкыр әйткәнем бар, минем белән инглизчә сөйләшмә,—диде ул кырыс кына. Мондый көннең ямен җибәрәсе килмәсә дә, улының өйдәге кагыйдәләрне бозуына битараф кала алмады.

Әнисенә каршы килүнең ни бәягә төшәсен яхшы белгән Илдар килешергә ашыкты, татарчага күчте һәм нәкъ сабый чакларындагыча сузып әйтте:

—Ә-ә-әни-и, дим, ашыкканда мин шулай ялгышкалыйм инде, гафу ит. Бүген көннең нинди икәнен беләсең...

—Шуңа күрә дә ашыкмаска кирәк. Һәр сүзеңне уйлап, үлчәп әйтәсе. Кем белә, бәлки безнең күптәнге, бик күптәнге хыялыбызның тормышка ашар вакытын якынайта торган көндер әле бу. Урыны җәннәттә булсын дип әйтә алмыйм, җәһәннәмдә икәнлегенә иманым камил, Йосыф Сталин үлгәннән соң беренче өметебез, ышанычыбыз бөреләнгән чак бу! Әтиеңнең дә, минем дә туган илләрне кайтып бер күрергә зар-интизар икәнне, шул көннәрне тилмереп көткәнне яхшы беләсең, улым. Анда кайтып килү сезнең өчен дә хаҗга баруга тиң гамәл булыр иде.

—Беләм, әни, беләм!—Илдар хәйләкәр елмаеп куйды.—Тик минем туган җирем анда түгел, Кытайда бит! Мин нишлим?..

—Алай димә, улым. Ата-анаңның туган җире—синең дә Ватаның, нәсел тамырың тернәкләнгән җир! Ул синең дә туган илең була. Ата-бабаларыбызның кендек каны тамган изге туфрак ул! Йә, ярый... Алдын-артын уйлап эш ит! Хатны үзенә үк бирә алмассың, әмма дәрәҗәлерәк, сүзе үтәрдәйрәк кеше табарсың... Һәрхәлдә, инде дөнья күргән егетсең. Анысын гына үзең чамаларсың...—Оркыя ханым нигәдер авыр сулап куйды.—И ходаем, ышанасы да килми, ничәмә-ничә еллардан соң бит... Ходаем сиңа тел ачкычлары бирсен!

—Амин, шулай булсын, әни! Мин дә шуны телим. Йә, хәерле сәгатьтә. Мин кузгалыйм инде.

Соңгы мизгелдә туктатуны күңеле тартмаса да, ана кеше гадәткә кергән йоланы үтәмичә кала алмады, инде ишек янына барып җиткән улына тагын эндәште:

—Улым, дим, Илдар, онытып җибәрә язганмын, дога кылмадык түгелме соң? Догасыз мондый изге эшне башлап җибәрергә ярамас!

Ана белән улы зал түрендәге кәнәфиләргә утырдылар һәм авыз эченнән генә дога сүзләрен кабатлап кулларын күтәрделәр.

—Барысы да алла кулында. Хәерле сәгатьтә, улым!. Юлың уңа гына күрсен! Аллаһы тәгалә тел ачкычлары бирсен! Амин!—дип кабатлады Оркыя ханым тагын бер мәртәбә.

Илдарны озаткач, әллә нишләп күңеле тулды, күзләренә тыгыла башлаган яшьләрен тыеп ирен читен тешләде. Кулъяулыгы белән күз читләрен сөртә-сөртә күңелендә җыелып килгән сүзләрне кабатлады: «Йа, хода, мондый көннәрне дә күрәсебез бар икән. Ничә еллар буе каңгырап, илләр, җирләр гизеп йөргәннән соң менә шушындый тормышка иреш инде. Йа, Ходаем, биргәнеңә шөкер. Инде моннан соң да рәхмәтеннән ташлама!»

Көн әле башлана гына иде. Улы кайтмыйча, иренең киңәш-табышын ишетмичә җанына тынычлык таба алмаячак иде ул. Нәрсәгә генә тотынмасын, бер эшкә дә кулы ятмады. Күңелең өзгәләнгән, җаның бәргәләнгән чакта шулай булмый ничек булсын инде! Вак-төяк эшләрне мин үзем дә ерып чыгам инде, дип сылтау табып, Мартаны озатты да уйларына чумды. Ә уйлар өермәсе, йөрәккә яра булып яткан хатирәләр аны үтә дәһшәтле, шомлы кырык бишенче елның көзенә алып кереп киттеләр.

Ул чактагы чарасызлыкны, Әмирҗан кулга алынганнан соң булган

хәлләрне, Акчуриннар нәселенә берсе артыннан берсе ишелеп төшкән кайгы-хәсрәтне һич кенә дә онытырлык түгел шул! Ниләр генә күрмәде дә, ниләр генә кичермәде Оркыя. Ерак Чәнчүндә, жиде ят арасында өч бала белән ялгыз калган яшь хатынның барып ялварыр кешесе дә, ярдәм кулын сузардай туган-тумачасы да юк иде. Ярый әле милләттәшләр, кан-кардәшләр табылды. Алар ана бөтенләй егылырга, эт типкесендә калырга ирек бирмәде. Чит илләрдә үз милләтең бигрәкләр дә якын, кадерле икән ул.

Үткәннәр искә төшүгә Оркыя ханымның йөрәге калтырый башлады. Юк! Болай кул кушырып утырырга ярамый. Нәрсә дә булса эшләргә кирәк. Эш кенә, нинди дә булса шөгыль, хәрәкәт кенә яман уйлардан арындыра...

Оркыя ханым урыныннан торып бер сәдәф баш даруы капты һәм болай да ялтырап торган бүлмәләрне жыештырырга, юеш чүпрәк белән өстәлләрне сөрткәләргә кереште. Әмиржанның эш бүлмәсенә керде дә китап тулы шкафларны күздән кичереп бер генә минутка тукталып калды. Әмиржан үз өстәлендәге кәгазьләргә кагылганны яратмый. Ә Оркыя андагы тәртипсезлеккә үртәлә. Һәр кәгазьне, китапны матурлап, тигезләп куярга кирәк, дип саный. Шуның өчен баштарак күпме сүз була иде. Хәзер инде Марта да, Оркыя ханым да өстәл яныннан читләтеп үтүне кагыйдә санийлар. Чөнки андагы тәртипсезлек ул Әмиржанның, чит кешегә аңлашылып житмәсә дә, үз тәртибе, үз холкы дигән сүз. Һәр кәгазен, һәр язмасын Әмиржан кирәк чагында куйган урыныннан ялгышмыйча табып ала.

Шулай да өстәлгә күз саласы итте һәм ире кулы белән язылган хатны кулына алды. Аны бергәләп әллә ничә тапкыр төзәткән, тикшергән булсалар да, тагын бер кат укыйсы, чит-ят колакларга аның ничек яңгыраячагын күз алдына китерәсе килеп китте. Ерак ватандагы түрәләргә адресланган, бүген Илдар аннан килгән дипломатларның берәрсенә тапшырасы хат иде ул.

Кереш сүзләрне сикереп кенә үтте дә кан белән язылгандай тоелган юлларны укый башлады.

*«Моһажирларның бер өлеше Кытайда яши иде. 1945 елны совет гаскәрләре Маньчжуриягә керде. Нәтиҗәдә андагы татарлар кулга алынып, төрлесе төрле илларга хөкем ителеп, лагерьларга озатылдылар, гаиләләреннән, балаларыннан аерылдылар. Демократия кануннарына күрә, инсаният йөзеннән болар бер дә юкка кулга алынып, бер дә юкка җәфа чиктеләр.*

*Һәрбер кешенең үзенә күрә шәхси фикере һәм шәхси карашлары булу—бик табигый эштер. Ул карашлар яхшы карашлар булганда, аны гаепләргә һичкемнең хакы юктыр.*

*Инде кыскача үзем турында.*

*Мин, Әмиржан Хәсән улы Акчурин, 1912 елның 22 гыйнварында Казан губернасының Чистай өязендәге Чишмәбаш авылында туганмын. Рәсәйдә Октябрь инкыйлабына кергәндә миңа нибары биш яшь булган. 1923 елда безнең гаилә Харбинга килде, ә 1933 елда Чәнчүнгә күчтек. 1945 елны, совет солдатлары Кытайга кергәч, 26 августта Чәнчүндә мине кулга алдылар. Хәрби трибунал ноябрь аенда хөкем карары чыгарды. Шул хөкем карары җирлегендә дүрт ел Чита төрмәсендә утырдым.*

*Аннары шул хөкем карарын үтәү йөзеннән сигез ел хезмәт белән төзәтү лагерена билгеләндем. Лагерьга җиткәнче Чита, Иркутск, Красноярск төрмәләрендә утырдым. 1945—1949 елларда Решеты станциясендәге Красная Лага лагеренда, 1949—1953 елларда Иркутск өлкәсендә, Тайшет лагерьларында тоткынлыкта булдым, аннары лесоповал участкысында. Хөкем җәзасының сәбәбе—милләтчелек, Синьсзяндагы «Идел-Урал» төрки-татар җәмгыятендә сәркәтип булып эшләү. 1927—1934 елларда татар җәмгыяте каршындагы яшьләр оешмасының идарә әгъзасы булу, «Идел-Урал» ирекле дәүләте турындагы фикерләрне тарату. Коммунизм идеологиясе белән килешмәү, боларны*

*милләттәшләр арасында уртаклашу, чыгышларда һәм газета битләрендә үткәрү, яшьләрне милли рухта тәрбияләү һәм башкалар. Ә чынында исә, сине татар булуың өчен хөкем итәбез, дигән фикер аңлашылып тора иде.*

*Кытайда кулга алынганнан соң гаилә белән күрешергә дә рөхсәт булмады. Анда әтием Хәсән Фәтхулла улы, әнием Гайнижамал Ибраһим кызы, сеңлем, кечкенә өч балам белән хатыным торып калдылар. Алар 1955 елны зур авырлыклар белән, зур михнәтләр чигеп, Төркиягә күчеп китә алганнар. Мин үзем бик озак еллардан соң гына алар янына, Төркиягә күчеп бара алдым. Бу юнәлештә миңа Төркия хөкүмәте һәм милләттәшләрем зур ярдәм күрсәттеләр. Шулай итеп мин гаиләм белән очрашу бәхетенә ирештем. Инде хәзер без АКШларында сыенып җир таптык. Америкада—ирекле илдә яшәсәм дә, ерак ватанымда хаксызга рәнҗетелүем исемнән чыкмый.*

*Тоткын лагереннан азат ителгәннән соң мәңгелек сөргенгә сөрелдем, тора-бара ул срок ун елга калдырылды.*

*Мин беркайчан да совет гражданлыгын алырга теләмәдем һәм сөргендә дә бернинди гражданлыксыз йөрдем.*

*Минем белән бергә Синьсзяндагы «Идел-Урал» төрки-татар җәмгыятенең унике ел буе алыштыргысыз рәисе булган Фәсхетдин Гыйльман да кулга алынды һәм ул да сигез елга хөкем ителде. Аның хатыны Галия, кызы Мәүлия, улы Камил исемле иде. Аларның язмышы мәгълүм түгел.*

*Сорау алган вакытларда безне төрлечә мәсхәрәләделәр, кыйнадылар. Гыйльман, җитмәсә, патша армиясендә офицер булган кеше. Аңа тагын да ныграк эләгә иде. Гыйльманның хатыны урыс милләтеннән, әмма ул мөселманлашкан, татарча да яхшы белә иде. Ире кулга алынганнан соң, бәлки, ул туганнары янына, Ворошиловка кайтып киткәндер. Ул үзе шул якныкы иде. Кызы Мәүлия Хабаровскида мәктәптә чит тел укыта, дигән хәбәр бар иде.*

*Харбиндагы татар җәмгыяте рәисе Хәбибулла Сәләев 1945 елны шулай ук кулга алынган һәм, ул газапларны күтәрә алмыйча, юлда ук вафат булган.*

*Моһаҗирлыктагы татар зыялыларының каймагын тиз арада сөзеп алдылар. Безнең җәмгыятьнең бөтен үзәге кулга алынып хөкем ителде.*

*«Идел-Урал» төрки-татар җәмгыятенең Мукдендагы мәркәзе җитәкчеләре—Әхмәтша Гыйззәтуллин, Ибраһим Дәүләтгилде, Рөкыя Дәүләтгилде (Мөхәммәдиш) һәм башкалар кулга алындылар, алар артыннан башка шәһәрләрдәге барлык татарлар эзәрлекләнә башлады.*

*Әлбәттә, мин аларның барысының да исемнәрен хәтерләп бетерә алмыйм.*

*Безне нигә хөкем иттеләр? Моңа җавап аңлашылгандыр.*

*Инсаният йөзендә бер генә кешене дә милләте, дине вә дөньяга карашы өчен хөкем итмиләр. Инде күп еллар узса да, ерак ватанымда мине һәм минем шикелле Маньчжуриядә кулга алынып, тоткынлык газаплары күргән башка шәхесләрне аклау карары чыгарылыр, дип өметләнәм. Шундый көннәр җиткәндер, дип беләм.*

*Әмирҗан АКЧУРА.*
*Нью-Йорк.*

Оркыя ханым хатны кире урынына куйды һәм уйга калды. Әллә нишләп кенә күңеленә шик корты керде. Ай-һай, мондый үтенечне канәгатьләндерерләр микән? Йосыф Сталин ук булмаса да, дәүләт башында барыбер большевик-коммунистлар ич! Алар Рәсәйдә дә, Кытайда да, Алманда да барысы да бер калыптан. Әмма өмет чаткысы да юк түгел иде. Кем белә, бәлки, Сталинның канлы сәясәтен бөтен дөньяга фаш иткән, шуңа батырчылыгы житкән кеше илдә яңа тәртип урнаштыргандыр!? Демократия кануннары кабул ителгәндер...

Күпме генә уйланса да, уйларының очына чыга алмады. Мондый чакта өйдә ялгызың булу бигрәкләр дә авыр икән бит. Бу өметне, бу хәлләрне кем беләндер уртаклашырга кирәк иде. Оркыя ханым телефонны алды да үзләреннән ике квартал гына арырак торучы, кайчандыр Америкага килеп урнашырга ярдәм иткән Агишларның номерын җыя башлады. Алар белән бөтен серләреңне уртаклашырга була, ичмасам! Америкага

бик күптәннән, инде егерменче елларда ук килеп Нью-Йоркта төпләнгән Агишлар мондагы татар җәмгыятенең йөрәге. Барысы да аларга тартыла, алар белән киңәшмичә бер генә эш тә башламый. Америка кануннарын яхшы белгән Агишлар икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы хәерчелектән, изелүдән, эзәрлекләүләрдән качып Төркия, Кытай, Япония, Алмания кебек илләрдән килеп егылган кан-кардәшләрне туплаучылар, укмаштыручылар, беренче матди ярдәм күрсәтүчеләр иде. Рөстәм Агиш замана сулышына үтә сизгер, эшкуарлыкка үтә дә маһир кеше. Аның электрон җиһазлар—компьютерлар өчен детальләр житештерүче, шундый нәрсәләр белән сәүдә итүче фирмасы инде Америкада яхшы ук тамыр җәеп өлгерде, башка илләрдә дә танылып килә. Иң мөһиме—Агишлар кысмыр, саран түгел. Күпме татар баласына фирмада эш таптылар. Үз хисапларына университетларда, колледжларда укытып чыгардылар. Шулай итеп төпле белем алган риясыз яшьләр—хәзер Агишларның төп таянычы, фирманың горурлыгы. Әнә бит, ять-яшь кенә булса да, Илдар хәзер Нью-Йоркта компьютер буенча абруйлы белгеч. Бусы да шул Агишлар ярдәме!

Дөньяның ачысын-төчесен күп татыган Рөстәм әфәнденең катгый саклый торган, канунга әйләндерелгән үз кагыйдәсе бар: кан-кардәшләрне якын күргән, аларның киләчәге өчен дә борчыла белгән бу кеше, гадәттә, беренче ярдәмне күрсәтә, кемгә дә егылып калырга ирек бирми. Калганы инде синең үз кулыңда. Тырыш, тырмаш, чәчең белән жир себер, әмма үз юлыңны үзең тап, тормышта беркемгә дә әзергә—бәзер түгел. Илдарга аның ниләр әйткәнен Оркыя ханым әле бүгенгедәй яхшы хәтерли.

—Менә син чебешкә кара,—дигән иде ул Илдарны аркасыннан кагып.—Йомырка эчендә аңа беркем дә ярдәм итми, ярдәм итә дә алмый. Каты кабыкны ватып якты дөньяга ул үзе чыга. Чебеш бары үз көченә генә ышана ала. Шулаймы?

Бу сәер чагыштырудан аптырап калган яшүсмер башта ни әйтергә белмичә торды һәм, инсәсен җыерып:

—Шула-а-ай!—дип куюдан уза алмады.

Рөстәм әфәнде исә рәхәтләнеп көлде һәм егетнең югалып калуын аның тыйнаклыгына яисә аңлап бетермәвенә санадымы, фикерен үстерергә кереште.

—Синең хәзер нәкъ шундый чагың,—диде ул кинәт житдиләнеп.—Йә йомырканы ватып чыгасың, йә вата алмыйча калып шунда тончыгасың. Америкада яшим дигән кешегә белем кирәк. Белемсез бер адым да атлый алмыйсың. Белем дигән нәрсә хәерчелекнең сине чорнап алган каты кабыгын ватып, яктыга, үзең теләгәнчә иркен тормышка чыгу коралы ул... Инде аңладыңмы?

Агасының табышмагын аңлаган егет елмаеп җавап бирде:

—Инде болай да аңламасаң...

—Яхшы, Илдар, шулай буласын белә идем,—дип куйды Рөстәм Агиш һәм үзенә тиң күреп, егетнең кулын каты итеп кысты.—Болай булгач, килештек. Колледжга урнашасың. Имтихан тотарлык чамаң барын беләм. Керү чыгымнарын, беренче елда уку өчен түләүне фирма күтәрер. Ә аннан соң барысы да үз кулыңда. Әгәр ышанычыбызны акласаң, фирмага рәхим итәсең. Акламасаң...

Акламаса нәрсә буласын Рөстәм әфәнде әйтеп бетермәде, ике кулын як-якка җәеп, битенә чарасызлык кыяфәте чыгару белән чикләнде. Ләкин бу ишарә сизенгән, төшенгән кешегә бик күп нәрсәне аңларга мөмкинлек бирә иде.

Агишларның да, Оркыя ханым белән Әмирҗанның да ышанычын аклады Илдар. Бусы Акчуриннар өчен сөенеч булса, Агишлар өчен киләчәккә өмет тә иде. Фирмага шушындый белемле, тынгысыз яшьләр кирәк!

Рөстәмнең җәмәгате илгәзәк холыклы Гайшә ханым исә Америка хәтле Американың төрле штатларына сибелгән татар хатын-кызлар таифәсенең жаны, аларның сердәше, фикердәше. Һәрвакыт ачык йөзле,

яшь кызлардай хәрәкәтчән Гайшә белән аз гына аралашып, серләшеп алу да Оркыя ханымның бәргәләнгән җанына, һичшиксез, тынычлык бирәчәк иде.

Телефон трубкасын Гайшә ханым үзе алды. Аның күкрәктән чыккан таныш тавышын ишетүгә Оркыя ханым ахирәтенең ак йөзен, ике толымга үреп баш артына чорнаган сары чәчләрен, куе зәңгәр күзен, ягымлы карашын күз алдына китереп елмаеп куйды.

—Һелло,—дип инглизчә эндәште Гайшә ханым.

—Хәерле көн, Гайшә! Оркыя шалтырата, дип белерсең. Хәлләрегез ничек? Барыгыз да исән-аманнармы?

—Ай, ахирәткәем,—дип тезеп китте Гайшә.—Хәлләребез, американнар әйтмешли, о'кей! Нишләптер, бүген сезнең хакта уйланган идем. Иртән Рөстәм белән дә шул хакта гәпләшеп алдык. Шалтыратуың әйбәт булды әле. Никита агайның Нью-Йоркка килүендә бик зур мәгънә күрәм мин. Хезмәт күрсәтү персоналына Илдарның чакырулы икәнен белгәнгә күрә, аңа да өметләр баглыйм. Кара әле, ахирәткәем, телефоннан гына сөйләшеп бетереп булмас, күрешик әле...

Элегрәк, икенче дөнья сугышы башланганчы, Берлинда, аннан соң озак еллар Нью-Йоркта яшәгән, Төркиядә дә еш булган Гайшә ханым үзе дә сизмичә татар, инглиз, алман, төрек сүзләрен кушып сөйләшә иде. Ләкин аның ихластан, ачылып сөйләшүе шул хәтле табигый килеп чыга ки, беркем дә аның йөгерек телендәге бу чуарлыкка игътибар итми, шулай булырга тиеш дип саный иде. Бу юлы да шулай булды.

—Хәзер мин yavaş-yavaş[1] идәнне vakuumcleaner[2] итәм дә, паркта schpaziergang[3] ясап кайтырбыз. Әле бүген генә Рөстәм дә әйтеп торган иде, туйдым бу американ ашларыннан, үзебезчә, үз кулың белән берәр нәрсә әзерләмәссеңме, дип. Гөбәдиям әзер, бәлеш—мичтә, дигәндәй. Кайтырбыз да рәхәтләнеп үзебезчә, татарча иттереп чәй эчәрбез. Алай теләмәсәң, берәр кафе-мазарда ланчка кереп эчләребезне бушатырбыз... Мин бездән ерак түгел авенюда бик тыныч бер кафе беләм. Килештекме?

—Әлбәттә, әлбәттә,—дип җөпләде Оркыя ханым.—Илдар беренче утырышка китте. Һич кенә дә җаныма тынгы таба алмыйм. Шуңа шалтыратуым...

—Яхшы, ярты сәгатьтән көтәм сине! Ә онытып торам икән, машина җибәримме?

—Юк, юк,—дияргә ашыкты Оркыя ханым.—Үзебезнеке бар. Борчылма!

## II

Асия белән Сирин житәкләшеп коридорга чыктылар. Шулчак кемдер аның жилкәсенә кагылды, колак төбендә генә пышылдап әйтелгән, әмма шактый ук таләпчән тавыш ишетелде:

—Теге башка барып килик әле!

Мондый тәкъдимнең нигә һәм нинди максатта әйтелгәнен, аның ничек тәмамланачагын шактый ук яхшы күз алдына китергән Сириннең бөтен тәне пружина сыман киерелде. Юк, курыкмады. Мәктәптә укыганда ук бокс секциясенә йөргән, хәзер дә спорт белән дуслыгын өзмәгән егет теләсә кем белән бергә-бер очрашудан курыкмый, курыкмый гына түгел, тиешенчә җавап бирәчәгенә дә шикләнми иде. Сызганган җиңнәреннән бүлтәеп чыккан мускуллары уйнап алды, тәне буйлап, ярышка әзерләнгәндәгедәй, кайнар кан йөгереп узды.

—Барыйк соң,—диде ул тавышына дустанә төсмер салырга тырышып. Дөресен генә әйткәндә, аның бүгенге кичәнең ямен җибәрәсе дә, кем беләндер тарткалашып, бәхәсләшеп кәефен бозасы да килми иде. «Кемнең

---

1 yavaş-yavaş—az-az *(төрекчә)*, 2 vakuumcleaner—тузан суырткыч *(инглизчә)*,
3 schpaziergang—йөреп керү *(алманча)*.

авырткан жиренә бастым икән тагы? Юкса, барысы да әйбәт кебек иде бит»,—дип уйлап куйды ул. Әмма тәкъдим кабул ителгән иде инде.

Коридорның карангы башына, туалет белән кухня урнашкан борылышка кереп бастылар.

Каршысында Асияның группадашы, төп кебек таза, чәчен а ля Канадка итеп алдырган күксел чырайлы Казан егетен күреп, Сирин бер мәлгә аптырап калды.

—Чем могу служить?—диде ул юри русчалатып.

Егет аның сүзенә игътибар итмәде. Кесәсеннән студентлар арасында аеруча затлы саналучы, ни дисәң дә, чит илнеке бит, «ТУ-134» сигареты чыгарды, бармаклары арасында изгәләп торды һәм капны Сирингә сузып битараф тавыш белән эндәште:

—Тартасыңмы?

—Юк!

—Анысы әйбәт...

—Карале, Дамир, мине шуны әйтер өчен чакырдыңмы?

Сириннең соравы шактый дорфа килеп чыкты булса кирәк, егетнең битенә кара күләгә йөгерде, теше сызлагандай йөзен чытып куйды.

—Синең белән ирләрчә сөйләшергә мөмкинме?—диде ул, ниһаять, тавышына кырыс төсмер биреп.—Минем синең белән ачыктан-ачык сөйләшәсем килә...

Кинәт Сириннең нигәдер көләсе килеп китте. Һәрвакыт эрерәк кыланырга яратучы, авылдан килгән яшьләрдән кием-салымы белән дә, тәкәбберлеге белән дә аерылып торучы Дамирны таныйрлык түгел иде. Бәйсез һәм эре кыланырга тырышып та югалып калуы, бер сәбәпсезгә бәйләнергә сәбәп эзләве мәзәк иде.

—Мәйлен,—диде Сирин каяндыр отып калган һәм үзенә бик ошаган сүзне кулланып.—Мин тыңларга әзер...

Кинәт Дамир аның беләгеннән кысып тотты һәм күзенә туп-туры карап теш арасыннан кысып чыгарды:

—Сирин, мин уйнап сөйләшмим! Асияны калдыр. Тимә! Сезнең үзегездә, үз факультетыгызда да кызлар бетмәгән...

«Юкәдә икән чикләвек» дип уйлап куйды Сирин һәм усаллык күрсәтмичә, әмма көчен шактый сиздерерлек итеп Дамирның кулын беләгеннән алды.

—Мин болай сөйләшергә күнекмәгән,—диде ул әле һаман аңлашуның дустанә тәмамланачагына өметләнеп.—Аннан соң, бу хакта минем белән түгел, Асия белән сөйләшергә кирәк. Ул ни уйлыйдыр бит!..

Дамирның йөзе яктырып киткәндәй булды:

—Ә аның белән мин... үзем аңлашырмын.

—Юк инде! Татарга тылмач кирәкми. Без аның белән үзебез дә бик әйбәт аңлашабыз.

—Авыл гыйбады!

Дамирның сүгенгәндәй әйтеп куйган сүзенең мәгънәсен яхшы, бик яхшы аңлады Сирин. Йодрыгы йомарланды, боксерларча якын арадан күкрәк астына бәреп тә ул аны бернидән шикләнмичә нокдаунга да җибәрә ала иде. Әмма иң соңгы мизгелдә тыелып калды. Моның ахыры ни белән бетәсен бик ачык күз алдына китерде ул. Йодрык ярдәмендә түгел, ә тел белән, кире каккысыз мантыйк белән аңлашырга кирәк иде.

Сирингә элеккеге тынычлыгы, сабырлыгы, үз-үзенә ышануы кире кайтты. Сүгенү—көчсезлек билгесе. Моны яхшы белә ул. Йомшак ягын күрсәтеп өлгергән, төптән юан чыккан, тыгыз тәнле, көчле егет булса да, үзеннән бер башка тәбәнәгрәк һәм житезлектә, елгырлыкта биш-ун тапкырга калышучы Дамир аңа куркыныч түгел иде.

—Дамир, мин сине бик хөрмәт итәм, төпле, акыллы егет икәнеңне дә беләм. Синең белән бәхәсләшәсем дә, сина дошман буласым да килми. Урыслар белеп әйтә: «Насильно мил не будешь!» Көч белән үзеңне яраттырып булмый,—дип сөйли башлады ул әле һаман әтәчләнергә

маташучы Дамирга туп-туры карап.—Ярый, без Асия белән ташлаштык, ди. Ә бит ул барыбер синең белән булмаячак. Булырга теләмәячәк. Чөнки... Чөнки ул мине, мин аны яратам. Французлар әйтмешли, си ля ви!

Дамирның кинәт теле тотлыкты:

—Ул... ул... бу хакта сиңа үзе әйттеме?—Һәм ярсып тагын кабатлады.—Үземе?..

Сирин кистереп җавап бирде:

—Әйе!

Дамир бүтәнчә аңлашуны кирәк тапмадымы, кырт борылды да коридор буйлап китеп барды. Аның асылынып төшкәндәй кинәт шәлперәйгән җилкәләренә, аягын идәннән сөйрәп атлавына карап, Сирин хәтта кызганып та куйды. Ләкин ул аңа берничек тә ярдәм итә алмый иде.

Ун-унбиш адым ераклашкач, коридор борылышына җитәрәк, Дамир соңгы сүзнең барыбер үзендә калуын белдерергә теләгәндәй борылып кычкырды:

—Иртә сөенәсең, Сирин, иртә!.. Асия барыбер минеке булачак! Әйтте, диярсең...

Бу сөйләшүдән соң Сирин өчен кичәнең яме китте. Үзенә үчле, көнчел караш астында биисе дә, кемнедер үртәгәндәй күңел ачасы да килми иде. Хөсетлекне, үч алуны, кара көнчелекне белмәгән егеткә тулай торакның стеналары кысылып тарая башлаган кебек тоелып китте. Бер нәрсәне төшенде: кыяфәтенә, үз-үзен тотышына караганда ук үҗәтлеге сизелеп торган Дамир аны беркайчан тынычлыкта калдырмаячак, үз дигәненә ирешер өчен теләсә нинди юлга басачак иде. Һәм шул ук вакытта Сириннең күңел төбендә әллә нәрсә кымырҗып куйды: читенсенеп үзенә үзе елмайды. Асиядан башка бер генә көнен дә күз алдына китерә алмаган егетнең кыз авызыннан әле бер тапкыр да «Яратам!» дигән тылсымлы сүзне ишеткәне юк иде. Хәлбуки, үзенең дә бу хакта турыдан-туры әйткәне булмады. Ләкин ул моның нәкъ шулай икәненә чын күңеленнән ышана иде. Җир йөзендә әйтмичә дә аңлашыла торган хисләр бар. Алар бер-береңә мөнәсәбәттә, бер-береңә карата, әхлак, вөҗдан һәм рухи җаваплылыкта чагыла. Һәрхәлдә, Сирин шулай уйлый.

Кинәт аның Асия белән ялгызы гына каласы, бу шау-шулы, ыгы-зыгылы мәҗлестән чыгып китәсе килә башлады. Джаз шавыннан туеп, баянга вальс әйләнә генә башлаганнар иде, Сирин кызның колагына пышылдады:

—Әйдә, моннан сиздерми генә чыгып таябыз.

Әллә егетнең кәефе үзгәргәнне чамалады, әллә аның да Сирин кебек үк шау-шудан читтә буласы, сөйләшәсе, аңлашасы килә идеме, Асия берсүзсез ризалашты. Үзе шикелле үк пышылдап җавап кайтарды:

—Син аста көт! Мин хәзер бүлмәгә кереп плащны гына алам да...

* * *

Сентябрь азагы. Әбиләр чуагы. Урамда җәй көнендәгечә җылы иде. Бер болыт әсәре булмаган күк йөзендә йолдызлар җемелдәшә, көнчыгыш тарафта чалкан ятып яңа ай туып килә. Шагыйрь әйтмешли, җил дә исми, яфрак та селкенми. Сирин Асияның кулыннан тотып алды да аның күзләренә карады.

—Асия, менә хәзер яңа туган айга кара да эчтән генә, күңеленнән генә иң зур теләгеңне телә. Барысы да кабул булачак. Бүген шундый көн. Күрәсеңме айны? Ай туганда теләгән теләк кабул булмыйча калмый. Тик аны беркемгә дә әйтмә...

Һәм үзе дә айга карап тынып калды. Бераздан аның иреннәре кыймылдый башлады, тылсымлангандай күккә текәлгән иң газиз, иң олы теләген тәкрарлаган Асия колагына дога сүзләре килеп керде:

Ай күрдем аман белән,
Авызым тулды иман белән.
Дөньялыкта мал белән,
Ахирәттә иман белән...

—Ой,—дип соклану катыш гаҗәпләнде Асия.—Әле син шундый борынгы ырымнарны да беләсенмени?—Һәм кинәт житди итеп сорап куйды.—Әллә син, чынлап та, аллага ышанасыңмы? Шундый дини кешеме син?

—Юк! Мин—дөньяви кешемен. Ләкин... Алламы ул, әллә башка берәр Илаһи затмы, белмим, әмма кешелек дөньясы да, бөтен табигать, жир шары, хәтта бөтен галактика нинди дер бер канунга буйсынып яши, алардан өстен ниндидер көч, гомумгалактик Акыл барлыгына ышанам мин,—диде Сирин уйчан гына.—Ә бу мөнәҗәткә килгәндә, аны кайчандыр әбием өйрәткән иде. Яңа туган айны күрсәм, шуны кабатламыйча калмыйм. Йоласы шундый. Борынгылар белеп әйткәннәр: һәр йоланың, ырымның бик тирәннән килгән тамыры була. Бары тик без аны инде белмибез, аңламыйбыз. Чөнки кеше табигатьтән аерылган хәзер.

—Сиңа тарихчы яисә философ буласы калган икән бит,—диде Асия елмаеп.—Юкка гына математика бүлегенә кергәнсең. Ә бит хәзер бергә, бер группада укып йөрер идек...

Сирин Асияны иненнән кочып алды да көлеп жибәрде.

—Их, Асия! Анысы мөһиммени аның! Тарихчымы, математикмы, физикмы-лирикмы... Тарих ул, нигездә, сугышлар елъязмасын өйрәнә. Әдәбият кешеләр мөнәсәбәтен, аларның үзара мөгамәләсен тикшерә. Кайсысы кызыграктыр әле. Математик та шул ук әдәбиятчы. Чөнки саннарның да, математик гамәлләрнең дә үз шигърияте, көе бар. Ә бергә булу дигәннән, без бит болай да бергә. Шулаймы? Бергә бит, әйеме?!

—Әлбәттә, бергә,—дип сузды Асия иркәләнеп.—Күп нәрсәне беләсең син. Аптырап куям хәтта.

Аның озын буйлы, дулкынланып торган куе кара чәчле, тыгыз мускуллы егетнең киң күкрәгенә сыенасы, дөньядагы барлык вак-төяк мәшәкатьне, ыгы-зыгыны ташлап, аның белән бергә онытыласы, бөтен барлыгы белән үзен шушы егеткә тапшырасы килә башлый. Дөньяда иң ышанычлы кеше, мөгаен, шушы егеттер дә әле. Аның коңгырт күзләрендә үзенең шәүләсен, чагылышын күрү ошый Асияга. Һәм ул хәтта үзен шунда оялап калган дип хис итә һәм бу уйдан аңа әйтеп бетергесез рәхәт булып китә иде.

Сирин Асияны култыклап алды, тавышы шаян, шук яңгырады:

—Әйдә, үзебезнең күпергә! Поезд карарга!..

Тулай торак артында гына Себер тимер юлы үтә. Аны салу өчен кайчандыр тирән чокыр казылган, аның өстеннән җәяүлеләр өчен корылган агач күпер бар. Аны Сирин белән Асия үзләренчә «мәхәббәт күпере» дип йөртәләр иде.

Күпернең уртасына кереп бастылар да бер-берсенә сыенып тынып калдылар. Еректан поезд тавышы ишетелде. Күп тә үтмәде, рельсларга, шпалларга ут көлтәсе сибеп ерак Себер тарафларына китеп баручы пассажир поезды күренде. Унжиде вагон сөйрәгән куәтле тепловоз очкыннар чәчрәтә-чәчрәтә алар басып торган агач күпер астына ыргылды. Шулчак Асия аяк очларына басып Сириннең колагына үрелде һәм инде әллә кайчаннан бирле әйтергә теләп тә беренче булып әйтергә базмаган, кыюлыгы житмәгән сүзләрне пышылдады:

—Сир-и-ин, мин сине ярата-а-а-ам! Бик, бик яратам!..

Поезд гөрелтесе сүзләрен ишеттермәс, йотып калыр, дип ышанган иде Асия. Әмма кызның һәр хәрәкәтен, һәр ымын күңеленә сеңдереп барган Сирин, дисталәгән вагон дөбердәве арасыннан да таныш тавышны, кайчан да булса үзе әйтәсе сүзләрне танып алды. Кызның кайнар сулышы колагын яндыргандай булды, озын керфекләренең яңагына тиеп китүеннән

буыннарын сулкылдатып сәер бер рәхәтлек йөгереп узды. Мондый ләззәтне татыганы юк иде әле. Кызны кочагына алып зыр-зыр әйләндерә башлаганын сизми дә калды. Теленнән беренче булып ул әйтергә тиешле, әмма инде Асия пышылдап өлгергән сүзләр чыкты. Ләкин бу пышылдау түгел, ә назга, мәхәббәткә сусаган җанның дөньяга оран салуы, хисләрнең ташып чыгуы иде.

—Мин сине яратам, Асия! Ярата-а-а-ам!..

—Ярар! Шул хәтле кычкырма инде. Кешеләр ишетер, әллә ни уйларлар тагы...

Асияның сүзләре үзен канатланып очкандай хис иткән Сиринне җиргә тартып төшерде. Поездның инде ерактагы тоннельгә кереп югалганлыгын, үзенең исә кызны үбә-үбә һаман бер үк сүзләрне кабатлавын шунда гына сизеп алды ул. Әмма туктый алмады.

—Ишетсеннәр, белсеннәр, күрсеннәр! Мин сине яратам, Асия! Ярата-а-ам!

Егетнең көчле тавышы яңадан төнге тынлыкка чумган поезд юлы өстендә кайтаваз булып яңгырады:

—Я-ра-та-ам!

Шул көннән Асия белән Сирин бер-берсе белән күрешер вакытларны минутлап саный башладылар. Аларга бергә булган һәр минут, һәр сәгать кадерле иде. Ә алда—иксез-чиксез яшьлек, мәхәббәт, бәхет!..

Ләкин алар нәкъ шул ук көнне, шул ук сәгатьтә икенче хронометрның—дәһшәтле хронометрның да вакытны аяусыз рәвештә саный башлавын белмиләр иде әле.

## III

Ни гаҗәп тоелмасын, Нью-Йорк гадәттәгедән тынычрак иде кебек. Әллә Илдарның машинасында махсус пропуск булу ярдәм итте, әллә бәхете басты, ул анда-санда бөялгән машиналар ташкынын җиңел генә үтеп, егермешәр метрлы су баганаларын күккә ыргыткан зур фонтан янына—сессиягә хезмәт күрсәтүчеләрнең машиналарын куяр өчен махсус билгеләнгән тукталышка вакытыннан ярты сәгатькә алдан килеп җитте.

Машина ишеген бикләп азапланганда гына кемдер инсәсенә сугып алды. Шушы гадәтеннән, күкрәк төбеннән чыккандай гөрелдәгән тавышыннан ук таныды Илдар, бу университетта бер үк кафедрада эшләүче Джо иде.

—О, Эль, кайчаннан бирле шушындый төгәл кешегә әйләндең әле,—диде ул. Елмайган иреннәре арасыннан ап-ак тигез тешләре ялтырады.—Хәтта, артык төгәл.

—Үзең дә соңга калу гадәтеңне оныткансың, ахрысы,—дип төрттерде Илдар дустының теңкәсенә тия торган кимчелегенә ишарәләп.—Юкса, сине көтә-көтә кайчагында яртышар көн уза...

—Ярый, ярый, әйткәнеңне онытмам, әмма мондый көнне сүзгә кереп торасым килми. Шулай да, әйдә, бәхәсләшәбез: сессия беткәч, беренче булып кем соңга кала, шул Манхэттендагы иң кыйммәтле ресторанга чакыра. Йә, килештекме?

—Акылың укалы икән,—диде Илдар һәм инде шактый күпне күргән «Форд»ка таба ымлады.—Анда барганчы мин менә бу чытыр арбаны алыштырыр идем. Мондый җирләргә йөрер өчен хәзер кимендә «Кадиллак» кирәк буласы.

—О кэй,—дип килеште Джо.—Мин монысына да риза. Башта машинаңны алыштырабыз, аннан соң ресторанга... Хәтта болай яхшырак та әле.

—Туктале, тукта, син инде бүген үк откан кеше кебек кыланасың.

Әле бит бу мәрәкәне ерып чыгасыбыз бар. Аннары күз күрер.—Илдар кайчандыр әнисеннән ишеткән мәкальне исенә төшереп, аны мөмкин кадәр төгәлрәк итеп инглизчәгә тәрҗемә итәргә тырышты.—«Тумаган тайның билен сындыра күрмә», диләр бездә. Әле тагын «Эрләмәгән, сукмаган, менә сиңа—ыштанлык» дигәне дә бар.

Джонын рәхәтләнеп, каерылып көлүеннән мәйданда чүпләнеп йөрүче күгәрченнәр пырхылдап һавага күтәрелде, хәтта машиналар гөрелтесе, фонтан көпшәләреннән ыргылган суның чажлавы да ишетелмәс булды кебек.

—Ничек, ничек дидең?—дип кабатлады ул көлүеннән тыела алмыйча.—Тумаган атның дисеңме? Тагын ничек әле?.. Тегелмәгән ыштан киепме? Һа, шәп бит ә! Нәкъ бездәгечә, Ирландиядәгечә каты итеп, кистереп сөйли беләсез икән. Минем хәзинәмә тагын бер тамчы өсталде... Шәрекътәгечә һәр сүзгә яшерен мәгънә сала беләсез...

Чыгышы белән ирландияле Джо, чыннан да, сүз тәмен белә, аңлый торган кешеләрдән иде. Компьютерлар өлкәсендә инде сизелерлек ачышлар ясарга өлгергән бу егетнең сәер мавыгуы, хоббие бар. Кемдер почта маркасы җыя, кемнәрдер шырпы кабы, тагын кемнәрдер төрле илләрнең акча бер әмлеген, борынгы тәңкәләр туплый. Ә Джога телләр өйрәнүдән, аларда охшашлык табудан да кызыграк нәрсә юк. Дөнья телләрендә бер-берсенә тулаем тәңгәл килгән мәкальләр һәм әйтемнәр эзләп җенләнгән егет аларны таба калса кош тоткандай сөенә иде. Балачактан ук шактый илләр гизгән, яшьләре ягыннан да бер чамадагы Илдар белән Джо Нью-Йорк компьютерчылары арасында сирәк телләр белүчеләрдән саналалар, аларга галим-голәмә шактый өмет тә баглый иде. Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль ассамблеясының электрон-хисаплау машиналарына, аларның әле күптән түгел генә куелган иң яңа төрләренә хезмәт күрсәтү группасына эксперт итеп алынуларына, компьютерчы белгеч булу белән бергә, әнә шул күп тел белүләре дә сәбәпче иде.

—А-а, сорарга да оныткканмын. Эль, сине кайсы секторга билгеләделәр?—дип куйды көлүеннән кинәт туктап калган Джо.—Янәшә туры килсәк, сөйләшкәләп, фикер алышкалап утырып кешe булыр иде ичмасам. Юкса, минем урысчам чамалы.

—Белмим, белмим,—дип каршы төште Илдар.—Бүген арка кашырга да вакыт булмас кебек. Урыс аюы Сэм агайга нинди көчтәнәч белән килгәндер, анысын бер алла белә. Шактый ук яхшы төшенсәм дә, бу утырышта минем урыс тәрҗемәчесе буласым килмәс иде.

—Сон, алла колы, мин бит синнән кайда кем буласың килүе турында сорамыйм,—диде Джо зәңгәр күзләрен ялтыратып.—Ә кайсы секторда утырасың дим...

Ирландияле егетнең кайчагында шулай бик тиз кызып китүенә күнеккән һәм аңа игътибар итмәскә өйрәнгән Илдар сабыр гына елмайды:

—Лабораториядә нинди телләр белән эш иткәнемне беләсең ләбаса.

—Сон...

—Сон шулай булгач, монда да шул инде. Кытай, төрек, урыс, өлешчә япон һәм кирәк булса... татар теле.

—Ярый, житте, житте,—дип ике кулын күтәрде Джо.—Болай булгач, хәрбиләр әйтмешли, сугышсыз гына бирелəм.

Илдар көлеп җибәрде һәм нәкъ Джонның тавышына охшатып, рәсми рәвештә әйтте:

—Капитуляция кабул ителә, хөрмәтле Джо галиҗәнаплары!

Дустының сүзләре бетмәгән икән әле, ул шаяртуын да, ясалма рәсмилеген дә югалтып, күз алдында гап-гади ирландияле егеткә әйләнде дә куйды.

—Мин шул испан, инглиз, индиан телләреннән ары китә алмам, ахрысы. Көнләшәм мин синнән, валлаһи,—дип куйды кинәт басынкыланып калган Джо.—Әллә нинди сирәк телләр беләсең син. Үзең төрек булгач, мин сине төрекчәдән гайрене аңламыйсың дип йөрим тагын.—

Көтмәгәндә аның йөзенә тагын шаяртуга охшаш елмаю кунды.—Бер нәрсәне аңлап җиткермәдем, ул татар теле дигәне нинди тел инде? Ялгышмасам, инглизчә «tartar»—җәһәннәм, ягъни тәмуг дигән сүз. Димәк, син җәһәннәм халкының да телен беләсең. Кыяфәтеңә караганда, һич тә җәһәннәм кешесе димәс идем мин сине.—Ул, гомерендә беренче кат күргәндәй, Илдарны баштанаяк күздән кичереп чыкты һәм кинәт аның маңгаен капшап карады.—Йөзең-битең, буең-сының, килеш-килбәтең тулысынча Европа кешесенеке. Койрыгың чалбар эчендәдер инде, анысы... Тик менә мөгезең барлыгы сизелми. Ышанасы да килми, валлаһи! Син—минем якын дустым Эль—җәһәннәм кешесе!

Аның шаяртып сөйләнгәнен, күңелендә нинди дә булса яман уй, кимсетергә теләү булмаганын бик яхшы аңласа да, Илдарның кинәт ачуы чыкты. Милләтенә карата уйнап кына әйтелгән авыр сүзне дә күтәрә алмаган егет аңа җилле итеп җавап та кайтармакчы иде, соңгы минутта үзен тыеп кала алды, шаяртуга борып өлгерде һәм көтмәгәндә кырт итеп Джога арты белән борылды.

—Капшагач-капшагач, койрыкны да капшап кара инде. Бәлки, анысын табарсың...

Ләкин, үзе санаганча, мондый урынсыз шаяртуны да җавапсыз калдырырга ярамый иде. Көләргә дә, ни дип җавап бирергә дә аптырап калган дустының күзләренә туп-туры карап, кистереп әйтте:

—Әйе, мин андый телне дә беләм.

Илдарның кинәт үзгәреп китүенең сәбәбен белмәсә дә, аның хәтерен калдыра язганын аңлаган Джо гафу үтенгәндәй мыгырданып куйды:

—Йә инде, мин шаярттым гына бит. Гафу ит! Мин бит сине төрек дип йөри идем...

—Ә татар булсам ни була? Мине төрек дип сиңа кем әйтте?

—Кем әйтте, дип... Төркиядән күчеп килгәнеңне беләм ич. Үзем шулай фаразлыйм.

—Алайсаң, дускаем Джо, белеп тор, мин татар баласы булам,—диде Илдар.—Бу дөньяда татар дигән халык та бар, ләкин ул, син уйлаганча, җәһәннәмдә түгел, ә Никита бабаң, ягъни урыс аюы килгән илдә халык саны буенча дүртенче урында. Шулай булгач, Сэм агай белән сөйләшүләрдә сүз безнең исемнән дә, татарлар исеменнән дә барачак.—Арттырып җибәрүен сизсә дә, Илдар туктала алмады, күңелендәгесен әйтеп калырга ашыгып тезде дә тезде.—Татарлар заманында дөньяны тетрәткән халык, олы дәүләтләр төзеп, югары мәдәниятккә ия булган цивилизацияле халык... Урыс табаны астында калып кына дөньяга сүзен әйтә алмас хәлгә килгән халык...—Кинәт ул авыр сулап куйды һәм әңгәмәдәше белән ризалашкандай әйтте.—Хәер, синең сүзеңдә дә хаклык бардыр, ахрысы... Хәзергә татарлар җәһәннәмдә—коммунизм җәһәннәмендә...

Аның күкерт шикелле кинәт кабынып китүен сәерсенеп күзәткән Джо баш чайкады.

—Нәкъ безнең Ирландия кебек икән. Хәер... Бер без генәме?.. Әнә чехлар, поляклар, болгарлар, румыннар, словаклар... тагын әллә кемнәр елан авызына ашкынган бакадай суырылып советлар авызына кереп баралар. Әйе,—дип куйды ул уйчан гына.—Советларның аппетиты зурдан. Океан артыннан сузылган куллары инде менә Кубага килеп җитте. Нәфесләрен чикләмәсәң, эһ! дигәнче кабып та йотачаклар. Урыс аюының нинди максат белән килүен төшенәм кебек мин.

Фетнә, революция, инкыйлаб, түнтәрелеш кебек чуалышларның, теләсә-кайсы сугышның адәм баласына кайгы-хәсрәт, күз яшеннән гайре берни дә китермәгәнен яхшы аңлаган, әтисе язмышында күргән-кичергән Илдар сәясәтне сөйми, аның белән мөмкин булганча кызыксынмаска, сәяси бәхәсләрдә катнашмаска тырыша иде. Америка татарлары җәмгыятендә шундый гамәл хуплана. Бу юлы да ул үзенә тугрылыклы калды.

—Кубалылар үз язмышларын үзләре хәл итә алмыймыни? Монда

Рәсәйнең ни катнашы бар?—диде һәм шунын белән чикләнмәкче иде.

Әмма сәясәт дингезендәге су асты агымнарын шактый тирәннән тоемлаучы Джо анын белән ризалашмады.

—Бөтен хикмәт тә шунда шул!—Һәм йөзенә акыллы кыяфәт чыгарып, имән бармагын өскә күтәрде.—Куба бу очракта порт фахишәсе шикелле кылана. Сэм агай кочагыннан ычкынуын ычкыныр ул, әмма икенче берәүнең астына ятмыйча барыбер яши алмас. Инкыйлаб белән, никадәр яхшы, матур булмасын, идеяләр, сугышчан шигарьләр белән генә тамак туйдырып булмый. Революционерлар Кубаны урыс аюы кочагына ташларга җыена. Сэм агай белән аю шунын өчен тарткалашалар да инде. Берсенең дә бу «чибәр»не кулыннан ычкындырасы килми.

Дустынын әле бик озак фәлсәфә сату мөмкинлеген яхшы аңлаган, сәяси сөйләшүләрдән качарга омтылган Илдар аны бүлдерергә ашыкты:

—Без монда дипломат булып түгел, электрончы белгеч сыйфатында чакырылган. Сәясәтне, әйдә, аларнын үзләренә калдырыйк. Йә, йә, житте. Беренче көнне үк сонга калабыз түгелме соң!—диде ул һәм ашыгып беләгендәге сәгатькә күрсәтте. Юкса, Ирландия һәм сәясәт хакында сүз чыкса көннәр буе сөйләргә дә ялыкмаган Джоны башкача туктатып булмас иде.—Онытмыйк, әле бит аппаратураны карап чыгасы, әзерләнәсе бар...

Үзен бүлдергәнне яратмаган Джо башка вакыт булса үпкәләргә дә күп сорамас иде. Әмма ул «Менә мин шундый инде» дигәндәй инсәләрен җыерып куйды да кесәсеннән дингезчеләр йөртә торган кыйммәтле сәгатен чыгарды. Ашыга-ашыга секундларны санаган сәгать телләренә төбәлгән ике дус, Атлантик океаннан искән җилгә йөзләрен куеп, тынып калдылар.

* * *

Сентябрь ахырлары.

Америка кинлекләренә соңлап килгән көз.

Шәһәр урамнарында, Берләшкән Милләтләр Оешмасынын штаб-квартирасы каршында сабан туе колгасыдай озын баганаларда дөнья илләренең байраклары. Гудзон култыгыннан искән талгын җилдә алар акрын гына лепердәшәләр, үзләре генә белгән нинди дер серләрен уртаклашалар. Җир шарынын барлык кыйтгаларында яшәүчеләрнен—ак һәм кара, сары һәм кызыл тәнлеләрнен карашы Нью-Йоркка, шушы бинага төбәлгән.

Адәм баласы җиргә бәхет өчен туа, якты дөньяга бәхет өчен килә. Үзенә тиңнәр тап, дуслаш, сөй һәм сөел, балалар үстер, яшә һәм башкаларга да үзләре теләгәнчә яшәргә ирек бир.

Дөньянын ике кыйтгасында туып-үскән, язмыш шаяруы беләнме әллә тәкъдирләрендә шулай язылгангамы, Нью-Йоркта очрашып дуслашкан ике егет талгын җилгә битләрен куеп, бәлки, шул хакта уйланганнардыр. Ләкин алар бер-берсенә ләм-мим сүз әйтмәделәр.

Тынлыкны Джо бүлде.

—Йә, ярый, киттек,—диде ул һәм сәлам биргәндәй уң кулын күтәрде. Илдарнын кулы анын уч төбенә бәрелде. Нинди дә булса эшне башлаганда шулай кул сугышып алуны гадәткә керткән егетләр әле генә бәхәсләшүләрен онытып, рәхәтләнеп көлештеләр һәм киң якты тәрәзәләре балкып утырган бинага таба атлап киттеләр.

Илдар кәнәфигә җайлап утырды, пиджагын салып утыргыч аркасына элеп куйды. Кондиционерлар эшләп утырса да, бүлмәдә эссе иде. Галстугын бушатып, күлмәк изүен ычкындыра төште һәм колагына наушникларны киеп йомшак урындыкнын аркасына ятты. Пультта төрле төсләр белән җемелдәшүче кнопкаларга баскалап алды. Наушникларда әлегә тынлык. Тагын берничә минуттан аларда бөтен дөнья бирелеп тыңлаячак сүзләр яңгырар. Бераз тынычлана төшкәч, як-ягына каранып алды. Латин

Америкасы секторы янәшәдә генә. Пыяла стена аркылы күршедәге Джонның да нәкъ үзе шикелле хәрәкәтләр белән пультта бармакларын уйнатуын күреп үзалдына елмаеп куйды. Эксперт буларак, алар турыдан-туры хезмәт күрсәтүдә катнашмыйлар, дубль системаның әзерлеге өчен генә җавап бирәләр. Ә система инде кат-кат сыналган, аның ватылуы яисә көтмәгәндә сафтан чыгу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Шунлыктан, алар эксперт сыйфатында үзләрен башка электрончылардан һәм тәрҗемә секторындагы ыгы-зыгыдан өстен саныйлар иде. Сөйләшеп алырга да, фикерләрен уртаклашып барырга да вакыт табыласы. Куандырганы, әчке бер горурлык биргәне исә бик гади—ул да булса дөньякүләм мәсьәләләрне хәл итүдә үзеннең дә күпмедер катнашың барлыкны тоюдан иде.

Шуларны уйлап өлгергән Илдар өстәле янынннан торды һәм пыяла стена янына килеп утырышлар залына күз салды. Уч төбендәгедәй күренгән залда төрле илләрнең югары даирә кешеләре кайнаша. Дипломатия итагате нигезендә барысы бер иштән диярлек киенгән сәясмәннәрнең кайсы илдән, кайсы кыйттадан икәнлеген дә аңлап бетерерлек түгел. Бары тик һәр делегациягә билгеләнгән урыннардагы табличкалардан, алар янына кем килеп утырганына карап кына кемнең кайсы ил вәкиле икәнен чамаларга мөмкин иде. Мондый югары дәрәҗәдәге җыенга беренче тапкыр эләккән Илдар күзләре белән «СССР» дип язылган тамганы эзләргә тотынды һәм җиңел сулап куйды. Рәсәй вәкилләре иң алда утыра икән. Алар инде алларындагы кәгазьләрен таратып салганнар, әлегә наушникларын кимичә генә үзара нәрсәдер турында гәпләшәләр иде. Беренче булып күзгә ташланганы—аларның йөзендәге житдилек, кырыслык, ерактан ук сизелеп торучы салкынлык булды. Елмаю, көлемсерәү кебек адәм баласына иң хас сыйфатлардан мәхрүм ителгәндәй тоелган кешеләрне күздән кичереп, Илдар шөбһәле уйга чумды. Аларның кайсысы белән сөйләшеп булыр икән? Әтисенең әманәтен кайсысына тапшырырга? Кайсысы риза булыр да, кайсысы ул хатны алыр? Өйдә чакта бик гади тоелган йомышны үтәү, кинәт кенә артык катлаулы, артык четерекле мәсьәлә булып тоела башлады. Советлар иле делегациясе, әйтерсең, үзен күзгә күренмәс ниндидер киртә белән башкалардан аерып куйган кебек иде.

Башында кайнаган сорауларга җавап таба алмый аптыраган Илдар акрын гына пульт янына килде һәм сөйләшү җайланмасындагы төймәләрнең берсенә бармагын тигереп алды. Колагында Джонның таныш тавышы ишетелүгә җиңел булып китте.

—Джо, утырыш башланганчы синең белән киңәшеп аласы бар икән. Баягынак онытып җибәргәнмен. Вакытың бармы,—диде ул микрофонга иелеп.

—Бар, әлбәттә! Кер, әйдә...

Илдар пультны тулы әзерлеккә куйды да янәшә бүлмәгә, дусты янына ашыкты.

—Мин монда бернинди проблема да күрмим,—диде Джо Илдарның ашыгып-кабаланып, бер вакыйгадан икенчесенә сикерә-сикерә әтисе, гаиләсе тарихы турында сөйләвен тыңлаганнан соң.—Дөрес, безгә утырышлар залына болай тиктомалдан гына кереп йөрү рөхсәт ителми. Тәнәфестә берәр җаен тапмый калмабыз. Әле бит бер генә көн барасы җыелыш түгел...—Һәм дустын тынычландырырга теләгәндәй, аның җилкәсенә сугып күз кысты.—Урыс аюның үзенә якын килә алмабыз алуын, әмма аның безнең шикелле ярдәмчеләре дә бар бит әле. Алай да барып чыкмаса, инглиз дипломатларына яисә аларның ярдәмчеләренә бирү ягын карарбыз. Араларында танышларым бар. Ничек тапшырырга икәнен алар үзләре белер...

Бу сөйләшүдән Илдар тынычланып калды һәм бүлмәсенә чыгып тагын утырышлар залын күзәтә башлады. Әмма күзе үз ихтыярыннан тыш һаман-һаман СССР делегациясенә таба юнәлә иде. Әти-әниләренең, үзенең һәм туганнарының, Нью-Йорктагы, Америкадагы, башка илләрдәге дистәләрчә, йөзләрчә милләттәшләренең язмышын ботарлап ташлаган,

үз илен канга батырган, икенче бер канлы илне тезләндергән, фашизмны тар-мар иткән дәүләт житәкчеләре нинди кешеләр икән?

Башында мен төрле уй бәргәләнде. Жир шарындагы коры жирнең алтыдан бер өлешен «тимер пәрдә» белән томалап куйган хәйләкәр һәм астыртын, жае чыкканда калын мыеклары астыннан үткен тешләрен күрсәтә белүче каты куллы грузин хөкемдарының тәхетенә утырган йомры гәүдәле, йомры башлы, холкы-фигыле, сөйләшү рәвеше белән дә дингез суы шомарткан чуерташны хәтерләтүче Никита Хрущев бу михнәтле илгә, ниһаять, демократия кануннарын алып килде бугай. Иншалла, шулай гына дәвам итә күрсен! Бер очы белән Американың бер штатына—Аляскага терәлгән, икенче очы белән Европаның бәгыренә ук булып кадалган СССР дигән иллә барган үзгәрешләрне Илдар белми түгел. Әти-әнисе, апалары һәм ул үзе дә гәжит-журнал актарганда, телевизор караганда иң әүвәл шул ил хәбәрләрен эзләүне гадәткә керткәннәр иде. Рәсәй төрмәләрендә жәфа чигеп, Себер урманнарында ярты сәламәтлеген калдырып кайтып егылган әтисе Хрущев әфәндене үзен большевиклар тоткынлыгыннан коткаручы чын демократ дип саный, аны дөньяның иң акыллы сәясмәннәре исәбендә йөртә. Мен-меннәрчә сәяси тоткыннарның Йосыф Сталин кордырган төрмәләрдән, үлем конвейерына әйләндерелгән концлагерьлардан чыгарылуы, адәм яши алмаслык жирләргә сөрелгән кешеләрнең азат ителүе, әдәбият-сәнгатькә салынган тимер кыршауның бушатыла башлавы шуңа өметләндерә. Дуамалрак булса да, Никита әфәнде СССРдагы бозларны эретә башлады кебек.

Шул ук вакытта Илдар үзен башкалардан аерым тотучы бу делегация вәкилләренә әле һаман бераз шикләнеп карый иде. Аларда ниндидер чишелмәс табышмак, сер тоемлана. Хәер, шикләнмәслек тә түгел. Жир шарындагы барлык коралның яртысына якыны шул иллә ясалуын, үтеп чыккысыз тайгаларда, аның иярченнәренә әйләнгән илләрдә туплануын Илдар яхшы белә иде инде. Житмәсә, завод конвейерларыннан танклар, самолетлар, тупларның яңа, тагын да камилрәк төрләре агыла тора икән. Никита бабаң кулында атом һәм водород бомбасы, куәтле ракеталар, су асты көймәләре... Дуамал империянең дуамал юлбашчысына шикләнеп карау бер дә гажәп түгел. Бу минутларда залдагы башка дипломатлар да, бәлки, мең тугыз йөз илле жиденче елны исләренә төшергәннәрдер. Коммунизмның кайнар кочагыннан ычкынырга маташкан Венгриянең канга батырылган шәһәр-авылларын әле күпләр бик яхшы хәтерли иде. Совет коралы аяуны белми. Дөнья язмышы кыл өстендә калган көннәр иде ул. Дәһшәтле көннәр... Инде менә хәзер Куба...

Уйларына чумган Илдар трибунага Никита Хрущев чыгып басканын да абайламыйча калган иде. Колагындагы наушникта Джо тавышы яңгырагач кына яңадан залга күз салды.

—Тыңлыйсыңмы, сез татарларның юлбашчысы сөйли,—диде дусты.—Әллә тагын бер кат сезне жәһәннәмгә озатмакчымы? Тыңла... Урыс аюы ниләр сөйли анда?

Үзенә шулай төрттерергә маташкан дустының мыек астыннан елмайганын күз алдына китереп, Илдар ирен чите белән генә көлемсерәп алды һәм үзен Хрущев урынына куеп карады.

Яшүсмер чагында Курск губернасының Калиновка карьясында көтү көткән, яшьлегендә Донбасс күмер шахталарының тузанын иснәгән Никита менә хәзер, шушы минутта, дөньядагы иң югары, иң дәрәжәле мөнбәргә аяк баскач нәрсәләр уйлый икән?! Бәлки, ачлыкта, ялангачлыкта үткән балачагын исенә төшергәндер, бәлки хәтерендә Рәсәйдәге «ач-ялангачларның канын имеп симергән, тук кикереп, дөньясының артына тибеп» яши белгән «буржуй»ларга рәнжеше янаргандыр... Бәлки күз алдына кояш нурында балкып утыручы ап-ак украин авыллары килгәндер... Ә бәлкем, гап-гади Никитадан дөньяга үз ихтыярын тага алырлык дәһшәтле көчкә ия дәүләт башлыгы дәрәжәсенә күтәрелүе, ваграк ил житәкчеләренең аның исемен телгә алганда ук каушап калуларын, «ләббәйкә» дип торула-

рын белеп горурлангандыр... Кеше күңеле—төпсез диңгез. Аның төпкелләрендә ни-нәрсә ятканын дус-ишләре, якыннары гына түгел, кеше дигәнең хәтта үзе дә белеп бетерми. Һәм белеп бетерә дә алмый. Андый кодрәт бирелмәгән адәм баласына. Әмма гарьчел һәм моны бик оста яшерә белүче, тәкәбберлек һәм мин-минлектән дә хали булмаган Никита әфәнденең һәр хәрәкәтендә кискен максатчанлык, сез әле мине белерсез, дигәндәй ертлачлык ярылып ята иде.

Илдар гына түгел, күрше бүлмәдәге ирландияле егет тә моны ачык тоемлаган ахрысы, наушникта тагын аның пышылдаган тавышы ишетелде:

—Дөнья сәясәте акулаларын акылга утыртырга җыена бу. Сизәсеңме?

—Сизәм, бик яхшы сизәм,—диде Илдар микрофонга.—Колак салыйк әле, тагын ниләр кырырга җыена икән бу абзый...

Трибунадагы йомры башлы адәм исә кызганнан-кыза иде. Кинәт ул аска чумды, ялтыравык баш берничә секундка трибунадан югалып торды һәм бераздан мөнбәр өстендә аның көчәнүдән кызарган йөзе күренде. Кабартмадай түгәрәк кулында исә чем-кара ялтыравык туфли иде.

—Менә шулай! Безне тиң күреп сөйләшүегезне таләп итәм,—диде ул кемгәдер янагандай һәм... Йа хода, туфлие белән шапылдатып трибунага китереп сукты. Алдындагы микрофоннар чайкалды. Биниһая олы залда бомба шартладымыни, ялтыратып шомартылган трибунага төшкән туфли авазы дистәләрчә динамикларда көчәйтелеп барлык почмакларда кайтаваз булып яңгырады.—Совет ракеталарының көчен әле сез белмисез. Ләкин беләчәксез! Беләчәксез... Я вам покажу Кузькину мать!

Өстәлгә тагын шапылдап туфли табаны килеп төште.

Үтә итагатьле дипломатик сөйләшүләр генә бара торган урын дип күз алдына китерелгән бинада күз күрмәгән, колак ишетмәгән мондый хәлдән Илдар авызын ачып катты да калды. Монда андый хәлләр дә була микәнни? Шул ук мизгелдә миеннән шөбһәле уй йөгереп узды: «Юк, бу абзый әтинең гозер-үтенеченә игътибар итә торган адәм түгел! Әллә хатны биреп тә тормаска микән?.. Барыбер җавапсыз калдырачаклар. Без алар өчен әле һаман дошман икән. Моннан мәрхәмәт көтеп булмас».

Штаб-квартирада тынлык урнашты. Иң ярсулы, иң катлаулы, дөнья язмышы кыл өстендә калганда да салкын канлылык саклый белгән дипломатлар, дәүләт башлыклары бер мизгелгә телсез калгандай булдылар. Моңарчы күрелмәгән мәнсезлек, БМОның иң төп кагыйдәләрен аяк астына салып таптау, ачыктан-ачык янау иде бу. Дипломатлар, дәүләт җитәкчеләре бер-берсенә караштылар, күзләрендә сәерсенү һәм аптырау чагылып алды.

Илдарны уйларыннан наушникта яңгыраган Джо тавышы бүлде.

—Аңлап бетермәдем, Эль... Нинди Кузькинаның анасын күрсәтергә җыена ул? Анысы кем? Бу тәгъбир нәрсәне аңлата? Минем коллекциягә бара торган әйтемме?

Пыяла стена аша ирландияле егетнең гаҗәпләнгән йөзен күреп алган Илдар исә залда ниләр буласын сагаеп көтә иде, сорауны җавапсыз калдырды, иңсәсен генә җыерып куйды. Маңгаена бәреп чыккан салкын тирне кульяулыгы белән сөртте һәм уң кулының имән бармагын чигәсе янында уйнатып алды. Бу хәрәкәткә бер генә телдә дә тәрҗемә кирәкми, ул һәр кыйтгада сүзсез дә аңлашыла. Бу очракта аны трибунадагы кешегә карата күрсәтелгән дип тә, «Үзем дә төшенеп җитмәдем» дип тә аңлап була иде.

Беренче утырыштан соң икесе дә урамга ашыктылар. Ялгыз калып, кешеләрдән читтә беренче тәэсирләрне уртаклашасы, фикер алышасы килә иде. Ләкин урамга чыккач икесе дә телсез калгандай булды. Джоның йөзе кырыс иде. Ул Илдарга таба иелеп акрын гына әйтеп куйды:

—Аңлаган кешегә аңларлык булды бу. Хәтта ышанасы килми. Никита әфәнде ачыктан-ачык янауга күчте бит. Бу инде болай эзсез генә уза торган нәрсә түгел.

Сәясәттә шактый тирән йөзгән дустына Илдар кайтарып бер сүз дә әйтә алмады. Хәер, әйтергә кирәк тә түгел иде инде. Әйе, аңларлык булды бит...

—Әтинең хатын нишләтәбез инде болай булгач?—диде ул нәүмизләнеп калгандай.

—Анысын әйтүе кыен. Шунысын гына беләм, Русия кешеләре мондый гадәттән тыш хәлдә Америка гражданыннан хат алырга шикләнәчәк. Иманым камил. Алар хәзер бер-берсеннән курка. Һәр сүзләре, гамәлләре контрольдә...—диде Джо һәм маңгаен җыерып бераз уйланып торгач кулын сузды.—Бир әле хатыңны. Таныш инглизләремә барып карыйм. Тәвәккәл таш яра, ди.

Хатны алып ашыгып китеп барган Джога карап Илдар тагын уйга чумды. Бу нинди каһәрле заман, каһәрле көн булды соң? Юкса, бөтенесе дә шулай әйбәт бара, әйбәт башланган иде бит! Илдән илгә каңгырап йөри-йөри картайган, инде газиз туган җирләрен кайтып бер күрергә, туган якның шифалы һавасын иснәргә, изге чишмәләрнең саф суларыннан авыз итәргә тилмергән, шуның белән хыялланып яшәгән әти-әнисенең өмете акланмасмы? Ул аларның мәңге тормышка ашмас хыялы гына булып калырмы?! Хатны биргәненә хәтта үкенеп тә куйды. "Ялгыштым бугай",—дип учына йодрык белән сугып алды. Джо белеп әйтә булыр, мондый чыгыштан соң Америка белән СССР арасына чөй кагылмый калмас. Ә андый чөйләрне бәреп чыгару ай-һай авыр шул!

Джо бик озак көттереп кенә әйләнеп килде. Йөзе караңгы иде. Түш кесәсеннән хатны чыгарды да кире Илдарга сузды.

—Эль, хәленне, кичерешләреңне аңлыйм. Мин барысын да аңлатырга тырыштым. Әмма бу эшне киләчәк заманнарга калдырып тору хәерлерәк булыр,—диде ул үзен гаепле хис иткәндәй уңайсызланып.—Инглиз дипломатлары шулай киңәш итә. Кистереп әйтмәсәләр дә аңладым. Русиянең сугыш игълан итүенә тиң хәл икән бу. Никадәрле сак, сүзләрен җиде кат үлчәп сөйли торган инглиз дипломатлары да шулай дигәч... Калганын инде үзең дә төшенгәнсеңдер...

* * *

Мең тугыз йөз алтмышынчы елның егерме өченче сентябре!.. Кешелек дөньясын салкын сугышның яңа чорына бөтереп алып кереп киткән көн. Материкларны икегә аерып торган Атлантик океанның ике ягында да сугыш машинасы котырып эшли башлаган көн. Кемнең ракеталары, очкычлары, кораблары, танклары күбрәк—дөнья шуның кулында булачак. Аларны эшләтү, карау өчен, әлбәттә, армиягә яңа көчләр, пушка ите кирәк иде. Һәм сугыш чорында туган, унсигез-унтугыз яшенә җиткән егетләр әнә шул сугыш машинасының аяусыз тәгәрмәчләре, чыгырлары арасына барып эләктеләр.

Салкын сугыш тегермәне кеше язмышларын чәйнәп төкерергә кереште. Тегермәнгә исә акыллы, белемле, әзерлекле яшьләр кирәк. Азиатлар, наданнар—стройбатка, төзелешкә. Әйдә, маңгайлары белән җир сөрсеннәр, буласы сугыш мәйданнарын тирләре, каннары белән сугарсыннар. Яулап алган халыкларны инде күптән үз юлына төшәп барырга өйрәнгән ил ул Рәсәй.

Әйдә, алга, яңа җиңүләргә!

Ялгышулар, абынулар егерменче гасыр кешелек дөньясында күп, ай-һай күп булды шул! Бу гасыр тоташ кан коюлардан, ялгышлардан, төзәтә алмаслык хаталардан гына торадыр да. Иң аяныслысы—аларның берсе дә җир шарындагы коры җирнең алтыдан бер өлешен биләгән, дистәләрчә милләтләрне «кочагына кыскан» коточкыч зур илне—СССРны читләтеп үтмәде. Алай гына да түгел, аларның байтагына нәкъ менә

шушы ил, шушы илнең токымсыз һәм затсыз хөкемдарлары сәбәпче булды. «Һәр пешекче хатын ил белән идарә итә ала» дигән мәгънәсез тәгъбирне аксиомага әйләндергән дәүләттә башкача була алыр идеме икән!

Мең тугыз йөз алтмышынчы ел. Вакыт елгасы ярларын кысып тарайткан ел ул. Нәкъ менә шушы елны СССРда кораллы көчләрнең яна төре—стратегик максатлы ракета гаскәрләре оештырылу турында игълан ителде. «Токымсыз һәм затсыз» хөкемдарлар ил, дөнья язмышы белән шаярырга керештe.

Вакыт бара, вакыт барысын да саный. Вакыт угы  мең тугыз йөз алтмышынчы елның егерме өченче сентябрендә!...

## IV

Егетләрнең өсләренә, чыннан да, бәхет ишелеп төшкәндәй булды. Нигә дисәң, машина фаралары яктылыгында алар зур шәһәрләрдә генә була торган ниндидер корылмалар: завод дисәң, завод түгел, склад дисәң, склад түгел кебек тоелган соры төстәге зур һәм биек корылмаларны шәйләп алдылар.

—Әһә, димәк, нинди дә булса зур бер шәһәргә якынлашып киләбез!

Бу минутларда егетләрнең миләрендә уйнап алган беренче уй шушы иде. Чөнки Казаннан бирле аларны кайда алып баруларын әйтергә теләмәгән командирларның серләре ачыла башлады кебек. Ә бу инде хыялларда бөреләнгән өметнең һичьюгы яртысы тормышка аша дигән сүз иде. Шулай булып чыкты да. Борылышларның берсендә алар тимер торбалардан ук сыман итеп ясалган юл күрсәткечтә китап дәреслекләреннән шактый ук таныш бер өлкә үзәгенең исемен абайлап алдылар. Китте үзара төрткәләш, китте уен-көлке.

Әлбәттә, барысы да соңыннан ачыкланды. Алар артиллерия өчен сержантлар әзерләүче мәктәптә, хәрбиләр әйткәнчә, «сержантлар мәктәбе»ндә укыячаклар икән! Бу инде көткәннән дә яхшырак иде.

Их, бу бәхет дигәнеңне! Нигә иң кирәк чагында гына ишелеп төшә икән ул! Үзара танышып, дуслашып өлгергән егетләр җылы казармаларда ике атна да яшәргә өлгермәделәр, мәктәптә кинәт ыгы-зыгы купты.

Офицерлар каядыр чабыша, сержантлар мәж килә. Һәм сержантлар мәктәбенә дип тәгаенләнгән дүрт йөз егетне көтелмәгән ашыгычлык белән машиналарга төяп алып чыгып та киттеләр. Тагын билгесезлек, тагын өметсезлек. Һәм бу юлы да, нишләптер, төнлә. Хәрби частьлар шулай юлбасарлар шикелле гел төнлә генә күченеп йөри микәнни соң?

Озак көттереп таң ата башлады. Юл буена брезентка сибәләп килгән тамчылар биюе дә тынып калды. Бер-берсенә терәлеп йокымсыраган егетләр машиналарның акрынрак бара башлавын һәм, ниһаять, моторларның сүнүен дә абайламыйча калдылар. Кискен, кырт янгыраган команда барысын да кинәт айнытып җибәрде:

—Машиналардан төшәргә! Тезелергә!

Хәрби комиссариатка аяк баскан минуттан ук гаскәри тормышның төп мәгънәсе сафка тезелүдән гыйбарәт икәнен инде аңлап өлгергән булачак сержантлар, алар шуна ышана башлаган иде инде, шыбырдашып асфальтка коелды. Йокымсырауны кул белән алып ташладылармыни. Әле аннан, әле моннан егетләрнең бер-берсеннән сорашканы ишетелде:

—Нинди җир икән бу?

—Юл күрсәткечкә берәр нәрсә язылган идеме? Күрмәдегезме? Берәр исеме булгандыр ич...

—Нинди шәһәр соң?

Сөйләшүләрне җикерүгә охшаш әмер тавышы бүлде:

—Сафта лыгырдауны туктатырга! Рязань катыншалары түгелсез. Равняйсь! Смирно!

Сирин бер нәрсәгә игътибар итте: хәрбиләр янына килеп эләккәннән

бирле, булсын офицер, булсын сержант—һәммәсенен—егетләрне рәнжетү өчен кулллана торган бер ямьсез сүзе бар икән. Ул да булса—«Рязань катыншалары». Әйтерсен, катыншалар бер Рязаньда гына. Хәер, каян белеп бетермәк кирәк, бәлки, чыннан да, шулайдыр. Һәрхәлдә, командирлар теләгенә ирешә—«катынша-баба» дигән шушы ямьсез бер тәгъбир егетләрне күз ачып йомганчы жыйнаклана төшәргә, үзләренең ир затыннан икәнлеген, оешкан, сугышчан затлар икәнен исләренә төшерергә мәжбүр итә иде.

Бу юлы да шулай булды. Әле һаман сафта тигез бер рәткә тезелеп бетә алмаган яшьләр, хәрбиләр кушканча сыннарын катырып, тынып калдылар, күзләре исә тирә-якны айкады.

Ләкин күпме генә эзләнмәсеннәр, күзне иркәләрлек нинди дә булса ямьле манзара табарлык түгел иде. Кайсы якка карасаң да, бер үк төрле күренеш. Алда да, артта да, унда да, сулда да өстенә аварга торган кара урман. Өстә—кургашындай авыр болытлыр йөзгән күк йөзе, тирә-якта гомер бакый кеше аягы басмаган кара урман һәм... бушлык. Аяк астында лычпырдык сазлык. Тагын бер-берсенә бер тамчы судай охшаш агач бараклар шәйләнә. Аларның номерлары да, башка бүтән бер аеру билгеләре дә юк. Алар янында бары тик солдатны йә үрә катырып, йә аяк атлап барган итеп, йә булмаса, командирына «честь» биргән рәвешле итеп төшерелгән фанер такталар... Әмма алар гына бу ямьсез бертөрлелеккә, кәжүнни кырыслыкка ямь бирә алмыйлар иде.

Сирин баракларны санарга да тырышып караган иде, ләкин ниятенә кул селтәде. Ни мәгънә! Бараклардан ары һәр тарафта биек стена булып куе нарат урманы күтәрелгән, урманга житәрәк кеше буеннан ике-өч тапкыр биегрәк баганалар күренә. Баганалар арасына чәнечкеле тимер чыбык сузылган һәм алар томанга охшаш челтәр белән дә уратып алынган иде. Бу инде китапларда гына укып белгән «зона»ны, хәрби әсирләр асрала торган лагерьны хәтерләтә иде. Ничә йорт булса да барыбер түгелмени! Һәрхәлдә, бу өмет иткән зур шәһәр дә, дингез буе да түгел. Монысы бик ачык аңлаешлы иде.

Сирин агачларны, анда-санда төртеп чыккан үләннәрне күздән кичерде. Һичьюгы кайсы яклар икәнен алардан чамалап булмасмы. Ләкин уеннан бик тиз кире кайтырга мәжбүр булды. Үсемлек дөньясы дисеңме, табигате дисеңме, берсе дә үзеннең кайда икәнлегенне аерыр дәрәжәдә нииндидер аерымлыкка ия түгел иде. Димәк, без Рәсәйнең урта полосасыннан әллә ни читкә китмәгәнбез икән, дип фараз кылды ул. Тик менә бу күккә ашкан биек наратлар кайсы якларда булырга мөмкин соң? Мәскәүдән соң бик үк ерак китмәдек бугай ла. Йорт димәсәң хәтере калыр, агач бараклардан бернәрсә белерлек түгел. Аларның бик ашыгып, кабаланып төзелгәнлеге сизелә. Әле хәтта кайберләренә юл да салып өлгермәгәннәр. Төзелеш чүп-чары да шунда. Цемент капчыклары, известьлы мичкәләр... Алардан ерак та түгел тагын нидер төзергә жыеналар булса кирәк, жир өсте тирән траншеялар белән ертмачланып беткән иде.

Иптәшләренең күзләрендә ялтыраган кызыксынучанлыктан, Сирин аларның да үзе кебек үк бер башваткычны чишеп азаплануларын аңлады. Ләкин сержант буласы яшьләргә, хәрби ант та кабул итеп өлгермәгән егетләргә «хәрби уку»ның кайда һәм ничек узачагын тиз генә белү насыйп булмаган икән әле. Ул гынамы!.. Күп тә үтми егетләрне унарлап та, бишәрләп тә кайдандыр килеп чыккан машиналарга төяп тагын кайсыдыр тарафларга озата башладылар. Монысы инде бөтенләй көтелмәгән хәл иде.

Сирин өчен иң куанычлысы шул: ул Комаров белән бер төркемгә эләкте. Моңа улмы әллә Комаровмы ныграк сөенгәндер, әйтүе кыен, әмма икесенең дә күзендә сөенеч нуры балкый иде.

Һәм, шулай итеп, алар үзләрен көткән яңа бер частька килеп эләктеләр. Монда аларны үзләре шикелле үк «салага»—иксез-чиксез СССРның төрле якларыннан китереп тутырылган утызлап егет белән

аралаштырып та куйдылар. Алар бергәләп «Яшь сугышчы» курсын үтәселәр икән. Монысы да мәгълүм булды. Яшьләрне башка солдатлар белән аралаштырырга бик үк ашыкмадылар. «Яшь сугышчы» курсын үткәнче, ягъни сафта йөрергә, «унга», «сулга», «кругом» борылырга, офицер вә сержантларга кайчан, кайда һәм ничек «честь бирергә» өйрәткәнче, җиде төн уртасында торгызып сорасалар җавап бирерлек итеп хәрби устав ятлатканчы, аларны башка бараклардан шактый еракта, урман буена ук корылган зур палаткада асрадылар. Гимнастеркага ак яка тегәргә, аркасына, солдат модасында аерым бер затлылык билгесе саналганча, үтүкләп сыр салырга, җиз төймәләрне чистартырга, кирза итекләрне күзге урынына карап кырынырлык дәрәҗәгә җиткергәнче ялтыратырга өйрәттеләр. Баксаң, болар хәрбиләр тормышында аерым камиллеккә җиткерелгән үзе бер сәнгать икән ләбаса!

Кышка да ерак калмаган иде инде. Көз салкын килде. Әле яңгыр сибәли, әле, озакламый зәмһәрир суыклар да киләчәген хәбәр иткәндәй, җил канатларында кар бөртекләре уйнаклый. Палаткада тимер мичнең көнен дә, төнен дә сүнеп торганы юк. Әмма уртада кукраеп утырган бу «җылыту җайланмасы» гына аннан тишек, моннан ярык белән чуарланган иске брезент палаткага җылы өрә алмый. Салкынлык, шыксызлык. Хәтта идәнгә көн саен кочаклап түшәлүче хуш исле чыршы ылысы да палаткага ямь бирми. Тимер мич янында кизү тору егетләрнең иң теләп, иң яратып башкарган шөгыленә әйләнде. Ул беразга гына булса да ялгыз калырга, үз уйларың белән яшәргә мөмкинлек бирүче бердәнбер урын. Утызлап егет исә көне буе өч сержант һәм бер лейтенант карамагында. Алар рөхсәтеннән башка ашау да, йокы да һәм... буш вакыт та юк. Егетләр өчен болар командир гына түгел, бер үк кимәлдәге газраил вә фәрештә дә, хөкемдар вә казый да иде.

Ниһаять, озак көткән көн дә килеп җитте. Азмы-күпме укытып азапланганнан соң, егетләрнең кулларына автомат тоттырдылар, парад мундирларына киендерделәр дә плацка—часть җирендәге бердәнбер асфальтланган тигез мәйданга чыгарып тезделәр. Күрәсең, хәрби әзерлек дәрәҗәсе җитәрлек дип санадылар булса кирәк. Хәрби ант кабул итү шулай башланды.

Полк командиры, башка офицерлар килеп җитмәгән иде әле. Башка роталар чыгып тезелгәнче, «Яшь сугышчы» курсының башлыгы лейтенант Майорчук саф алдында көязләнде. Дагалы яңа хром итекләре белән шак-шок басып, аларның музыкаль шыгырдавына колак салып әрле-бирле йөренде. Әле бер, әле икенче солдатның бил каешын тикшереп карады. Тыгыз буылганмы, гимнастеркада артык җыерчык-фәлән юкмы, ак якалары чистамы, итекләре ялтырыймы?

Сиринне нишләптер баштан ук яратып бетермәгән лейтенант тагын бер тапкыр аңа каныгасы итте. Аның ни эшләргә җыенганын белгән Сирин каешы соң чиккәчә тыгыз буылган булса да, табигый ки, эчен җыйды. Лейтенантның йодрыгы каеш белән корсак арасына бик җинел генә кереп тә китте. Шуны гына көткән диярсең, ул ирен чите белән мыскыллы елмайды, тавышы тантаналы, үчле иде:

—Нәрсә бу? Корсаклы хатын шикелле биленңне ныклап буарга куркасыңмы? Исеңдә тот, моннан соң аелыңны бер тапкыр әйләндерсәм—чираттан тыш бер наряд, ике тапкыр әйләндерсәм—ике наряд... Һәм *и так дальше*.

Бу яратмауның сәбәбен Сирин сизенә, хәер, сизенә генә түгел, яхшы ук чамалый да иде. Нинди дер хәрби училище тәмамлап килгән, аннан күп булса өч-дүрт яшькә өлкәнрәк бу украин егете урысча сөйләшкәндә адым саен шундыйрак «хата» ясый, җитмәсә, татар егетләрен надан «азиатлар» саный идеме, аларга үзенчә акыл өйрәтүдән аерым бер тәм, ләззәт таба иде. Шундый «сабак»ларның берсендә Сирин түзмәде, аны төзәтәсе итте һәм аз гына ялгышты—«иптәш лейтенант» диясе урынга, нәкъ гражданкадагыча:

—Иптәш Майорчик! Русча *«Это мое не дело»* дип әйтелми, дөресе *«Это не мое дело»* була,—дип ычкындырды.

Солдатлар барысы да мыек астыннан гына елмайды, кемдер хәтта пырхылдавын да тыя алмады. Чыннан да, алар аны үз араларында «Майорчик» дип йөртәләр. Бу лейтенантның үзеннән кала инде беркемгә дә сер түгел иде. Әмма сүз уйнатудан аерым бер кызык таба белгән һәм урысчасы шактый камил Сирин теленнән шул яшерен сүз ычкынганны сизми дә калган иде. Аның ялгышын солдатлар алдында үзен, ягъни командирны кимсетү, түбәнсетү өчен махсус эшләнгән эш дип кабул итте булса кирәк, лейтенант тамагына ипи тыгылган кеше кебек авызын ачып катып калды, аннары гына һушын җыеп телгә килде.

—Беренчедән, салага, минем *фамилием* Майорчик түгел, ә Майорчук, икенчедән, сезнең ишеләр өчен мин бары тик иптәш лейтенант кына. Өченчедән, гражданкадагы бу гадәтләреңне коеп төшермәсәң, үкенергә туры килмәгәе. Ай-һай, нык үкенергә туры килмәгәе...

*«Фамилие»* түгел, *«фамилия»* дип төзәтергә теле кычытса да, Сирин бу юлы «Сүзең көмеш булса, дәшмәвең алтын» дигән акыллы мәкальне исенә төшереп, дәшми калуны мәгкульрәк күрде.

—Гафу итегез, иптәш лейтенант, ялгыш әйттем. Минем сезне рәнҗетәсем килмәгән иде,—диде ул кыенсынып.

Әмма аның гафу үтенүе Майорчукны тагын да ярсыта төште.

—Син... мине рәнҗетергә... Салага! Исеңдә тот, әгәр теләсәм, мин синең үзеңне мең мәртәбә рәнҗетә алам. Ишеттеңме? Мең!..

—Гафу итегез, иптәш лейтенант,—дип кабатлады аннан мондый ук гарьчеллек, ачу көтмәгән Сирин.

Нинди дә булса тагын башка берәр сүз әйтсә, ярсыган офицерның аны дөрес аңламаячагы көн кебек ачык иде инде.

Бу мәгънәсез һәм кирәксез бәхәс нәрсә белән тәмамланган булыр иде, билгесез, солдат белән лейтенантның сүз көрәштерүен елмаеп күзәткән егетләр арасында Комаровның хәйләкәр йөзе пәйда булды һәм аннан да хәйләкәррәк тавышы яңгырады:

—Иптәш лейтенант, армиядә командир солдат өчен туган әниең, туган әтиең кебек инде ул. Ачуланыр да, ярлыкар да. Тик менә мичтә утын бетеп килә. Алып керергә рөхсәт итегез! Туңабыз бит, хлопцы...

Акыл өйрәтү шуның белән өзелде, бераз гына куштанланудан күңеле булган Майорчук ризалыгын белдереп вәкарь белән баш селкеде:

—Рөхсәт итәм. Барыгыз!

Яратмау, үз итмәү шуннан килә иде булса кирәк. Менә хәзер дә бил каешын кысып тоткан лейтенантның аны борып карарга җыенганын сизенеп Сирин корсак мускулларын киерде. Ничек кенә тырышмасын, лейтенант аны бора алмады.

—Ярый, ярый! Истә калдырырбыз,—дип мыгырданды ул үзалдына һәм тагын сафлар буенча китеп барды. Бераздан аның тагын акыл өйрәткәне ишетелә башлады:

—Менә хәзер сез дә тулы хокуклы совет солдаты булачаксыз,—диде ул.—Ант кабул иткәннән соң гражданкадагы иркәләнүләр, сырпаланулар бетте. Хәрби хезмәттә «Белмим», «Булдыра алмыйм», «Теләмим» кебек төшенчәләр юк. Була да алмый. «Белмисең икән—өйрәтербез, теләмисең икән—мәҗбүр итәрбез!» Аңлашылдымы? Бу—закон!

Майорчукның фәлсәфәсе күпмегә сузылган булыр иде, билгесез, аны плацка чыгып тезелә башлаган солдат һәм офицерларның ыгы-зыгысы, багана башындагы тимер чиләк рәвешендәге радиорупордан яңгыраган хәрби марш авазлары бүлдерде. Шуның өстенә, рашкы сибәләргә тотынды. Күшеккән солдатлар бер-берсенә суккалап, сикергәләп җылыну чарасына тотынды. Һәм озак та үтми полк командиры кычкырып әмер бирде:

—Полк, смирно! Полк байрагына карап тигезләнергә!

Парад мундирлары кигән офицерлар, автоматлар тоткан солдатлар

мәйданга полк байрагын алып чыктылар. Әллә нинди сәер хисләр кичерде шул чакта Сирин. Монарчы киноларда күреп, китаплардан укып кына белгән бу хәрби йолада галибанә тантаналык, бәйрәмчәлек һәм шул ук вакытта гаскәри кырыслык та бар иде. Ярты гомерләрен казармаларда, штабларда, хәрби өйрәнүләрдә үткәргән өлкән офицерларның—ир уртасы һәм инде гомер көзенә кереп баручы ирләрнең байрак күренүгә кыл кебек тартылып үрә катулары, йөзләренә чыккан җитдилек бу горефнең бер уен-муен гына булмыйча, чыннан да зур вакыйга икәнлеген күрсәтә иде. Нишләптер, пионерга кергәндә тантаналы вәгъдә биргән мизгелләре искә төште. Читләренә чәчәкләр төшереп, булдыра алганча төсле карандашлар белән бизәп, кулдан күчереп язылган «Тантаналы вәгъдә» тексты да, аны сәхнәдән күмәкләшеп кабатлау да бер балачак уены гына булган икән. Ә монысы башкача. Монысында син язмышыңны хәл иткәндә бинаһая киң вәкаләтләр бирелгән командирлар каршында, илгә тугрылыкка, Ватан хакына хәтта гомереңне корбан итәргә әзер булуыңа ант итәсең. Бу вәгъдә генә түгел, бу—кызыл байрак үбеп, имзаң белән беркетелгән хәрби ант. Күз алдына Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин кебек күкрәкләре белән дошман амбразураларына ташланган батырлар килде. Алар әнә шул антларын үтәп үзләрен корбан иткәннәр. Хәрби ант әнә шундый адымга әзер булуыңны раслап кул кую дигән сүз дә әле ул.

Уйларына чумып тантананың хәлиткеч минутлары җиткәнен Сирин сизми калган икән.

Мәйдан өстендә тагын полк командирының тавышы яңгырый башлады. Мичкәдәй юан биле өстенә алтынланган аеллы, сары төстәге парад каешы атландырган полковникның тавышы торбадан чыккандай калын иде, һәрбер сүзе потлы гердәй саллы иде:

—Капэсэс үзәк комитеты һәм туган совет хөкүмәтебез, алар йөзендә данлы совет халкы, сезгә, эшче-крестьян канына буялган сугышчан кызыл байрак янында тантаналы шартларда хәрби ант кабул итүче яшь сугышчыларга, кадерле Ватаныбызны саклау кебек иң җаваплы һәм иң изге бурычны ышанып тапшыра,—диде ул.

Әллә нишләп Сириннең башында сәер яңгыраш туды: «Эсэс—капэсэс»,—дип эчтән генә кабатлады ул, тиктомалдан көләсе килеп китте. Мондый вакытта көлеп җибәрү яисә елмаю сәерлек кенә түгел, хәтта командирлар тарафыннан җинаять дип кабул ителергә мөмкин иде. Йөзенә чыккан елмаюны басар өчен иренен тешләп полковникны тыңларга керешге. Ә уйга салырлык нәрсәләр күп иде.

—Сезгә «сугыш алласы» саналган гаскәр төрендә—артиллериядә—Совет кораллы көчләренең иң алдынгы сафында торучы гвардия берләшмәсендә хезмәт итү бәхете эләкте. Дөньяда сәяси ситуация гаять катлаулы. Кубада кабынган социалистик революцияне буар өчен Америка сугыш чукмарлары котырынып коралллана, НАТО һәм башка хәрби блоклар ашкынып кораллы бәрелешкә әзерләнә. Капэсэс һәм совет хөкүмәте аларга каршы совет кораллы көчләренең җимерелмәс һәм куәтле калканын булдырды. Горурланыгыз! Чик буенда булмасагыз да, сез—ил чикләрен саклаучылар! Һәм ышанычлы, тугрылыклы саклаучылар булырсыз, дип ышанам.—Полковник хәрби хезмәтнең авырлыкларына да тукталуны кирәк тапты.—Әйе, кыенлыкларсыз булмас. Әмма ил чикләрен саклау җинел, дип кем әйтә ала. Без озакламыйча сугышчан дежурлыкка басачакбыз. Дөрес, әлегә казармалар әзер түгел, ашханәбез дә тәгәрмәчләр өстендә... Ләкин болар вакытлы кыенлыклар. Айлар, атналар үтәр, сез барлык уңайлыклар тудырылган казармаларда яши башларсыз, ашханәбез шәһәр рестораннарыннан ким булмас. Мунча проекты әзер. Төзүчеләр нигезен сала башлады... Клубыбыз да, Ленин бүлмәсе дә, китапханәбез һәм чәйханәбез дә гөрләп эшләп торыр. Командование боларның барысын да булдыру өстендә эшли. Солдатларның, ил сакчыларының мәнфәгатен кайгырту—командованиенең изге бурычы.

Полковник дәртләнеп, илһамланып бик озак сөйләде. Ак төстәге

вак ярма сыман рашкыны сибәләүче пыскак яңгыр алыштырды. Җил канатында күбәләктәй кар бөртекләре уйнаклый башлады. Алар да, үзәкләргә үтәрлек күзгә ачы җил дә аны туктатырлык түгел иде кебек. Әмма аның бу патриотик сүз агымы да алдан билгеләп куелган хәрби кысаларга сыя икән.

—Кадерле яшь сугышчылар!—диде ул, ниһаять, аталарча кайгыртучан кыяфәт алып.—Бүгеннән сез сугышчан роталарга, взводларга җибәреләчәксез, өлкән солдатлар белән бергә ил сагына басачаксыз. Сезгә сугышчан һәм политик әзерлектә уңышлар телим. Ә хәзер... бәйрәм ашына!

Хәрби ант кабул иткәннән соң бәйрәм ашы булырга тиешлеген беләләр иде инде. Аны тансыклап көтәләр дә иде. Һәм, ниһаять, командир боерыгына буйсынган соргылт-яшел төстәге кешеләр—солдатлар һәм сержантлар агымы җыр сузып, саф-саф булып ашханәгә таба юнәлде.

Түбәсе рубероид белән ябылган, колхозның ябык ындыр табагы—авылларда рига дип йөртелүче корылманы хәтерләткән вакытлы ашханә ягыннан борыннарны кытыклап хуш ис бөркелде. Пешкән ит, кыздырган бәрәңге исе. Әмма аннан-моннан әтмәлләнгән түбә астына кертеп утыртылган поход кухняларында, вакытлы мич-плитәләрдә әллә ниткән затлы ризыклар—бәйрәм ашлары әзерләп булмыйдыр шул. Шулай да пешекчеләр тырышкан. Төшке ашка өстәп әле берәр кружка компот, ике данә прәннек һәм берәр яшел алма да бирделәр. Калганнары исә гадәттәгечә ачыган кәбестәдән әзерләнгән сыек кына шулпа белән тары боткасы иде. Ботка янында кул яссуы кадәрле дуңгыз мае—сало да ялтырап ята. Әмма дуңгыз итеннән җирәнгән, һәм бу көнеле тырганууын берничек тә баса алмаган Сирин майны бер читкәрәк шудырды. Бу хәрәкәтне күреп торган Ильяс сиздерми генә аның иңсәсенә төртте, күз кысып елмайды:

—Үзең ашамасаң, мина бирсәң дә ярар дип беләм. Без өйрәнгән инде. Кич белән әҗерен балык белән кайтарырмын.

«Дембильгә хәтле ике километр балык ашарга кирәк» дигән солдат әйтемен инде ишетеп өлгергәннәр иде. Кемдер исәпләп чыгарган бит: һәр көнне солдатка биш-алты сантиметр озынлыктагы балык кисәге бирелә. Шуны өч елдагы көннәр санына тапкырласаң, ике километр чамасы балык килеп чыга икән. Сирин дә шаяртасы итте.

—Ике километрны тизрәк ашатып, мине тизрәк дембильгә җибәрәсен килә, ахрысы.

—Их, алай гына аны якынайтып булса, мин көненә бер метр балык ашарга да риза,—диде Ильяс ике кулын балыкчыларча ике якка сузып.—Балык ашап дембильне якынайтып булмаган кебек, дуңгыз ите ашап кына мыркылдый башламам әле. Их, Казанда, әни табак тутырып пылау пешерер иде, аның янына шулпалы бәлеш, берсе-берсе йодрык кадәрле пилмән...

—Йә, җитте сина, искә төшермә әле,—дип куйды ачусыз гына Сирин. Солдат ашының бертөрлелеге инде һәммәсенең җелегенә үткән иде.—Шунысын да туйганчы ашарга бирмиләр, ичмасам!

Солдат өстәл янына команда белән килеп утыра, команда белән торып китә. Сержантның әмере яңгырауга барысы да өстәл яныннан торды. Хәер, ачык һавадагы бу ашханәдән чыгу өчен әлләни күп кирәкми. Өстәл яныннан тордың, димәк, син инде тышта дигән сүз.

Тагын тезелергә әмер яңгыраганчы, кемдер тәмәке кабызып җибәрде, кемнәрдер төркем-төркем булып төрле мәзәк хәлләр сөйләшергә кереште. Кая барып кушылырга белмичә торган Сирин үзенә кемнеңдер текәлеп каравын сизеп туктап калды. Өстендәге бушлатының, башындагы бүрегенең искелегеннән генә түгел, ә йөз чалымнарының ирләрчә кырыслыгыннан да «карт» солдат икәнлеген абайларга мөмкин булган бер егет Сирингә текәлгән иде. Менә ул аңа таба атлады һәм кычкырып та җибәрде:

—Нәрсә, якташыңны танымыйсыңмы әллә?

Сирин кай ягы беләндер кемнедер хәтерләткән, әмма тәгаен гына кем

икәнен әйтә алмаган бу егетне, чыннан да, танымый иде.

—Ялгышмасам, син Сирин буласың түгелме соң?—дип дәвам итте солдат.—Сирин Сабиров! Балтамактан. Без унда укыганда жиденчене бетереп азаплана идең...

—Әйе, мин Сирин... Тик, нишләптер, танымыйм димме.

—Соң... Балтамакта ат чаптыручы Газетдинны белмәгән кеше юк бит. Мине, Газетдин Рифгатен хәтерләмисеңмени?

—Беләм, әлбәттә,—дип чак кына кычкырып җибәрмәде Сирин.—Ничек инде белмәскә!?

Теле шулай диде. Әмма күзләренә ышанмады. Әле балалыгы да чыгып бетмәгән, борын астында мыек җебе күренә генә башлаган, зур елтыр күзле егет иде авылдашы Рифгать. Ә монда каршысында күз читләрен әллә нинди вак җыерчык баскан, алдагы бер теше урынында кара бушлык ыржайган, ир уртасына якынлашып килүче кемсә басып тора. Әмма, җентекләбрәк карагач, күргәненә ышанмыйча булдыра алмады. Бу, чыннан да, шаянлыгы, җорлыгы белән авыл кызларын бер карауда әсир итә белүче, терекөмештәй җитез гармунчы Рифгать иде. Теленнән чак кына «Ай-һай, картайгансың якташ» дигән сүз ычкынмыйча калды. Ярый әле вакытында телен тыя белде. Юкса, авылда чакта кемнендер яңак төбенә менеп төшәргә дә күп сорамаган Рифгать аны дөрес аңламас иде. Шуннан соң «якташ» дип кара инде. Шулай да гаҗәпләнүе теленә чыкты:

—Үзгәргәнсең, танымый торсам да гаҗәп түгел,—диде.

—Үзгәрерсең монда,—дип кул селтәде Рифгать.—Әйдә, бер читкәрәк китик әле.

Ашханәдән, башка солдатлардан читкәрәк, карт чыршы янына барып бастылар. Рифгать кесәсеннән бер кап «Аврора» чыгарды, Сирингә сузды:

—Көйрәтеп җибәрик булмаса!

—Мин тартмыйм!

—Анысы әйбәт! Кешегә ялынычын төшмәс, ичмасам. Ай, якташ, сине күргәч, күзләремә ышанмый торам. Билләһи, җирне кысан диләр, тар диләр, чыннан да, шулай икән бит әй! Әллә кайда, җир тишегендә якташыңны, авылдашыңны очрат инде, ә!

Рифгатьнең сүзләре, сораулары, беләсе килгәннәре бетәрлек түгел иде. Мәктәпне бергә бетергәннәрдән, аннары тагын яшьрәкләрдән кемнәр кайда урнашкан, кем кайда укый, кайсы кыз кем белән йөри? Кайсы егет өйләнгән, кайсы кыз кемгә, кайчан кияүгә чыккан. Клубта бичырлар элеккечә узамы, гармунда кем уйный? Тагын әллә ниләр, тагын әллә нинди сораулар...

Сирин аларга җавап бирә-бирә арды.

—Шулай да сине очратуым әйбәт булды әле,—диде Рифгать һәм, күзләренә ышанмагандай, Сиринне ике иненнән тотып каршына бастырды.—Туйганчы бер карыйм әле. Сине күргәч, авылга кайткан кебек булдым. Рәхәт булып китте.—Һәм авыр сулап, кинәт уйчанланып калды.—Сине очратуым әйбәт анысы, тик синең монда эләгүең әйбәт булмаган, якташ. Әйбәт түгел...

—Нигә алай дисең? Әнә, полковник ничек мактап сөйләде бит әле... Казармалар да, клуб та төзелә ди...

—Ул хәтле беркатлы булма инде,—дип теше сызлагандай йөзен чытты Рифгать.—Безгә килгәннән бирле шуны вәгъдә итәләр. Дембиль җитте, әле күрә алган юк. Күрә дә алмабыз. Их, тизрәк өйгә кайтасы иде...

Сирин исә тагын төпченәсе итте:

—Шулай да монда эләгүнең кайсы ягы начар? Башка җирдә дә әлләни түгелдер әле.

—Башка җир—башка җир инде ул. Кайда килеп эләккәненне беләсеңме соң син?

—Белмичә,—дип елмайды Сирин.—Данлыклы артиллерия гаскәрләренә. Гвардиягә...

Рифгать тагын йөзен чытып куйды.

—Чистый башыгызны әйләндергәннәр икән. Е-мое... Ярый, минем бәхет басты, инде дембиль дә житте. Ә сез... Дембильгә хәтле һичьюгы бер тапкыр увольнение күрергә тилмереп хезмәт итәсегезне әйтteләрме? Монын бит хәтта адресы да юк. В/ч. Ягъни «хәрби часть» кына. Гвардия, имеш.—Ул тагын бер кат мыскыллы елмайды.—Син үзен хезмәт курсәтәчәк нәрсәнең—мондагы «изделие» дип аталган нәрсәнен ни икәнен беләсенме сон?

—Ю-у-ук,—дип баш чайкады Сирин.

—Һәм әйтмәсләр дә...—Ул Сирингә якын килеп пышылдауга күчте. Ашыгып-ашыгып татарча тезә башлады.—Әлегәчә әйтмәгәннәр икән, сонрак та әйтмәсләр. Урман кырыендагы юлга чыгарып тезелгән пушкаларны күрденме?

—Күрдем... Артиллериядә тагын ни булсын инде?—дип елмаерга мәжбүр булды Сирин.

—Күргәнсендер шул... Башта безнен часть, чыннан да, артиллерия иде... Ә хәзер алар шулай күрсәтер өчен генә калды... Частьнын, хәрбиләр телендәгечә, татарча ничек әйтим икән... үз әкияте булып. Янәсе, монда еракка ата торган артиллерия полкы. Ә чынлыкта...

Сиринне кызыксыну хисе биләп алды, Рифгатьнен үзе шикелле үк пышылдап сорады:

—Ә чынлыкта нәрсә?

—Анысын үзегез белерсез инде,—дип сәер генә елмайды Рифгать.—Анысын белү өчен күп вакыт кирәкмәс. Бу хакта теләсә кайда сөйләнеп йөрергә ярамый. Якташ булганга гына әйтәм. «Особый отдел» дигән нәрсәнен күзе үткен, колагы сизгер. Хатларында да язасы булма. Һәр хат әнә күзеннән үткәрелә. Безнен берничә егет шунын аркасында дисбатка эләкте. Ан бул! Теләсә кая тыкшынма. Ин куркынычы—«изделие» янына эләгүдән саклан. Мен сәбәп тап, авыруга сабыш, ялганла, алдалаш. Радиация дигән нәрсәне укып булмаса, ишетеп беләсендер. Монда саклану чаралары әлегә юк дәрәжәсендә. Нурланыш коточкыч. Бер-ике ел анын янында маташсан, кайткач кызлар янына барасын килмәс. Хәер, кирәге дә булмас... Анлашылдымы? Тагын «заправщик» дигән белгечлектән курык! Анысынын үз хикмәтләре. Тора-бара барысын да белерсен әле.

Сирингә аптырап баш чайкаудан башка чара калмаган иде:

—Анлап бетерә алмыйм... Радиация... Без бит уран руднигында түгелдер.

—Түгел, хет анысына аллага шөкер диген! Тьфү!.. Стратегик ракеталарны кыш бабай күчтәнәче ташый дип белденме әллә? «Ин куәтле корал бездә»,—дип мактандылармы? Мактандылар! Ишеттен бит! «Ин куәтле корал»ны ни дип беләсен инде? Анын да ин куәтлесе әле. Әнә Хиросимада ул «күчтәнәч»не ташлаганнарына инде егерме елга якын, ә аны «авыз иткәннәр» бүген дә тормыш белән бәхилләшә тора. Күпме гарип бала туа. Ә мондагы «күчтәнәч»не андый гына дип беләсенме? Исе дә, төсе дә юк. Иссез-төссез үлем, диләр ич аны.

Сирин ни дип әйтергә дә белмәде. Шулай да Рифгатьнен бөтен әйткәннәрен анлап, бәяләп бетерерлек хәлдә түгел иде әле.

—Әйткәнен, кисәткәнен өчен рәхмәт,—диде ул бөтенләй югалып.—Мин хәзер ни генә эшли алам сон?!

—Әлегә бөтенесе дә үз кулында. Әйттем ич, теләсә ничек алдаш, авыруга сабыш... Мин моны сина авылдаш буларак та, егет кеше буларак та әйтәм. Безнен әтиләр авылдан сугышка бергә киткән, бергә исән-сау кайткан бердәнбер кешеләр. Шул хакка сөйлим.

—Мин алдаша белмим. Нәселебез андый түгел...

—Башына төшсә, башмакчы булырсын, диләрме әле. Башына төшкәч, белерсен. Ин куркынычы...

Әмма аларга сөйләшеп бетерергә ирек бирмәделәр. Сержантларнын «Фәлән взвод... Тезелергә!» дигән командалары янгырый башлады. Үч

иткәндәй лейтенант Майорчукның чәрелдәвек тавышы килеп житте:

—Рядовой Сабиров! Син тагын кая олактың инде?

Рифгать хушлашып кулга кул сугар алдыннан бер-ике генә сүз пышылдап өлгерде:

—Мине табарга тырыш! Хәер...

Сирин иптәшләре янына сафка килеп басты. Якташы белән очрашу аңа шатлык урынына күңел тынычсызлыгы, җан бимазасы гына өстәгән иде. Чынлап та шундый бер куркыныч җиргә килеп эләктеләрмени соң алар? Алай булырга тиеш түгел! Рифгать нәрсәнедер арттыра, күзгә төтен җибәрә булса кирәк. Тик болай итеп борчак сибү аңа ник кирәк? Бу частьта хәзер Ильястан кала иң якын кеше шул Рифгать ич! Әле алай гынамы?! Бәлки, иң якыныдыр. Яшь аермалары булса да, челтерәп аккан бер үк чишмә суларын эчеп, ашкын сулы бер үк елга кочагында тирбәлеп, шомыртлы-баланлы, чытырманлы-куралы бер үк урман сукмакларын айкап, бер үк һаваны сулап үскән малайлар бит алар. Бәлки, Рифгатьнең үзен бераз серлерәк, күпне белүче иттеребрәк күрсәтәсе килгәндер. Өч ел хезмәт иткән кешегә анысы да гаеп түгел инде. Кайткач, авылдагыча иттереп, сөйләп «җиффәрергә» дә кирәк бит әле: «Мин менә, парин, шундый-шундый җирләрдә служить иттем»—дип. Ә совет армиясендә Рифгать сөйләгәнчә була алмас. Сугыш вакыты түгел. Әнә бит полковник та ничек мактап, горурланып сөйләде. Мондый җирдә хезмәт итәргә әллә аларның башына тай типкәнме?! Сирин, үзе ышанып бетмәсә дә, күңеленнән үзен тынычландырырга тырышты. Әйе, монда да кемдер хезмәт итәргә тиештер бит инде. Ләкин никадәр генә баш ватмасын, күңелендә айкалган уйларының очына чыга алмады. Җан бимазасы күңеленә корт булып төшкән иде инде.

## V

Эш көне бетәргә ярты сәгать калганда гына бүлмәдә селектор кыштырдаган тавыш ишетелде, бераздан директорның сөйкемле сөяге сәркәтип кызның тавышы да килеп җитте:

—Эль, Джо! Ишетәсезме? Сезне директор бүлмәсенә керергә чакыралар.

—О’кей! Хәзер килеп җитәбез,—диде Джо сөйләшү җайланмасының кнопкасына басып һәм шул арада Илдарга күз кысып өлгерде. Монысы абзаларыгызның дәрәҗәсе күтәрелде хәзер, дигәнне аңлатырга тиеш иде. БМО штаб-квартирасында эксперт буларак катнашканнан соң, егетләрнең абруе компаниядә икеләтә арткан иде. Иң җаваплы, ашыгыч эшләрнең нәкъ менә үзләренә тапшырыла башлавын алар сиземлиләр. Бу исә егетләрнең мин-минлеген дә бераз кытыкламыйча калмый. Һәм тагын шулай булачагына ышанган егетләр үз дәрәҗәләрен белеп ашыкмыйча гына урыннарыннан күтәрелделәр. Табигый ки, мондый заказлардан кесә ягы сизелерлек җайлана бара. Гәрчә инде байтактан сәмән дигән нәрсәгә артык кытлык кичермәсәләр дә, яшьләр өчен һәр артык доллар мая туплау, ерактагы, әлегә хыялда гына йөргән киң һәм якты, яшьлеккә хас олы максатларның чынбарлыкка якынаюы дигән сүз дә иде.

Джо Илдарга карап тавышсыз гына көлеп куйды:

—Сизәсеңме, мистер Эль? Безнең капиталны арттыру фирма директорының төп максатына әйләнеп бара ахрысы. Юкса, безне күрергә бу хәтле ашкынып тормас иде. Шулаймы?..

Көне буе тиз арада тапшырылырга тиеш бер заказның исәп-хисабын ясап утырган һәм шактый арган Илдар күзләрен дисплейдан алып, чигәләрен бармаклары белән ышкып алды, әмма дустының артык өметләнүенә кушылырга ашыкмады. Бу ашыгыч эшләр күпкәрәк китте түгелме соң? Дустына җавабы да кыска булды:

—Белмим, белмим... Безнең кесәне кайгыртамы, башканыкынмы?..

—Бу хәтле пессимист булып кыланма инде! Без ерып чыга алмаган эшләр бу дөньяда юк!

Джонын үз-үзен мактавыннан көләсе килгән Илдар кулын селтәде.

—Ярый, синенчә булсын. Килешәм...

Егетләр сүз берләшкәндәй кулга кул сугып алдылар һәм ышанычлы адымнар белән директор бүлмәсенә юнәлделәр. Директорның гадәтен— иң мөһим хәбәрләрне эш көне азагында житкерүен алар инде беләләр һәм бу юлы да шулай буласы шик тудырмый иде. Әмма референт кыз аларның сораулы карашына инсәләрен жыерып кую белән чикләнде һәм серле кыяфәт ясап ишеккә таба ымлады: «Керегез, кергәч, күрерсез, янәсе». Башка вакытта яшь, чибәр егетләр алдында чытлыкланып алырга да күп сорамый торган кызны алыштырып куйганнар диярсең. Аның артык житди ымы, гади рәсмилектән узмаган хәрәкәте бераз сагайтса да, егетләр аңа әлләни игътибар итмәделәр. Чыккач та тел чарлап алырга жай табылыр әле...

Ләкин кабинетта директор үзе юк иде, аның урынында—култыксалары, йомшак арка терәгече белән бөтен гәүдәне кочып ала торган йомшак күн кәнәфидә исә озын буйлы, ач яңаклы, керпе энәләре кебек тырпайган кыска чәчләрен артка каратып тараган урта яшьләрдәге бер кеше утыра иде. Ул егетләрне күптәнге танышлары шикелле елмаеп каршы алды һәм өстәл янына кара-каршы куелган урындыкларга ымлады:

—Рәхим итегез, утырыгыз!

Илдар белән Джо моның нәрсә аңлатканын белергә теләгәндәй бер-берсенә карашып алдылар, әмма берсе дә сүз әйтергә ашыкмады, икесе берьюлы урындыкларга утырдылар.

Ул арада таныш түгел кеше үзен нәкъ хужаларча тотып, өстәлдәге кыйммәтле сигарет тутырылган көмеш портсигарны аларга таба этеп куйды һәм сөйли дә башлады:

—Теләсәгез, сигарет! Теләсәгез, кофе... Рәхим итегез... Мин хәзер китертәм.

Беренче карашка сәеррәк тоелган кешенең кунакчыллыгыннан югалып калган егетләр тагын икесе берьюлы жавап кайтарды:

—Юк, юк, борчылмагыз. Безгә берни дә кирәкми...

—Алайсаң, танышыйк. Сезнең кем икәнлегегезне яхшы беләм. Шунлыктан анысын сорап тормыйм, үзем белән таныштырам. Мин мистер Патиссон булырмын. Киләчәктә дә шулай дип эндәшүегез мәслихәт. Озын сүзнең кыскасы, мин сезгә яңа, тагын да кызыклырак һәм... табигый ки, шактый ук табышлы эш тәкъдим итмәкчемен. Фирма директоры булмаганга гажәпләнмәгез, мәсьәлә аның белән килешенгән, аны хәбәрдар дип санагыз.

Сүзләренең ничек тәэсир итүен белергә теләгәндәй, ул беразга сүзсез калды һәм каршында утыручыларга текәлде. Шешенке күз кабаклары арасыннан ике яшькелт күз егетләрне бораулый башлады. Әмма йөзеннән елмаю китмәде. Әйтерсең, ул аларны үтәли күрергә тели иде. Сүзләре ясаган тәэсирдән, күргән чаклысыннан канәгать калды булса кирәк, нечкә бармаклары арасына сигарет кыстырып, чакмадан ут элдерде һәм, төтенен тәрәзәгә карап өргәч, сүзен дәвам иттерде:

—Безнең корпорациягә компьютер белән эшләүдә гадәттән тыш фикерләү сәләтенә ия өметле яшьләрне туплау бурычы куелды. Илкүләм колачлы эш,—диде ул үз-үзеннән канәгать чырай белән.—Америка дөньяга электрон машиналары гасырын алып киләчәк. Сезнең кебек яшь талантлар акылы, хезмәте, тырышлыгы, энтузиазмы белән, әлбәттә... Менә мин сезне шул корпорациягә чакыручы булам инде.

Илдар кызыксынуын яшерә алмады:

—Ул бурыч... кем... тарафыннан куелды?—диде ул мистер Патисссонны бүлдергәнгә уңайсызлангандай.

Мистер Патиссонның йөзеннән бер генә мизгелгә елмаю югалып торды. Ләкин ул яшьләр белән сөйләшүнең, аңлашуның барлык серләрен,

бөтен нечкәлекләрен яхшы белә иде ахрысы, битенә елмаю күз ачып йомганчы әйләнеп тә кайтты.

—Соравыгызга җавап бирәм,—диде ул карашын Илдарга текәп.—Америка хөкүмәте... Җавап канәгатьләндергәндер, дип беләм. Канәгатьләндерсә, бер киңәшем булыр. Безнең корпорациядә «Ник, ни өчен, нигә?» дигән сораулар, гадәттә, бирелми. Аны бары тик җитәкчеләр генә бирәчәк. Килештекме? Электрон машиналар белән...—Ул сул кулының имән бармагын кисәтүле рәвештә өскә таба тырпайтты,—киләчәк машиналары белән эшләү дәүләт серен тәшкил итә. Шулай булгач, аңлашылгандыр.

Нинди эш, аның кайда һәм ничек булачагын, нәрсәдән гыйбарәт икәнен бик белергә теләсәләр дә, егетләр кайтарып сорау бирергә базмадылар. Башта әйткән хәтлесеннән дә күпмедер нәрсәне төшенеп була иде.

Мистер Патиссон урыныннан торып тәрәзә янына килде, калын пәрдәне күтәреп унөченче кат биеклегеннән урамга күз салды һәм, егетләргә туп-туры карап, монологының йомгаклау өлешенә күчте:

—Мин әлегә сезгә шунысын ышандырып әйтә алам һәм чын джентльменнарча гарантия бирәм. Үзегез өчен гаҗәеп дәрәҗәдә кызыклы эш табачаксыз. Бу инде көч-куәте, һәм, табигый ки, финанс ягы чамалы хосусый фирма түгел, мөмкинлекләр күпкә артыграк. Егерме беренче гасырда кешелек дөньясының йөзен билгеләячәк фәндә, инженерлык фикерендә колач җәеп йөзәсе дә йөзәсе... Мин сезне ашыктырмыйм, әмма алдын-артын уйлар өчен, ике көн вакыт җитәрдер. Шуннан артыгы минем вәкаләттә түгел. Калган рәсми вак-төяк, эш шартлары турында килешү, кем әйтмешли, кулга кул сукканнан соң, ягъни сезнең ризалыкны алгач. Ләкин алдан ук әйтеп куя алам, түләү хәзерге акчагыздан берничә тапкыр артык. Башка ташламалар, өстенлекләр дә булуы җитәрлек. Уйлагыз!

Егетләр директор кабинетыннан сүзсез генә чыктылар. Ишеткән кадәресе дә уйланыр өчен җитәрлек иде. Акрын гына эш бүлмәләренә таба атладылар. Өсләренә ишелеп төшкән бу кадәр вәгъдәне акыл бизмәнендә тагын бер кат үлчәп, сеңдереп бетерәсе бар иде. Тынлыкны Джо бүлде:

—Һа... Белмим, белмим,—диде ул бер ноктага карап барган җиреннән капылт туктап һәм каршы як капкасына хәлиткеч тупны керткән футболчыдай кинәт кулын йодрыклап һавага селкеп алды.—Син ничек уйлыйсыңдыр, Эль, белмим, ә миңа калса, Патиссон әфәнде шәп тәкъдим белән килгән. Һәрхәлдә, миңа ул бик мавыктыргыч тоела.

Илдарның күңелендә исә каршылыклы уйлар бәргәләнде. Бердән, ризалык бирү иң башлап ярдәм кулы сузган Рөстәм Агишка хыянәт итү шикеллерәк килеп чыгар иде. Икенче яктан карасаң, вәгъдә ителгән эшнең кызыклылыгы да, түләүнең нык артасы да ымсындыра. Биш җаннан торган гаиләдә төп ышаныч Илдарда. Монысын да истән чыгарып булмый. Шуның өстенә сәер фамилияле сәер кешенең табышмаклар белән сөйләшергә тырышуы бераз шикләндерә, икеләнергә мәҗбүр итә иде. «Әти Американы, мондагы яшәү рәвешен, су асты агымнарын әлегә яхшылап белеп бетерми, Агишлар белән киңәшми булмастыр». Күңеленнән шундый шөбһәле уйлар кичергән, Патиссонга ышанырга да, ышанмаска да белмәгән Илдар ирландияле егеткә җавап биреп тормады. Ләкин ул үзе тәкъдимне кабул итү ягына авыша башлавын тоя иде инде.

* * *

Шикләнгәне рас килде. Шул көнне үк кич җыелган гаилә киңәшендә Илдарның ордым-бәрдемрәк сөйләгәнен Оркыя ханым тыңларга да теләмәде. Әмирҗан ага исә кистереп әйтте:

—Без монда килеп урнашуыбыз, эшебез, тормышыбыз белән

тулысынча Агишларга бурычлы. Аларның кинәшеннән башка берни дә хәл итәсе түгел,—диде ул.—Агишларга хыянәт—милләтебезгә, игелек кылучыларыбызга хыянәт. Мин Америка кануннарын, мондагы эш-бизнес тәртибен житәрлек белмим, аганнар ни әйтсә, шул булыр.

Оркыя ханым шунда ук телефон номерын жыя да башлады. Патиссон әфәнде әйткән тәкъдимгә ашыгыч жавап, Рөстәмнең төпле кинәше кирәк иде.

Агишларның өлкән вәкиле озак көттермәде. Ишектән шаулап-гөрләп килеп керде, Әмиржан белән кул кысышкач, Оркыя ханымга бөгелеп сәлам бирде. Үз-үзен тотышыннан да, йөз-кыяфәтеннән дә яңа хәбәрнең аңа ничек тәэсир иткәнен белерлек түгел иде әле.

Һәм, ниһаять, ул агасының хөкемен көтеп тураеп баскан Илдарга беренче кат күргәндәй сынаулы караш ташлап алды һәм:

—Йә, дускай, сөйләп жибәр әле. Нинди тәкъдимнәр белән килгәннәр икән сиңа,—диде. Йөзенә яратып көлемсерәү чыкты.—Болай эзләп килә башлаганнар икән, таныла барасың, дигән сүз. Чебеш, димәк, кабыгын ватып чыккан, якты, киң дөньяга омтыла. Шулаймы?

Илдарга бар белгәнен түкмичә-чәчмичә сөйләп бирүдән башка чара калмаган иде.

Кинәт агасының йөзе кырысланды, иң хәтәр чакларда да күкрәктән тигез гөрелдәп чыккан тавышында борчылу сизелеп куйды.

—Кем, кем килде дидең? Ялгышмасам, мистер Патиссон исеме чыкты бугай...

Аның бу фамилияне болай кабул итәсен белмәгән Илдар аптырый калды.

—Әйе, ул үзен шулай дип таныштырды. Мин үзем дә нинди сәер фамилия дип уйлаган идем...

Рөстәм утырган жиреннән торды һәм сүзсез генә бүлмә буйлап әрле-бирле йөрергә тотынды. Күрәсең, ул уенда нәрсәнедер хәл итте булса кирәк, бераздан янадан Илдар каршына утырды.

—Үзенең каян икәнлеген әйттеме? Корпорациянең исемен, ни белән шөгыльләнәчәгегезне?

—Юк, кистереп әйтмәде.

—Һым... Алай булуы, бәлки, яхшыгадыр да әле.

Патиссон исеме чыккач агасының да сөйләү рәвеше үзгәрүен бик тиз сизеп алган Илдар сүзне ахырына хәтле үзенчә дәвам иттерергә булды.

—Нәрсәсе яхшы соң аның?—диде ул берни дә аңламаганга салышып.

—Синең бернәрсә дә белеп өлгермәвең белән яхшы, дускай. Димәк, әле соң түгел... Син Патиссонның кем икәнен чамаламадыңмы? Ә...

—Юк!

—Алайсаң белеп тор,—диде Рөстәм кинәт тавышына кырыслык өстәп.—Патиссон әфәнде оборона министрлыгының яшерен бер департаментыннан. Дөрес, электрончы ул. Әмма борыныңа киртләп куй, аңардан ераграк булуың хәерле. Дөнья хәлләрен беләсең, бүген-иртәгә СССР белән сугыш кабынырга тора. Сукыр кешегә дә күренә, барысы да шуңа бара. Бөтен нәрсә кыл өстендә. Кариб кризисы дигән нәрсәне дә ишеткәнсеңдер... Сугыш машинасында бер шөреп буласың килмәсә, кач син ул Патиссоннан да, армия, гаскәр дигән ялган романтикадан да. Аңлашылдымы?..

Кинәт Илдарның күз алдына дусты Джо, бүлекләрендә эшләүче һәм юк-юк та сәясәт турында гәпләшеп алырга яратучы башка егетләр килде. Кара тәнлеме, ак тәнлеме—алар барысы да Американы ватан саный. Колагында аларның сүзләре яңгырый башлады кебек. Үзен инде күптән америкaн дип хис иткән, алардан аерымлыгын тоймаган егет нәкъ алар теле белән сөйли башлаганын сизми дә калды.

—Ил язмышы кыл өстендә чагында чын америкaн егетләре бер читтә посып кала алырмы?—Һәм үзе дә сизмәстән кайчандыр Джодан

ишеткәннәрне тезә башлады.—Патрия—ватан дигән сүз. Патриотизм—ул ватандарлык! Андый хис бездә дә бар. Без бу ил гражданнары, димәк, американнарбыз. Бу ил безгә ирек һәм бәхет биргән икән, аның мәнфәгатьләрен яклау безгә дә кагыла. АКШларында армия иреклеләрдән туплана. Мин бер ирекле була алмыйммыни?!

Һич көтмәгәндә әнисе күз яшьләренә буылды.

—Юк, син американ түгел, син—татар,—диде ул яшьләрен тыя алмыйча.—Син—татар баласы!..

Моңа кадәр сөйләшүгә катнашмыйча тыңлап утырган Әмирҗан ага акрын гына урыныннан торды һәм улы каршына килеп басты. Күзләрендә бер үк вакытта әрнү дә, сагыш та, ниндидер үкенү һәм чарасызлык та тоемлана иде. Илдарга хәтта болай кызуыннан уңайсыз булып китте. Әтисе акрын гына күлмәген салды һәм аркасы белән борылды. Илдарның бөтен тәне куырылып килде. Әтисенең аркасы аркылы-торкылыга бармак юанлыгы тирән җәрәхәтләрдән генә тора иде диярлек.

—Күрәсеңме, бу яраларны? Утлы шомпол эзләре. Совет солдатлары салган канлы җәрәхәтләр алар. Сугыш шундый мәңге онытылмас эзләр калдыра ул. Ә бит мин солдат түгел идем. Кеше жаны кыйганым булмады. Кулыма мылтык тотканым юк. Һәм булмаячак та... Инде син...

Әмирҗан ага сүзен әйтеп бетермәде, бөтен гәүдәсе калтырарга тотынды. Дәһшәтле концлагерьларда, төрмәләрдә жәфа чиккәнен белсә дә, әтисенең мондый яраларын беренче тапкыр күргән Илдар ни әйтергә дә белмичә телсез калды. Ул инде бу сүзләрне ник башлаганына үкенә иде. «Һы, Америка патриоты» диде ул эчтән генә үз-үзен үчекләп.

Әмирҗан ага улына йөз белән борылды һәм калтырануын басарга тырышып сөйли башлады.

—Болар бөтенесе дә мин татар булган өчен генә эшләнде. Мине татар булган өчен җәзаладылар. Менә бу шомпол эзләрен күрәсеңме? Аларны миңа совет солдатлары ясады. Мине совет солдатлары кулга алды. Араларында татар солдатлары да бар иде. Әмма мин аларны гаепләмим, аларга рәнҗемим. Алар алданган, большевиклар пропагандасы белән агуланган, сукыр хәлендәге кешеләр. Хәзер инде син мондагы пропагандага алданырга, акча хакына сатылырга, алар шикелле үк сукыраерга җыенасыңмы? Татар кулы белән татарны изү урыс гадәте иде. Гасырлардан шулай килә. Инде хәзер син шундый уенга катнашмакчысыңмы? Ул якта татар егетләре юк дип беләсеңме? Бәлки әле, якын туганнарың бардыр... Нәсел-нәсәбебез туган илдә корымаган. Син хәзер милләттәшләрең белән сугышка керәсеңме? Синең Америка гаскәренә керүең татарга каршы сугышка керү дигән сүз, улым. Аңла!..

Илдар дәшмәде. Әтисенең җәрәхәтләрен беренче тапкыр күрүдән тетрәнгән егет аның сүзләрендәге хаклыкны аңлый, әмма аны йөрәге аша уздырып өлгермәгән иде әле.

Бөтен гаилә җыелган зур залда авыр тынлык урнаша башлады. Бәхеткә аш бүлмәсе ягыннан апасы Галия килеп чыкты.

—Чәй суына, табын янына чыгыгыз инде,—диде ул бу киеренкелекне тоймаган да сыман.

Аның сузып әйтелгән сүзләре, йомшак тавышы Илдарга коткаручы фәрештәнеке сыман тоелып китте, җиңел сулап куйды. Акчуриннарда табын янында бәхәсләшү, сүз куертып утыру гадәткә кермәгән. Бу тегәл үтәлә торган һәм борынгыдан килүче бер йола иде. Башында каршылыклы уйлар бәргәләнгән Илдар фикерен ачыграк күзаллау өчен вакыт буласына сөенеп тә куйды. Башкалар да шулай уйлый иде, ахрысы, һәрхәлдә, беренче булып кузгалган Оркыя ханымга кунак буларак Рөстәм Агиш, әтисе Әмирҗан иярде, алар артыннан Илдар атлады.

Нью-Йоркның артык байлардан ук саналмаса да уртача хәллерәк катлавы яши торган кварталындагы гап-гади бер йортта, американнар күзаллавынча, гадәти булмаган бәйрәмчә табын әзерләнгән иде. Инглиз кухнясында бөтенләй таныш түгел ризыклардан Оркыя ханым өстәленнән

өзелмәүче кәләвә, гөбәдия, чәк-чәк кебек тәм-томнар янына бүген хуш ис бөркеп утыручы кечкенә өчпочмаклар белән сирәгрәк пешерелә торган кыстыбый да өстәлгән иде. Боларны күргәч, Рөстәм соклануын белдермичә кала алмады:

—Һай, Оркыя ханым, кызларын бигрәкләр дә унган инде,—диде ул ерак туган тиешле сеңлесенә илгәзәкләнеп. Һәм шаярткандай иттереп өстәп тә куйды.—Нәкъ үзең кебек инде. Сезгә килгән саен әллә нишләп ерактагы туган ил искә төшә. Төшләремдә күреп уянганны сездә очратам мин. Сагыну дигәннәре шул буладыр инде...

—Сагынмый кая барасың,—дип җөпләде аны Оркыя ханым.—Кендек каныбыз тамган җир, ата-бабалар менәр ел гомер кичергән изге туфрак бит ул. Сүзләрең күңелемә май булып ятты...

Һәм өстәл яныннан кузгалып стена буендагы серванттан яшел фонга алтын белән сырлап бизәкләнгән затлы чынаяклар алып өстәлгә тезә башлады.

—Менә карагызчы, болар бит туган ил истәлекләре. Әниемнән калган савыт-саба,—диде ул. Йөзенә моңсулык чыкты.—Рәсәйдән Кытайга килдек, аннан соң көч-хәл белән Япониягә килеп егылдык. Аннары Төркия. Хәзер менә Америка. Ничә илләр үтеп, ничә диңгез кичеп шушыларны күз карасыдай саклап алып килдем. Болар безгә туган җирнең бердәнбер истәлеге шул. Сүзләрең белән күңелемә бәйрәм ясадың, Рөстәмкәем, шуңа күрә бәйрәмдә генә тота торган чынаякларымны куйыйм әле.

Һәм аның ни өчен болай эшләвен өлкән ир-атлар гына түгел, Илдар да бик яхшы төшенеп алды. Әнисенең шундый гадәте бар: берәр бик тә мөһим эш эшләнәсе, мөһим сүз сөйләнәсе булса, шул көнне табынга шушы чынаякларны куя. Алардан туган ил җылысы бөркелә, газиз әнкәсенең җылы бармаклары тоткан савыт-саба үзе белән өйдәгеләргә күңел тынычлыгы, иминлек алып килә, дип уйлый ул. Һәм ялгышмый да бугай. Һәрхәлдә, шушы йола үтәлгән мәҗлесләрдән кунаклар да, йорт хуҗалары да күңелләре хушланып, бер-берсеннән разый-канәгать калып таралышалар иде.

Чәй эчү йоласы тәмамланыр алдыннан Рөстәм Агиш тынлыкны бүлде:

—Безне кичерә күрерсез,—диде ул эшләнмәгән гаебе өчен алдан ук гафу үтенгәндәй иттереп.—Без чәйдән соң Илдар белән аерым гына, ирләрчә сөйләшеп алырга булдык әле. Шулай бит, энекәш? Килешәсеңме?..

Илдар ризалыгын белдереп, көлемсерәп баш селкеде. Агасының үтә җитди сөйләшергә теләвен ул да, башкалар да аңлап алган иде инде. Агиш—дипломатия кануннарын үтә сизгер тоемлый, куллана белә торган кеше.

Илдарның бүлмәсенә кергәч тә Рөстәм беренче кат күргәндәй бар нәрсәне: стеналарны, ябыштырылган рәсемнәрне, дөнья әдәбияты классиклары һәм техник китаплар шыплап тутырылган шкафны, төрле детальләр тезелгән киштәләрне һәм, ниһаять, эш өстәлен тагын бер кат күздән кичереп чыкты. Ишек өстендәге аятелкөрсиле шәмаилгә озаклап карап торды. Күргән хәтлесеннән канәгать калды булса кирәк, акрын гына тамак кырып алды һәм, янына Илдарны да чакырып, диванга килеп утырды.

—Йә, Илдар, инде синең белән турыдан-туры, ачыктан-ачык итеп сөйләшсәк тә була,—диде ул.—Үсеп җиттең, белем алдың, кулыңда менә дигән һөнәр бар. Инде беркайда да югалмасыңны беләм. Шулай бит?

Агасының кайсы якка сукаларга чамалавын абайлап өлгермәгән Илдар сабыр гына әйтеп куйды:

—Шулай дип... Мин әле эшемне башларга гына җыенам. Калганын күз күрер, дигәндәй...

Агиш кинәт җитдиләнде, күзләренә кырыслык чыкты.

—Менә монысы белән килешмим, энекәш!—диде ул катгый тавыш белән.—Күз күрер әле, дип нидер башлау «Иртәгәге өчен ишәк кайгырган»

дигән белән бер. Ә без үзебезнең ни теләгәнебезне, нәрсәгә ирешәчәгебезне белеп эшләргә тиеш. Без—татарлар өчен монда башка юл юк. Әтиең сиңа сиздерерлек итеп әйтте. Әйе, безгә бу дөньяда татардан башка дус та, иптәш тә юк. Бер-беребезгә таянмасак, бүген булмаса иртәгә юкка чыгарбыз. Ә юкка чыкмаска кирәк.

—Килешәм, әлбәттә!—дип куйды Илдар.

—Килешсәң, тагын тыңла. Безнең милләт кайда гына юк хәзер. Бөтен җир шарына сибелгән. Ерактагы туган илне әйтеп тә тормыйм. Ал Америкаңы. Нью-Йоркта, Сан-Францискода дистәләрчә татар гаиләсе яши. Австралия, Япония, Төркия, Кытай... Берсендә дә безнең халык төшеп калганнардан түгел. Алар бу дәрәҗәгә, чагыштырмача хәлле, мул тормышка ничек ирешә сон? Барысына да үз хезмәтләре белән, үзара ярдәмләшүләре белән. Безгә яһүдиләр кебек булырга кирәк. Сине дә ярдәмнән ташламаска дидек бит. Без сәясәт кешесе түгел, кайсыдыр илләрнең сугышларында катнашу да безнең эшебез түгел. Чит илләрдә безгә берләшеп, акыл белән эш итәргә кирәк. Башка милләтләрдән, сугыш-тарткалаш белән түгел, бары тик акыл өстенлеге белән генә алдыра алырбыз. Бу безнең, безнең милләтнең тормыш кануны булырга тиеш! Әйе, кайчандыр булган ул сугышлар да, татар дөньяны үз кулында тотып патшаларны, корольләрне дер селкетеп торган чаклар да булган. Хәзер заманы андый түгел. Бездә андый көч-куәт тә юк.

Озак кына сөйләшмичә утырдылар. Ниһаять, агасы әңгәмәне тәмам дип санадымы, урыныннан күтәрелде һәм Илдарга туп-туры карап әйтте:

—Инде килеп, сезне кодаларга килгән әфәнде турында. Зинһар, коткысына бирелмә! Бусын колагыңа киртләп куй. Артыгын сиздермичә генә дустыңа да төшендерергә мөмкин. Ләкин мин әйткәннәр сер булып калсын. Аның тырнагына барып эләксәң, төрле илләр арасында бик еш кабынучан вак-төяк сугышлардан башың чыкмаячак. Сәм аганның дөньяда корал белән хәл итә торган үз мәнфәгатьләре дә бар. Канлы бәрелешләр сиңа да, безгә дә кирәк түгел. Мин сиңа барысын да булдыра алганча аңлатырга тырыштым, Илдар. Ә хәл итү—синең кулда. Ләкин мин сиңа ышанам, акыллы, төпле егет икәненне беләм.

Патиссонга ризалык биргәндә нинди капкынга барып эләгәчәген әле генә төшенеп алган Илдар каты итеп абыйсының кулын кысты.

—Рәхмәт, абый,—диде ул. Тамак төбенә ниндидер төер килеп тыгылгандай булды.—Миңа бер олуг изгелек эшләгән идең, монысы икенчесе. Гомеремдә дә онытмам. Онытмам!

## VI

Профессор сөйләгәннәрне түкми-чәчми язып барырга тырышкан Асия үз янындагы буш урынга кемнеңдер килеп утыруын сизде, әмма күтәрелеп карамады. Факультетта иң зурлардан саналган йөзенче аудитория бу. Филологлар да, тарихчылар да уртак лекцияләрне шушында тыңлыйлар. Гадәттә, белгечлек буенча дәресләр кечерәк аудиторияләрдә уза һәм анда инде һәркемнең үз урыны бар. Бу—язылмаган канун. Ә монда кем утырса да барыбер түгелмени!

Асия ашыга-ашыга дәфтәренә үзе генә белгән тамгалар төшерә-төшерә язды, үзе күнеленнән шуларны уйлап өлгерде. Бу профессорны бик усал диләр. Бар фәнне үз лекцияләре буенча сөйләтә имеш. Аларны белмәсәң, зачет дигәннән колак кагуыңны көт тә тор.

Әмма бер-ике минут үттеме-юкмы, колак төбендә Дамирның карлыккан тавышы ишетелде:

—Асия, бүген минем белән ресторанга барасыңмы? Чакырам. Олы бәйрәм минем бүген... Башка егетләр-кызлар да булачак.

Башы-аягы белән лекциягә йотылган Асия «ә» дә димәде, «җә» дә димәде, язуын белде. Бераздан соң гына ачулы тавыш белән пышылдады:

—Комачаулама әле!

Лекцияне язу турында уйлап та карамаган Дамирга күнелсез иде ахрысы. Күз кыры белән аның дәфтәренә карап алган Асия ак битләрдә кеше башы сурәтләре, ук кадалган йөрәк рәсемнәрен генә абайлап өлгерде. Эчтән генә көлеп тә куйды: лекция-конспект сорап тагын группа кызларының тенкәсенә тиячәк икән бу. Ә мин бирмәячәкмен. Минем тамгаларымны үземнән башка беркем дә аңламый...

Аудиториядә шылт иткән тавыш та юк. Бары тик дәфтәрләргә иелгән башлар өстендә профессорның янгыравык тавышы дулкынлана да каләм кыштырдаганы ишетелә. Шулчак Асия аркасында ниндидер җылы нәрсә тойган кебек булды, сискәнеп китте. Җылы нәрсә кинәт аска таба, билгә таба шуыша башлады. Язуыннан башын күтәреп борылып карауга, Асиянын битенә куе кызыллык йөгерде:

—Ал хәзер үк кулыңны, оятсыз,—дип пышылдады ул.—Нишлисең син?

—Фигураң бигрәк матур синең, Асия. Түзә алмадым, сыйпап карыйсым килеп китте...

Дамирның күзләрендә соклану түгел, мыскыллау елтырый кебек иде. Һәрхәлдә, Асияга шулай тоелды. Ул кискен хәрәкәт белән аның кулын биленнән алып ташлады һәм, бит кызыллыгын күрсәтмәс өчен, дәфтәренә тагын да ныграк иелә төште. Эче тулы ачу, рәнжү, кимсенү иде.

Ләкин бераздан ул чигәсе янында тагын Дамирның кайнар сулышын тойды:

—Йә, барабызмы минем белән. Җавап бирмәдең бит әле. Көтәм... Мин бит чын күңелдән...

—Юк!—диде Асия ачуына буылып.—Бар, читкә күчеп утыр! Син миңа комачаулыйсың.

—Ачуланма инде, Асия! Бүтән комачауламам, тычкан баласы кебек шыпырт кына утырырмын...

Ләкин ул барыбер сүзендә тора алмады, тагын пышылдарга керешге:

—Ни таптың инде син бу карт убырның лекциясеннән? Шул хәтле бирелеп тыңламасаң...

Асия җавап биреп тормады, дәфтәре белән өстәл астындагы кечкенә сумкасын алды да буш урын эзләп аудитория буенча арткы рәтләргә таба китеп барды. Үз лекциясендә гомер бакый булмаган мондый хәлдән профессор бер мәлгә сөйләвеннән туктап торды, гаҗәпләнеп кашларын күтәрде һәм шундый ук тигез, тыныч тавыш белән әйтте:

—Сеңлем, лекциядән соң минем янга килергә онытма!

Җир ярылса, җир тишегенә кереп китәргә әзер иде Асия. Ләкин ул бу очракта аклана да, кемнедер гаепли дә алмый иде шул. Арткы рәттәге буш өстәл янына барып утырды да башы белән дәфтәренә иелде. Бу минутларда залдагы йөз пар күз аны күзәтә кебек тоелды, чарасызлыктан нишләргә белмичә ирен читләрен тешләде.

Бүтән дәресләрдә күренмәгәч, аның турында бөтенләй оныткан да иде инде. Дәресләр тәмамланганда ул бераз тынычлана төшкән, күңеле дә үз урынына утырган иде. Плащын киде һәм авыз эченнән генә соңгы вакытларда аеруча яратып тыңлый башлаган «Зәңгәр төймә» көен көйлекөйли урамга ашыкты. Әмма бер-ике адым да атларга өлгермәде, факультет бинасының шакмакланып күтәрелгән юан колонналары артыннан сискәндереп каршына көтмәгәндә ул килеп чыкты. Калын табанлы туфли, үтә тар балаклы чалбар, ак сәдәфле чем кара күлмәк өстеннән шакмаклы соры пинжәк киеп җибәргән факультет моднигын Асия бер күз сирпүгә үк танып алды. Бердән кәефе бозылды. «Лекциядә комачаулап утырганы, хур иткәне генә җитмәгән», дип уйлап куйды ул. Ләкин борылып китәргә дә соң иде инде.

Ләкин Дамир чын күңелдән борчыла, аны уңайсыз хәлгә куйганына үкенә иде булса кирәк. Ул ашыгып Асия каршысына атлады һәм кабаланып

сөйли башлады:

—Асия, зинһар гафу ит! Мин сине үпкәләтермен, унайсыз хәлгә куярмын дип башыма да китермәгән идем.—Һәм үзенең гаебе юклыгын аңлатырга, акланырга теләгәндәй, өстәп куйды.—Ул карт убырга ни җитмәгән инде? Лекциядә кеше тораташ кебек катып утыра аламыни?! Йә, Асенька, минем чакыруны кабул итәсеңме?

Асияның тагын ачуы чыкты.

—Юк!—диде ул кискен тавыш белән һәм ашыга-ашыга Черек күл ягына таба китеп барды.

* * *

Сирин киткәннән бирле Асияның җан тынычлыгы бетте. Дөнья кинәт кенә ямьсезләнеп, гәрчә кешеләр белән кайнап торса да, бөтен шәһәре тулаем әллә нинди бер күңелсез бушлыкка әйләнеп калгандай булды. Бердәнбер юаныч Сириннән килгән хатлар. Бушлыкны алар тутыра, шушы ямьсез дөньяда да түзәргә, озын-озак өч елны—Сирин кайтасы көнне көтеп алырлык көч һәм дәрман бирә. Асия бөтен буш вакытын китапханәдә уздырырыга тырыша. Анда дөнья ваклыкларыннан, сагыну хисеннән онытылып торырга була. Әйе, аерылуга, сагынуга түзәр дә иде. Әмма Дамирның адым саен юк йомышны бар итеп сүз катуы, кирәксә дә, кирәкмәсә дә каршысына чыгуы, инде тупаслыкка әйләнә башлаган бәйләнчеклеге, лекцияләрдә, дәресләрдә аның янына, һичьюгы янәшәдәнрәк утырырга җай эзләве кызны тәмам алҗыткан, башын алып теләсә кая чыгып китәр дәрәҗәгә житкергән иде. Ярый әле Диләрә бар. Дус кызы барысын да белә, барысын аңлый. Ул коткара. Ул ярдәм итә. Үз хәле хәл чакларда да Асияны ялгыз калдырмаска, аның янәшәсендә булырга тырыша. Көне буе Агылый белән Тагылый шикелле дә йөри алмыйсың бит әле. Җитмәсә, Диләрә янына геофактан Нәкыйп исемле бер егет кереп йөри. Армиядән кайткан, дөнья күргән, сабыр, тыйнак егет. Үзе чибәр, үзе акыллы, дигәндәй. Чем-кара чәчле, куе кара кашлары астыннан зәп-зәңгәр күзләре балкыган бу егет килеп керүгә кызлар бүлмәсенә нур өстәлгәндәй була.

Дөрес, Нәкыйп тә Диләрәнең үзе кебек үк киң күңелле, аралашучан, җор телле. Берничә тапкыр Асияны алар үзләре белән киногa, театрга чакырып караганнар иде. Бер барды, ике барды, әмма мөнәсәбәтләренең ни чамадарак икәнен төшенгәч, Асия мәхәббәт мәҗлесендә артык кашык булырга теләмәде.

Көннәрнең берендә Диләрә тыны кабып кайтып керде. Һәрвакыт пөхтә һәм ыспай йөри торган кызның бит очлары алланган, матур ак башлыгы астыннан бер тотам чәче бөселеп чыккан, пәлтәсен җилбәгәй җибәргән иде. Кергән шәпкә ул юеш пәлтәсен, башлыгын, гомердә булмаганча, ак караватка болгап атты да өстәл янында дәрес хәзерләп утырган Асияны килеп кочаклады, әллә нинди шомлы тавыш белән пышылдады:

—Ишеттеңме?—диде.

—Нәрсәне?

—И җаным!—диде үрсәләнеп Диләрә.—Көн саен без кем хакында борчылып сөйләшәбез соң?

Әллә нинди яман сизенүдән Асияның күз аллары караңгыланып китте, тыны кысылды. Шул ук мизгелдә күз алдында елмаеп торучы Сирин сурәте пәйда булды. «Аңа бер-бер хәл булганмы?» Бу уй тимер кыскыч булып, авырттырып ике чигәсенә кадалды. Үзе дә сизмәстән, теленнән дөньядагы иң газиз, иң кадерле исем, шигырьдән дә матуррак яңгыраучы сүз ычкынды:

—Сирин! Сирин хакында...

Көтмәгәндә Диләрә кычкырып көлеп җибәрде. Башка вакытта

дустының урынсыз кыланышына ачуланыр да иде, әмма аның көлүе хәлен жинеләйтеп жибәрде. Өстеннән тау төштемени! Теләсә-нәрсә булсын, теләсә-кем теләсә-ни эшләсен—бары тик Сирин генә исән булсын, Сирингә генә тимәсеннәр! Бу көлү исә сүзнең Сирин хакында бармавын анлата! Дустының сөйгәне, аның исеме Диләрә өчен дә газиз һәм якын бит. Алар шулай сүз куешкан ахирәтләр ләбаса!

—Уф!—диде Асия жинел сулап һәм дустының кочагыннан чыгып караватка барып ауды.—Котымны ала яздың бит... Нәрсә ишетеп кайттың тагы? Сирингә бер-бер хәл булганмы дип торам...

—Ай, бар белгәнең Сирин инде синең,—дип кинаясез генә төрттерде Диләрә.—Сирингә түгел, сиңа куркыныч яный әле монда.

—Мина? Минамы?—дип кабатлады Асия.—Мина нинди куркыныч яный алсын?

—Сиңа шул, жаным, сиңа. Юкса болай хафаланып йөрмәс тә идем.

—Йә, ярар, кеше шикелле анлатып кына сөйләп бир инде. Ни булган, кемне нишләткәннәр?—диде ул ахирәтенең шаярткан чагында әйтергә яраткан үз сүзләрен кабатлап.

—Әлегә беркемне дә берни дә эшләтмәгәннәр. Ләкин синең өчен... әй лә... безнең өчен бик үк әйбәт хәбәр дә түгел.

—Соң, әйтеп бетер инде...

—Әйтсәм әйтим, Дамир тулай торакка күчеп килгән. Менә шул!

Моны ук көтмәгән Асияның колаклары кызыша башлады. Университетта сөткә төшкән таракан кебек күнелен болгата башлаган бәйләнчек егетнең инде хәзер янәшәдә генә яшәячәге бер дә күнелле яңалык вәгъдә итми иде шул.

—Ул бит... ул бит... Казанныкы,—диде ул тотлыга-тотлыга.—Тулай торакта читтән килгәннәр генә яши. Шулай булырга тиеш...

—Тиешләр күп тә, безгә тиешлесе генә юк,—дип уфтанып куйды Диләрә.—Әллә син дөньяны тиешенчә генә, без теләгәнчә генә бара дип беләсеңме? И, дускаем! Дамир бит шәһәр ышпанасы, йөрмәгән жире, кермәгән тишеге юк. Берәр жаен тапмагандыр дисеңме?!

Икесе дә уйга калдылар. Асияга гына түгел, аның хәлен үз хәледәй яхшы белгән Диләрәгә дә уйланыр урын житәрлек иде шул.

—Бәлки, син берәр фатир табарсың. Беткәнме Казан хәтле Казанда ялгыз карчык... Шулай тынычрак булыр, бәлки,—дип куйды Диләрә бик озак сүзсез утырганнан соң.

Асия кистереп жавап бирде:

—Булмый. Бердән, фатирга акчам юк, икенчедән, сезнең янда, кешеләр арасында мина, бәлки, аның бәйләнүеннән котылу жинелрәк. Бергә-бергә шул Казан стилягасын акылга утырта алмабызмыни?!

Кинәт Диләрә кулларын чәбәкләп көлеп жибәрде:

—Билләһи утыртабыз, болай булгач! Бәлки әле, Нәкыйп тә ярдәм итәр, ә?

Көтмәгәндә әйтелгән, әлегә бернинди нигезе булмаса да, башкарып чыгарлык булып яңгыраган шушы сүзләр икесенә дә айныткыч тәэсир ясады, икесе дә жинел сулап куйдылар һәм тынычланып студентларча чәй табыны әзерләргә керештеләр. Бер карасаң, чыннан да, Асия сүзендә дөреслек бар кебек иде. Мыж килеп торган тулай торакта ул бәйләнчекне, ниһаять, күрмәмешкә салышып та була лабаса!

## VII

Күз ачкысыз бураннары, зәмһәрир суыклары белән кыш та житте, яңа ел якынлашты. Әмма полк командиры вәгъдә иткән мунча, клуб, солдат чәйханәсе, китапханә, башка уңайлыклар гына түгел, хәтта казарма да өлгереп житмәгән иде әле. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр һәм, хәтта, төнлә дә эшләргә мәжбүр ителгән, чиктән

тыш арыган стройбат солдатларын әле бер, әле икенче объектка ыргытып кына тордылар. Инде барлык хәрби техника, җиһазлар, шул исәптән, «изделие» дигән нәрсәләр дә кайтарып тутырылган булса да, полкның кайбер сугышчан биналары һаман әзер түгел икән. Табигый ки, сугышчан дежурлыкка баскан частьта беренчел әһәмият күз карасыдай саклыйсы хәрби техникага юнәлдерелгән иде. Моны барысы да: офицерлар да, солдатлар да яхшы аңлый. Теләсә кайсы минутта ил өстенә ажгырып дошман ракеталары ыргылырга әзер көннәрдә һәркемнең нервысы кыл кебек тартылган, һәркем ватан өчен никадәр мөһим эш башкаруын яхшы тоя, үзен Павка Корчагиннар белән тиңләп, авырлыкларга теш кысып түзә иде. Хәтта моның әле күпләр өчен ниндидер бер романтикасы да бар иде кебек. Күпләр үзләрен Павка Корчагинга тиңли, ил өчен аерата авыр көннәрдә монда булуы белән горурлана. Политзанятиеләрдә бу хакта өзлексез аңлатып, туглап торалар.

Таләпчәнлек, кырыслык иң югары кимәлдә. Әнә бит, полк командиры да, башка офицерлар да әйтеп тора: «Полк сугыш хәлендә. Теләсә кайсы һәм теләсә нинди тәртип бозу сугыш вакыты законнары белән хөкем ителәчәк. Һәр солдаттан, сержанттан, офицердан уяулык, җыйнаклык, уставны һәм кагыйдәләрне катгый үтәү таләп ителә».

Авылдашы Рифгатьне, хәер, аны гына түгел, өченче елларын тутырып дүртенчегә чыккан башка карт солдатларны әле бик озак демобилизацияләми тордылар. Сугышчан шартларда үтә катлаулы хәрби техникага хезмәт күрсәтүне өйрәтелеп бетмәгән яшьләргә генә тапшыру мөмкин түгеллеген алар үзләре дә аңлый иде аңлавын. Ләкин күңел дигән нәрсә бар бит, җан бар. Хәрби хезмәт срогыннан соң узган һәр көн алар өчен тәмуг газапларына тиң иде. Көнен-төнен автоматтан аерылмаган, чишенеп тә тормый автомат кочаклап йоклаган солдатларның хәлен дә аңлавы кыен түгел, әлбәттә. Һәрхәлдә, алар инде моңа күнгәннәр иде. Күнмичә кая барасың?! Сугыш заманы кануннары үтә каты.

Демобилизация, солдат теле белән әйткәндә, дембиль бары тик ел азагында, инде яңа елга санаулы көннәр калганда гына игълан ителде.

Рифгатьнең кайтып китәсен белгәч, Сириннең күзләренә яшь тыгыла язды. Зәй буйларын, тауларны, әрәмәләрне, урманнарны, авылдашларны сагынып сөйләшеп утырыр бердәнбер кеше туган якларга кайтып китсен әле! Их, аның белән бергә барысын да ташлап, барысын онытып кайтып китәсе иде. Дембиль дигән нәрсәдән дә кадерле, якын нәрсә юктыр ахрысы солдат өчен! Күңеле бәргәләнгән, җаны үрсәләнгән егет шулай да авылдашын кисәтергә кирәк дип тапты. Кичке аштан соң буш вакыт иде. Казарма хезмәтен үти торган агач баракның алгы ягына чыктылар да тәмәкечеләргә җайланган беседкага кереп утырдылар. Атна буе төкерегең бозга әйләнеп җиргә төшә торган суыклардан соң һава кинәт кенә җылынып китте, хәтта казарма, штаб кыекларында боз сөңгеләре хасил булып, тамчылар тама башлаган иде инде. Шуның өстенә, иртәдән бирле кояш елмайды. Һавада якындагы тайга урманыннан бөркелүче нарат сагызы исе дулкынлана, ул исә үзе белән туган як, туган җир турындагы хатирәләрне алып килә. Их, чаңгы тагып Балтамак урманнарын айкап кайт идең бер! Ничек моңынчы белмәгән, нинди ләззәтле, хозурәнә чаклар булган икән ул.

—Их, кызыгам мин сиңа,—диде Сирин иптәшенә карап.—Иртәгә инде син поездда булырсың, мондагы матавык, мондагы хәлләр искә алып сөйләргә генә калыр. Их, малай, синең урыныңда булыр өчен мин әллә ниләр бирер идем... Бер генә сәгатькә, һичьюгы бер генә минутка булса да Балтамакка яисә Казанга кайтып килер идем дә... Сагынуларым басылыр иде.

—Әйе шул, искә алырлык, сагынып-саргаеп сөйләрлек булды бу,—диде кинәт Рифгать авыр сулап.—Әллә ниләр бирер идем дигәнеңне бүтән кабатлама, авызыңнан җил алсын! Монда синнән сорап тормыйлар, иң кирәген болай да тартып алалар аның. Сизми дә калырсың.

—Анысы шулай, анысын аңлыйм мин,—дип килеште Сирин.—Шулай да, кайткач безнекеләргә бөтенесен дә сөйләп бетермә, кайда хезмәт иткәнне дә, кем булып йөргәнне дә... Әйбәт, диген, хезмәте яхшы гына бара, диген. Шул җитәр. Юкса, әти белән әнине беләсең, кайгыдан чиргә сабышырлар...

Рифгать Сирингә туп-туры иттереп карап алды, ирен читләренә мыскыллауга охшаш елмаю кунды.

—Әйтмәм... Бик теләсәм дә синең кем булып һәм кайда хезмәт иткәнеңне әйтә алмыйм бит мин. Оныттыңмыни, ун ел буе беркайда һәм беркемгә, берничек тә сөйләмәскә, авыз да ачмаска дип ант эчкәнеңне, шул антны имзаң белән беркеткәнеңне? Ничек диелгән әле анда: «пусть меня постигнет суровая кара советских законов»мы? Әллә, особый отделның кулы Балтамакка ук барып җитмәс, дип беләсеңме? Без инде хәзер синең белән пыяла колпак астындагы тычкан кебек. Уйларыбыз да, кайда ни эшләвебез дә контрольдә. Аңладыңмы, дускай?

—Гафу, онытып җибәргәнмен,—дип ризалашырга ашыкты Сирин.—Ул нәрсә уен-муен гына түгел, күрәсең... Әнә безнең әти әллә кайчан булган сугыштагы кайбер нәрсәләрне әле бүген дә сөйләми. Сөйләмәскә ант итеп кайттым, ди...

—Хафиз абыйга хәзер инде сөйләсә дә ярый,—дип куйды Рифгать кулын селтәп.—Ул сугыштагы нәрсәләрне бүгенге белән чагыштырырлык та түгел.

Ике якташ бик соңга кадәр сөйләшеп утырдылар. Чалт аяз күк йөзендә берәм-берәм йолдызлар кабынды. Часть территориясендә тыгыз карны шыгырдатып анда-монда йөреп торучы автоматлы каравылчылардан гайре беркем дә калмады. Ә дуслар салкын һәм шыксыз казармага керергә ашыкмады. Армия хезмәтендәге соңгы көнне якташы янында үткәрергә теләгән Рифгатьнең дә, аның белән саубуллашыр чак җитүен аңлаган Сириннең дә сөйләшер сүзләре күп иде. Рифгатьнең чемоданы әзер, дембильгә дигән нәрсәләр тутырып куелган, мундир үтүкләнгән, ак яка тегелгән, күн итек карап кырынып дәрәҗәгә җиткереп ялтыратылган иде.

Егетләр буйга бер чама. Сирин авылдашының өч ел буе каравылда йөреп, тайга урманнарын аралап ышкылып, кыршылып беткән шинеленә карап-карап торды да әйтеп куйды:

—Шинелең бигрәк беткән икән, дембильгә моның белән кайтырга ярамас. Әллә минекен алып китәсеңме, димәкче идем. Миңа тагын берәр җае табылыр әле...

—Әйткәнең өчен рәхмәт, Сирин! Биргәннән дә артык булды,—дип елмайды авылдашы.—Әллә син мине бу алама белән кайтыр дип уйлыйсыңмы? Юк, туган, дембильный бушлат өр-яңа минем. Каптерщик белән дуслык шәп бит. Ну, шулай да сөендердең... Чит җирдә авылдашлар туганың кебек була, диләр иде, чыннан да, шулай бит, ә!..

Сириннең инде байтактан бирле телен кычыттырып торган соравы бар иде, шуны бирмичә кала алмады:

—Карале, Рифгать! Авылга кайткач, беренче эшең итеп нишлисең,—диде.

Рифгать аның уйларын аңлагандай җавап бирде:

—Иң беренче эш иттереп мунча ягам. Суын да үзем ташыйм, утынын да... Үзем ягам, үзем әзерлим дә...—Ул хәтта төкереген йотып куйды.—Мәтрүшкәле пиннек белән тән суелып чыкканчы, егылганчы чабынам. Тышка чыгып йомшак карда ауныйм да тагын керәм, тагын чабынам... Их, кайтып кына җитим!..

Кинәт ул нигәдер уфтанып сулап куйды һәм бер ноктага текәлеп бик озак сүзсез утырды.

—Их, туган,—диде ул, ниһаять, башын ике яктан учы белән кысып. Күзләрендә яшь бөртеге күренде.—Кайтасы килә, кайтасы килә авылга... Шул ук вакытта куркам да, шикләнәм дә... Бу чырай белән ничек

кайтып керим? Йә, кара инде миңа! Чәч коела, авызда теш юк. Бер мин генә түгел бит! Төрмәдән йә каторгадан кайта диярсең, билләһи! Нишләттеләр безне? Нишләдек, ни булды безгә?—Һәм кемнедер сүккәндәй ачу белән чертләтеп җиргә төкерде.—Сволочьлар... Нәрсәнедер әйтеп бетерми бит алар. Әйтеп бетерми... Әйтеп бетерми түгел, эшләмиләр...

Сирин исә авылдашын үзенчә тынычландырырга тырышты:

—Соң, ничек әйтеп бетерсеннәр. Үзең беләсең, хәрби сер дигән нәрсә дә бар бит әле.

—Анысын әйтмим мин,—диде Рифгать кул селтәп.—Бик кирәк миңа аларның хәрби серләре! Миңа сәламәтлегем кадерле.

—Аптырама сана. Авылга кайтып бер мунча керсәң, үзебезнең шифалы чишмә суларын эчсәң, әниеннең сөтле чәе, катыгы белән бер айда яңадан туган кебек булырсың. Шулай бит!

Әллә сүзе беткән иде, әллә урынсыз шикләре белән якташ булса да әлегә салагалардан саналган яшь егетнең күңеленә борчу өстисе килмәде, Рифгать янадан бу хакта сүз куертмады.

* * *

Адәм баласының җайлашмый, ияләшми торган нәрсәсе юктыр ахрысы. Инде җылыту торбалары ноябрь ахырында ук шартлаган, фанер щитлардан, такта кисәкләреннән аннан-моннан гына вакытлыча дип әтмәлләнгән салкын баракта яшәргә дә күнегеп беткәннәр иде. Урын җитмәгәнлектән, тимер сиртмәле солдат караватларын өчәр катлы итеп тезделәр дә, бер баракка бөтен полкны дыңгычлап тутырдылар. Караватлар араларында бер кеше көчкә сыярлык арада иртәләрен өчәр солдат мәшәләнә.

Бөтен солдатларның бергә булуының бер өстенлеге дә бар әле. Кемнең кайчан дежурлыкка, каравылга яки ашханәгә нарядка киткәнен алдан белеп торасың, аның матрасын, одеялын «сугып алырга» өлгерәсең. Юкса, бер кат одеял астында, гәрчә бушлат, киез итек киеп, бүрегеңнең колакчынын бәйләп ятсаң да, җылынып бетеп булмый. Өскә салган матрас астында әле син үзеңне, Комаров әйтмешли, байларча хис итәсең. Тимер мичкәләрдән ясалган һәм казарманың ике башында көнен дә, төнен дә дөрләп утыручы ике калай мич утынны убыр урынына ашасалар да, казарманы җылыта алмыйлар. Хәер, ут булып кызган мичкәләргә якын да килерлек түгел. Тик аларның җылысы яннарыннан ике-өч метр китүгә зәмһәрир суыгы белән алмашына.

Сирәк кенә салынган түшәм такталарын ап-ак бәс сарып алды. Алар арасындагы кул тыгарлык ярыклардан йолдыз санарга мөмкин. Иске баракта башкача булуы да мөмкин түгелдер. Инде монысына да күнегеп беттеләр. Тик мунча, кайнар су юклыгы үзәкләрне өзә. Дөрес, атна саен күлмәк-ыштанны алыштырып торалар. Аптыраган егетләр иртән чыгып, утыз градуслы суыкта ах-ух килеп бил тиңентен кар белән ышкынып керә керүен. Үзләренең әлегәчә бетләп бетмәүләренә солдатлар үзләре дә ышанмый башлаган иде инде.

Төньяк көзенең иң шыксыз, быкырдык көннәре иде ул. Бертуктаусыз яңгыр пыскаклый. Күк йөзен тоташы белән кургашындай авыр, чуендай кара болытлар каплап алган. Ул инде беркайчан ачылыр сыман түгел. Иртәләрен хәрби шәһәрчекне тешләргә сылана торган авыр томан йота. Ул үпкәләргә кереп тула, өс киемнәренә юка су элпәсе булып ята.

Кайчандыр асфальт тротуарларда кәттә атлап йөргән шәһәр егетләре дә, яшел чирәм өстеннән яланаяк йөрүнең чын тәмен татыган авыл малайлары да чәкәненә җитәрлек сыек саз ерып йөрүне бернигә дә санамый башлады. Кайчагында бу гомер бакый шулай булгандыр, ул шома асфальтлар, яшел чирәмнәр ниндидер хыялый төштә генә күргән нәрсәләр шикелле тоела башлый. Инде алар беркайчан да кире кайтмас

кебек. Аяклар коры жиргә басып йөрүнең тәмен онытты.

Солдат хезмәте солдат хезмәте инде. Аяк астында сазмы, өстеннән яңгыр коямы дип тормыйлар. Син сафта булырга тиеш. Сафка тезеләсең дә чапыр-чопыр саз ерып ашханәгә, чапыр-чопыр саз ерып иртәнге зарядкага...

Ләкин үзәккә үткәне икенче нәрсә иде. Тәүлек әйләнәсендә юешлектән, саздан тагын да авырая төшкән кирза итек киеп йөрергә мәжбүр солдатларның аяклары бозыла башлады. Чүп өстенә—чүмәлә, дигәндәй, ана гөмбәчек чире килеп өстәлде. Элегрәк сугыш турындагы китаплардан гына укыган «казарма исе, каты ирләр исе» дигән нәрсәнең чын асылын шунда төшенде Сирин. Баксаң, китапка язганча, бер дә романтик нәрсә түгел икән ул! Казармага килеп керүгә борынга тынчу ис килеп бәрелә. Аны идәнгә, почмакларга мул итеп түшәлгән нарат, чыршы ылысы исе дә җинә алмый. Бу тынчулык кеше артык күп җыелган биналардагыча һава җитмәүдән түгел, ә айлар буе мунча күрмәгән унтугызегерме ике яшьлек ир-егетләрнең тән исе, аяк чолгавы исе. Гәрчә күн итекләрен салмыйча йөрсәләр дә, сизгер борын казармада сөрем булып дулкынланган бу исләр арасыннан иң беренче чиратта нәкъ менә шуны—аякчу исен тотып ала иде.

Әгәр алга таба да шулай дәвам итсә, солдатларның йөрер рәте дә калмаячак, мәрхәмәтсез гөмбәчек чире бөтен полкны аяктан егачак иде. Күпләр инде болай да адым ясаган саен сыкранып, авыртудан йөзен чытып йөри. Офицерлар да, санчастьта да моны беләләр, ләкин алар бу мәңге бетмәс юешлеккә каршы көрәштә инде көчсез иде.

Котылу әмәлен карт солдатлар, үзләре әйтмешли, «старик»лар тапты.

«Дәһшәтле корал»ны, аның үтә сизгер детальләрен, ачуым килмәгәе, көненә бер мәртәбә спирт белән юып, чистартып торалар икән. Спиртның исәбе-хисабы юк. Кемнең башына килгәндер, анысы билгесез, әмма аның башлы кеше икәнлеге шиксез. Тимер-томырны иркәләп, сөртеп торырга яраган спирт кеше тәненә ярамыймыни?! Һәм спирт чишмәсенең мул агымы солдат флягаларына күчеп акрын гына казармаларга таба да челтери башлады.

Сирин авылдан әнисе бәйләп җибәргән, инде сөрси башлаган йон оекбашка карап, нишләтергә микән моны, дип аптырап утыра иде. Чыгарып ташласаң кызганыч, ташламасаң бүтән киярлеге калмаган. Атнага бер бирелә торган чолгау белән генә ерак бара алмыйсың. Шунда әллә каян гына Комаров килеп җитте.

—Әйдә, шифа сеансына алып барам,—диде ул күз кысып, җитмәсә, күп мәгънә салып, имән бармагы белән ияк астына чиертеп тә күрсәтте.

Дустының юкка-барга мондый «дипломатик итагать» белән маташмаганын күптән белеп өлгергән Сирин сүзсез генә аның артыннан иярде. Караватлар арасындагы тар аралыктан шуып кына үттеләр дә каптенармусның хәзинәләре саклана торган бүлмә ишеге янына килеп туктадылар. Ильяс, монысы шартлы билге иде булса кирәк, өч тапкыр каты гына итеп тамак кырып куйды. Эчтән дә шундый ук аваз ишетелде. Бары тик шуннан соң гына Ильяс телгә килде:

—Ачыгыз, мин!

Каптеркага керүгә Сирин телсез кала язды. Түшәмгә хәтле сузылган киштәләргә дыңгычлап тутырылган аякчу, гимнастерка, тастымал ише нәрсәләргә, әлбәттә, ис китәрлек түгел. Бүлмәдә тыгыз булып спирт исе дулкынлана иде. Түр башындагы ачыклыкта өч урындыкта яланаякларын нинди дер үтә күренмәле сыекча тутырылган ләгәнгә тыгып өч солдат утыра. Алар торуга Ильяс каптенармусның колагына нәрсәдер пышылдады һәм Сирингә ымлады:

—Әйдә, сал итегеңне, «аяк төзәтәбез». Безгә әле баш төзәтергә иртәрәк...

Һәм үзе үк үрнәк күрсәтеп аягыннан итекләрен тартып алды да янындагы урындыкка утырды, аякларын ләгәнгә тыкты. Авыртуданмы, рәхәтлек-

тәнме, йөзен чытып: «Э-эх!»—дип куйды. Шул ук хәрәкәтләрне кабатлаган Сирин шунда гына ләгәннәрдә саф спирт икәнен аңлады. Баштарак яндыргыч авырту кулының чәнти бармак башларына кадәр барып житте, аннан соң аяктагы авырту чиста, таза тәннең рәхәт сулкылдавы белән алышынды.

Аякларын киенгәч, Ильяс канәгать бер хис белән әйтеп куйды:

—Менә хәзер кимендә өч көн үзеңне мунча кердем дип хис итеп йөрергә була инде. Сәламәт аякта—сәламәт рух!—диләрме әле...

Ниһаять, солдат тормышы җайга салына башлады. Яз житкәндә, апрель башларына вәгъдә ителгән казарма белән ашханә дә өлгереп житте. Беренче тапкыр взвод-взвод итеп, чиратлаштырып, әллә кайдагы жәһәннәм тишегенә урнашкан район шәһәренә—мунчага алып бардылар.

* * *

Солдатның туймый торган ике әйбере бар. Берсе—йокы, икенчесе—ашау.

Башыңны мендәргә терәргә өлгермисең, жир йөзендәге иң кабахәт, иң әшәке сөрән яңгырый.

—Подъем!

Дневальныйның яшь әтәчнекедәй яшелле-мөшелле тавышы казарманың өч катлы сәке-сәндерәләрен урап чыгарга да өлгерми, аны старшинаның чәнечкеле гөлжимеш сабагыдай бөгыреңне тырнап үтә торган, чырае шикелле үк жете кызыл карлыккан, таләпчән тавышы куып житә:

—Подъ-е-е-ем!..

Солдатның бөтен уяу гомере ике команда арасына сыеп бетә:

—Подъем!

—Отбой!

Алар арасында бертуктаусыз яңгырый, солдатны билгесезлеге белән сискәндереп жибәрә торган тагын бер әмер бар. Анысы:

—Тезелергә!

Тик торганда «Батарея, тезелергә!» дигән сөрән беркайчан да солдатка нинди дә булса рәхәтлек, тынычлык вәгъдә итми.

Солдат йоклап ята, хезмәт бара тора. Солдат халкы йокларга дигәндә мең дә бер ысул табарга сәләтле. Биш-алты гына минут буш вакыты булсын, сафта торганда ук ул, хәтта, аягүрә дә йоклый ала. Ә башы мендәр күрсә, син инде аны вакыты житмичә, колак төбендә туптан атсаң да, уята алмыйсың. Ләкин дөньясын онытып йоклаган шул солдатларны да уята торган бер дәһшәтле тылсымга ия сүз бар, ул—тревога!

Бу юлы да шулай булды. Йокының иң тәмле, иң ләззәтле мизгелләренә генә кереп барган казармаларның барысында берьюлы солдат өчен иң хәтәр боерыкларның берсе яңгырады:

—Батарея, тревога!

—Тревога! Тревога!

Өсләренә Америка кораллы көчләренең атом яисә водород бомбалары төягән ракеталары юнәлтелгәнен, бүген булмаса иртәгә, теләсә кайсы минутта өсләренә ракета удары ясалу ихтималын белгән солдатлар, офицерлар өчен моннан да коточкыч сүзнең булуы мөмкин түгел. Сугышчан дежурлыктан чыгып инде бераз ял итү, хәл жыю мөмкинлеге туган полкта—тревога!

Хәер, бу хакта уйлау түгел, беркемнең дә башына килеп тә өлгермәгәндер. Әче тавыш егетләрнең желегенә үтәрлек дәрәжәдә зәһәр иде, таләпчән иде.

Сирин өстеннән одеялны, жәймәне ничек алып атканын да, икенче каттагы караваттан идәнгә ничек сикергәнен дә хәтерләми. Куллары күнегелгән хәрәкәт белән урындыкка бөкләп салынган чалбарына,

гимнастеркасына үрелде, аяклары күн итекләрне барлады. Йомык күз белән дә унбиш-егерме секундта киенергә өйрәтелгән солдатлар теш арасыннан сүгенә-сүгенә күз ачып йомганчы караватлар арасындагы күнегелгән урыннарына чыгып та бастылар. Кемнәрдер гимнастерка төймәләрен каптырды, кемнәрдер юл унаеннан бил каешын буып маташты. Әмма тиешле вакытта батарея әзер иде инде.

Саф алдына батарея буенча дежур офицер чыгып басты. Әле күптән түгел генә погоннарына өченче йолдыз тагып алган, өлкән лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелү шатлыгыннан айный алмаган Майорчукның йокысызлыктан күзләре кызарган, йөзе ачулы иде.

—Барысы да сафтамы?—дип сорады ул старшинага борылып.

Җиде төн уртасында торгызып сорасалар да кайсы солдатның кайда басып торганын биш бармагыдай белгән старшина сафка бер генә күз төшереп алды һәм гөбедән чыккан юан тавышы белән казарманы яңгыратты:

—Комаров! Тагын... син... йоклап... калдыңмы? Комаров!..

«Аш салып бир!» дигән иң гади үтенечне дә сүгенү ләһҗәләре катыштырмыйча әйтә белмәгән старшинаның карлыккан тавышы казарма түшәмнәре астында бәргәләнде.

Шул ук минутта түр башындагы караватлар арасында Ильясның мышкылдаганы ишетелде һәм бераздан көчәнүдәнме, вакытсыз уятуданмы йөзе кып-кызыл булган егет үзе дә күренде, ашыгып сафка килеп басты. Ләкин тревоганың өйрәнчекме әллә сугышчанмы икәнен белмәгән старшина да, Майорчук та бу гадәттән тыш хәлне элеккечә чәйнәп тормадылар. Кызарган күзләрнең усал карашы гына солдатка: «Соңыннан моның әҗерен кайтарырбыз әле!»—дигәнне аңлатырга тиеш иде.

Яңа приказ яңгырады:

—Сугышчан расчетлар—үз урыннарына!

Солдатлар, сержантлар корал бүлмәсенә ташланды. Казарманың бөтен катларын аяк дөпелдәгән авазлар күмеп китте.

Автомат алып маташканда Сирин Ильяс белән янәшә туры килгән иде, дусты өчен борчылып колагына пышылдап өлгерде:

—Ни булды соң сиңа? Хәзер Майорчук тагын бәйләнеп җанына тиячәк инде...

Ильясның йөзе кырысланды.

—Бәйләнеп кенә карасын, без инде юеш борын салага түгел хәзер,—диде ул һәм автомат сумкасын каешына беркетә-беркетә ирен чите белән елмайды.—Йокылы-уяулы килеш чалбар белән гимнастерканы бутаганмын. Үч иткәндәй, кире сала алмыйча җан чыкты... Башта каешын таба алмыйча интеккән идем...

Чалбар урынына гимнастерка, гимнастерка урынына чалбар кигән дустын күз алдына китергән Сирин башка вакыт булса, рәхәтләнеп тәгәри-тәгәри көләр иде, якташ өстеннән шаярткаларга бер сәбәп булыр иде. Әмма тревога ыгы-зыгысында елмаюын яшерергә мәҗбүр булды, вакыты ул түгел. Хушлашып та тормыйча үз расчеты янына йөгерде. Тревога! Барысын да секундлар хәл итә. Ашыгырга, ашыгырга кирәк! Часть өстендә нинди болытлар куерганын хәтта командирлар да белмидер.

Сәяси яктан политзанятиеләрдә чыныктырылган, сугышчан хәзерлектә тиешле муштра узган егетләр бердәм булып, бер саф булып сугышчан бурыч үтисе урыннарына йөгерделәр. Төнге тынлыкны солдат күн итекләре дөпелдәве күмеп китте. Ара-тирә яңгыраган командаларны искә алмаганда, полк тулы тынлыкта үзенең сугышчан бурычын үти башлады.

Тагын берничә минут үтәр, җир асты бункерларының бинһая калын тимер ишекләре тавышсыз гына ачылыр, куәтле тягачлар дөнья империалистларының котын алган дәһшәтле коралны якты дөньяга сөйрәп чыгарыр, алар янында эш сөючән тырыш кырмыскаларны хәтерләтеп, һәркайсы үзенең урынын, үзенең нинди эш башкарырга тиешлеген автоматик дәрәҗәдә белгән, шуңа махсус өйрәтелгән солдатлар, гомерләрен

шушы эшкә багышлаган яшь офицерлар кайнаша башлар. Үзәк пульт янында армия штабыннан киләсе хәлиткеч сүзне—әмерне көтеп полк командирлары катып калыр... Бу ни бу? Чыннан да, сугышчан тревогамы әллә полкның әзерлеген сынап карау өчен үткәрелә торган чираттагы өйрәнүме? Ул хәтлесен әлегә частьта гына түгел, хәтта дивизия штабында да белмиләр иде. Ракета гаскәрләрендә төнге тревога гадәттән тыш хәл ул! Монысын исә рядовой белән ефрейтордан алып генералга кадәр барысы да бик яхшы төшенә.

* * *

Инде ничә тапкыр күрсә дә, Сирин бу мәһабәтлеккә, дәһшәтле матурлыкка тагын бер кат сокланмыйча кала алмады. Һәр линиясе, һәр сызыгы, корыч тәнендәге һәр бөгелеше иң югары камилләгә зарурияткә буйсындырылган ракета хәтта кайчагында җанлы булып тоела башлый иде. Бу, чыннан да, камиллек, матурлык өлгесе. Ләкин бу матурлык—ерткыч матурлыгы.

Кайчандыр кеше аягы басмаган урман куелыгындагы йөзьяшәр нарат, карагай кебек агачлардан да биегрәк булып күккә омтылган ракетаның тупыйк башы прожектор нурларында җемелди. Ул, борыны белән болытларны тишеп, теләсә кайсы секундта күккә ыргылырга әзер. Аның бер селтәнүдә җир шарын урап чыга алырдай тизлеккә ия булуын, Нью-Йорк яисә Вашингтон кебек шәһәрне күз ачып йомганчы утлы тузанга, миллионнарча кешеләрне, җан ияләрен парга әйләндерергә сәләтле икәнен күз алдына китерүгә, Сириннең тәнендә бала йоннары кабарды, тәне чымырдап куйды. «Йа, Ходаем, моны кулланырга гына язмасын иде, язмасын иде»,—дип эчтән генә кабатлады ул. Ирексездән күнелендә әбисе өйрәткән дога сүзләре янара башлады. Кеше акылы белән, кеше куллары белән ясалган коралда шул кадәр җимерү, тар-мар итү куәте, үлем дәһшәте туплансын әле! Җир йөзендә моннан да кабахәтрәк, моннан да зуррак гөнаһ юктыр!

Коточкыч вәхшәт, үлем йөге төягән мондагы ракета кайсыдыр илнең кайсыдыр бер шәһәренә төбәп куелган кебек, кайсыдыр илнең кайсыдыр бер калын урманында, йә булмаса, джунгли ешлыкларында нәкъ менә шушындый ук йөк төягән икенче бер ракетаның Сириннәр хезмәт итә торган частька, моннан сиксән-туксан чакрымнардагы борынгы өяз шәһәренә төбәп куелуы да ихтимал ич. Постта нинди генә уйлар килми икән солдат башына!

Сирин жилкәсенә аскан автоматын рәтләп куйды һәм шинель якасын күтәреп аркадашы—Оренбург егете Потапов артыннан ашыкты. Ул урман манзарасына карап хозурланган, автоматын караштырган, жылыну өчен бераз сикергәләгән арада иптәше инде егерме-утыз адым алгарак китеп өлгергән иде. Куып житте дә, үзалдына мыгырдагандай, шаяртып әйтеп куйды:

—Нәрсә, якташ, әллә парлы патрульнең аерым-аерым йөрергә тиеш түгеллеген онытып жибәрдекме?

Пошмас жанлы, бераз ваемсызрак егет әллә аягүрә йоклый иде, тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты:

—Ә,—дип кул селтәде ул.—Пусть не волнуются. Монда кеше түгел тычкан да үтеп керә алмый. Безне рәвешен китерү өчен генә йөртәләр бугай ла...

Ул хаклы иде шул. Бу турыда каравылга чыккан вакытларда аз сөйләшенмәгән. Әнә бит, еллар буе тоткынлыкта яткандай яшәүдән гарык булган кайбер солдатлар частьтан чыгу жаен да эзләп карадылар инде һәм аның өчен... гомерләре белән түләделәр. Кайдадыр урман эчендә нindидер ярымташландык авыл барлыгын белгән, һичьюгы шунда барып кайту ниятеннән «самоволка»га ыргылучылар, ягъни командирлар

рөхсәтеннән башка частьтан качып чыгарга маташучылардан җәй саен бер-ике кеше һәлак була.

Ракета җибәрү җайланмасы урнаштырылган мәйдан һәр ягыннан чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган, чыбыкларга югары көчәнешле электр тогы җибәрелгән. Монысы да частьтагы һәр солдатка мәгълүм. Дошман ниятле берәр кемсә күзгә күренмәс тимер челтәр тотылган полосаны исән-имин үтсә дә, аның полигонга кадәр җитүе шикле. Чәнечкеле тимер чыбыкларга хәтле булган арада, кеше йөрердәй сукмакларда көтелмәгән кунакка мәкерле кучтәнәч бар—анысы мина кыры.

—Шулай шул,—дип куйды Сирин килешкәндәй иттереп һәм егетләр акрын гына урман сукмагы буйлап атладылар.

Потапов белән сүз көрәштерүнең мәгънәсе юк. Ул барыбер үз фикерендә калачак. Һәрхәлдә, аның ни уйлаганы беркайчан да билгеле түгел. Авызына су капкандай үз алдына текәлә дә борып җибәрелгән агач курчак кебек бер көйгә атлый да атлый ул. Кем белә? Бәлки, аның да башында мең төрле уе, мең борчуы бардыр... Алар белән уртаклашырга яратмый икән, аны гаеп итеп буламыни?! Егерме минуттан алар маршрутның уң канатында икенче парлы патруль белән очрашырга һәм кире борылырга тиешләр, тагын егерме минуттан сул канатта аларны бүтән бер патруль, ягъни тагын ике солдат каршы алачак. Патрульдә йөрүнең үз кызыгы бар әле хәтта. Сүзгә, фикер алышырга артык һәвәс булмаган Потапов белән пардашлыкның өстенлеге исә шунда—аның янында рәхәтләнеп үз уйларыңа бирелә, теләгәнчә хыяллана аласың. Беркем дә, бернәрсә дә комачауламый. Сирин тагын уйларына бирелде.

Кайдадыр еракта, урман эчендә артиллерия полкы урнашкан, тупчылар көнен дә, төнен дә гаскәри осталыкка өйрәнү белән мәшгуль дип күз алдына китергән ярымташландык авыл халкы ни уйлый икән бу минутларда? Өсләрендә шундый дәһшәт бар икәнен тоемлыйлар микән анда? Шүрәле каргаган бу авыл нишләп адәм аягы басмаган ерак чытырманлыкка кереп поскан? Әллә кайчандыр берәр төрле җәзадан, афәттән качып киткән кешеләрме алар? Әллә кайчандыр олы юлларда кеше җаны кыйган юлбасарлар токымыннанмы? Юкка гына кара урманнарда яшәп ятмыйлардыр әле...

Башында кайнаган бу уйлардан Сирин хәтта сәерсенеп китте. «Минем бу авылда ни эшем бар соң әле? Кем әйтмешли, башка кайгым юкмы?» Һәм ул, кирәксез уй-фикерләрен коеп төшерергә теләгәндәй, баскан урынында сикергәләп алды. Шул ук мизгелдә күз алдына туган авылы Балтамак килде, хыялы белән Казан урамнарын инләде. Менә алар Асия белән елга порты причаллары янында йөриләр, имеш.

...Иделдән талгын җил исә. Су өстендә аккошлар кебек мәһабәт пароходлар чайкала. Менә аларның берсе дебаркадер яныннан кузгалып китте. Озатучыларның күзеннән яшь чыгарып елга киңлекләрендә мәшһүр «Славянка» аһәңнәре яңгырады. Их, ул Казандагы көннәр бәхетнең үзе булган икән! Кайтсам кадерен белер идем...

Кайдадыр еракта ябалак уфылдап куйды. Күк гөмбәзен кисеп койрыклы йолдыз атылды. Сискәнеп киткән Сирин яңадан җиргә әйләнеп кайткан кебек булды. Кай арада җил чыгып өлгергән соң әле, әнә, агач ябалдашлары салмак кына тирбәлешә башлаган. Колагына аларның тонык шавы килеп керде. Аркадашы Потапов исә һаман бер көйгә атлый да атлый икән. Икенче патруль белән очрашу урынына—рубероид түбәле агач гөмбәчек янына җиткәннәрен сизми дә калдылар. Бераздан төн караңгылыгын ертып очрашырга тиешле егетләр килеп чыкты. Болар белорус егете Геращенко белән Оренбург татары Гыйләҗев иде.

—Барысы да тәртиптәме?

—Тәртиптә!

Егетләр кире борылыр алдыннан бер генә минутка хәл алырга туктадылар.

—Тегендә безнекеләр нишли икән инде?—диде Гыйләжев һәм башы белән урман өстеннән ялтырап күренүче ракетага таба ымлап куйды.

—Алла белсен!—дип җавап кайтарды Сирин.—Анысы инде безгә караңгы.

Тагын бераз сүзсез тордылар. Кинәт Геращенко болай да озын муенын сузды һәм борын яфракларын киереп иснәнергә тотынды.

—Сез берәр төрле ис сизмисезме?—диде ул шомлы тавыш белән.—Каяндыр нәрсәдер янган ис килә, димме? Янган пластмасса исенә охшаган димме? Әйтә алмыйм, ниндидер сәер ис тоям бугай... Таныш түгел ис...

Башка егетләр дә борыннарын төрле якка сузып иснәнгәндәй иттеләр. Ләкин ул-бу сизелми иде кебек.

Тынлыкны Потапов бозды:

—Юк ла, сиңа шулай тоелгандыр гына,—диде ул үзенең иссез-төссез битараф тавышы белән.—Монда черегән агач, сазлык исеннән башка берни дә сизелми.

Геращенко аптырагандай иңнәрен җыерып куйды.

—Ай-һай, белмим, белмим... Минем борын, югыйсә, ау этенеке кебек. Авылга кайтканда мин өч чакрымнан әнинең нинди аш пешергәнен сизеп кайта торган идем...

Егетләр көлешеп куйды.

—Борының этнеке төсле булганга каравылда йөрисең дә инде менә,—дип төрттерде Гыйләжев.

Геращенко, солдатлар аның фамилиясен кыскартып, Гера, дип йөри, үпкәли торган затлардан түгел иде, бакчасына ыргытылган ташны күрмәмешкә салышты. Тагын борынын сузып иснәнеп алды һәм сабыр гына әйтеп куйды:

—Җил алышына. Сизәсезме?

Чыннан да, моңа кадәр полигонга таба акрын гына искән җил уйнаклый башлаган, юнәлешен капма-каршы якка үзгәртеп, үзе белән ерактан команда биргән, металлга металл бәрелеп ышкылган, кыршылган тавышларны да алып килә башлаган иде.

Кинәт саргылт болыт булып томан җәелә башлады. Ул полигон ягыннан агыла һәм акрын гына агачларны, куакларны чорный, тезгә җиткән үләннәр арасына шуышып керә. Геращенконың тавышына тантаналы, менә әйткән идем бит, дигәндәй төсмер чыкты. Ләкин егетләр сизмәде түгел, сизде, аның тавышында ниндидер шом, әйтеп бетермәгән шөбһәле төсмер бар иде:

—Инде хәзер сизәсезме? Ят ис томан белән килә бит! Көчәя бара бит...

Патруль солдатлар шунда гына борыннарына, чыннан да, ниндидер ят, моңа кадәр таныш булмаган ис килеп бәрелүен абайлап алдылар.

Бу юлы да Потапов телгә килде.

—Төтен шашкасы салдылар,—диде ул белдеклелеген күрсәтергә теләп. Арада иң карт солдат буларак, аның моңа хакы бар дип исәпли иде булса кирәк.—Өйрәнү тревогасы вакытында шулай була ул!

Кинәт Геращенко ашыгып противогаз сумкасын актара башлады.

—Шашка исен... беләм мин, ул... ул мондый булмый. Аның исе бүтән,—дип кабатлады ул тотлыга-тотлыга.—Теләсәгез нишләгез, мин противогаз киям...

Геращенконың сүзләреннән кинәт солдатларның чәчләре үрә торды, шул ук секундта тәннәре салкын тир белән капланды. Ничек онытып җибәргәннәр?! Ракетаны җибәрергә әзерләгәндә, өйрәнү вакытларында «окислитель» дигән зәһәр нәрсәнең түгелү ихтималы, аның «зарин», «заман»нарга* тиң агу икәнлеге хакында бер генә тапкыр сөйләмәделәр ләбаса! Барысы да калтырана-калтырана противогаз сумкасына тыгылды. Тизрәк! Тизрәк! Агулы парлар үпкә элпәсен яндырып өлгергәнче тизрәк! Тизрәк! Үлем куркынычы янаганда да постны ташларга ярамаган егетләр сүзсез иде. Алар мәңге гафу ителмәслек коточкыч ялгыш ясаганнарын

соң, артык соң анладылар түгелме? Һәммәсенең миен кызган тимер булып шушы сорау яндыра башлаган иде инде.

Әмма, ни генә булмасын, бер урында озак торырга ярамый. Хәзер полигонда һәм аның тирәсендә көтелмәгән әллә нинди хәлләр чыгарга мөмкин. Кем белә, бәлки, дошман диверсантлары берәр нәрсә кылгандыр. Бер мизгел эчендә картаеп калгандай бөкрәйгән дүрт фигура акрын гына атлап янадан урман карангылыгына кереп югалды.

## VIII

Комаров суга төшкән кебек юкка чыкты. Икенче көнне патруль каравылыннан кайткач, Сирин иң беренче итеп дустын эзләгән иде. Әмма очрашкан саен кояштай балкып күрешүче якташы казармада да күренмәде, ул хәтта төшке һәм кичке ашта да юк иде. Командирлар кая да булса җибәргәндер яисә үз йомышы белән йөри торгандыр, дип үз-үзен тынычландырган Сирин, икенче көнне дә аны очратмагач, бөтенләй пошаманга төште. Бер казармада яшәсәләр дә, икесе ике төрле хәрби бурыч үтәүче группаларда исәпләнгәнлектән, аларга еш кына шулай аерылгалап торырга туры килә иде. Ләкин Ильясның ана бернәрсә белгертмичә юкка чыгуы сәер иде. Болай булганы юк иде. Түзмәде, Ильяс группасындагы таныш егетләрнең берсеннән сорыйсы итте.

Өченче елын хезмәт итүче солдат Сирингә өстән генә карап җавап бирмәкче иде, ләкин егетләрнең якташлар, шуның өстенә, күпләрне көнләштерерлек дуслар икәнен исенә төшердеме, ни әйтергә белмичә беравык уйланып торды.

—Сволочьлар!—диде ул кемнедер сүккәндәй һәм ачу белән йодрыгын кысып, чертләтеп җиргә төкерде.—Башка вакыт булса әллә ниләр сөйләп, тикшеренеп желегенне суырырлар иде. Ә монда ләм-мим. Әйтерсең, берни дә булмаган, барысы да—ал да гөл...

Аның турыдан гына берни дә әйтмәгәненә түземсезләнә башлаган Сирин сорауны икенче яклатып куярга мәҗбүр булды:

—Мин бит ул хакта сорамыйм. Комаровның кайда икәнен генә белергә телим.

—Соң мин дә шуны сөйләп торам лабаса!—диде егет Сирингә беренче кат күргәндәй карап.—Нәрсә булганын белмисеңмени?

—Каян белим, мин бит төне буе патрульдә идем... Ниндидер сасы ис чыкты инде анысы. Противогаз киеп йөрергә туры килде.

—Алайсаң, әйтмәсәләр дә белергә тиешсең инде,—дип куйды егет һәм тагын чертләтеп җиргә төкерде.—Кыскасы, нәрсәдер булды ул көнне... Ягулык системасында ниндидер житешсезлек димме, ватылу димме... Комаров, кирәк бит ә, шайтан алгыры, нәкъ шунда, авария булган урында иде. Безгә дә төгәл генә әйтмәделәр әйтүен, ләкин... Аны шул ук көнне госпитальгә алып киттеләр бит...

Сирин гажәпләнүеннән сызгырып җибәрә язды. Күңелен үтә дә яман, авыр һәм шикле сизенү чолгап алды.

—Димәк, ул госпитальдә? Нәрсә булды соң аңа?

—Анысын инде ул кайткач белербез,—диде егет авыр сулап.—Бер ул гына да түгел бит. Тагын берничә егет бар анда... Өченче ел хезмәт итәләр иде. Минем якташлар. Тиздән өйгә кайтасы идек бит!..

Юкка гына хәрби өйрәнүдән туп-туры госпитальгә алып китмиләр. Бу кадәресен Сирин генә түгел, армия хезмәтендәге теләсә кайсы солдат инде күптән бик яхшы белә. Рифгать сөйләгәннәрдән дә, башка солдатларның әйткәләп куюларыннан да «ягулык» белән эш итүчеләрнең

---

*Зарин, заман—сугыш вакытында дошманның җанлы көчен күпләп юк итү өчен кулланыла торган агулы газлар, химик корал.

хәтәр җирдә икәне мәгълүм иде. Әмма бу хәвеф, бу хәтәрлек нәкъ менә дустына, Ильяска кагылыр дип аның башына да килеп караганы юк иде. «Хәер, кем белә, бәлки, тикшерү өчен генә алып киткәннәрдер. Барысы да яхшы булыр», дип үзен тынычландырырга теләсә дә, күңеленә кереп оялаган авыр шиктән арына алмады.

* * *

Шул китүдән Комаров һәм аның белән киткән егетләр бары тик бер айдан гына әйләнеп кайттылар. Часть командирлары моннан ниндидер вакыйга ясарга теләмәсәләр дә, полктагы һәр солдат диярлек шул ук көнне үк аларның комиссовать ителәчәкләре, монда бары тик документларын рәсмиләштереп бетерер өчен генә кайтарылганлыкларын белә иде инде. Армиядән юкка гына, тиктомалдан кайтарып җибәрмиләр. Комиссовать итү дигән нәрсә—ул синең хәрби хезмәткә яраксызлыгыңны рәсми рәвештә тану, дигән сүз. Моның өчен үтә җитди сәбәпләр кирәк. Ә аларны хәрби врачлар бик сирәк очракта гына таба.

Ильясны казарма янындагы беседкада, тәмәке тарту урынында очраткач, Сирин хәтта башта гаҗәпләнеп куйды. Дусты хәтта бераз тазарып, яктырып киткән кебек иде. Әле берни белмәгән Сирин аны кочаклап ук алды.

—Уф, ниһаять, кайтыр көннәрең дә бар икән! Чистый сагындырдың,—диде ул якташының аркасыннан кага-кага, шатлыгы, сөенече йөзенә бәреп чыкты.

Ләкин... шул мизгелдә Ильясның күз карашы белән очрашты һәм имәнеп китте. Әле кайчан гына шаянлык, хушкүңеллелек, тормыш дәрте бәреп торган чаткылы кара күзләрдә әйтеп аңлатып булмый торган моң, тирән хәсрәт, газап яшеренгән кебек иде. Сирин кинәт артка чигенде һәм янадан дустына текәлде. Дустын күрүдән туган шатлык, сөенеч аптырау белән алышынды:

—Нәрсә булды сиңа? Әллә очрашуга шатланмадың да инде...

—Шатландым, дустым, ничек шатланмыйм,—диде Ильяс Сириннең кулын кысып.—Ичмасам, кайтыр алдыннан сине күрәм менә. Күрә дә алмыйча калам, дип курыккан идем.—Ләкин тавышында битарафлыкка охшаш төсмер бар иде.

Сөенеченнән көлеп җибәрергә әзер Сирин аны аңлый алмады, дустын иңнәреннән тотып каршына бастырып куйды.

—Йә, әйт инде, нигә болай сөмсерең коелып кайттың әле. Бер-бер хәл булдымы? Монда, частьта әллә ниләр сөйлиләр иде. Менә кайткансың, тазаргансың. Бераз ял иткәнсеңдер, ичмасам!

—Их, дускаем!—диде Ильяс кинәт Сириннең җилкәсенә кулын салып. Күзләрендә яшь бөртекләре ялтырады.—Кайтсам ни дә, кайтмасам ни. Комиссовать итәләр бит мине.—Һәм кинәт гимнастеркасының утыртма якасын ачып муенына төртеп күрсәтте.—Теге көнне авария булды бит. Окислительнең нәрсә икәнен беләсең. Шул чәчрәде... Бетә, төзәлә торган яра түгел икән ул. Тәнне ашап, сөягенә үткәнче газаплаячак икән. Күп булса, бер-ике ел гомерем калгандыр. Әйтмиләр аны. Ә мин беләм... Врачларның карашыннан, медсестраларның, госпитальдә эшләүчеләрнең мөнәсәбәтеннән сизәм мин аны.

Чыннан да, Ильясның муенында чәнчә бармак чамасы гына кызарып торган ике-өч җәрәхәт шәйләнә иде.

—Менә, күрәсеңме,—дип дәвам итте ул.—Башта әле ике тапкырга диярлек кечкенәрәк иде. Нишләтеп кенә карамадылар, нинди генә уколлар ясамадылар... Ярага сыламаган майлары, ашатмаган дарулары калмады. Яра үсә дә үсә... Вот шул, дускай! Ә син тазаргансың дисең. Менә шундый тазару инде ул...—Һәм кинәт авыр итеп уфтанып куйды.—Син Казанга кайтканда мин булмам инде...

Сирин ишеткәннәренә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Яраның бу кадәр хәтәр нәрсә икәнен ул күз алдына да китерә алмаган иде. Ильясны тынычландырырлык сүз таба алмады. Хәер, бәлки, аның үзеннән күп белгән егетне тынычландырырга, юатырга маташу урынсыз да булгандыр. Ике рәнжетелгән бала сыман ике якташ, ике дус беседкада сүзсез генә утыра бирделәр.

* * *

Тирә-якта бал кортлары, шөпшәләр, төклетуралар выжылдаша. Урман өстендә җәйге кояшның яндыргыч нурлары уйный. Ябалдашлары белән күкне тоташтан каплаган агачлар арасында исә күләгә, рәхәт, аз гына искәләп алган җил бөркүлекне, эсселекне тагын да киметә төшә. Нарат сагызы исенә каен җиләгенең баш әйләндергеч хуш исе өстәлә дә башларны әйләндерә. И Ходаем, нинди матурлык, хозурлык! Нәкъ Балтамактагы кебек.

Буш вакытларында дустын бер генә минутка да күнелсез, бимазалы уйлары белән ялгыз гына калдырырга теләмәгән Сирин Ильясны урманга, полигон артындагы җиләклеккә алып чыккан иде. Солдатның да ял көне бар! Пилотка тутырып бармак башы кадәрле, кызарып пешкән җиләк җыйдылар да кечкенә генә яланлыктагы чирәмгә сузылып яттылар.

—Их!—диде Ильяс күккә карап.—Мондый матурлык безнең якларда, Идел буйларында гына була, дип белә идем. Монда да табигатьнең үз матурлыгы бар икән! Кара инде бу болытларга, алар шулай Казанга да барып житә торгандыр инде. Шуларга гына утыр иден дә яңгыр белән бергә ишегалдына кайтып төш икән!..—Һәм кинәт Сиринне гаҗәпләндереп көтелмәгән сорау бирде.—Карале, дускай! Бу хакта сөйләшкәнебез дә юк иде бугай... Яшерми генә әйт әле, синең кызлар белән булганың бармы?

Сирин аның бу сорауны нинди мәгънәдә биргәнлеген бик яхшы төшенсә дә, анламамышка салышты һәм гадәти бер нәрсә турында сөйләгәндәй әйтеп куйды:

—Бар! Әлбәттә, бар...

—Яратып йөргән кызың бар икәнен беләм мин. Анысы турында күп сөйләштек инде,—диде уйчан гына Ильяс.—Мин синнән икенче мәгънәдә сорыйм. Гомумән, хатын-кыз белән якын мөнәсәбәттә булганың бармы?

Сирингә дөресен әйтүдән башка чара юк иде. Никадәр булдыклы, күпне кичергән, ут-сулар кичкән егет булып күренергә тырышмасын, дөресен әйтте:

—Безнең якларда аулак өйләрдә кызлар белән куну гадәте бар. Минем дә кунганым бар. Ләкин син әйткән мәгънәдә—юк! Анысын бездә өйләнмичә... эшләмиләр. Ә Асия ул башка...

Ильяс мәмрәп пешкән бер уч җиләкне авызына ыргытты һәм үкенгәндәй әйтеп куйды:

—Минем дә юк,—диде.—Синең әле бөтенесе алда... Ә минем инде—бетте! Күпме гомерем калганны да белмим бит. Мондый хәлдә, ә йөргән кызым бар минем, аның янына барырга... Ай-һай... Аның язмышын бозасым килми. Бозасым килми, Сирин! Әйт, нишлим? Хатын-кыз тәмен татып та карамаган килеш якты дөньядан китимме? Егет кеше бит мин!.. Җир йөзендә нәселем дә калмасмы!? Әтинең бердәнбер малае бит мин!

Аның тавышында кинәт үксүгә охшаш иңрәү чагылып китте. Мондый да әрнеткеч, үкенечле тавышны аннан ишеткәне юк иде әле Сириннең. Дустының ни әйтергә теләгәнен бик яхшы, үтә дә яхшы аңлады ул. Аңламаслык түгел. Тик аны нәрсә белән, ничек кенә тынычландыра аласың? Шулай да җавапсыз калуны яхшысынмады. Тавышына көрлек, үз-үзенә ышану төсмере салып әйтергә тырышты:

—Син алай бәргәләнмә әле, Ильяс. Кем белә, Казан бит ул мондагы

карангы бер госпиталь түгел. Андагы медик галимнәрне бөтен дөнья белә. Бәлки, берәр чарасын табарлар. Болай була алмый бит инде. Булырга тиеш түгел!..

—Тиеш түгел дә бит... Тиеш түгел нәрсәләр бик күп ул. Тик алар һаман була тора, була тора...

Дустын ничек тә тынычландырырга омтылган Сирин кинәт Лермонтовның кайчандыр үзе бик яратып укыган, хәтта ятлап та алган шигырен искә төшерде.

—Тыңла әле, бер шигырь укыйм мин сиңа,—диде.

И скучно и грустно, и некому руку подать
В минуту душевной невзгоды...
Желанья!.. что пользы напрасно и вечно желать?
А годы проходят—все лучшие годы!
Любить... но кого же?.. на время—не стоит труда,
А вечно любить невозможно...
В себя ли заглянешь?—там прошлого нет и следа:
И радость, и муки, и все так ничтожно...
Что страсти?—ведь рано иль поздно их сладкий недуг
Исчезнет при слове рассудка;
И жизнь, как посмотришь с холодным вниманием вокруг—
Такая пустая и глупая шутка...

Аны бирелеп тыңлаган Ильяс нидер әйтергә дә өлгермәде, полигон ягында, аткан тавышлар яңгырады. Берьюлы берничә автомат телгә килде.

—Нәрсә бар икән анда?—диде Сирин һәм терсәкләренә таянып урыныннан күтәрелә башлады. Көтмәгәндә Ильяс мәче житезлеге белән аның өстенә ташланды һәм торып басарга җыенган дустын көч белән тартып җиргә яткырды, колак төбендә ачулы тавышы яңгырады:

—Башыңны күтәрмә! Сузылып ят! Үләсең киләмени?!.

Шул ук мизгелдә аларга полигоннны каплап торучы карлыган куагыннан Сириннең алдына пуля кискән зур гына бер ботак килеп тә төште, аның тулып пешкән җимешләре, кара кучкыл яшел яфраклары егетнең күз алдында әле бик озак дерелдәп торды. Баш очыннан сызгырып пулялар оча башлады. Алар бәйләнчек шөпшәләр шикелле бер-берсе белән куышкандай выжылдап очалар да егетләрдән күп дигәндә утыз-кырык метр чамасы ераклыкта аз гына беленеп торган калкулыкка барып кадалалар. Тирә-якка ком, балчык, вак чуерташ, җәрәхәтләнеп өзгәләнгән үлән тамырлары оча.

—Ату тиры артына барып кергәнбез ич,—дип кычкырды Ильяс.—Әйтәм, җиләккә кеше кулы тимәгән.—Якшәмбе көнне күрше батареяда төз ату ярышлары үткәреләсен белә идек бит югыйсә... Менә сиңа тормышның мәгънәсезлеге!..

Сирин үзләренең нинди зур хата ясаганнарын, кичермәслек ваемсызлык күрсәткәннәрен шунда гына аңлап алды да. Бер взвод солдат тулысынча атып бетерсен өчен, гадәттә, бер сәгатькә якын вакыт кирәк. Аннан соң әле тагын әллә ничә взвод бар! Юлын ялгышкан, саташкан, адашкан пуля беткәнмени?! Ул-бу килеп чыкканчы ничек тә тизрәк моннан ычкынырга, баш очында зәһәрләнеп чинаучы пуля ташкыныннан котылырга кирәк иде.

—Нишлибез?—диде ул Ильяска һәм тир ягына таба ымлап күрсәтте.

Ильяс югалып кала торган егетләрдән түгел, учына җыеп өлгергән җиләген авызына ыргытты да кулы белән йөзгәндәй хәрәкәтләр ясап күрстәтте. Монысы «Шуышып чыгабыз», дигәнне аңлатырга тиеш иде, күрәсең.

Һәм егетләр терсәкләре белән җиргә таянып, аяклары белән гәүдәләрен алга таба этә-этә башларын җиргә сыендырып акрын гына куркынычсыз тоелган якка шуышып киттеләр.

* * *

Ильясны һәм анын белән бергә авариягә эләккән егетләрне әле тагын берничә мәртәбә дивизия штабы урнашкан элеккеге өяз шәһәрчегенә, госпитальгә алып барып кайттылар. Хәрби бюрократия нәрсәнедер әзерләп бетермәгәнме, әллә врачлар аларның хәле яхшыруга өметләнә идеме, билгесез. Әмма егетләргә дивизия штабы коридорларын да, госпиталь бүлмәләрен дә байтак таптарга туры килде. Тик кайткан саен аларның чырае карангырак, карашлары өметсезрәк була бара иде. Ниһаять, барысын да хәл итеп бетерделәр булса кирәк, сугышчан полк өстенә «кара тап» булып яткан солдатларны күзгә таба бернинди тантанасыз, речьләрсез генә, кеше-кара күзенә күрсәтмичә, дежурный машинага төяп, күршедәге шәһәрчеккә озаттылар. Ә аннары—Мәскәү... Туган яклар... Тик ни көтә аларны туган шәһәрләрендә, поселокларында, авылларында—монысы штабтагы югары командирлардан, мондый авыруларны дәвалау өчен махсус өйрәтелгән хәрби табиблардан кала инде беркемгә дә билгеле түгел. Алар ата-аналарына, туганнарына, якыннарына һәм, ниһаять, өзелеп көткән сөйгән ярларына нәрсә әйтер, нәрсә дияр... Монысын исә хәтта егетләр әлегә үзләре дә белми иде. Кайтып китәр алдыннан соңгы кичне Сирин белән Ильяс бергә үткәрделәр. Икесенә дә монсу иде, күнелсез иде. Ул монсулыкның төбендә Ильяс өчен егерме яшьлек егет күтәрә алмаслык олы кайгы ятса, Сирин өчен дустыннан аерылу, аның өчен борчылу, нишләргә белмичә үрсәләнү ята иде. Сүзсез генә утыра бирделәр. Сүзсез булсалар да алар бер-берсен яхшы, үтә дә яхшы аңлыйлар иде инде. Тынлыкны Ильяс бүлде, ирен чите белән генә елмайды һәм бөтенләй көтелмәгән сорау бирде:

—Беләсең киләме, безнең гомерләрне туган илнең ничек, ни хакка бәяләгәнен,—диде.

Сирин иңнәрен җыерып куйды.

—Алайсаң кара,—диде Ильяс һәм чемоданыннан урталай бөкләп салынган кәгазь чыгарды.—Менә шушы безнең бәһабез...—Һәм полк командиры тавышына охшатып, иреннәрен бераз кыйшайта төшеп, сүзләрне сузып әйтә-әйтә кычкырып укый да башлады:

«Часть командованиесе һәм партия оешмасы Бөек Ватаныбызның изге чикләрен саклау буенча сугышчан өйрәнү вакытында батырлык һәм кыюлык үрнәкләре күрсәткән, сугышчан һәм сәяси әзерлектә ирешкән казанышлары өчен рядовой Комаров Илья Фәлән-фәлән углын мактау кәгазе белән бүләкли».

Сирин ышанмыйча аның кулыннан кәгазьне алды да машинкала басылган юлларга текәлде. Әйе, барысы да нәкъ Ильяс әйткәнчә язылган иде. Ленин башы һәм Кызыл байрак фонында автомат тотып сурәтләнгән солдат рәсеме төшерелгән ялтыравыклы калын ак кәгазьдә полк командиры белән аның сәяси эшләр буенча урынбасары имзалары ярылып ята. Икесе дә югары хәрби чиндагы, меңнәрчә егетләр тормышы ышанып тапшырылган кешеләр...

—Исемемне тагын бозганнар икән,—дип куйды Сирин кәгазьгә ымлап.

Якташы тагын ирен чите белән елмайды. Сүзләрендә аяну да, мәсхәрәләү дә бар иде:

—Исемемне генә бозсалар бер хәл иде... Аларга нәрсә, ике чабата бер кием бит. Илья ни дә, Ильяс ни... Барыбер түгелмени? Без бит «пушка ите»» Итнен фамилиясе дә, исеме дә, милләте дә булмый... Әле ярый болай язганнар. «Фәлән номерлы рядовой» дип куйган булсалар, ни дияр идең?!

Бу хәтле дә өметсезлекне, часть командованиесенә карата бу кадәрле дә мәсхәрәле сүзләрне Сириннең моңарчы әле беркем авызыннан да ишеткәне юк иде. Һәм менә Ильясның тулы хакы бар иде...

## IX

Их, ул загс бүлегендәге тантана, матурлык! Озын сары чәчле, зур зәңгәр күзле, баштанаяк ап-актан киенгән Диләрәнең чибәрлеге! Аның янында озын буйлы, кара тут йөзле Нәкыйпнең мәһабәтлеге! Группадаш егет-кызларның, Нәкыйпнең иптәшләренең бәйрәмчә кәефе! Уен-көлке, шаярышу! Кочак-кочак чәчәк... Бу студент халкыннан да илгәзәк, алдын-артын уйламаучы бүтән берникди дә кавем юктыр ахрысы! Стипендия алган көн шул. Ярты акчаларын чәчәккә сарыф иткәннәр инде, билләһи! Хәер, Нәкыйп белән Диләрәнең бәйрәменнән, аларның кавышу көненнән дә кадерлерәк бүтән бәйрәм Асия өчен дә юк! Була да алмый. Якын дусты, ахирәте, киңәшчесе, ярдәмчесе Диләрә булмаса, авыр минутларында ни эшләр иде икән?

Асия загс хезмәткәре алдында басып торган кияү белән кәләшкә— тормышта иң бәхетле минутларын кичергән якын дусларына карап әллә ниләр уйлап бетерде. Мондый вакытларда да уйланасың икән ул. Үзен Диләрә урынына куеп карады. Ә Нәкыйп урынында Сирин, имеш. Бөтенләй көтмәгәндә башына килгән мондый чагыштырудан хәтта үзе үк сискәнеп тә куйды. Йөрәге ашкынып тибә башлады. Әйтерсең, монда аның туе! Алар да шушылай бәхетле булырлар, бергә булырлар ич! Йа, Ходаем, Нәкыйп белән Диләрәгә бәхет биргән кебек, безгә дә кавышырга, пар күгәрченнәр булырга язсын иде!

Залның түшәмнәре биек, тәрәзәләрендә ап-ак өрфия пәрдәләр, диварларында таштан уеп ясалган бизәкләр, туй күренешләре сурәтләнгән рәсемнәр... Ләкин Асия аларның берсен дә юньләп күрми. Күңел күзе башкада. Диләрәнең шаһиты буларак, ул да загс хадимәсе каршында ич. Ул ягымлы карашлы чибәр ханымның сүзләрен йотлыгып тыңлый. Әйтерсең лә аларны Асия белән Сирингә карата әйтәләр, аларга бәхет телиләр. Хадимәнең һәр сүзе кызның йөрәгенә уелып бара. Әнә ничек матур сөйли бит:

—Бер-берсен сөешеп, яратышып, тигез гомер итүчеләр хакында, гадәттә, чәчләре чәчкә бәйләнгән, диләр. Бүгеннән сезнең чәчләрегез чәчкә бәйләнә, сез бүгеннән яңа гаилә хасил итәсез. Ир белән хатын мөнәсәбәтеннән дә изге, газиз һәм ныклы бердәмлек, бергәлек була алмый. Үзара килешеп, аңлашып, татулыкта яшәүче гаиләләрдән бәхет бөркелеп торыр, мондый гаиләләрдә бәхетле балалар туар. Андый гаиләләрне туганнары да, дуслары һәм күршеләре дә, таныш-белешләре дә яратыр, хөрмәт итәр, аларга тартылыр...

Асия үзе янындагы Диләрәгә күз төшереп алды. «И бәгырькәем, Диләрәкәем, бәхетле дә инде син!»—дип уйлап куйды ул ахирәте турында. Әнә бит, дулкынланудан битләре уттай яна, нечкә ак бармаклары да сизелер-сизелмәс кенә дерелди түгелме соң? Ә күзләре... Бәхетле кешенең күзләре шулай елтырыйдыр инде ул! Аннары Нәкыйпкә борылды. Егет кеше—егет кеше инде. Тыштан тыныч күренсә дә, агарып калган йөзеннән аның да ниләр кичергәнен яхшы аңлап була иде.

Загс хезмәткәре исә сөйли дә сөйли:

—Гаилә дигән изге йортыгызны, татулык-дуслыгыгызны күз карасыдай кадерләп саклагыз. Бүгеннән башлап «минеке, синеке» дигән сүзләрне «безнеке» дигән сүз алыштырсын. Мәхәббәтегез сүнмәсен, сүрелмәсен, еллар үткән саен тормышыгызга ямь, яшәвегезгә мәгънә, үзегезгә көч биреп, һаман көчлерәк ялкынлансын. «Ирне ир иткән дә хатын, хур иткән дә хатын», ди халык мәкале. Шушы хакыйкатьне истән чыгармагыз. Монысы синең колагыңа әйтелә, кадерле Диләрә! Синең колагыңа да бер сүз бар, кадерле Нәкыйп! «Бодай яхшысы жирдән, хатын яхшысы ирдән!» Тормыш юлы аллы-гөлле чәчәкләр түшәлгән гөлбакча түгел. Аның авырлыклары да, кыен чаклары да, тормыш йөген бергәләп тарту мәшәкатьләре дә булыр. Андый чакларда бер-берегезнең арка терәге, ярдәмчесе һәм киңәшчесе була белегез!

«Карале, бу сүзләрне ятлап калырга кирәк икән»,—дип уйлап куйды Асия. Моның һәр сүзе алтын бәһасенә тора ич. Боларны әйтеп күпме кешене сөендерер әле ул! Тагын күз алдына Сирин килде. Әйе, язачак ул ана бүгенге туй тантанасын да, монда әйтелгән сүзләрне дә, Диләрә белән Нәкыйпнең уртак бәхете хакында да. Тагын әле «син булмагач, мина бик күнелсез булды» дип тә өстәп куяр. Сирин, ерактагы бер татар авылында туып-үскән Сирин урыс шагыйрьләре әсәрләрен үтә дә яхшы белә. Үзен сөендереп Пушкинның менә шушы юлларын да язып жибәрер әле. Ул анда сагынудан тилмерсә, мин монда саргаям. Ләкин болар барысы да үтәр, матур көннәр житәр. Өстебезгә бәхет янгыры явар. Бу юллар шуны анлатмыймыни.

Если тебя жизнь обманет,
Не печалься, не сердись!
В день уныния смирись:
День веселья, верь, настанет.

Сердце в будущем живет;
Настоящее уныло:
Все мгновенно, все пройдет;
Что пройдет, то будет мило.

Туй мәжлесенең студентлар ашханәсендә, нәкъ менә алар Сирин белән беренче тапкыр очрашкан ашханәдә узуында Асия аерым бер мәгънә, киләчәгенә ишарә күрә иде. Бәлки... кайчан да булса алар да бу залга яңадан парлашып, кияү белән кәләш сыйфатында житәкләшеп керерләр...

Туйның иң кызып кына килгән чагы иде. Яшь гаиләгә күпме матур теләк, күпме матур сүз әйтелде. Бәйрәм рухы инде урамнарга ташып чыкты. Һәм шунда Асия ишек төбендә үзе бүген иң күрергә теләмәгән кешене—Дамирны күреп алды. Йөрәге дерт итеп китте. Бер-бер ямьсезлек чыгара инде бу, дип уйлап куйды. Чакырулы түгел иде ул. Әмма студентлар ашханәсенең, студентлар туенын үз кагыйдәләре. Монда беркем дә ишекне бикләп, аның янына сак куймый. Әдәп дигән нәрсә бар, йола бар. Теләгән кеше керсен, котласын! Бу бит группаның, бөтен курсның, хәтта факультетның уртак бәйрәме. Чакыру кәгазьләрен кемнәргә атап язарга, кемнәрне дәшергә дип баш ватканда Диләрә белән Асия да шулай фикер йөрткәннәр иде.

Дамир күзе белән залны айкап чыкты. Егетнең һәр хәрәкәтен өстәл башындагы чәчәкләр арасына посып күзәткән Асия аның үзен эзләгәнен бик яхшы белә иде, әлбәттә. Бәйләнчек егеттән котылу өчен нишләргә? Башында шул сорау бөргәләнә башлады. Әмма шул чакта талгын музыка уйнап жибәрде. Егетләр, кызлар парлашып зал уртасына ашыктылар. Дамир күзенә чалынырга теләмәгән Асия исә биюгә чыкмады. Һәм... бик нык ялгышты. Моны ул соңыннан гына анлап алды. Чөнки, үч иткәндәй, Нәкыйпнен шаһиты булган егет тә каядыр югалып өлгергән иде. Дамир зал уртасына ук үткән һәм өстәл янында ялгыз калган кыз, табигый ки, ана уч төбендәгедәй күренәчәк иде. Шулай булып чыкты да. Йөзенә елмаю жәелгән Дамир, кулындагы чәчәк бәйләмен алга сузып, ул утырган жиргә—кияү белән кәләшнең ике ягындагы дәрәжәле урынга якынлашып килә иде инде.

—Диләрә белән Нәкыйпне котлап чыгарга кердем әле,—диде ул һәм кыланчыкланып баш иде.

Асия кырт кына жавап бирде:

—Аларны котларга кергәнсең, ә үзең минем янга киләсең. Аларны күтәргә иде.

—Ничего, бию беткәч тә аларны котлый алам бит мин. Хәзер, әйдә, алар хөрмәтенә синең белән без дә биеп алыйк, туй безгә дә бәйрәм булсын.

—Юк, нигәдер башым авырта,—дип сәбәп тапты Асия.

Ләкин кызны ничек буйсындырырга кирәклеген «Казан ышпанасы» бик яхшы белә иде шул. Ул нәкъ шундый юлны бик тиз тапты, иелеп колагына пышылдады:

—Минем бит сиңа Сирин турында бик мөһим хәбәр әйтәсем бар. Бер биюдән укаң коелмас, әйдә, чыккач, барысын да әйтермен.

Асияның йөрәге дерт итеп китте, кинәт кенә бөтен бите яна башлады. Үзе өчен иң якын, көне буе башыннан чыкмаган кадерле исемне ишетүгә миеннән шөбһәле уй йөгереп узды: «Әллә аңа берәр хәл булганмы? Аны әйтер өчен генә туй хәтле туйга килмәс иде бит!» Агасының хәрби комиссариатта эшләве белән мактанып өлгергән Дамирдан теләсә нинди хәбәр көтәргә мөмкин, тик яхшыга гына була күрсен иде. Теләсә дә, теләмәсә дә сихерләнгәндәй егеткә иярде. Алар арасындагы мөнәсәбәтне яхшы белгән Диләрә белән Нәкыйп күзенә ташланырга теләмәгән Асия егетне бер читкәрәк, ишек ягына таба алып китте.

—Рәхмәт, Асия! Шулай булырын белә идем,—дип канәгать елмайды Дамир һәм кулын кызның биленә салды, авызыннан аракы сасысы бөркелде.

Асия чирканып башын читкә борды. Ләкин ишетәсе килгәне кадерлерәк иде, үзе сүз кушты:

—Йә, әйт инде, Сирингә ни булган?

—Әлегә берни дә юк! Тик булмасына ышанычым да юк.

—Шул «юк»ларыңны әйтер өчен мине чакырдыңмы?

Дамир кинәт айнып киткәндәй күз алдында җитдиләнде, кызны кочагына якынрак алып, колагына иелеп ашыга-ашыга пышылдарга кереште:

—Абый әйтте, аның белән армиягә киткән берничә егет кайткан, ди. Ниндидер өйрәнү вакытында төзәлмәс яра алганнар, ди. Ни-нәрсә булганы—хәрби сер. Сирин дә ул өйрәнүдә катнашмагандыр дип кем әйтә ала? Калганын белгертергә хакым юк... Аның белән дә шулай булу ихтималын гына әйтәм...

Асияның башы әйләнеп китте.

—Без аның белән атна саен хат алышабыз, ул миңа барысын да язып тора,—диде.—Андый-мондый хәлне мин беренче белер идем...

Дамир көлеп җибәрде, тавышында каһкаһә яңгырады:

—Ул хәтле беркатлы булма инде. Әллә син частьтагы хәлләрнең барысын да язарга ярый дип беләсеңме? Аныкы гына түгел, синең хатларың да кат-кат цензура үтә бит!

Сирингә генә аталган, ул гына белергә тиешле сагыну, сөю, наз тулы мәхәббәт сүзләренең кемнеңдер пычрак куллары аша үтүен аңлаудан Асия имәнеп китте. Әмма ирешергә теләмәде.

—Юк, яралы, гарип булып кайтса да мин аны көтәм, көтәчәкмен!—диде ул ачуына буылып.—Аның турында болай сөйләнеп йөрергә синең ни хакың бар?

Дамир тагын үзенекен тукларга кереште:

—Әгәр бер-ике елдан үләсен белсәң дәме?

Асия инде үз-үзен белештермәс хәлгә житкән иде, аның яңагына чылтыратканын сизми дә калды. Бер мәлгә ап-ак булган егет кинәт Асияны ике кулы белән буып кочаклады:

—Әйткән иде диярсең, син минеке булмасаң, башканыкы да була алмаячаксың.

Ачудан һәм чарасызлыктан Асияның күзләреннә яшь бәреп чыкты, иреннәрен тешләде. Ул инде нишләргә дә белми иде. Шунда чакта биючеләр арасыннан озын буйлы, кыска чәчле, чегәнгә охшаган каратут йөзле чандыр егет килеп чыкты һәм, нәкъ менә аларны эзләп йөргәндәй, Дамир белән Асия янында туктап калды. Асияга сынагандай туп-туры карап торды да кыю гына эндәште:

—Гафу итегез, син Асиямы?

—Әйе... мин...

Ләкин калганын әйтеп бетерергә дә өлгермәде таныш түгел егет, яшен тизлеге белән Дамирнын кулыннан борып алды һәм кискен итеп артка таба каерды. Авыртудан йөзе чалшайган Дамирга хәрбиләрчә кыска һәм кискен итеп, боерык биргәндәй әйтте:

—Ә синең белән без, дускай, хәзер урамга чыгып сөйләшербез.

Кулы дзю-до алымы белән артка каерылган һәм авыртуга чыдый алмаган Дамир теләсә дә, теләмәсә дә таныш түгел егеткә иярергә мәҗбүр булды.

Шул чыгудан алар кире әйләнеп кермәделәр.

* * *

Бүтән ул егетне очратмам инде. Кем булды соң ул мине коткаручы, минем үземне, исемемне каян белгән? Туй көнне дә, аннан соң да шушы сораулар белән баш ватты Асия. Дус кызларыннан, егетләрдән сораштырып карады, әмма беркем дә юньле-рәтле аңлата алмады. Инде ул «игелек кылучы рыцарь» онытыла да башлаган иде.

Көннәрдән бер көнне җавап үзеннән-үзе табылды, дәресрәге үз аягы белән килеп керде. Туйдан соң берничә көн узган иде инде. Кичкә таба кыяр-кыймас кына кемдер бүлмә ишеген шакыды.

Бүлмәдә ялгызы гына утырган Асия китаптан башын күтәрмичә генә дәште:

—Керегез!—диде.

Әкрен генә ишек ачылды һәм китабыннан башын күтәргәч, Асия телсез кала язды. Ишек төбендә аны Дамир кулыннан йолып алган, берничә көн буе исеннән чыкмаган таныш түгел егет басып тора иде. Йөзе җитди, кыяфәте бәйрәмчә иде. Аның энәдән-җептән төшкәндәй яңа киемнәрдән икәнлеген күргән Асия, һәрхәлдә, шулай фаразлап куйды.

—Сез мине туйдагы тупаслыгым өчен гафу итегез инде! Бераз артыграк та кыланылды бугай,—дип елмайды ул берничнди кереш сүзсез-нисез.—Теге егетнең бик ямьсез бәйләнгәнен күрдем дә түзә алмадым... Бүген менә танышырга, гафу үтенергә кердем.

Егетне түргә чакырырга да оныткан кыз гаҗәпләнүдән һәм аптыраудан күзләрен зур ачып катты да калды, иреннәре арасыннан исә сүзләре аңа буйсынмаган килеш чыкты бугай:

—Ә-ә... сез мине... каян беләсез?

Егет һаман табышмак белән сөйләвен дәвам иттерде:

—Фотографиягездән таныдым.

—Ул сезгә ничек килеп эләкте?—дип көч-хәл белән әйтә алды Асия.

Кызны шаккатыруын аңлаган егет тагын ап-ак тешләрен күрсәтеп киң итеп елмайды:

—Ә-ә... Аны әйтәсезмени? Сирин күрсәткән иде.

Асия тагын авызын ачып калды.

—Сез... Сиринне беләсезмени?

—Әлбәттә! Ул минем иң яхшы дустым. Бергә хезмәт иттек. Сина сәлам җибәрде. Адресынны да ул бирде...

—Туктале, тукта! Ә ничек итеп туйга барып эләктегез?

Таныш түгел егет гаебен таныган баладай инсәләрен җыерды:

—Анысы кыен булмады аның. Сине эзләп тулай торакка килгән идем, сезне туйда дип әйттеләр. Барып күрим әле, мәйтәм. Йә инде, хәзер танышыйк булмаса. Мин Ильяс булырмын. Комаров Ильяс!

—Ә мин... мин Асия инде. И-и әйтергә дә онытып торам икән, бик-бик зур рәхмәт сез... сиңа. Сирин киткәннән бирле шулай бәйләнеп интектерә иде...

—Моннан соң бәйләнмәс,—дип каттый итеп кистерде Ильяс.—

Мин синең тән сакчысы булырга Сирингә вәгъдә биреп кайттым. Бүтән якын да килмәс...

Армия хәлләрен кызык итеп, мәзәккә әйләндереп сөйли белгән егет тәмам авызына каратты. Аның сөйләвенчә, армиядә хезмәт итү шулай гел уен-көлкедән генә тора икән.

Ильяс күзен кыса төшеп сөйли бирде.

Менә мондый бер мәзәк:

—Әбекәй, кунып чыгарга керт әле.

—Кер, солдат балакай, кер.

—Мин берүзем генә түгел, ефрейтор белән.

—Соң, этенне коймага бәйләп калдырсаң да ярар,—дип әйткән ди әбекәй.

Асия рәхәтләнеп көлде.

Инде менә тагын бер мәзәк:

Көннәрдән беркөнне хәрби цензорга "Игорь полкы турында жыр" дигән китапка виза салырга кушканнар ди. Полк командирларының исем-фамилияләрен матбугатта күрсәтергә ярамый, дигән инструкция буенча цензор китапны болай төзәткән имеш: «N-нче хәрби часть турында жыр».

Ул көнне чәй янында алар бик озак сөйләшеп утырдылар. Әле һаман Дамирның кабәхәтлеген, ул әйткән сүзләрне онытып бетермәгән Асия шул хакта да сорамакчы иде, теле кычыткалап алды, әмма кыюлыгы җитмәде. Ильяс исә үзе кайда, ничек хезмәт итүләре хакында ник бер сүз әйтсен, аныңча барысы да әйбәт иде. Тәкрарлаганы бер генә нәрсә булды:

—Сирин исән-сау. Хезмәте менә дигән. Солдат йоклый, хезмәт бара тора, дигәндәй, күп тә үтмәс, кояш кебек балкып кайтып та керер әле.

Шул көннән Асия Диләрә кебек үк якын, ышанычлы икенче дустым бар, дип саный башлады. Һәркайда, һәрчакта Ильясның кайгыртуын, аның турында борчылуын белеп тору рәхәт иде кызга.

Бу мөнәсәбәтләргә баштарак сәерсенеп караган ахирәте шаяртып та куйды әле:

—Кара аны, гашыйк булып куя күрмә. Бу кара чутыр, әллә нишләп, бигрәкләр дә мәхәббәтле күренә инде.

Асия үпкәли язды.

—Егетләр белән кызлар арасында дуслык булмыймыни? Аның кем икәнен беләсең ич. Ул Сириннең дусты, димәк, минем дә дустым.

Диләрә эндәшмәде, елмаеп кына куйды. Күз карашы исә «Бәхетле кеше син, Асия!» дигәнне аңлата иде.

## X

Үзен котылгысыз үлемнән Ильяс кына алып калганлыгын Сирин соңлап, бары тик ул кайтып киткәч кенә яхшылап аңлады. Әгәр ул тартып яткырмаган булса, куак ботагын кисеп төшергән пуля аныкы иде бит. Йөрәге кысылып куйды, күзләренә яшь килде. «Рәхмәт тә әйтә алмыйча калдым,—дип өзгәләнде.—Мин ана хәзер гомер буе, мәңгегә бурычлы булып калачакмын». Шуның белән бергә очраклы, мәгънәсез үлемнән котылуы күңеленә әллә нинди бер шатлык, юаныч бирә иде. Димәк, ул, кем әйтмешли, бәхетле йолдыз астында туган! Ләкин... Ләкин... Бәла ялгызы гына йөрми, диләр. Ильяс кайтып киткәнгә ярты ел уздымы—юкмы, авылдан, әтисеннән хат алды.

Әнисеннән, барлык туган-тумачадан, күрше-күләннән, барча авылдашларыннан күптин-күп, чуктин-чук сәлам тезгән хатында Хафиз абзый Сиринне тәмам тетрәткән, пошаманга калдырган сүзләр тезгән иде:

*«И улым! Авылда адәм ышанмаслык хәл булды бит әле. Теге, синең янда хезмәт итеп кайткан Рифгать атлы егет асылынып үлде бит. Нинди чибәр, таза, матур егет иде армиягә киткәнче. Шуннан бозылып кайтты микән? Кайткач та балтасы суга төшкән кеше кебек йөри башлады. Кичләрен клубка да чыкмады, элек яратышып йөргән кызы белән уртак тел тапмадымы шунда. Белмим. Эчүгә сабышты. Авылда андый хәлнең булганы юк иде. Үзең беләсең. Кисәтеп куйыйм әле, аның кебек эчәргә өйрәнеп кайта күрмә. Карт башыбызны хур итәрсең. Ата-аналарына нинди тирән кайгы китергәнен аңлыйсыңдыр. Инде тагын шунысы гаҗәп, үләр алдыннан язу язып калдырган. Анысы бөтенләй табышмак. «Үлемемдә беркемне дә гаепләмәгез, гаепләрлек кешеләр бик еракта, безнең кул җитә торган җирдә түгел»,—дигән. Әллә соң юньсез адәмнәр белән бәйләнештә булдымы икән?»*

Шул чакта Сириннең бөтен жанын көтелмәгән шөбһәле уй айкап чыгарды: «Әллә минем якыннарыма, минә дус кешеләргә генә киләме соң ул афәт, бәхетсезлек дигән нәрсә? Башта Ильяс, адәм әйтеп, адәм ышанмаслык хафага, авариягә юлыкты. Инде менә Рифгать. Алда тагын кемең бар? Иң якының кем?» Бу уйдан бөтен тәне куырылып килде. Тагын иң якыны—Асия ич! Инде ана да, син—Сирин, шундый ук бәхетсезлек китерерсеңме?! Юк! Моны булдырырга ярамый! Иң яхшысы—араны өзү! Асиядан баш тарту! Ичмасам, аның бәхетенә зыян килмәсен, үз язмышын үзе корсын! Ә сина, Сирин, беркем белән дә дус булырга, якынаерга ярамый! Ярамый! Болар егетнең бөтен яшәү мәгънәсен юкка чыгарган коточкыч уйлар иде. Алардан Сирин бер генә минутка да арына алмады.

Ләкин Асиядан килгән хатлар, аның эчкерсез сүзләре, киләчәккә өмете-ышанычы бу шөбһәне куып тарата торды. Хәзер аның янына Ильяс килеп йөри икән! Менә баштарак бераз үртәлсә дә, армия дустының күңел чисталыгын, керсезлеген белгән егет тынычлана башлады. Аның үзен үлемнән йолып калган Ильяс кешегә янаган куркынычны туктата белә түгелме соң? Сиземли бит ул аны... Бәлки, Асияга куркыныч янамасын өчен аның янында булырга тырышадыр... Әнә бит Асия ничек дип яза:

Сердце в будущем живет;
Настоящее уныло:
Все мгновенно, все пройдет;
Что пройдет, то будет мило.

Их, шулай булсачы!..

...Яз көннәре иде. Инде кояш көннән-көн яктырак балкый, түбә кыекларыннан тамчылар тама башлады. Ылыс исе, бөре исе тагын да куерды, тыгызланды. Күкрәк тутырып сулыйсы, бөтен буең белән үскә, кояш янынарак үреләсе килә. Адәм баласы шулай инде ул, яз башлануга бөтен иске кайгылар, мәшәкатьләр коелып калгандай тоела ана. Әйтерсең, яз табигатьне генә түгел, кешеләрне дә яшәртә, аларга да янару алып килә. Бәлки, шулайдыр да...

Ләкин яз шатлыгына уралып казармаларга аяусыз бер шом үрмәләп керде. Шул шом, шөбһә бер Сириннең генә түгел, бөтен солдат егетләрнең күңелен кара пәрдә белән чорнап алды, язгы көннәрнең ямен җибәрде. «Подъем!»га кадәр үк уянган Сирин күрше ятактагы егетнең сәер хәрәкәтләренә игътибар итми кала алмады. Күршесе торып баскан да тырышып-тырышып, әйләндереп карый-карый мендәр кагып азаплана иде.

—Нәрсә, төнлә тузан жыелганмы әллә?—диде ул шаяртырга теләп. Тик егетнең чырае караңгы иде.

—Син үз мендәреңне кагып кара,—диде ул төксе генә.

—Мендәргә ни булган? Мендәр—мендәр инде ул.

Шулай да башын күтәреп мендәрен карыйсы итте. "Подъем!" сүзен ишеткәч тә сикереп торып киенергә, аны-моны абайламыйча тизрәк

урын-җирен рәтләргә, юынгычка чират алырга ашыккан Сирин күзләренә ышанмады. Мендәрнең ак сүрүе кап-кара булган иде. Селкеп җибәрүе булды, ак җәймәгә чәч бөртекләре коелды. Ирексездән куллары башына үрелде. Кыскан бармакларыннан тарак ясап чигәсеннән баш түбәсенә үткәрде һәм бөтен тәне эсселе-суыклы булды. Яшерен горурлыгы, мактанычы булган дулкын сыман куе коңгырт чәчләренең бер учмасы бармак араларына ияреп чыккан иде. Күрше егете дә шул ук хәрәкәтләрне кабатлады. Нәтиҗә шундый ук. Һәм алар бер-берсенә карашып телсез калдылар. Сүзләр артык иде.

Һәр частьның үзенә генә хас терминнары, солдатлар һәм офицерлар арасында гына кулланыла торган, аларга гына билгеле яшерен сүзләре була. Полктагы солдатлар арасында иң еш кулланыла торганы—«барак». Элеккеге казармалардан бушап калган, тыштан шыксыз һәм ташландык күренсә дә, бу солдатларның зарын тыңлый, сүзләренә колак сала торган бердәнбер урын шушындагы санчасть иде шул. Язга чыккач, егетләрнең бер-берсенә сиздермәскә тырышып кына «барак»ка йөрүе тагын да ешайды.

Сиринне полк врачы, сәер һәм озын фамилияле капитан караңгы чырай белән каршы алды. Әллә артык үзсүзле, туры булгангамы, әллә алар белән артык аралашмагангамы, әллә инде солдатларны тегe яки бу төр хезмәттән еш азат иткәнгәме офицерлар аны өнәп бетерми, үзара "Теге латыш врачы" дип кенә йөриләр иде. Хәер, алар бик тырышсалар да, частька күптән түгелрәк кенә килгән хәрби табибның үтә катлаулы һәм озын фамилиясен дөрес итеп әйтә алмаслар иде. Солдатлар өчен исә, киресенчә, полктагы офицерлардан ул иң ышанычлы кеше, аны хөрмәт итәләр, кыен вакытта аңа барып таянырга мөмкин икәнен дә яхшы беләләр. Алар өчен ул—«доктор Янис».

—Яз житте, яз. Барыгызда да авитаминоз башланды, ягъни витамин җитми,—диде ул Сириннең оялып, кыенсынып кына сөйләгәнен тыңлагач. Һәм үзенең төкселегеген акларга теләгән кебек елмайгандай итте, авыр сулап куйды.—Ризык ярлы, җитмәсә, гел бер төрле, егеткәем. Сезгә җиләк-җимеш, яшелчә кирәк. Командованиега күпме әйтеп киләм, безнең частьларда ашату башка төрле, витаминга бай булырга тиеш, дип. Нормалар башка булырга тиеш, дип. Нишлисең... Армиянең үз кануннары.

—Миңа нишләргә соң инде?—диде нәүмизләнеп калган Сирин.—Бер чара да табып булмыймы?

Доктор нәрсәдер эшләргә кыймагандай кулындагы авторучкасын бер алды да, бер куйды, өстәлдәге кәгазьләрне рәтләштерде.

—Витаминнар язып бирәм мин сиңа, егеткәем,—диде ул, ниһаять.—Тик башта ук әйтеп куйыйм, алар безнең аптекада юк. Бәлки, өеннән җибәрә алырлар, эзләсәләр, бәлки, табарлар. Үзең кайсы яктан буласың инде?

—Татарстаннан мин.

Доктор Янисның кинәт кашлары өскә күтәрелде, күптән күрмәгән танышын очраткан кебек кулларын җәеп җибәрде:

—Һай, егеткәем, безне якташлар дияргә дә ярый икән. Гаҗәп нәрсә шул ул тормыш дигәнең...

Бу юлы инде гаҗәпләнү чираты Сириндә булып чыкты. Әмма ышанып җитмәвен яшерә алмады, сузып кына әйтеп куйды:

—Се-е-ез... Татарстаннанмы?

—Юк. Мин үзем Латвиядән анысы, әмма балачагым Татарстанда үтте.—Ерак үткәннәрне искә алудан булса кирәк, докторның йөзенә бер мәлгә моңсулык кунып алды һәм ул үзен сынагандай Сирингә туп-туры карап кинәт татарчага күчте.—*Исянме, энекяш! Хялляр ничек? Тәмле бярянге.* Йә, дөрес әйттемме?

Телсез кала язган Сирин:

—Әйе, әйе,—диюдән уза алмады.

—Ялгышмасам, Балтамак иде бугай... Бәлки, андый авылны да ишеткәнең бардыр... Ниндидер бер кечкенәрәк кенә елга буенда иде.

—Зәй буенда түгелме?

—Әйе, әйе, нәкъ шулай! Зәй иде, Зәй...

Таныш исемне ишетүдән, әллә нинди сәер төштәге кебек тоелган бу хәлдән, Сирин инде ни әйтсәләр шуна ышанырга әзер иде.

—Ишеткәнем бар... Беләм, белмичә, ул бит минем туган авылым. Зәй суы буенда!—диде ул үз авылларын ерак Латвиядә дә белүләренә горурланып.—Әти-әниләрем хәзер дә шунда яши.

Доктор Янис ана кинәт кенә үз туганы шикелле якын тоела башлады.

Доктор урындыгыннан торды һәм Сиринне иннәреннән кочып алды, кулъяулыгын чыгарып күзләрен сөрткәләде, үзе туктаусыз сөйләнде дә сөйләнде:

—Йа Хода, ниһаять, күпме еллардан соң игелекле шул авыл кешеләреннән кемне дә булса очратырмын икән... Ышанасым да килми... Ул бит минем төшләремдә... Ул бит безне ач үлемнән коткарган авыл! Фәрештәгә тин, мәрхәмәтле әби-апалар яши торган жир... И аларның ягымлылыгы, шәфкатьлелеге! Күп еллардан соң гына аңладым, алар үзләре дә ачлы-туклы яшәгән икән бит, үз балаларына да ашарга житкерә алмыйча интеккәннәр... Үз авызларыннан өзеп безгә көн саен кем дә булса сөт, теге ни әле... катык ташулары. Андагы ярмалы бәрәңгенен тәмлелеге! Аны әле дә телемдә тоям мин...

Салкын канлылар, хисләрен тышка чыгарырга яратмыйлар, дип саналган Балтик буе кешесенен, үзеннән унбиш-егерме биш яшькә диярлек өлкән ир-атның, житмәсә, офицерның болай сөйләнүен әле аңларлык хәлдә түгел иде Сирин.

Доктор, ниһаять, айнып киткәндәй булды, градусниклар, төрле приборлар, белешмәлекләр белән тулы өстәле янындагы урынына барып утырды һәм каршысыннан Сирингә дә урын тәкъдим итте.

—Гафу ит, туган, бераз хисләнеп киттем бугай,—диде ул бераздан тынычрак тавыш белән.—Үз-үземне белә башлаганнан бирле барып күрергә теләгән авыл ул. Сугыш башлангач безне—кырыклап латыш баласын Татарстанга эвакуацияләделәр. Детдом балалары... Арада ике-өч яшьлектән башлап иң олы дигәненә дә нибары ун яшь иде. Берсе дә үлеп калмады. Дүрт ел буе безне авыл халкы карады, тәрбияләде. Рәхмәтләр яусын ул Балтамак апаларына, әбиләренә! Юри генә, кызык өчен генә чагыштырып кара әле: Балтика—Балтамак!.. Бәхетле очраклылыктырмы, белмим, әмма бу охшашлыкта мин символик мәгънә дә күрәм. Балтика балалары кем инде юкса балтамаклыларга. Бәлки, әле ул апалар арасында синең әниең дә булгандыр?..

Сирин ризалашкандай баш селкеп куйды, кинәт әнисенен «Детдом балалары кебек...» дип сөйли торган гадәте исенә төште, йөзе яктырып китте. Тагын бик озак сөйләшеп утырдылар әле алар. Зәй буйлары да, карлыганга, бөрлегәнгә бай әрәмәләр дә, язга чыгуга ук чебиләп беткән ялан тәпиле балаларның беренче куанычы—болыннарда иң алдан калкып чыга торган кузгалак белән юа да, балтырган белән какы да, Ялгыз таудагы карт тирәк тә искә төшерелде. Доктор Балтамактагы бик күп нәрсәне хәтерли икән әле.

Бераздан ул кинәт житдиләнеп китте. Ул инде янадан таләпчән һәм гадел табиб иде. Балтамаклыларга хас булганча, көрән күзле, чибәр бу егет аның хәлиткеч сүзен, ярдәмен көтә, аңа ышана. Ул шуның өчен килгән.

—Йә әле, гимнастерканны сал. Тикшерик, карыйк. Совет армиясендә нинди чынығу үттең икән,—дип сөйләнә башлады ул дусларча елмаеп.—Рас, килгәнсең икән, бар жиренне дә тикшермичә, карамыйча жибәрмим инде мин хәзер.

Чыннан да, аның карамаган жире калмады бугай. Кан басымын үлчәде, пульсын санады, үпкәләрен тыңлады, күз алмаларын тикшерде, телен чыгарып күрсәтергә кушты. Егет тулаем аның карамагында иде инде.

—Сәламәтлегең аллага шөкер,—диде ул, ниһаять, бөтен эшләрне башкарып чыккач. һәм Сириннең күзләренә туп-туры карап сөйли башлады.—Ләкин мин сине кисәтергә тиешмен, дустым! Укыган егетсең, аңларсың. Синнән яшерә дә алмыйм, сез монда шактый күп, әйе, шактый күп дозада нурланыш алып өлгергәнсез. Доктор буларак, мин моны сиңа әйтергә тиеш түгел идем. Шулай да сиңа гына, аң бул, үзенә генә әйтәм. Чирне белгәндә генә дәвалап була. Ләкин моны сезгә беркайда да әйтмәячәкләр, мең комиссия үтсәгез дә, берсе дә бу диагнозны расламаячак. Бу бит хәрби, сәяси һәм, ниһаять, стратегик сер. «Безнең илдә радиация юк»,—диде ул ачынып.—Димәк, даруы да, дәвалау чаралары да юк. Дөрес, аны Америкада, Япониядә инде уйлап тапканнар, диләр. Ләкин аны кайтартып булмый... Шулай да мин кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышырмын. Күпмегә төшсә дә. Бу минем Балтамак каршындагы изге бурычым да. Балтамак дигәннән, кәләшең, сөйгән кызың бармы?—диде ул бөтенләй көтмәгәндә сүзне икенче якка борып.

Сириннең битенә бер генә мизгелгә кызыллык йөгереп алда. Әмма горурланып әйтте:

—Бар! Армиягә киткәндә вәгъдәләр бирештек. Ул мине көтә. Атна саен хат алышып торабыз. Бергә укый идек...

—Бик яхшы,—диде доктор.—Тагын бер сорау: аны чын-чынлап яратасыңмы? Аңардан башка тормышыңны күз алдына китерә аласыңмы?

Монысы инде тагын да сәеррәк сорау иде. Докторның анда ни эше бар икән, дип уйлап куйды егет. Ләкин якташ буларак сорашырга хакы бар лабаса, дип нәтиҗә ясады һәм инде күптән хыялында йөргәнне кистереп әйтмичә булдыра алмады:

—Чынлап яратам, аңардан башка миңа тормыш бик ямьсез, мәгънәсез бер нәрсә...

—Бик яхшы,—диде доктор, ниһаять, хәлиткеч бер карарга килгәндәй.—Алайса минем сиңа бер киңәшем бар: кайткач та өйлән син, дустым. Бер алты-җиде ел әйбәт булыр, дип беләм. Аннан... ул сине аңлар... Аңа хәтле, бәлки...

Ул нәрсәнедер әйтеп бетерми иде. Куркыныч сизенүдән Сириннең йөрәге кысылып куйды. Әмма яшь һәм көчле ихтыярлы егет моны докторга сиздермәде.

Хушлашыр алдыннан инде дуслашып һәм тәмам үз булып беткән доктор иптәшләрчә итеп Сириннең аркасыннан кагып куйды:

—Син минем янга кереп йөр! Онытма, мин ярдәм итәргә тырышырмын!—Бер генә секундка уйланып торды һәм иң куркыныч, дәһшәтле сүзләрне әйтте.—Әгәр инде соң булмаса!

Их, доктор, доктор! Нигә әйттең син бу сүзләреңне? Эндәшмичә генә калсаң булмый идемени?! Шушы сүзләр Сиринне баш очына элеп куелган кылыч кебек гомере буе эзәрлекләячәк бит: «Инде соң булмаса, инде соң булмаса!»

* * *

Поезд тәгәрмәчләре ашкынулы ритм белән тыкылдыйлар да тыкылдыйлар. Алар өч ел буе көткән минутларны тизрәк якынайтырга телиләр сыман. Әнә бит көйләре дә, тыкылдаулары да тизләнгәннән тизләнә бара. Рельс тоташкан урыннарда вагон чайкалып куя. Өстәлдәге стаканнарда калаклар зеңгелдәшә. Әйтерсең лә алар да тәгәрмәчләр җырына кушыла. Сирин күңелендәге ашкыну, дәрт аларга да күчкәндер, мөгаен.

Сирин моннан өч ел элек Казаннан чыгып киткән чакларын исенә төшерде. Ул чакта да поезд тәгәрмәчләре көйли иде. Тик хәзер аларның көе башкача. Алар инде билгесез язмыш вәгъдә итеп такмакламый, ә киресенчә дәртле көйләре белән күңелеңне үстерергә тырышалар. Сирингә рәхәт иде. Өч ел тоткынлыкта яшәгәндәй үткән хезмәттән соң, ул беренче

тапкыр бернинди боерыксыз, үз теләге белән теләсә кая бара ала. Ә аның теләгән җире бер генә—ул Казан, күрешергә теләгән кешесе бер генә—ул Асия!

Вагонда эссе иде. Сирин гимнастерка якасын ычкындырып җибәрде, бил каешын бушатты һәм эсселектән һичьюгы беразга котылып тору өчен тамбурга чыкты, маңгаен салкын тәрәзә пыяласына терәп очрашу минутларының ничек буласын күз алдына китерергә тырышты. Шул чак әллә нәрсә булды, күңелле генә көйләп барган тәгәрмәчләр җырларын алыштырдылар түгелме соң? Әнә бит алар хәзер ничек тыкылдыйлар:

—Соң-бул-ма-са... соң-бул-ма-са...

Кинәт Сирин эсселе-суыклы булып китте. Каян килеп чыкты соң әле бу каһәр суккан көй? Ул нәрсәгә ишарәли? Киләчәген юк, димәкчеме әллә?

Вагон янышнан шуып артка йөгерүче урман-кырлар, иксез-чиксез киңлекләр, юл буенда җемелдәшеп калучы семафор утлары аңа күз кысалар, күңелен төшермәскә өндиләр. Ләкин хәрби частьтан чыгып беренче тапкыр үз ирке, үз теләге белән аяк баскан тимер юл станциясендәге шатлык, күтәренкелек эри, минут саен югара, кими иде инде. Казанга якыная барган саен шик-шөбһәләр куера, тыгызлана төште, бераздан йөрәген авырттырып кыса башлады. Алда аны нинди язмыш көтә? Үткәнгә кире кайтып буламы? Башында тәшвиш, вәсвәсә котырды. «Егеткәем, син нәрсә, әллә унтугыз яшьлек чагыңа кире кайтмакчысыңмы? Юк инде! Булмас! Син моннан өч ел элек чыгып киткән Сирин түгел!»—дип пышылдады аларның берсе ямьсез җете кызыл тавыш белән. Аңа икенчесе каршы төште. Монысының тавышы мәрхәмәтлерәк, ягымлырак иде, ул Сиринга яңа тишелелеп чыккан бәбкә үләне төсен хәтерләтте. «Син—шул ук Сирин, борчылма, авырлыклар артта калды, ә алда—якты көннәр, дуслык һәм мәхәббәт көтә»,—диде анысы. Күз алдында төсләр биешә башлады. Сары төс куерды, караңгыланып томан төсенә кереп җәелде дә акрын гына шомлы тавышка әйләнде: «Ильяс язмышын, аның белән булган башка егетләрне хәтерлисеңме? Авылдашың Рифгать нигә үз-үзенә кул салды? Әллә син генә алланың кашка тәкәсеме? Доктор Янис кисәткәнне оныттыңмы?» Бу бәйләнчек авазлардан, бу шомлы уйлардан беркайда да качып котылырга мөмкин түгел иде инде.

Ә вагон тәгәрмәчләре туктаусыз тыкылдыйлар да тыкылдыйлар:

—Ә-гәр-соң-бул-ма-са... ә-гәр-соң-бул-ма-са...

## *Эпилог*

Мең тугыз йөз житмеш икенче елның җәй азагында казанлыларны шаккатырган «АКШларында тикшеренүләр һәм эзләнүләр» дигән күргәзмәдә очрашкан егетләрнең берсе электрон җиһазлар буенча эксперт, Нью-Йорктан килгән Илдар Акчурин булса, икенчесе Казан фәннитикшеренү институтларының берсендә фәнни хезмәткәр булып эшләүче Сирин Сабиров иде. Аларның ни-нәрсә сөйләшүен салам эшләпәсен күзенә батырып кигән юантыграк гәүдәле, әмма хәрәкәтчән, елгыр егет күзәтеп йөрде. Анысы—тиешле оешмаларда эшләүче Дамир Гыймаев. Боларның әтиләре—«Идел-Урал» яшьләр оешмасының сәркәтибе Йосыф Акчура, сугыш юлларын үткән солдат Хафиз Сабиров һәм СМЕРШ майоры Гыймаев—моннан нәкъ егерме җиде ел элек Чәнчүн шәһәрендә очрашканнар иде. Алар өчесе өч сыйфатта иде һәм, табигый ки, араларында дустанә мөнәсәбәт була алмый иде. Инде менә егерме җиде елдан соң аларның балалары изге Казан туфрагында. Алар да бүген өчесе өч сыйфатта. Ләкин аталарының кайчандыр очрашулары хакында белмиләр һәм кайчан да булса белүләре дә икеле. Дөнья дигәнең шундый сәер һәм катлаулы инде ул.

Егетләр бу көннәргә өчесе өч юл белән килде. Ләкин әлеге юллар

һәрчак үзара кисешеп йә булмаса параллель юнәлешләрдә барды. Алар, үзләре дә белмичә, бер-берсенең язмышына төрлечә йогынты ясадылар йә шул үзгәрешләрне тудыручы вакыйгаларның шаһиты булдылар. Моны язмыш шаяруы, дияргәме, әллә инде тәкъдирләрендә язылган котылгысызлык, дип бәяләргәме? Анысын, күрәсең, анык кына итеп әйтү мөмкин дә түгелдер.

* * *

Сүз куешканча, кичке биштә очрашырга тиеш булсалар да, Сирин Кремльнең Спасс манарасы янындагы мәйданга ярты сәгатькә алданрак килде. Американнарны белмәссең, йә алданрак килерләр, аларны көттереп торырга ярамас. Беләгендәге сәгатькә күз төшерә-төшерә кин мәйданны урап чыкты һәм Муса Җәлил һәйкәле янындагы эскәмияләрнең берсенә килеп утырды. Бәхеткә, аларның барысы да диярлек буш иде. Американнар белән шулай бик тиз генә танышып китүенә, аларның, һичшиксез, киләсенә ул юньләп ышанып та бетми иде әле. Азмыни Казанда аның кебек күргәзмәгә йөрүчеләр, кызыксынучылар...

Утырды да уйларына чумды. Нинди кешеләр икән соң бу американ дигәннәре? Алар, чыннан да, шундый гади һәм аралашучан микәнни? Гомер бакый безнең илгә дошман дип саналган, дошман күреп яшәгән океан артындагы мәмләкәттә шундый дустанә кешеләр яшиме? Чит ил кешеләре белән юньләп аралашканы булмаган, кызыксынучан холыклы Сирин өчен сораулар артык күп иде. Тик аны шунысы сөендерә, һәрхәлдә, бүген бик күп сорауларына җавап табылыр кебек.

Кремль чаңнары кичке биш тулганны белдереп суга башлаганда, колак төбендә генә таныш тавышны ишетеп сискәнеп китә язды. Ул аларны цирк ягыннан килерләр дип көтә иде, ә алар бөтенләй башка яктан—Ленин урамы ягыннан килеп чыкканнар икән.

Илдар елмаеп кул сузды:

—Менә без килеп тә җиттек,—диде ул күптәнге танышына эндәшкәндәй.—Таныш бул, әнием Оркыя Акчурина, ә сеңлем белән сез күргәзмәдә инде танышып өлгергән идегез бугай.

Икесе дә бердән джинсы чалбар кигән Илдар белән Галия янында гап-гади бер хатын басып тора иде. Колакларында, гадәттә, татар хатыннары тага торган ярымай рәвешендәге алтын алка, беләгендә нәкъ татар авылларындагыча бизәкле көмеш беләзек... Кулында бераз таушала төшкән, әмма элеккеге затлылыгын югалтмаган, илленче елларда модада йөргән кечкенәрәк ридикюль. Сирин хәтта сәерсенеп куйды. Әгәр Илдар, әнием, дип таныштырмаса, Сирин аны каяндыр Мөслим, Балтамак яисә Сарман якларыннан килгән берәр укытучы-фәлән дип уйлар иде.

—Вәгъдә иткәнчә, мин сезгә бүген шәһәр күрсәтермен. Яңа микрорайоннарны карыйбызмы әллә искерәк урамнар кызыксындырамы?—диде Сирин, һәммәсе белән баш иеп күрешеп чыккач.—Табигый ки, кире уйламаган булсагыз...

—Юк, юк... Без рәхәтләнеп йөрербез,—диде барысы өчен дә Илдар.—Югыйсә, инде ничә көн Казанда торабыз, ә борынгы пайтәхетебез белән юньләп таныша алганыбыз юк.—Аннары әнисе белән сеңлесенә борылды.—Әни, синең беренче итеп нәрсә карыйсың килер икән?

Оркыя ханым, күрәсең, Казанда ниләр караячагын, кайларда йөриячәген алдан ук тәгаенләп куйган, башта Сирингә, аннары Илдарга карап алды һәм бер генә дә икеләнмичә теләген белдерде:

—Иң элек, улым, мәчеткә барып килербез, аннары шәһәрнең Татар бистәсендә йөри алсак, начар булмас иде... Шулаймы, кызым! Әллә нишләп Казанда татарлык җитми башлаган кебек тоела миңа. Бу татар шәһәре түгелдер сыман... Монда кан-кардәшләребез тупланып яши торган берәр урын бардыр ич!..

—Әни, Казанда синең сүз—безгә канун! Балачагың эзләре сакланган

кала ич бу. Хәтерендә янартыр әйберләр күптер,—дип елмайды Галия әнисенә һәм Сирингә борылып карарга да онытмады.

Бу кызда кешеләрне бер күрүдә әсир итә торган ягымлылык, садәлек бар иде. Андыйлар турында Балтамакта «бигрәкләр дә мәхәббәтле бала инде» дип сөйлиләр. Бу нәкъ шундый бала икән, дип уйлап куярга өлгерде Сирин һәм үз чиратында елмаеп җавап бирде:

—Мәйлегез, мин—сезнең ихтыярыгызда!

Татар башкаласындагы соңгы могиканны—Мәрҗани мәчетен карап чыктылар. Аннан соң бик озак Кабан күле буендагы, Болак аръягындагы Иске бистә урамнарында йөрделәр. Монда һәр нәрсә борынгы татар тормышын хәтерләтә иде әле. Оркыя ханымның күзләре яшьләндеме, ул ридикюленнән кульяулыгын чыгарып берничә тапкыр читкәрәк карап торгандай итеп алды. Илдар белән Галия дә сүзсез иде. Мәрҗани яшәгән, Тукай иҗат иткән, Фатих Әмирхан эзләрен саклаган, башка зыялылар көн күргән җирләрдә, татарның кибет-базарлары шаулап торган, матбагалары гөрләп эшләп утырган урыннарда йөрүдән Сирин үзен дә борынгы тормышка чумып алгандай хис итте.

Кайту ягына сүзсез генә борылдылар.

—Хәзер мин яши торган хөҗрәне дә карап чыгарбыз инде,—диде тынлыкны бүлеп Сирин.—Вәгъдә иткәнчә, анысы да программда каралган.—Ул инде яна танышлары белән аралашудагы җинеллекне тоеп алган һәм аларча итеп сөйләшүдән тәм таба башлаган иде.—Анда безне Хәдичә апам көтәдер... Өчпочмакларым суынганчы кайтып җитегез, дип калган иде.

Такси туктаттылар да янадан Ленин урамына менеп киттеләр.

Соңгы елларда шактый бирешә башлаган карт биючене танырлык түгел иде. Кайсы сандык төпләрен актаргандыр, бу хәтле зиннәтне кайда саклагандыр—кунаклар каршында сигезенче дистәне куып баручы карчык түгел, әйтерсең, борынгы аксөяк бикә басып тора иде. Башында энҗеле бәрхет калфак, иңнәрендә ефәк шәл, аякларында чигүле читекләр, куе зәңгәр төстәге озын күлмәге өстеннән укалы камзул киеп җибәргән.

Хәдичә апаның киемнәренә аеруча сокланучы Оркыя ханым булды.

—Ай, Аллакаем, сездә әле мондый затлы, милли киемнәр дә саклангалмыни? Аны әле һаман да кияләрмени?—дип сөйләнде ул.

Хәдичә апа белән алар беренче күз карашыннан ук уртак тел таптылар.

Чәйләр эчеп, танышып, сөйләшеп алгач, Илдар Сиринне хатын-кыз таифәсеннән аерып алды.

—Минем бер йомышым бар иде. Артык катлаулы түгел түгелен... Ярдәм итә алмассынмы, димәкчемен. Хикмәт шунда, безнең инде Казанда торыр көннәребез күп калмады, шуңа күрә, синнән үтенмәкче идем,—дип башлады ул сүзен шактый еракган уратып.

—Һич кенә дә авырыксынмыйм, әгәр кулымнан килердәй икән, нигә ярдәм итмәскә ди әле,—диде Сирин.—Зинһар, читенсенмәгез, әйтегез, ниндирәк йомыш инде ул?..

Илдар иңсәсенә аскан күн букчадан бер конверт чыгарды һәм Сирингә сузды.

—Менә шушы хатны үз кулың белән җөмһүриятнең югары хөкемханә оешмасына яисә гаделия министрлыгына* тапшыра алмассыңмы, димәкче идем. Җавабының ниндилегенә карамастан, аны безгә, Нью-Йоркка җибәрергә кирәк. Бу безнең гаилә өчен бик мөһим бер гамәлләр. Шуңа күрә, аны без болай гына... ул оешмага биреп кенә китә алмыйбыз. Кемнеңдер кызыксынып торуы кирәк. Беләм, бәлки, өстәмә мәшәкать ясый торганбыздыр...—Илдар букчасыннан акча янчыгы чыгарды, үзе, Сирин баш тартыр, дип курыккандай, ашыга-ашыга сөйләвен дәвам иттерде.—Шулай да, мин бик үтенер идем. Әгәр нинди дә чыгым буласы

*Гаделия министрлыгы—юстиция министрлыгы.

икән, аны һичсүзсез күтәрербез... Без...

Американ егетенең ни эшләргә жыенганын сизенгән Сирин гажәпләнүен яшерә алмады, иңнәрен жыерып куйды. Аның бу хәрәкәтен икеләнү дип кабул иттеме, Илдар, яңа танышын тынычландырырга теләгәндәй, конвертны ачып, аннан дүрткә бөкләнгән берничә бит кәгазь чыгарды:

—Сез боларда әллә ниләр язылган дип уйлый күрмәгез тагы. Хат савыты ачык, теләсәгез, һич тартынусыз алар белән таныша аласыз. Шикләнмәгез, бу кәгазьләрдә бернинди сер юк...

Сирин яңа дустын уңайсыз хәлдән чыгарырга ашыкты:

—Юк, юк, миңа моның бер авырлыгы да юк. Һәм берни дә кирәкми. Зинһар, борчылма! Кирәкле жиренә, әлбәттә, кертеп бирермен. Аннан гына аягым калмас лабаса! Сезгә ышанмасам, алай димәс идем!

Ике егет каты итеп ирләрчә кул кысышты.

Кунаклар кат-кат рәхмәт укып китәргә жыена башладылар. Хәдичә апа тиктормас телен бу юлы да тыеп кала алмады:

—Оркыякаем,—диде ул йөрәгеннән өзелеп төшкән тавышлар чыгарып,—сер сыя торган кешегә охшагансың. Күңелемә шул хәтле хуш килдегез, жибәрәсем дә килми хәтта.—Һәм кинәт хәйләкәр елмаеп Сиринга карап алды, үзе исә Оркыя ханымга атап сөйләвен дәвам иттерде.—Һич тә мактанмыйча әйтәм, алтын багана бу минем егетем. Синең дә зөбәржәтең бар икән... Асыл ташка алтын кыса кирәк буласы инде ул, әлбәттә. Киләчәктә, бәлки, кулыбызга зөбәржәт кашлы алтын йөзек кию хакында уйлашсак та комачауламас иде, димәкче идем...

Аның сүз төбендә ни ятканын Оркыя ханым гына түгел, Галия белән Сирин дә бик яхшы аңладылар. Америка тәрбиясе алган Галия шәрекъ дипломатиясенең чуклы-чачаклы тезмәләреннән елмаеп кына куйса, Сириннең битенә куе кызыллык йөгерде.

—Хәдичә апа, бу сүзеңне хет бүгенгә калдырып тор инде,—диде ул ризасызлыгын яшереп тормыйча һәм аның сүзләрен уенга әйләндерергә тырышты.—Чит ил кешеләре үзеңне ювелир дип уйламасын...

Көтмәгәндә Хәдичә апа кабынды да китте:

—Чит илнеке булса да чит кеше түгел алар безгә,—диде.—Ә сиңа инде күптән монах булып яшәвеңне ташларга вакыт! Башта университет бетерим, дидең, аспирант-маспирант булып йөрдең, хәзер кандидат-мандидатлык якларга кирәк, дисең. Ә синең үзеңне кем яклар? Тагын күпме шулай йөрергә була? Мин сине яклап сөйлим...

Каршы сүз әйтсә, Хәдичә апаның сүз тегермәнен мәңге туктата алмаячагын яхшы белгән егеткә телен тешләргә генә калды.

Хушлашып урамга чыктылар.

Икенче көнне иртән тиешле оешмаларның берсендә Дамир Гыймаев өстәленә мондый донесение ятты.

*«Сез тәгаенләгән объект 23 август көнне 17.00 дә Кремль янында Америка гражданнары: Оркыя, Галия, Илдар Акчуриннар белән очрашты. 17.30 да алар Казанның ислам дине сәременнән айный алмаучы диндарлары туплана торган Мәржәни мәчетендә булдылар. Мәчет янында Оркыя Акчурина теләнеп утыручы хәерчеләр белән бик озаклап сөйләште, мәчеткә кергәч, картлардан нәрсәләрдер хакында тәфсилләп сораштырды, аларга мулдан сәдака өләште. Ул картлар белән алга таба эшне «Изге» дәвам иттерәчәк. Аннан соң объект чит ил гражданнарына Идел Буе районының иң пычрак, туристлар өчен эстетик кыйммәте булмаган, ярымжимерек урамнарын күрсәтеп йөрде. 20.08 дә такси алып Ленин урамындагы фатирга кайттылар. 23.17 дә объект американнарны озатырга чыкты һәм алар белән кунак йортына кадәр килде. 23.59 да фатирына кайтып керде һәм бүтән чыкмады. Объектның фатирда чакта американнар белән ни хакында сөйләшүе билгеле түгел. Аны ачыклау эше башкарылачак.*

*Күзәтүче».*

* * *

Ни өчен Сирин ялгызы гына соң әле? Әллә Асия аны көтмичә кияүгә чыгып киткәнме? Юк! Барысына да Сирин үзе гаепле. Ул кайткан елны Асиялар курсы университетны тәмамлаган, студентлар төрлесе-төрле якларга таралган иде инде. Асия Сиринне эзләп берничә тапкыр килсә дә, егет аның белән очрашудан качты. Баш өстендә менә-менә өзелеп төшәргә тиешле кылыч тоеп яшәгән егет, Асияны да шул кылыч астына кертергә теләмәде. Вакыт узсын әле, үз хәлемне үзем бераз аңлыйм, аннары табармын мин аны, дип мең сәбәп табарга тырышты, үзен үзе юатты.

Сирин атлы егетебез ана тугрылык саклап көткән Асиядан баш тартып дөрес эшләдеме? Анысы да безгә билгесез. Бәлки, дөрестер дә... Ул гаилә барыбер таркалырга хөкем ителгән булыр иде. Сирин белән аерылуны бик авыр кичергән кыз бик озак әле кияүгә чыкмаган. Сонра аның тыныч, сабыр гына холыклы бер урыс егете белән кушылып, ярым татар, ярым урыс телле балалар үстереп ятуы турында ишетелде. «Әни, дай мне ипи»,—дип бытылдап йөрүче бу нарасыйлардан киләчәктә үзләрен «бөек милләт вәкиле» санаячак төзәтеп булгысыз кемсәләр чыгасы да билгеле.

Ә инде Әмиржан Акчуринның эшен яңадан карауны һәм аны аклауны үтенеп язган хатка Чита өлкәсе прокурорыннан шушындый хат килеп төште.

*«Ә. Х. Акчуринны рәсми аклау турындагы Сезнең хатыгыз буенча өлкә прокуратурасы архивтагы җинаять эшен тикшерде. Тикшерү күрсәткәнчә, Ә. Х. Акчурин 1934 елдан Чәнчүн шәһәрендәге советка каршы милләтче «Идел-Урал» оешмасы әгъзасы һәм аның сәркәтибе, ә соңыннан, 1945 елдан шушы оешманың рәисе урынбасары буларак, үзенең практик эшчәнлегендә татарларны Советлар Союзына нәфрәт рухында тәрбияләгән, оешма алдына Иделдән Уралгача җирләрне Советлар Союзыннан аерып алып, анда Япония кулы астында милли-буржуаз дәүләт төзүне максат итеп куйган өчен Байкал аръягы-Амур хәрби трибуналы тарафыннан РСФСР Җинаятьләр кодексы 58-11 статьясы буенча 8 елга ирегеннән мәхрүм ителгән. Моннан тыш, Акчурин япон сугыш чукмарларына матди ярдәм күрсәткән һәм «Идел-Урал» оешмасы әгъзаларын да шуңа чакырган.*

*Акчурин һәм Гыйльман, милләтчел «Идел-Урал» оешмасы җитәкчеләре буларак, бу оешма әгъзаларында Иван Грозный заманнарыннан бирле татар һәм башка мөселман халыкларын изеп килүче урыс халкына нәфрәт уятканнар, урысларга каршы көрәшкә тупланырга чакырганнар, Советлар Берлегенең Иделдән Уралгача җирләрен аерып алып, анда мөстәкыйль һәм бәйсез Төрки-татар дәүләте төзергә теләгәннәр. Мондый шартларда суд Ә. Х. Акчуринны, РСФСР җинаятьләр кодексының 58-2 һәм 58-11 маддәләрендә каралган җинаятьләрне эшләүдә гаепләп дөрес нәтиҗә чыгарган һәм гамәлдәге закон нигезендә аны дөрес хөкем иткән. Ә. Х. Акчуринга карата кулланылган хөкем карарын юкка чыгару һәм аны аклау өчен нигез күрмим.*

*Сезнең хатыгыз канәгатьләндерелмичә кала».*

* * *

Казанның Киров урамындагы пыяла сыраханәдә кичкә таба «Профессор» кушаматлы бер кеше күренә. Ул эшкә килгән кебек йөри. Ләкин һичкайчан егылганчы эчми, тиешле бер вакытын уздыргач, үзенә генә мәгълүм күләмдәге сыраны озаклап, тәмләп исраф иткәч, акрын гына чыгып гаип була. Ул килмәгән көнне аны хәтта юксына башлыйлар. Чөнки түшәмгә эленгән чебен ябыштыргыч тасмалар, өстәлләрдәге тозлы балык калдыклары, мең кеше бармагын тыккан кайсы ватык, кайсы китек

тоз савытлары сыман «Профессор» да сыраханәнең кирәкле бер атрибутына, хәтта аның мактанычына әйләнгән иде. Көнен-төнен шушында уздыручы эчкечеләр дә, эштән кайтышлый гына сусынын басарга дип сугылучылар да аны белә, хөрмәт итә. Ул теләсә нинди сузгә катнашмый, әмма аның белән сөйләшергә туры килгән кешеләр «Профессор»ның чын мәгънәсендә тирән белемле, зыялы кеше икәнен чамалыйлар. Хәтта аның белән сөйләшер, киңәш сорар өчен махсус киләләр. Бары тик июньнең унынчы көнендә генә «Профессор» сыраханәдә күренми. Бу көнне ул югалып тора. Яшьли үлгән иң якын дустының каберенә бара торган көн ул.

Менә инде икенче ай «Профессор»ның сыраханәгә килгәне юк. Баштарак аны сагынып сөйлиләр, хәтта урынын саклыйлар, кемгә дә утырырга рөхсәт итмиләр иде. Ләкин... вакытлар үтү белән ул да онытылды. Түр башындагы урынын икенче берәү алды.

Сыраханә үз тормышы белән яши бирә. Кружкаларда сабын, сода һәм су кушылган, ат бәвеленә охшаш сыра күбекләнә... Монда йөрүче кеше язмышлары да шул күбек шикелле. Алар да шулай ак өметләр уятып кабаралар, шиңәләр, шартлыйлар...

«Профессор»ның кая киткәнлеген, кайда югалганлыгын беркем дә әйтә алмады. Бик тә аяныч... 1960-1962 елларда Кариб диңгезендә кабыначак өченче дөнья сугышы учагында ялкын дөрләтергә тиешле, әмма әзерлексез стратегик ракета гаскәрләрендә дәһшәтле сынау узган йөзләрчә башка татар егетләренеке кебек, аның да алдагы язмышы миңа билгесез.

АВТОРДАН. *Әсәрнең соңгы битенә килеп җиткән кадерле укучым! Менә Сез күләме буенча артык зур булмаса да, тасвирланган вакыйгалары белән милләтебез язмышында гаять катлаулы, сиксән елга якын чорны үз эченә алган роман белән танышып чыктыгыз. Аның Сезнең күңелләрдә дә мин кичергән хисләр өермәсен кузгатуын телим. Мин аны бик яратып, сурәтләнгән геройларым өчен бөтен җаным-тәнем белән борчылып яздым, дүрт ел буе алар тормышы белән яшәдем. Геройларның исемнәре алыштырылса да, романда сурәтләнгән вакыйгалар—барысы да тормышта булган хәлләр. Кулланылган аерым документлар да рәсми чыганаклардан алынды. Шул ук вакытта роман документаль әсәр дә түгел. Күп нәрсәләрнең автор хыялында үзгәрешләр кичерүе табигый хәлдер.*

*Минем дә геройларымны исән итеп, бәхетле язмышлы кешеләр итеп күрәсем килгән чаклар булды. Кулымдагы каләм көченнән файдаланып, бәлки, мин аларның язмышын үзгәртә дә алган булыр идем. Ләкин... Ләкин ул инде уйлап чыгарылган вакыйгаларга әйләнер иде. Никадәр кызганыч тоелмасын, тормышыбыз шундый. Аны ясалма рәвештә бизәүнең дә һәм, шул ук вакытта, ямьсезләүнең дә кирәге юктыр.*

*Мин моһаҗирлыктагы каһарман милләттәшләребезгә һәм сугыш елларында туган, яшьлекләре бөреләнеп кенә килгәндә ракета гаскәрләренең касәфәтен күргән, вакытсыз вафат булган егетләребезгә сүздән һәйкәл куюны максат иттем.*

1996—1999.
Түбән Кама—Переделкино—Казан.

## ШИГЪРИЯТ



# Рим Идиятуллин

## ШИГЫРЬЛӘРЕМ—ЯШӘҮ ХАКЫНДА

### Толлар урамында

*Гөлҗамалның бер төне*

Яшьләргә куш! Тавышларын
Бар галәмгә чәчәргә,
Белмиләр дә, корт-корының
Торасы бар сәхәргә.

Вәт азгыннар! Түбән очтан
Булмыйдыр шул үтәргә,
Сынык җаннарның күңелен
Нигә кирәк үртәргә?!

Бәлки берчак урамымнан
Гармун тартып узарлар;
Моңнарының бер тәме юк,—
Тәмсезләнде дөньялар...

Өй турымда туктап, бәлки,
«Гөлҗамал»ны сузарлар;
Җырларының җылысы юк,—
И суынды дөньялар!

Таң атканчы бәлки әле
Тагы бер кат урарлар;
Сылу түгелдер кызлары,—
Картайды ич дөньялар.

... Без балавыз булып калдык
Бал тулышкан кәрәздән;
Ай көлгәндә яшьлегемә
Күз салыймчы тәрәздән...

### *Миңсылуның кичке уе*

**Байый кояш ындыр артымда...**
**Җитмеш тулар иде картыма.**
**... Гарифҗан да күптән ялгыз да бит,**
**Сүз тишәргә никтер тартына.**

### *Зар*

**Битләремне терәп кайттым**
**Картым каберенә кичә;**
**Барганда да, кайтканда да**
**Җиле гел каршы исә.**

### *Теләк*

**Кое сиртмәсе очына**
**Менеп кунгач та кояш**
**Бу көннең зәңгәр төсләрен**
**Бетерер инде ашап.**
**(Яшьлектә калыйк яшәп!)**

**Чыклардай чиста икән лә**
**Гомерләрнең иртәсе;**
**Башларың күккә чөелә,—**
**Нәкъ шул кое сиртмәсе.**
**(Килмәсен картлык исе!)**

### *Келәт алдында*

**Кырмыскалар чаба, йортын-җирен**
**Туздырган шул кайсы явыздыр,**
**Бүрәнәгә башын салган берсе,—**
**Ул да, бахыр, ялгыз калгандыр.**

### *Мирас*

**Дөнья көтү—көтү көткән кебек,**
**И чабасың, бетә җегәрең;**
**... Өй буш, салкын... саклыйм карткаемның**
**Мич алдында калган түмәрен.**

### *Нигә генә?*

**Уйламадым түгелер дип,**
**Учымдагы бодаем;**
**Алыр булгач, нигә генә**
**Бирдең икән, Ходаем?!**

## *Кабер казучы*

Казый иде жырлый-жырлый,
Бүген казый жылый-жылый.

Акса да яшь күзен тырнап,
Кулда көрәк тора уйнап.

Аптырарлык түгел һич тә:
Шушы эштә—ике дистә...

Казыганын чыксаң барлап,
Рәхмәт укыр мең-мең әрвах.

Хәер, күптер ләгънәте дә,—
Бәндәләрнең «лөгате»нә

Сыймасны да чутсыз кылды,—
Иссә хәтер—кысар тынны.

Тап булырмын дип «алтын»га,—
Җитте, залим, биш хатынга;

Биш хатыннан—алты сабый,
Алтысын да чит-ят саный;

Балалары бер хәл әле,—
(Булды ярдәм кылган мәле),—

Үз энкәсен читкә типте...
Ә ул—
Кичәгенәк үлеп китте...

... Белми булыр диеп язык,—
Мышный бүген кабер казып;

(Булышырга кемгә кушсын,—
Дошман күрде күрше дустын).

... Бермәл күккә күз терәде:
«Күккә дәме юк кирәге?!.»

Ялтлап яшен, күк күкрәде,
Ап-ак дөнья күм-күгәрде;

Утлы уктан сынды көрәк,
Тар кабергә башын терәп
Ауды өрәк...

* * *

Ихатада эт өере,—
Әйтерсең ач бүреләр,
Сынган үлән булып ята
Шарт киселгән гомерләр.

Баскан, яткан җирләрем дә
Салкын таш булыр кебек,
Күп тә үтмәс, бу дөньяга
Этләр баш булыр кебек.

* * *

Ябык шагыйрь дә симерде:
Данның майлы өйрәсен,
Кашыклап түгел, чүмечләп
Чөмергәнгә, күрәсең.

### Багышлау

*Нажар ага Нәҗмигә*

Җирнең тәмен арттырырга
Мөмкиндер дә ул ашлап,
Шигырь тәмен кем арттырыр
Нажарлар китсә ташлап?!

*1997—1998*

## Улым үлеменә багышланган шигырьләр

### *Күңел күнегер булса...*

Йөрәгемне ярыр идем,—
Кайгым түгелер булса.
Әгәр, улым, үлемеңә
Күңел күнегер булса
Каһәрләр идем үземне,
Бир, Ходаем, түземлек!

Минут эчендә сүндерден
Бөтен яктыларымны,
Иделләрнең чоңгылына
Күмдең шатлыкларымны.

Бу дөньяда яшәсәм дә
Ай-кояшны танымам;
Галәмгә сыймас җылымны
Суырдың шул җанымнан.

Ак Иделгә карасам да
Йөзкәйләрем карала.
Ходай, башка бәндәләрне
Бу кайгыдан арала.

*2 август, 1998*

Сүрелер, бәлки, ялкыным,
Салкын җилләр иссәләр;
Һушларны ала икән шул,—
Хушлашмыйча китсәләр.

Төн буена төньяклардан
Бөркү җилләр исәләр;
Аягүрә үләр идем,—
«Ул бит исән!» дисәләр.

Чишмәгә ятып су эчәм,
Чишмә суы да кайнар;
Аңладым кеше хәлләрен,
Минем хәлне кем аңлар?!

Күкләрдән җиргә атыла
Серле, сәер тавышлар.—
Ни галәмәт?—кышлар өчен
Төньякка китә кошлар.

* * *

Туксан яшьлек әби ята,
Үлем көтеп ята һаман;
Килен-улның тәкатьләре
Корып беткән инде тәмам.

Күрше йорттан бер егетне
Унҗидедә сулар алды,
Башка сыймас бу кайгыдан
Ата-ана гаҗиз калды.

Бу ни хикмәт?—әҗәлләрен
Берәү көтә, берәү көтми;
О, Тәңрем!
Җуй гакылны!—Барыбер дә
Безнең аңга барып җитми.

* * *

*Бирде дөнья кирәкне,*
*Еламаска өйрәтте...*

Хәсән Туфан.

Сикерәдер бу йөрәгем
Кырлы да үрле,
Җеп өзәрдәй хәлләрем юк
Иртәдән бирле.

Күзләремнең чылanганын
Дусларым күрде,—
Мин елый алмый башладым
Шул көннән бирле.

* * *

Сулар да сипкән идем бит,—
Бүлмәңдә гөлләр сулган;
Өстәлеңдә биш кат тузан,—
Туганымдай ул тузан.

Сулар да сипкән идем бит,—
Ул гөлләр соң ник сулган?
Сүндерегез Ай-учакны!—
Дөрләрмен күк бер куздан.

Өстәлдәге тузаннарны сөртмим инде,
Гөлләргә дә сулар сипмим инде...

* * *

Базарда бер җыр яңгырый,
Моңы бик таныш кебек,
... Кайларгадыр кемнәр белән
Китепләр барыш кебек.

Юл читендә кәрлә үлән,
Уңмаган арыш кебек;
Тәрәздән өргән җил биткә
Сибелгән сагыш кебек.

Күлнең зәп-зәңгәр күзләрен
Оеткан җылы томан;
Улымның сап-сау башларын
Иңбашларымда тоям.

Бер гөнаһсыз бәндәләргә
Сарылмыйдыр ла каргыш?!
Шатлык—төссез, кайгы—төпсез,—
Аралары бер карыш.

Машинада моң яңгырый
Йөрәкне өтеп алгыч;
Шартлар идең—күрәчәгең
Алдыңа килсә ялгыш.

Елак моңнар тирбәлгәндә
Егылып кала арыш...
Бу—улымның үләсенә
Ашкынып кайтып барыш...

* * *

Юл өстендә үлгән кош ята;
Алма сата әби шул чакта;
Тукта, тукта! Нигәр генә уйлап
Шигырь язам соң мин бу хакта?

Кош—ка-ап-кара, алма—ап-ак;
Мин табындым гелән шау акка;
Алыр идем алма, үлгән кошны
Мин күрсәтмәс идем ул чакта.

Көннәр елак, төннәр йончу чакта
Торыр идең, улым, син сакта.
Ниләр генә уйлап, нигә генә
Шигырь яздым соң мин бу хакта?!

Юл өстендә үлгән кош ята;
Алма...

*1998*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



### Мәгъсум Хуҗин

# ИКЕ ХИКӘЯ

### Каңгый иләндә

Агач түбә әйләнәсенә чыпчыклар чыркылдашып атылалар да, жим чүпләгәч һәм сөенешеп серләшкәч, алмагач ябалдашына дәррәү менеп куналар. Бераздан җиргә тагын мактанышып төшәләр, аннары тагын агачка җырлашып ябырылалар. Алар, шулай өерелеп очканда да, агач ботакларына һич тә бәрелмиләр, бер-берсенә ялгышып та комачауламыйлар.

... Ничек шулай булдыра алалар икән алар? Ничек осталыклары җитә икән аларның моңа?..

Хәяли тәбәнәк читән буена, баш-башларына юкарак ташлар кыстырып, әйләндереп каплаган ярык тагарак өстендә утыра иде. Каршыдагы күршеләренең алмагачларына кунып-төшеп рәхәтләнүче чыпчыклардан көнләшеп тә куйды ул—аларга агачта да, җирдә дә тамак туйдырырга җим муллан, аларның киемнәре җәйгә дә, кышка да ярый.

... Әллә очышта чыпчыкларның бер-берсенә комачауламаулары сәбәбе бүтәндәме икән? Мөгаен, алар тамак туйдыруда бер-берсенә ярдәмләшәләрдер, югыйсә өергә җыелып сөенешмәсләр иде...

Хәялине уйларыннан ат аягы тавышлары бүлде. Җигүле ат. Тарантаска җигелгән бугай, кешесе-кешеләре күренми. Аты олы гәүдәле. Дугасы күккә тия, диләр җигүле мондый атлар турында. Йөгәне һәм шлеясы алтынсу төймәләр белән чуарланган күк атның адымнары эре. Безнең авыл аты түгел, дип тәгаенләде малай.

... Авылга кунаклар киләдер. Их, кешеләр кунакка да йөрешәләр. Әллә безгә турылыйлар инде? Без кунак чакырмадык ла. Әй, кунак чакыру, ди, үзебезгә ашарга да...

Тарантас Хәяли турысына житкәч, дилбегә тоткан агай атны дәшеп туктатты. Ул кара кыска мыеклы, башына тар читле тәбәнәк эшләпә кигән. Шәмәхә күлмәге, тышланган затлы тире камзулы агайны абруйлы, зыялы итеп күрсәтә. Тарантастан ашыкмыйча гына төште ул, дилбегәне янәшәсендә утырып килгән хатынга тоттырды, аңа акрын гына:

—Син кузгалмыйча тор,—диде дә Хәялигә таба атлады.

Малай тезләре өстендәге карындык тышлы әфтиякне уң кулы белән алып күкрәгенә кысты, сул кулы белән артындагы читәнгә үрелеп тотынып, аягүрә басты.

—Әссәламегаләйкем!

—Вәгаләйкемәссәлам!—дип агайның сәламен олыларча алды Хәяли.

Агай Хәялине башыннан аягынача сөзеп, гаҗәпләнеп карады. Аның каршында чыра юанлыгыдай алты яшьләр тирәсендәге малай тыйнаклыгын кинчә йөзендә сиземлерәк чагылдырырга тырышып басып тора иде. Шомаруга житкән кара бәрхет түбәтәенең авырлыгын тырпайган колаклары гына күтәрәдер—түбәтәе үтә зур, димәк, үзенә атап тегелмәгән, әтисенеке яки бирәр бабайныкыдыр. Чәчләрен түбәтәе бөтенләй каплаган, чәчләре төсе, кашлары кебек булса, чем карадыр. Җилкәләре салынкы ук түгел үзенең, ит кунса, киңәеп төзәерләр. Карындык тышлы китабын очлы күкрәгенә кыскан куллары тиредән дә сөяктән генә торадыр... Ә... Ә якты шар күзләре ябык йөзен мөлаемландыра, әй.

Булса да булыр икән тән ите кипкән бала, дип уйлады агай. «Синең өчен килдек микәнни?»—дип сорыйсы килде аның. Тик ул тәненнән җаны китәргә торган малайны күрүдән гаҗиз иде.

Агайның мондый халәтен малай сизде-аңышты. Ул, агайның әйтелмәгән соравына турыдан җавап кайтарырга теләп, үзен олыларча тотып:

—Менә шундый инде мин,—диде.—Сез мине алырга килгән булырсыз.—Малайның тавышында каушау юк иде, шулай да аның:—Алсагыз...—дип сузуында шөбһә беленеп алды.

Монысы инде агайга турыдан бирелгән сорау иде. Агай моңа капылт җавап кайтармады, тарантаста аптырап утыручы хатынын, ымлап, янына чакырды. Шуннан соң малайга:

—Күрешик әлгәре... кем, дим соң...—диде.—Минем исемем—Хуҗанур, ә хатыным Мөсәгыйдә була.

Малай да исемен әйтте.

—Хәяли... хыялый бала күренәсең шул,—дип дәвам итте агай һәм:—Бу кадәресе әйбәт,—дип нәтиҗә чыгарды.

Хуҗанур белән Хәяли ике куллап күрештеләр, малай карындык тышлы юка китабын култыгына кыстырып торды. Мөсәгыйдә Хәялинең аркасына ике куллап кагылып алды, үзенә тартып сөясе килде бугай, әмма моңа җөрьәт итмәде.

—Утырып гәпләшик,—диде Хуҗанур.

—Өйгә узыгыз. Анда кеше юк үзе.

Агай урам як читәннән ун аршин чамасы эчкә кертеп салынган, инде бүрәнәләре карасуланган тәбәнәк өйгә текәлеп карады. Йортның түрдәге тәрәзәләре (икәү) йөзлекләре бизәксез такта (инде унган) иде, ә пыялалары чиста-ялтыравык иде. Салам түбә өстендәге бастырык-колгаларның башлары өстә тигез озынлыкта иде, тар өйалды түбәсе кыеклап-шатрунлап төшерелгән иде.

—Әниең өйдә түгелмени?—дип сүзгә кушылды Мөсәгыйдә, әмма аны ире ишарәләп туктатты.

—Өйдә кеше юк, дим ич.

Алар утырдылар. Хуҗанур бөтен гәүдәсе бизгәк тоткандагыдай калтыраган хатынына Хәялинең сул ягына утырырга ымлады, үзе уңнан урын алды. Малай аларның кайсына карарга белмәде, каушый төште, шулай да, Мөсәгыйдәнең йомшак кулы аркасына тиеп алгач, тынычланды, шул мәл хатынның дерелдәвен дә бетерде. Малай белән хатынның бер-берсен баштан ук үз итешүләре билгесе идедер бу. Әмма соңгы сүзне әйтүнең Хуҗанурда икәнлеген алар икесе дә беләләр иде. Ә Хуҗанур әлегә эндәшмәде. Һәм алар шактый ук вакыт сөйләшмичә утырдылар. Ниһаять, агай:

—Әниең...—диде,—Дәрига исемле бит әле, әйеме.—Җавап та көтмәстән, сүзен дәвам да итте.—Әниең Дәрига тиз кайтырмы соң? Монда хәтле килгәч, аны күрмичә китү ярамас.

Агайның карарын төгәл белдермәве Мөсәгыйдә белән Хәялине сискәндерде, икеләнергә урын калдырды аның бу сүзләре. Шулай алайса, фикерен тәгаенләмәгән икән әлегә Хуҗанур агай. Ләкин ат кузгалып, аны Хуҗанурның каты ук дәшеп туктатуы хатын белән малайның уйлары тирәнәюгә ирек

бирмәде. Агай йөгән тезгенен, дуга бoжрасыннан ашыкмыйча чыгарып, иннек капканың тәбәнәк баганасына чалды. Ул шушы эш белән мәшгуль арада Мөсәгыйдә Хәялине аркасыннан тагын сөеп алды, малай аның җылы-йомшак тәненә елышарак төште. Хуҗанур, урынына килеп утыргач, тезләре башларын учлары белән ышкыды да малайга тагын карап торды, аннары, иеләрәк төшеп, карашын җиргә төбәде, тамагын кырды.

—Алай икән...—Хуҗанур тагын тамагын кырды.—Син, Хәяли, өнле бала икәнсең, әфтияк укыйсың икән. Синең яшьтәгеләр хәреф тә танымый бит әле,—дип әһәмиятле сүзне читләтеп башлады ул.—Әфтияк сүрәсен башламагансыңдыр әле.

—Башладым инде!—дип сөенде малай.—Ижексез укыйм инде әфтиякне! Мине Хәбия өйрәтте укырга. Ул үзе дә кечкенә әле, миннән бер генә яшькә зур. Аның әнисе—абыстай, Хәбияне әнисе өйрәтте. Мена генә аларның өе.—Хәяли бая гына чыпчыклар өере кунып уйнаган шау чәчәкле биек алмагачлар арасыннан горурланып күренүче йортка күрсәтте. Тик анда, әле җиргә атылып, әле алмагачларга ябырылып, чыпчыклар очмыйлар иде инде, каядыр киткәннәр икән. Хәяли моны күңеленә нигәдер салып куйды да:—Укыйммы соң?—диде.—Мин тәһарәтле үзем. Ә, ярар, алайса, өйгә кергәч укырмын, яме.

—Ярар, ярар,—дип куәтләде аның теләген Мөсәгыйдә.

—Тыңларбыз,—диде Хуҗанур, аңа катгыйлык хас, күрәсең, малай аның бу сүзен шулай бәяләде.—Хәзергә син үзең турында, үзегез турында сөйлә. Безгә белергә кирәк сезнең хәлләрне, белү хаер. Акылың җиткәнчә сөйлә. Дөресен. Турыдан әйтеп.

—Шулай ит, балам,—дип кушылды Мөсәгыйдә. Бу юлы аны ире ымлап та, әйтеп тә туктатмады.—Ялган-алдау катышмасын, берүк катыша гына күрмәсен. Башың әйбәт эшли икән синең, балакаем, Аллаһе Тәгаләнең кылганы булсын, шөт, ялгышмассың. Төгәле ничә яшь соң әле сиңа?—диде хатын, малайның күлмәгенә караганда таушалмаганрак камзулын тәненәрәк сыландырды.—Барысын да сөйлә, бәйнә-бәйнә сөйлә, без барысын да белергә тиешбез. Бик кечкенәдән акыл утырткансың, боларны, безнең теләкләрне, дим, үзең дә төшенәсең булыр. Үз балаларыбыз юк шул, үземдәдер гаеп, үземдә инде... Ничә яшь икәнеңнән башла, яме.

Хәяли зур якты күзләрен кул аркасы белән угалады, иреннәрен тешләштергән итте, әфтияген камзулының эчке кесәсенә җайлап салды, тирән итеп сулады. Үзе-үзләре турындагы хикәятен башларга ашыкмады ул. Аны ир белән хатын ашыктырмадылар, түзем көттеләр.

—Әфтияктән башка китапларны да укыдым инде мин,—дип башлаган иде малай, әмма Мөсәгыйдәнең соңгы кинәшен исенә төшереп:—Ә-ә, әйе, алты яшем тулып дүртенче айга китте, февраль башында туганмын мин,—дип фикереннән бүленеп алды.—Азын аз әле мин укыган китаплар. Унсигез генә. Юкалар да алар,—дип баштагы фикеренә кайтты аннары.—Латин хәрефләренә күчәселәр икән бит. Мин андый хәрефләрне танымыйм шул. Урыс хәрефләре бөтенләй дә бүтән икән. Хәбияләрдә андый китаплар да күп. Хәбиянең әтисе безнең хәзрәт бит, укымышлы да, әйбәт тә кеше ул. Мине ярата ул. Әти үлгәч, гел дә әти итеп саныйм инде мин аны. Безгә алар ярдәм итәләр. Ә алар үзләре дә ишле, уникe җан барысы. Әти үлгәч, җирләүне хәзрәт кайгыртты. Барлык чыгым алардан булды, ди әни.

Хәяли сөйләвеннән туктады. Аны ир белән хатын ашыктырмадылар.

—Әти үлгәч... Әтинең елы узган айда булды. Апрельдә. Табынны хәзрәт әзерләтте. Килгән кешеләр белән өебез тулды, ризык җитте, бүтән күршекүлән дә булышты бит. Хәзрәт әти турында, гөнаһсыз бәндә иде, яшьтән сәламәтлеккә туймады, мәрхүмкәй, диде. Әтинең башына бәрде безнең, баш өянәкле иде ул, башы чатнап-чатнап авырта иде. Шуннан, әти үлгәч, дим, әнинең ялгызына өч бала калдык инде без, аяксыздан ... шул сүз инде, бу җайда әйтелә торган сүз...

Малай тагын бүленде. Мөсәгыйдә аның зур түбәтәен арткарак этәреп куйды. Хуҗанур башын читкә борды, күңеле кинәт йомшый торган гадәте бар, күрәсең.

—Әни бик бетеренде. Без булыша алмыйбыз бит әле аңарга. Тамагын туйганчы әлләнидә бер ашагач, бетеренәсең шул инде, бетеренмичә ди... Шуннан соң әни икебезне балалыкка бирмәкче булды инде. Апам белән мине. Апама сигез генә яшь минем. Энебез бөтенләй дә бәләкәй: дүрте генә тулды. Сез мине уллыкка алсагыз, хәзрәттән дә ризалык сорый күрегез.

Хәяли кипкән иреннәрен ялады, тагын сүзсез торды.

—Хәзер сөйләп бетерәм мин. Күп нәрсә калмады инде.—Малай тагын туктады. Мөсәгыйдә аны үзенәрәк тартты, алдына утыртып сөяргә теләде бугай. Хуҗанур аларга таба карамады.—Мине кызганудан гына уллыкка алмагыз. Кызганмагыз мине, мескен итмәгез. Әни апам белән мине асрамага бирәсен әйткәч, мин үземә үзем шулай дидем.

Мөсәгыйдә бу сүзләрдән сискәнде, янгарак тайпылды, аның күзләре зур итеп ачылган иде. Шулай да ул каушавын-аптыравын сиздермәскә тырышты, яшелле-кызыллы бизәкләр төшерелгән саргылт яулыгын яңаклары тирәсендә төзәткәләде, җилкәсенә салган мамык шәлен күтәрәрәк итте дә җайлап куйды.

—Балам, юкны сөйләмә, яме!—дип кырыс кына әйтте Мөсәгыйдә.—Минем үз холкым да ирем холкына тартым. Туп-турыдан әйтеш бездә, хәйләсе дә юк, мәкере дә юк, хәрәме күптән юк.

—Мин дә шундый,—дип килеште Хәяли.

—Шулай булмыйча ди! Карале... ни... нигә өйгә кермибез соң без?—дип урыныннан торырга җыенды Мөсәгыйдә.

Әмма малай:

—Мин сөйләп бетермәдем әле,—дигәч, кузгалмады.

—Сөйлә, сөйлә, балам, бушат күңелеңне, авыр хәлләреңне исенә төшермәслек ит.

—Әни Дөррия апамны озата китте. Кечкенә энебезне дә үзе белән алды. Инде сәгать чамасы бар аларның китүенә. Тагын шул чамасыз кайтмаслар. Апамны асрамага алырга кичә килеп белешкәннәр иде. Бүген булачак әнисе үзе генә килгән. Аларның авылы бездән ун чакрымда ук булса да, безгә күрше авыл икән Дөррия апамны...

Хәяли Дөррия апасын яңа әнисенең яңа киемнәргә киендереп алып китүен әйтмәкче иде дә нигәдер тыелды. Ләкин моны Мөсәгыйдәнең күңеле сизенде бугай.

—Карале... ни...—һәм, ниһаять:—Әтисе, дим,—дип әйтеп салды ул,—нигә җебеп утырасың соң син?! Бар әле, атка су эчереп мен. Инешне уздык кына, кайда икәнен беләсең, ашарына сал аннары. Хәялиебезне тарантас башына утыртып, юк, минем алдыма утыртып алып кайтырлык булсын. Юк, элгәре өйгә кереп дога кылыйк. Җебеп утырмачы, дим, әтисе, сиңа әйтәм бит! Тарантас башы астындагы төенчекләрне алырсың. Берсендә—ризыклар, икенчесендә—киемнәрең, балам...—Мөсәгыйдә арткарак тайпылып Хәялигә карап торды да:—Киемнәрең тап-таман булыр үзеңә, балакаем...—дип урыныннан сикереп үк диярлек кузгалды.

... Нәкъ шул чакта ике авылның күрше басулары арасындагы юл читендә, тәгәрмәч эзләреннән кала бүтән төшләрен яшь чирәм каплап баручы юл читендә, кечкенә малаен һәм олы баласы Дөрриясне кочаклап, Хәялинең әнисе Дәрига елап утыра иде. Ана, күзләрен җепселләнгән яулыгы читләре белән сөртә-сөртә, кызы Дөррияненең уң кулын аның яңа әнисенең уң кулына уң кулы белән тоттырды. Кызны яңа әнисе юлның теге ягына—үзләре авылы ягына алып чыкты. Дәрига Дөрриягә кулын сузды, Дөррия ике куллап Дәригага сузылды. Ләкин юл киң үк иде, сузылган куллар бер-берсенә җитмәделәр...

Шушы вакыйгаларны тасвирларга тырышканнан соң, автор хикәясе кешеләре тормышында булып узган кайбер хәлләрне санап кына узуны кулай тапты.

... Дөррия әйбәт холыклы, уңган булып үсте, үз әнисен дә, тәрбия кылган әти-әнисен дә үзенеке итте. Бу ике гаилә туганлашты. Еш йөрешәләр

алар. Инде Дөррия кияүдә, үз балалары үсә. Дөррия тудырган әнисен дә, тәрбия кылган әнисен дә, кайнанасын да үз итә, мин бәхетле—минем өч әнием бар, дип мактанып та куйгалый ул. Бирсен Ходай—бәхет юлдаш булсын барча-барсына.

Ә Хәялине уллыкка алучылар Хужанур белән Мөсәгыйдә иде. Егерме жиденче елның май уртасында авылга кунакка кайткан чаклары иде аларның, бу чакта кырык яшь иде аларга. Асрамага-уллыкка ир бала бирелүен ишеткәч, шактый ерак авылдан килгәннәр алар. Хәялинең исә (һәм яңа әти-әнисенең дә) шул китүдән соң авылга кайтканы булмаган. Алар, өчәү булгач, ерак-еракка—таулар иленә күчеп киткәннәр, Дәригага беркайчан да хәбәр салмаганнар. Сәбәбе нидә? Кем белсен инде... Бәлки, Хужанур белән Мөсәгыйдә Хәялигә ятимлеген онытырырга тырышканнардыр... Һәм Хәяли яңа әти-әнисенең бу фикере белән килешкәндер—аның уй йөртү сәләте кечкенәдән үк акылы көченә буйсына иде ич. Шулай да Хәялигә озак еллардан соң туган нигезен күрү, аның яңа әти-әнисенә шул нигезне кабат күрергә Хәяли белән бергә кайту кадәресе насыйп булган икән.

... Алар ике жиңел машина белән кайтып төштеләр. Алдагысын Хәяли, арттагысын аның олы улы йөртә. Алгы машинада Хужанур белән Мөсәгыйдә утырган, арттагысында Хәялинең хатыны белән балалары (өчәү!) иде. Өйдә Дәриганың кече улы, аның хатыны һәм балалары (шулай ук өчәү!) таралышмаган чак иде, иртәнге як иде. Йорт алты почмаклы, тутыя калай белән ябылган. Хәялинең энесе үз машинасында апасы Дөррия гаиләсен алып килергә чыгып китте.

Дәрига башта малае Хәялине танымыйча торган иде, аннары елап та, күзләреннән саран ачы яше аша көлеп тә жибәрә иде. Сүзен бер нәрсәдән башлый да аннары бөтенләй бүтән унайга кереп китә.

—Улыкаем, нигә хәбәрләр бирмәдең соң?!. Утыз биш ел узды лабаса... Улым, дим, Хәбия апаңнарны, Игелекле хәзрәт гаиләсен, дим, теге утыз жидедә сөрделәр бит. Син яраткан алмагачлар үсми инде алар бакчасында, анда килгән кешеләр хужа... Улым, кайларда булдың соң? Кайларда?

—Кайларда, дип... Менә әти-әни белән Каңгый иленә үк—әкиятләрдә сөйләнә торган ерак-ерактагы таулар иленә дә барып чыктык. Бүз бала Каңгый иленнән кыз ала, диләрме әле? Менә мин дә... киленеңне шул илдә таптым...

—Рәхмәтләр генә яугыры бу киленемә дә, бу киленем дә әйбәттер... Улыкаем, профессор үк булып життеңме? Рәхмәт инде сине кеше иткән... яңа әти-әниеңә... Зур кеше булгансың, улым, зур кеше. Монда калсаң, тирес арасында гомерең узар иде...

Хәяли, жаен табып, урамга ялгызы гына чыкты. Биек капка төбендә теге замандагы, малайның хәтеренә сеңеп калган ярык тагарак юк иде, анда энесе эскәмияне артлы-терәлгечле итеп ясап куйган.

... Хәбия апалар бакчасында алмагачлар юк икән шул, дип уйлады Хәяли. Анда чыпчыклар өер булып, бер-берсенә комачауламыйча, ярдәмләшеп очалар иде. Кешеләр дә шулай оеша алалар икән ич, моны Хәялинең, апасы Дөрриянең язмышы-тормышы үк раслый. Әйе, чыпчыклар, алмагачы төбе әйләнәсендә сөенеп серләшкәч, агач ябалдашына жырлашып тагын ябырылалар иде...

Хәяли бәрәңге бакчасына чыкты. Абзар артында үк теге чактагы иннек капка төбенә әйләндереп куелган ярык имән тагарак түгелме соң бу? Шул икән! Череп бетмәгән, әй...

Тиресне эскерттәй итеп өйгән энесе...

Хәялинең башына нәрсәдер белән, авыр-саллы әйбер белән кинәт тондырдылар кебек—... тирес арасында гомерең узар иде... Әнисенең әле күптән түгел генә әйткән сүзләре икән...

«Тиресләребез арасында яшәү Каңгый иле рәхәтлекләреннән шәбрәк, мең тапкыр шәбрәк!»—дип уйлады Хәяли.

Нәкъ шул мәлдә Хәялинең йөрәген куәтле кыскыч сытты...

Хәялинең жансыз гәүдәсе эскерттәй тирескә сыланды...

Җеназада иң бирешкән кеше Хужанур карт булды. Әллә бала акылы керде инде үзенә—карчыгы Мөсәгыйдәнең күкрәгенә чәчсезлектән ялтыраган башын салып ачыргаланды ул. Өзгәләнүенең чиге-чамасы юк иде.

—Улым, безне нигә ялгыз калдырасың... Хәялием, әнекәең белән мин бәхеттән мәхрүм бит инде... Ятим-ятимә бит инде без...

*1996—1998.*

## Фидая

### I

Егетне беренче күрүдә Садирәнең йөрәге дерт итте. Шул кыска дертләү дөнья агышын туктатып торды. Ярый ла Садирәдәге көтелмәгән үзгәрешне аның үзеннән башкалар сизмәде. Хисләренең янартаудай атылуын киләчәктә томаларга көче житәр санады ул, тик йөрәгендә янгын дөрләвен берәү дә, хәтта шул утны төртүче егет үзе дә белмәсен, белмәсен...

Һәм моны көннәр, атналар, хәтта ел үтеп тә берәү дә белмәде. Шулай—вакыты житкәнче Садирәнең йөрәге ялкынланып януын күрмәделәр. Ялкыннар өстендәге ябынча нык булган, димәк. Әмма сер чишелүнең вакыты килде, һәм сөю ялкыннарын каплаган бөркәнчек, күз ачып йомганчы, дигәндәй, әллә янды да бетте, әллә очты да китте шунда...

Садирәләргә еш килеп йөрде егет, монда аңа ишек һәрвакыт ачык иде, аның гаиләнең гелгә үз кешесе булачагы шиксез иде. Чүкечсез йортта егеткә эш табылып кына торды—йә монысы какшаган да тегесе купкан, йә кием чөе салынган да тәрәзә ябылып бетми. Ә егетнең мондый эшләргә кулы ябыша икән, какканы-сукканы уңганлыгын бизи.

Өйдә Садирәнең ялгызы гына чакларына да туры килгәләде егет. Ләкин андый очрашуларда тегенди-мондый хәлләргә берсе тарафыннан да ишарә дә кылынмады, егет үзенә нинди дә булса шөгыль тапты, Садирә аның монда булуыннан өй һавасы ук иркенәюенә сөенеп йөрде.

Көннәр эссе тора, өйдәге бөркүлек төнлә дә бетми, ә көндезен кояш тәрәзәләрне уттай кыздыра. Шуңа күрә Садирә, өйне жыештырганда (бүген аның эш көне түгел), су коенгандагыча калып чишенде. Кыңгырау шалтырагач, өстенә халатын элеп, итәк ягын төймәләргә өлгермичә, ишек ачты. Егет балкып килеп керде, бу йортның һавасы (гәрчә бүген эсселек патшалык итсә дә) иркәләвенә инде күнегүе куандыра иде аны.

—Буш вакыт барында өстәлне жыеп куясы иттем,—диде ул һәм кичә кичен үзе күтәрешеп кайткан төргәкне сүтәргә кереште.

—Чәй куйыйм әле.

—Соңрак.

Садирә егеткә түгәрәк өстәлне жыярга булышты. Бер чүгәләгәч, төймәләмәгән халат итәкләре ачылды да төз-түгәрәк ботлары егетнең күзләрен яндырды. Садирә:

—Һай!—дип тиз генә төзәтенде.

Ләкин ук атылган, тиясе төшенә тигән иде инде. Һәм егетнең кулыннан эш төште, кулының бүтән шөгыльгә тартылуын тыя алмас дәрәҗәгә житте ул. Шулай да:

—Ир белән хатын мөнәсәбәтен белгәнем юк әле минем,—дип кузгалып китмәкче дә иде, әмма шул ук вакытта Садирә селкенеп куйды да халат итәкләре ян-якка шуып төште.—Өйләнгәнче, моны берәр ялгыз хатын янына барып өйрәнергә кирәктер инде...

Садирәнең дә жаны-тәне тәмам кызышкан иде.

—Әзерлегең ничек соң...

—Әй-й, гел әзер лә ул...
—Беркайчан да беркемгә дә бу хакта...
—Нинди хакта?
—Ашыкма... Бу хакта берәүгә дә әйтмәссеңме?—дип таләбен очлады Садирә.
—Юк инде!
—Үзем өйрәтәм сине...
—Бик әйбәт булыр иде!..
Эш узгач, егет, көче кайтып:
—Моны башкача-бүтәнчә дә эшлиләр бугай бит...—диде.
—Ашыкма...
Ләкин берәү—гөнаһсыз кыз балакай сөйгән егетендәге һәм Садирәдәге үзгәрешне әлеге хәлдән соң беренче күрүдә үк сизде, аларның үзләрен тотышларыннан төзәтелмәслек гөнаһның кылынуына тәмам ышангач, Садирәгә һәм егеткә авыр сүзләр әйтмәстән, өйдән китеп барды. Хәтта саубуллашмады.
Ә Садирә белән егет якынаймыйча түзә алмыйлар иде инде. Тик алар өйдә очрашмадылар, моңарчы егетнең еш килүенә һәм үз итеп аралашуына күнеккән күршеләрнең ямьсезлекне дә тиз күрүләре ихтималыннан курыктылар бугай, шулай булса, оятлары бөтенләй качмаган, димәк. Җәй айларында дүрт дивар арасына кереп бикләнүнең хаҗәте дә юк, әнә, шәһәрдән ерак түгел урманнар күп, анда үткер күзләр сагаламыйлар, кем кемне белгән анда...

## II

Фидая, биек түшәмгә житә язган ишекне акрын гына ачып кергәч, бүлмәдәге кешеләрнең күплегеннән аптырабрак калды. Егетләр һәм кызлар, төркем-төркем булып, пышын-пышын да, яңгыратып та гәпләшәләр иде. Кемдер күзләре чыланган тәбәнәк буйлы, тоташ карадан киенгән кызны тынычландырырга тырыша, бүтән төркемдәге колгасар егет, иптәшләре ни әйтсә дә, кулын гына селти—институтка кабул итмәүләренә исе дә китми, аңа дипломны укымыйча да бирәчәкләр, янәсе. Шулай да күпләре укытучыларны гаеплиләр, түбән билгеләр куеп, боларны кыерсытканнар ягъни.
Түрдәге өстәл янында берничә егет һәм кыз тезелешкән иде. Алары сөйләшмиләр, документларны кайтаручы чаларган чәчле чандыр апа каршына баскач кына нинди белгечлеккә имтихан тотып карауларын һәм кем булуларын атыйлар. Фидая шулар артына басты.
—Ходаем ла, монда да чират,—дип үзалдына шыпырт кына әйтеп куйды ул.
Аның сүзләрен алдындагы егет ишеткән икән, башын гына борып нидер шаяртмакчы иде ул, ләкин кызга күзләрен төгәп торгач, бөтенләй борылды һәм башта:
—Ашыгасы юк, безнең эшләр төгәлләнгән,—дип нәтиҗә чыгарудан узмады. Чираты житәр алдыннан гына, тагын кызга текәлеп:—Чират та чират, дисезме? Ә минә мәхәббәткә беркайчан да чират тезелми!—дип тавышын гүләтте, яңалык табуына сөенә иделер, калын кашлары сикергәләп алды.—Кире каккысыз хакыйкать монысы!
—Сезне институтка алмыйча ялгышканнар икән, хәтта шундый акыл иясен югалтып оттырганнар,—диде Фидая, башланыр-башланмас бәхәстә һич тә жиңеләсе килми иде аның.—Укытмыйча ук диплом бирәсе иде сезгә.
Егет җавап кайтарырга өлгергәнче, аның чираты житте. Ул (исеме Шәмсуар икән), документларын алгач, китәргә ашыкмады, адым гына читенде—Фидаяны көтүе икән. Кыз кәгазьләрен тәртипләп сумкасына салгач, Шәмсуар:
—Минә таныштык та,—диде һәм:—Исемең матур икән—фидакарь

жан,—дип сездән сиңа күчте.

—Үзең таныша белмәгәч...

Кызның беренче чибәрләр рәтендә торырлык брюнет егет белән әңгәмәне өзәсе дә килмәгән кебек, түп-түгәрәк һәм йонлач беләкләрен сыпыргалап көченә мактанучы егеткәйне үсендерергә теләмичә битараф калмакчы булуы да сизелә кебек. Ул, бүлмәдән чыгар алдыннан:

—Башкалар ярдәмендә белешүнең ахыры әйбәт бетми бугай,—дип фикерен ерakka илтеп терәде.

—Хорафатларга ияручән түгелмен! Элек димче әбиләр кавыштырган парлар бик тату яшәгәннәр,—дип сүзнең бу юнәлешкә керүен чикләде Шәмсуар.

—Җәһәт икәнсең—кавышуга бик тиз җиттең. Зур эштә вак мәсьәләдәге кебек кабаланасың.

—Безнең юл шушыннан башлануын күңелем сизенә. Бергә булырбызмы—монысын белгән юк, ләкин бер-беребезне беркайчан да онытмаячакбыз.

—Башка гамәлләреңдә дә үз көчеңә шулай симерттереп ышанасыңмы икән менә...

—Симерттереп, дисеңме... Ышанам! Күрәсең, ябыклардан түгелмен,—дип шаяртуга күчте егет.

—Туктале, нигә тузга язмаганны сөйләшәбез соң без?! Синең сукыр тиенгә тормаган сүзләреңне нигә тыңлап торам соң мин... Сау бул! Хуш...

Фидая троллейбус тукталышына таба кызуланып китеп барды. Шәмсуар киң маңгаен бераз ышкып торды да, калын кашларын сикертеп алгач, кызны тиз үк куып җитте.

—Ай-йай кырт синең холык, әй!

—Кем белән сөйләшүгә карап!

—Шулай да ипле булыйк. Сиңа да, миңа да рәхәт түгел анысы. Икебез дә институт бусагасында сөртендек, сөртенеп егылдык.

—Ләкин явыз нияттә булсаң, күземә дә күренмә!—дип кисәтте кыз, димәк, ул да танышлыкның башланыр-башланмастан өзелүен теләми икән.

—Нигә мине юлдан язган бәндәгә саныйсың әле? Мин шундыйга охшаганмы?

—Юк та... Нигә тупаслануым сәбәбен үзем дә анламыйм,—дип йомшарды кыз.

—Безнең бүгенге хәлдә төрлесе булуы ихтималдыр. Шулай да мин институтка керә алмавыма артык кайгырмыйм. Сигезенче класстан сон техникумда укыйсы булган да бит, баш эшләмәгән,—дип чигәсен бармак очлары белән бәреп шакылдатты егет.—Һөнәр-белгечне иртәрәк алу мәҗбүрлеген менә хәзер төшендем.

Кыз да:

—Анысы, югары белемсез калуыма мин дә егылып хафаланмыйм. Күңелдә үкенү оемасын, дип кенә тапшырып карадым керү имтиханнарын,—дип ачыла төште.—Әйбәт укытучы чыкмас та идедер әле миннән.

—Киләсе буыннар безнең укытучылар булмавыбыздан, шәт, оттырмаганнардыр.—Һәм Шәмсуар:—Һе, әкәмәт,—дип күлдә дә сүзне бүтәнгә күчерде.—Син, Фидая, юкка миңа шикләнеп карыйсың. Сиңа мөнәсәбәттә әшәке ниятем юк. Гомумән, берәүгә дә начарлык кылмыйм. Бик беләсең килсә... Бик беләсең килсә...—дип бөтен йөзенә елмаю җәелдерде дә тукталып калды ул.

—Бик, би-ик беләсем килә!..—дип чытлыкланды кыз.

—Бик беләсең килсә, мин—туп-тулы мәгънәсендә егет кеше! Һәм шуның белән горурланам!—дип акрынрак, әмма һәр сүзенә сузыбрак басым ясап әйтте егет.—Ә соң... Нигә акланам соң мин!..

Фидая сискәнеп куйды, үзенең киреле-морылы сөйләвеннән Шәмсуарның болай ук ерakka кереп китүен теләмәгән иде ул, төртмә кисәтүләрен егет бер селтәнүе белән юкка чыгарды да куйды менә, үзен егетнен күңеленә яра ясагандай сизеп уңайсызланды. Алар, кара-каршы басып,

шактый озак кына тын тордылар, бер-берсенең күзләренә күтәрелеп карарга кыймадылар. Ниһаять, кыз, нидер әйтмәкче булып, авызын ачкан иде, ләкин сүзе табылмады, танышуларының очраклы булмавын раслаучы әлеге сүзсез аңлашуның ямен җибәрәсе килмәде бугай. Тукталышка җитәрәк кенә:

—Ачуланма, яме, Шәмсуар...—диде Фидая.

—Ярар, Фидая...

Кыз, кибетчек артына елышып, янәшәсендә басып торучы егеттән яшермәкче булып, күзләрен сөртте.

—Менә күрдеңме минем җебегәнлекне... Елап та күрсәттем үзеңә...

—Гөнаһсыз күз яшьләре—гөнаһсызлык билгесе, Фидая...

—Аңладым аңлавыңны, Шәмсуар...

Ары сөйләшмәү аларны бер-берсенә ышанычлы якынайта иде, һәм алар тагын сүзсез калдылар. Шәмсуарның Фидаяны үз итеп култыклыйсы килде, тик моңа кыюлыгы җитмәде. Фидаяның Шәмсуар белән үз итеп җитәкләшәсе килде, ләкин кыймады. Алар, алдан белешкән кебек, тугызынчы трамвай тукталышына бер-берсен әйдәләмичә җиттеләр.

—Кая барабыз соң без?—дип башлап исенә килде егет.—Бер якта торабыз мәллә? Миңа, анысы, трамвай белән кайту җайрак, без Соцгородта торабыз. Әти-әни, бабай-әби, тагын өч энекәш. Фатирыбыз әйбәт, сугышка чаклы салынган йортта.

—Миңа трамвай да ярый, синнән соң ике тукталыш узам икән мин,—диде кыз һәм, егетнең самимилегенә җавап итеп, үзенең гаилә хәле белән таныштырды.—Без икәү генә, әни дә мин, бер бүлмәле фатирда. Тик...—Кыз егеткә күтәрелеп карады да:—Ары сорашма, яме,—дип кисәтте.

—Ярар.

—Әй-й, нәрсәсе сер соң аның!—дип бу мәсьәләдә чишелеп бетәсе итте Фидая.—Мин туганда, әти тиешле кешенең инде гаиләсе булган. Мин аны белмәдем һәм белмим. Әни ишарәләвеннән генә сизенәм—безгә ярдәм итеп торгандыр әти тиешле кеше. Үзе, мәҗбүр итмичә. Миңа унсигез тулды, хәзер бөтенләйгә онытырдыр...

—Бәлки, нәкъ менә хәзер табышырсыз. Тормышта ниләр генә булмас...

—Әти, дип эндәшәсе килгән чаклар хисапсыз инде... Хәзер дә... Яшь күренә әле әни, кызлар кебек... Унсигез яшендә тапкан мине...

—Ә бабаң-әбиең?—дип үзе дә сизмәстән кызыксынды егет, үзенең әбисе һәм бабасы турында искәртүен истә тотты бугай.

—Алар авылда яши. Бик әйбәтләр. Мине бик яраталар. Еш кайтам. Үзләре дә килә. Әни елына бер кайтса кайта. Менә бер серем дә калмады бугай...

—Ә сөйгән егетең?

Фидая көтелмәгән сораудан аптырап калмады, Шәмсуарның белешүе «юк» дигән сүз ишетергә ышануыннан иде дер кебек тоелды аңа һәм ул:

—Ә синең сөйгән кызың бармы соң?!—дип кыюланып җавап кайтарды.

Әмма Шәмсуар да җебеп төшмәде, изрәгән арыш боламыгы түгел икән егетебез.

—Минем сөйгәнем—син!—дип ярып салды ул.

Кыз, зәңгәрсу күзләрен зур ачып, егеткә текәлеп торгач:

—Тиле!—диюдән бүтән сүз тапмады.

—Менә бәхет—миңа гашыйк булуыңны авыз тутырып әйттең!

—Җитте сиңа, ә!..

—Җитмәде шул! Алдым да кайттым булыр сине үзебезгә! Килен итеп!

—Җитте, дим, ә...

Их-х, Шәмсуар гөнаһсыз теләген шул вакытта ук үтәгән булса соң...

Алар трамвайда янәшә утырганда гына бу фани дөньяның рәхәт хыялдан гына тормавы чынбарлыгын искәрделәр.

—Мин Оргсинтезга бармакчы идем бит,—диде Фидая.—Анда эшкә чакырып торалар.

—Киттек!

... Их-х, Шәмсуар Фидаяны, юлларын үзгәртмичә, шул вакытта ук

үзләренә алып кайткан булса соң... Килен итеп... Их-х, Фидая Шәмсуарны гомер-гомергә үзенеке итәчәгенә ышандырган булса соң, аның гөнаһсыз кыюлыгына тыйнак һәм өметле кыюлыгын өстәгән булса соң... Әгәр шулай булса, аларның язмышларында, бәлки, фаҗига өстенә фаҗига өстәлмәс тә иде...

## III

Егет белән Садирәнең табигать кочагында кичергән рәхәтлекләре әбиләр чуагына чаклы гына дәвам итте.

Алар Дөбъяз ягы урманыннан кайтышлый автобустан шәһәргә керүгә үк төштеләр. Аерылышасылары килмәде, ерак ук араны җәяүләп уздылар. Әмма икесе ике якка китәр төш һәм чак барыбер житте. Егет, зур сумканы җиргә куеп, үз әйберләрен алырга дип, кулын сумкага тыкты.

—Хәзер үзем рәтләп бирәм,—дип аңа булышырга ашыкты Садирә, сумкада актарына башлады.

Алар, берьюлы диярлек ачы кычкырып, сумкадан кулларын алдылар, ләкин кылынасы кылынган иде инде. Урманда сумка эченә ике кара елан кереп яшеренгән булган...

Алар икесе ике сырхауханәгә үзләре бармакчылар иде, бергә булуларын чит-ятларга белгертмәү теләгеннәндер бу кадәресе. Ләкин егет тыкрык буе җир китүгә үк аңын җуеп егылды. Табиблар аны коткара алмадылар, ул бер атнадан соң аңына кайта алмыйча вафат булды. Елан чагуы, вакытында чарасы күрелсә, заманы өчен котылгысыз һәлакәт түгел дә түгелен, әмма һәркемнең агуга каршы тору көче төрлечә шул. Садирә исән калды, тик аның бөтен гәүдәсе корышты, өстәл янына һәм йомыш-юлга бару аның өчен ерак сәфәргә әйләнде. Инде менә егерме ел буена шулай...

Ә егетнең сөйгән кызы... Ул ачу-үпкәсенә калкырга ирек куймады, сырхауханәдә егете янында озак-озаклап утырды, ләкин аңа ул да ярдәм итә алмый иде инде. Егете аның исемен әйтеп бәргәләнгәндә, караучыларга аны тынычландыруда булышты, тик егет аз гына вакытка да саташуларыннан айнымады, кызның күзләренә танышкан чактагыча үз итеп карый алмады...

## IV

Фидая белән мин болай таныштым.

Җәен без дачада торабыз. Эшкә алтыдагы—беренчесе—автобус белән кайтам. Аннары троллейбуска аның соңгы тукталышында күчеп утырам, анда кеше азрак була. Бу көнне дә троллейбуста иркен иде, әнә, тәгәрмәч турысындагы биек утыргычта буш урын бар. Андагы кыз, мин алданрак төшәмдер, дип, мине эчкә уздырды.

Кыз үзе сүз башлады. Сөйләшергә-аралашырга яратадыр. Фидая иде ул. Эштән кайтышы, төннән. Бер тукталыштан соң:

—Өемне узып китәм,—диде Фидая.—Элгәре әнинең хәлен белергә кирәк шул. Ялгызы ул, мин дә ялгызым, торабыз шулай—аеры-йоры, инде егерме ел...—дип җиңелчә уфылдады ул.—Әни авыру минем. Тик мин аның белән бер өйдә—ул өйдә,—дип басым ясады Фидая,—куна алмыйм. Бар инде моның сәбәбе. Ә әнине елан чаккач, аның янында һәр төнне кунган идем. Тик ул өйдә әнине сырхауханәдән алып кайткан көндә дә куна алмадым. Әни дә мәҗбүр итмәде. Әйтәм ич, бар инде моның сәбәбе.

—Язмышыгыз авырлыгына ишарәлисез кебек,—дип Фидаянең сөйләвен дәвам итүен теләдем мин, ә ул, кыстатмаса да, тәгаенләүгә тиз генә күчмәде.

—Узды инде гомерләр, узды,—дип офтаныбрак суза төште ул.—Пенсия яшем дә житә...

—Сезгәме? Яшь ич әле сез пенсиягә чыгарга!

Фидая гаҗәпләнүемнең анарга ярарга маташу түгеллеген аңлады, әмма үз сүзләренең дә ялган булмавын:

—Житә шул, житә пенсия яшем,—дип раслады.—Башта эшем жинел дә иде, гел көндезен генә дә эшли идем. Аннары сәламәтлеккә зарарлы цехка күчтем. Яшисе килмәү кортлары йөрәкне кимергәләгән чаклар иде. И-и, бар инде хәлләр, баштан төрлесе узды... Әле дә узып бетмәгән... Узып та бетмәс кебек... Уйга чумсаң, хикәя язарлык валлаһи...

Мин сискәнеп куйдым. Ләкин Фидаянең соңгы сүзләре минем хикәяләргә бәйле хезмәтемне белеп әйтүдән түгел иде, карашында мондый хәбәрдарлык сизелмәде. Һәм аның моңарчы мине күреп белмәвенә соңыннан ныклап ышандым.

—Языгыз соң,—дип тыныч кына киңәш иттем мин аңа.

—Хикәягә сыйдыра алмамдыр... Аннары... Булдыра да алмамдыр...

Ул Восстание тукталышында саубуллашып төште.

Икенче көнне иртән мин, дачадан кайтышлый, Фидаяне тагын очраттым. Янәшәсендәге буш урынга күрсәтеп, ул мине үз янына чакырды. Аның күңелендә жыелганны кемгә дә булса сөйләп бушанасы килүе чигенә житкән идедер.

—Сөбханалла!—дип башладым мин.—Төн буе авыр шартларда эшләп тә йончымагансыз.

Фидая минем мактавымны:

—Бүген черемләп алырга жай булды,—дип читтән уздырды.

—Хикәягезне яза башламадыгызмы? Миңа укытырсызмы?

—Сүз жаеннан әйтелгән теләк кенә булып калыр ахыры ул...

Восстание тукталышында Фидая белән бергә мин дә төштем һәм аны әнисе йорты уңаена озатып куйдым.

Моннан соң да Фидая белән юлларыбыз туры килгәләде. Кыска вакытлы очрашуларда ул башыннан узганнарны өзә-төтә сөйләде—аңа килгән фажигаларда аны гаепләямәчәгемә акрынлап кына ышанды. Әмма хикәясен язмады ул.

Һәм мин, аның тасвир кысаларыннан чыкмаска тырышып, ләкин ул кинаялап кенә узган хәлләрне үземчә күз алдына китереп, Фидая хикәясен яздым, бу язмамның алдагы өч өлеше—шул хезмәт.

Хикәяне Фидаягә укырга бирдем. Ул, аксыл тышлы, шакмаклы шома битле дәфтәремне кулына алгач, аны ачарга ашыкмады, тышын беравык йомшак кына сыпырып утырды. Фидая моңарчы минем исемемне генә белә иде, дәфтәр тышындагы фамилиямне күргәч, бәлки, аптырыйрак калгандыр, минем хикәяләрне укыганын яки радиодан ишетүен, бәлки, хәтерләгәндер.

Фидая Гагарин урамы буендагы бакчада хикәяне укый калды.

Мин әйләнеп килгәндә, Фидая дәфтәрне тагын сыйпап утыра иде. Дәфтәрне сүзсез генә миңа сузды. Мин аның хөкемен көттем. Әмма ул эндәшмәде. Үзе тәфсилләмичә калдырган хәлләрне минем күзаллавымны дөрескә санады микән Фидая? Хикәядә катнашучыларның, заводның һәм шәһәрнең кайбер төшләре исемнәрен үзгәртүгә килешкәндер ул. Хәер, болары—ваграк мәсьәлә...

Фидая урыныннан торды. Киемнәрен төзәткәләгәч:

—Күңелемне бушатырга кешесен тапканмын икән,—дип сизелер-сизелмәс кенә елмайды.—Мине аңлап тыңладыгыз. Рәхмәт. Китим инде мин. Әни көтәдер, соңладым бүген, борчыладыр. Әни... Мин аңа егерме ел буе әни дип эндәшмичә йөрдем бит, ә... Сантый мин... Әтине эзләп табасы иде, аңарга да минем ярдәмем кирәктер инде... Шәмсуарның, әтиең белән, бәлки, хәзер табышырсыз, дигәненә егерме... егерме бер ел узган...

*1998*



## *А. С. Пушкинның тууына 200 ел*

# «Хәзрәти Пушкин...»

*Бөек рус шагыйре Пушкинның тууына 200 ел тулуны (1799-1837) бөтен мәдәни дөнья зурлап бәйрәм иткән көннәрдә, ихтыярсыз, бу олуг исемнең татар шигъриятендә тоткан урынын күзаллыйсың. Әле узган гасыр азагында ук Казанда аның «Бакчасарай фонтаны» поэмасы татар телендә дөнья күрсә (башкорт мәгърифәтчесе М. Өметбаев тәрҗемәсе), аннан соң Г. Исхакый тәрҗемәсендә «Капитан кызы» повесте басылып чыга. Аннары—яңа гасыр башында—башка проза әсәрләре... Ниһаять, бөек Тукаебызның үзе остаз санаган рус шагыйреннән күпсанлы, гаҗәеп матур һәм милли рухлы (!) тәрҗемә-шигырьләре, «икътибас» иткән әсәрләре, Пушкинга эндәш белән шигырь-хитаплары... Ике дөнья, ике халык тудырган бөекләрнең мөнәсәбәте, шигърият офыкларының, тарафларның киңлеге, үзара бәйләнешы—гаҗәеп матур тема бу! Ә бу асыл традиция бездә бөтен гасыр буенча дәвам итте: совет чорында Пушкинны шагыйрьләребез өр-яңадан «ачтылар», тәрҗемә иттеләр. Сугышка кадәр Ф. Бурнашның «Евгений Онегин»ның татарчасын дөньяга чыгаруын, М. Җәлил, Ә. Исхак, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Ш. Маннурларның ярыша-ярыша тәрҗемә итеп, мәгълүм юбилеена (1937) калын китабын әзерләүләрен искә төшерик. Сугыштан соң аларга Н. Арсланов кебек шагыйрьләр кушылды, 1949 һәм 1954 елларда калын зур—бер һәм ике томлык «сайланма әсәрләр»е дөньяга чыкты. Шунысы кызыклы: без әнә шул китаплардан Пушкинны татарча укып үстек. Үзебез дә тәрҗемә иттек, акрынлап зур шигырь дөньясына кердек. Соңыннан, җитмешенче елларда Михайловское, Болдиноларда булып, зур Шигырь бәйрәме—Пушкин көннәрендә катнашкач та, бөек рус шагыйре турында уйларыбыз татар шигыренә тоташты, киңлекләргә әйдәде. Бу җәһәттән Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Зөлфәтләрнең үзенчәлекле шигырь һәм эсселарын хәтердә тотам. Г. Рәхим белән миңа бу шигъри сәяхәттә 1972 елда бергәләп катнашу насыйп булды... Шигырьләр, мәкаләләр язылды...*

*Быел, олуг юбилее мөнәсәбәте белән, «Мәгариф» нәшрияты (аның шагыйрь дә, әдәбият белгече дә булган директоры Мөдәррис Вәлиев инициативасы белән, әлбәттә!) Пушкин тәрҗемәләреннән сувенир басма—«Хәтерлим мин гүзәл бер мизгелне» исемле китап әзерләде. Шигырьләр—оригиналда да, безгә таныш һәм яңа тәрҗемәләрдә дә бирелгән (җөмләдән, Зөлфәт, Ш. Маннап, Н. Акмалларның бик әйбәт тәрҗемәләре урын алган!). Билләһи, матур бүләк бу! Без дә бу санда журнал укучыларыбызга олуг шагыйрьнең яңа тәрҗемәләрен һәм Казан дәүләт университеты профессоры Җ. Сафиуллинның «Пушкин иҗатында Коръән» исемле кызыклы мәкаләсен тәкъдим итәбез. Бөек Пушкин белән дуслык юлы дәвам итә!*

**Рәдиф ГАТАШ.**

# Александр Пушкин

## Коръәнгә иярүләр

*П. А. Осиповага багышлана.*

I

Ант итәмен такъ һәм җөп белән мин,
Газават вә кылыч, аваз белән,
Ант итәмен таңгы йолдыз белән,
Ант итәмен кичке намаз белән![1]

Мин ташламам сине, җанкисәгем!
Юккамыни билеңә кул салдым?—
Күзе үткер шымчыны мин хәтта
Алдадым бит... Сине саклап калдым!

Сусавыннан тәмам калгып төшкән,
Әлсерәгән гүзәл гөлләреңне
Кем саклады көеп барган чакта?
Бар яңгырым сиңа бирмәдемме?

Сусап ирен чатнар көннәрендә
Сугардым бит эссе чүлләреңне...
Минме өйрәтмәдем көчле сүзнең—
Зирәкне дә хәтта җиңәрлеген?!

Бичарага һаман мең чара бул,
Ялгансыз син яшә безнең көндә.
Курыкма! Һәм минем инанганны
Җиткер һәрбер тере шөбһәлегә.

II

Рәсүлемнең саф җефетләре,[2]
Сез—гел бүтән бит инде—
Өркетә хәтта шәүләсе,
Бер кагылып үтүе...

Шул аулак чатыр эчендә
Гөнаһсыз көн итегез,
Гыйффәт чәдрәсе каплаган
Килеш калсын битегез.

Шәригать кушканча гына
Киенеп чишенегез,
Кяфергә йөз күрсәтмәгез,
Зур гөнаһ бу—белегез!

Ирләр! Изге Мөхәммәттә
Сез кунак икән инде,
Берүк килешмәс гамәлләр
Кылмасагыз ла иде!

Уй—фәрештә... Ул—гарештә...
Сөймәс буш сүз сөрешен.
Догаң кыл да, сайла тизрәк
Хур кызларының берсен!..

III

Тетрәнде Рәсүл Сукырның
Килеп җиткәнен тоеп,[3]
Хәтта пәйгамбәр тупсасын
Атлап үтте ул кыеп.

«Синә вәхи иңде күктән—
Ул—Коръән... Син Коръәнне
Илләргә тарат, әмма да
Рәнҗетмә кяферләрне!»

Әллә кем ди үзен кеше...
Җиргә килә—бичара,
Бар гомере—тик бер сулыш,
Гүргә иңә—бичара.

Бәндәнең Газиз Аллаһы
Биргән вакыты бетә—
Чарасыз килеш килә дә,
Чарасыз килеш китә.

Үзе теләгәнчә Аллаһ
Үтерә, йә терелтә—
Бәндә яшисе һәр мәлне
Санап тора ул күктә.

Чын дөнья—теге дөньяда—
Шул аргы якта икән,
Анда гел алма-хөрмәләр
Шау чәчәк ата икән...

Тик фәрештә ике тапкыр
Өрер Сур мөгезенә—
Килер акылга сыймаслык
Афәт дөнья йөзенә.

Туган качар туганыннан
Һәм сабые—анадан...
Ходайга кайтып ялварыр
Һәммәсе дә яңадан.

IV

Илаһым, Синең беләң мин
Сүз көрәштермәк идем,
Сират күпере өстендә
Шаярып йөрмәк идем.

Тиле булганмын икән бит—
Ярлыка, берүк, Ходам!
Шәфкать иңдер ерактагы
Дөньялар арасыннан...

Диден: «Яшәү бирәм җиргә
Һәм җәзам булып—үлем,
Яшәвең дә, үлемең дә
Ихтыярымда минем».

Диден: «Еракларлан табам
Һәм еракларлан эзлим.
Минем кул җитмәс урын юк—
Һәммәгезне тигезлим!»

Ярый, гөнаһлы тормышны
Бик күп данладык... Җитәр!—
Шәрекъ якны мин күтәрәм,
Гареп якны син күтәр[4].

V

Җир шул килеш... Күк гөмбәзе—
Җиһан Синең җилкәндә,
Йолып кала күр, Ходаем,
Гарасатлар үткәндә.

Җиһанга кояш кабыздың,
Яктыңны бирдең инде—
Дөнья тирәгеннән һаман
Хуш ис аңкыса иде!

Табынабыз: «Аллаһ бөек,
Дөнья Аның иркендә,
Теләсә ул шау яңгырны
Яудыра эссе көндә.

Шәфкать кылып, Мөхәммәткә
Ачты ул Коръән серен...
Хәер, җиргә төшик... Аның
Күтәрик пәрдәләрен!

VI

Төшкә юкка кермәгәнсез лә бит
Такыр башлы яугир егетләр?—
Кирмән үре, манара һәм дивар...
Кылычларда канлы күбекләр.

Ярсу зәнкиләр, тыңлагыз
Минем бу өндәвемне:
Кол кызлар бүлешеп тату
Яшәсәгез лә иде!

Яу чапкан, ярар, җиңелсен...
Ни хуры бар? Көлсеннәр—
Үзләренең яу чыгарга
Шүрләгәнен белсеннәр.

Җиңелгән дәшә яу тынгач:
«Китәм мин синең белән!»
Җавап бер: «Юк, өметләнмә!»
Ник шулай? Җиңдем. Беләм.

Җиңелгәннәр! Изге зат сез!—
Җан оҗмахларга аша...
Инде һичкем дә аңламас
Дөньяда сез ләбаса!

## VII

И Аллаһ колы,
Уян, и, бәндә—
Чыра яна бит
Тын мәгарәндә.

Иртәнгә кадәр
Шул чыра яныр,
Тынмас сагыштан
Сине коткарыр.

Ихластан булсын
Кылган һәр догаң—
Ярлыкау сора
Газиз Аллаңнан.

Коткар, Ходаем,
Яман төшләрдән!—
Догалар кылам
Аулак кичләрдә.

Кояш та чыгар,
Булырсың көчле—
Таңгача укы
Коръән Шәрифне!

## VIII

Фәкыйрьләргә намусыңны син саткан чакта,
Малың мактап сата күрмә син хәрам хакка.
Барыбер бит иң югары—Ходай Тәгалә!
Ахырзаман җиткәч басу ялварыр сиңа:
—Җый уңышым! Җимешемне авыз ит сана?

Күккә ирешеп дөньяда, булсаң да маллы,
Онытсаң әгәр фәкыйрьне һәм горабаны,
Хәерчегә тиен тапмасаң авыр көннәрдә!
Барлык кылган шәфәгатем очар көл булып,
Юар барлык изге эшең яңгырлы болыт.

## IX

Ходайга сәйях ялвара икән,
Эсседән тәмам тилмергән, кипкән,
Адашып йөри өч көн вә өч төн—
Ком буранында калган бу мескен.

Бер йотым суга тәмам тилмергән—
Агач төбендә бер чишмә күргән.
Һәм сәйях шашып шуңа ашкынган,
Туйганчы эчкән, төшеп коенган.

**Телгә-күзенә мең рәхәт иңгән—
Ишәген кочып йокыга түнгән.
... Шуннан соң күпме киемнәр тузган,
Кире кайтмаслык гомерләр узган.**

**Уяна... Кемдер нидер дип әйтә,
Юк, әйтү түгел—күкләр күкрәтә:
—Күптәнме чүлдә йокыга талдың?
—Белмим... үзем дә аптырап калдым.**

**Кичәге кояш биектә иде,
Димәк, бер тәүлек, аһ, үткән инде!
Ә күктән аваз: «Йоклап эш кырдың—
Яшь булып яттың, карт булып тордың!»**

**Череде агач яп-якты көндә,
Чүл дымы кипте кое төбендә,
Бөек давыллар иште дөньяны:
«Бу—синең ишәк... сөяктән таны!»**

**Буш чүлдә шулчак могҗиза булды—
Кабынмас уйлар кабат кабынды.
Терелде тирәк—тибрәнеп куйды,
Саф салкын чишмә суларын койды.**

**Ишәктән калган сөяк терелде,
Чемченеп ишәк гөлгә үрелде.
Безнең бу сәйях көч-куәт алды,
Хәтта яшьләрдән яшь булып калды.**

**Шау яшьлек дәрте җанда кабынды—
Ходай япмасын гүя ябынды!
Юлларын дәвам итте бу юлчы—
Бәндәм, син аңа догадаш булчы!**

**ЗӨЛФӘТ** ***тәржемәләре.***

ИСКӘРМӘЛӘР:

1 Мөхәммәт болай ди («Бүләкләр сүрәсе): «Кяферләр фикеренчә, Коръән Шәриф дигәнебез яңа ялганнар һәм иске мәсәләләр тупланмасы гына, янәсе». Кяферләргә карата фикерләр хаклы. Әмма, аңа да карамастан, әхлак ягыннан дөреслекнең күбесе Коръән Шәрифтә көчле һәм шигъри яктан куәтле сурәтләнгән. Монда аятьләргә охшатып язылган берничә ирекле һәм охшаш уйлар гына тәкъдим ителде. Коръән Шәрифнең үзендә Аллаһе Тәгалә һәрчак үз исеменнән генә сөйли һәм бу Изге Китапта пәйгамбәр Мөхәммәт хакында икенче, хәтта өченче зат исеменнән фикер әйтелә. Коръәннең бүтән төшләрендә Аллаһе Тәгалә бия тояклары, инҗир җимешенең төшләре, Мәккәнең азатлыгы, игелек һәм явызлык, кешеләр һәм фәрештәләр белән ант итә. Мондый сәер һәм дәртле гыйбарәләр Коръән Шәрифтә адым саен очрап тора.

2 «Рәсүлем!» ди Аллаһе Тәгалә. Аның әйтергә теләгәне: «Рәсүлем тыйнак. Әмма мин сезгә турысын әйтергә мәҗбүрмен...» Бу сүрәләрдә чүл гарәбенең көнчеллеге кычкырып тора.

3 «Сукырлар» сүрәсеннән.

4 Начар физика, әмма нинди шигъри куәт!

*(А. С. Пушкин искәрмәләре)*

# А. С. ПУШКИН ИҖАТЫНДА КОРЪӘН

1820 елларда, әле беренче мәртәбә җәнүб якларына сөргенгә җибәрелгән вакытта, Пушкин Кара диңгез ярында кечкенә генә бер тау куышына сыенып, кулындагы китабын мавыгып, дөньясын онытып укый. 1825 елда язылган, тәмамланмаган бер шигырендә мондый юллар бар:

В пещере тайной, в день гоненья,
Читал я сладостный Коран...

Ялгызлыкка дучар ителгән көннәрендә, Пушкин шулай ук илләреннән куылган мәшһүр шәхесләр белән үз тормышын чагыштырып карый һәм еш кына күнелендә пәйгамбәр Мөхәммәт сурәте уяна. "В пещере тайной..." сүзләре юкка гына тумый: риваять буенча, Корьән Мөхәммәткә күктән тау куышында иңдерелә. Димәк, Мөхәммәт образы шагыйрьнең рухи халәтенә ул көннәрдә бик якын булган.

* * *

Бу мәкаләдә Пушкинның мул иҗатыннан татар укучысында аеруча кызыксыну уятырлык Корьән, Шәрекъ темасының үсешен аерып алырга булдык.

Бу юнәлеш, кызганычка каршы, әлегә җитәрлек өйрәнелмәгән. Рус тәнкыйте һәм әдәбият белеме Пушкинны аңлау, күтәрү өчен барлык чараларны күрде кебек. Пушкин турында язылган материаллар аның үзе язганнарыннан әллә ничә мәртәбә артык, хәтта аның мирасы белән француз, инглиз, немец һ.б. язучыларның иҗатлары арасында нинди дер аһәңдәшлек тә эзләп табалар, тик Пушкин иҗатында тамырланган Шәрыкъ темасы, көнчыгыш мотивлары турында бик аз, бик саран язалар. Рус галимнәре аурупаүзәк шаукымыннан айнып бетә алмыйлар.

Пушкинны Корьән белән тоташтырган җепләр әлегәчә фәндә күрсәтелгәннән тирәнрәк, ныграк, колачлырак. Шагыйрь иҗат иткән "Корьәнгә иярүләр" ("Подражания Корану") исемле шигырьләр бәйләме — аның Шәрекъкә карашының, мөнәсәбәтенең иң югары, иң киеренке ноктасы.

Шәрекъ Пушкин күңелен һәрдаим үзенә тарткан. Әле 14 яшьлек шагыйрьнең "Натальягә" дигән шигырендә үк көнчыгыш мотивлары ачык ярылып ята. "Руслан һәм Людмила" исемле беренче поэмасында "Мең дә бер кичә"нең тәэсире сизелә, шәрыкъ темалары һәм образлары очрый. Җәнүб сөргене елларында (1820—1824) шагыйрьнең Шәрекъ белән кызыксынуы көчәйгәннән-көчәя бара. "Кавказ әсире", "Бакчасарай фонтаны", "Чегәннәр" исемле поэмалар, уңлаган шигырьләр, хатлар моңа ачык дәлил. "Бакчасарай фонтаны"на Пушкин эпиграф итеп бөек Иран шагыйре Мөслихеддин Сәгъди сүзләрен ала, поэманың өслүбен аңлатып: "Шәрекъ стиле минем өчен өлге булды", — дип икърар итә.

1824 елның сентябрь-октябрь айларында Пушкин Михайловское авылында, сөргендә чагында иҗади җәүһәрләреннән берсе булган "Корьәнгә иярүләр"не язып чыга. Бу шигырьләр бәйләменә бөек шагыйрьнең Шәрекъне өйрәнүдә, үзләштерүдә үзенә күрә бер йомгак ясавы дип карау дөрес булыр. Сан ягыннан исәпләнә торган нәтиҗә генә түгел, ә бәлки Шәрекъне тирәнрәк аңлау, рухи дөньясына үткәрүе дигән караш бу. Телгә алынган романтик поэмаларында Шәрекъ Пушкин тарафыннан күбесенчә тышкы калып булып, аерым күренешләр, билге-тамгалар рәвешендәрәк кабул ителә. "Корьәнгә иярүләр"дә инде шагыйрь Шәрекъне, кабатланмас эчтәлегендә тоемлап, укучы күз алдына сурәтле-күргәзмәле рәвештә бастыра.

Ләкин бу бәйләмне язып та, шагыйрь Шәрекъ белән саубуллашмый. Б.Томашевскийның: "Корьәнгә иярүләр"дә Пушкин Шәрекъ белән саубуллашты",

— дигән фикере белән ризалашасы килми, чөнки соныннан көнчыгыш рухы, аһәңе колориты ачылган "Әрзерумга сәяхәт", "Кирджали", "Капитан кызы" кебек мәшһүр әсәрләре языла.

* * *

Ни өчен Шәрекъ темасы Пушкин иҗатында шундый күренекле урын алган дигән сорау тууы табигый. Ни сәбәпле шагыйрьне нәкъ Коръән китабы таң калдырган, кат-кат укырга мәҗбүр иткән?

Бу хосуста, беренче чиратта, шагыйрьнең биографиясе мөһим роль уйнаган. Ул һәрвакыт үзенең нәселе, шәҗәрәсенең бигрәк тә Африкага кагылышлы тармагы белән кызыксынган. Ибраһим Ганнибал шагыйрьнең ана ягыннан бабасының атасы булган. Сигез яшьлек малайны Россия җиренә алып киләләр, ул Петр I нең тәрбиясендәге яраткан кешесе булып китә, яна иленә олы хезмәтләр күрсәтеп, генерал дәрәҗесенә күтәрелә. Тәрҗемәи хәле нәкъ мажаралы роман диярсең.

Ибраһим Ганнибал Россиягә килеп чукындырылганчы мөселман булган, дип фараз кылырга нигез бар. Ибраһимның атасы хакында немец телендә язылган биографиядә болай дип күрсәтелә: "Мөселман гадәтенчә, аның утызлап хатыны һәм табигый рәвештә күп кенә балалары булган." Пушкин бу турыда хәбәрдар була, чөнки немецча язылган биографияне ул үзе рус теленә тәрҗемә итә.

Ерак бабасы Ибраһим Ганнибалның гаҗәеп тормышы һәм язмышы Пушкинны үзенә бер үҗәтлек белән кызыксындыра. Үзенең "кара бабасы" турында ул малай чакта әбисе М.А.Ганнибалдан ишетә һәм үсеп житкәч, Ибраһим Ганнибал исемен рус тарихында саклап калырга тырыша һәм, иң әүвәл, аны "Бөек Петр гарәбе" дигән тарихи роман каһарманы итеп тасвирлый. Күренекле тарихчы Д. Бантыш-Каменский Пушкин сүзләренә таянып, И.Ганнибал турында тикшеренү яза һәм аны "Словарь достопамятных людей русской земли" дигән сүзлеккә кертә. Пушкин Ганнибаллар нәселенең башка әгъзалары турында да мәгълүматлар туплый. 1817 елда, Лицейны тәмамлагач, ул Ибраһимның икенче улы Петр Ганнибалдан аның хатирәләрен тыңларга һәм Ганнибаллар шәҗәрәсенә караган документларның сакланганмы-юкмы икәнен тикшерү нияте белән аның утарына бара. Соңыннан, Бессарабиядә йөргән чагында, Пушкин өлкән яшьтәге кешеләрдән Ибраһимның олы улы, Россия белән Төркия арасындагы дингез сугышларында катнашкан Иван Ганнибал хакында сораша.

Бөек рус шагыйре Пушкинның тамырларында "чит", Африка каны булган икән, бередә бернинди шаккатарлык нәрсә юк. Күп кенә мәшһүр рус язучыларының тирән тамырларында, аерым алганда, бөтен дөньяга танылган Г. Р. Державин, Н. М. Карамзин, В. А. Жуковский, М. Ю .Лермонтов, И. С. Тургенев, Ф. М. Достоевскийларда, барыннан да күбрәк, татар каны аккан һәм бу—гадәти күренеш. Рус язучыларының күпчелегенең нәселләренә нигез салган ата-бабалары башка милләтттән булу аларда дөньяны яңача, полифоник күзаллау һәм үзләштерү хасиятен тудыра. Дөрес, күбесенең күзалламасында гайре рус ата-бабалар бары тарихи әһәмияткә ия булган, хикмәтле, әмма күптән узган күренеш булып саналган. Пушкин өчен, үзе әйтүенчә, аның "анасы ягыннан африкалы" булуы биш былтыр заманнарда бикләнеп калмаган, киресенчә, аның сәнгатьле иҗатына кискен рәвештә йогынты ясап килгән. Әңгәмәләрдә, хатларында, автопортрет, рәсемнәрендә Пушкин үзенең кыяфәтенә хас африкалы тамгаларны аерымларга ярата: кара тутлы, аска таба сузылган бите, калтырап-калтырап куйган африкалы иреннәре, эре ак тешләре, елгыр йөзе... Шук, ашкынулы, дәртле Пушкинга яшь чагында иптәшләре Шөрчек, Чаткын кебек кушаматлар тakkаннар. Аның бөтен торышыннан, холык-фигыленнән И.Ганнибал токымы нәсел итеп алган ярсучан холкы ташып тора. Тышкы охшашлык белән генә чикләнмичә, Пушкин үзенең И.Ганнибал белән тугандашлыгын рухи тигезлектә, психологик кичерешләрдә, тормыш-көнкүрешваклыкларында сурәтләргә тырыша. И.Ганнибал да, нинди генә рәхәт тормышта яшәмәсен, үз илен онытa алмый, ялгызлык хисен кичерә. Петр I вафатыннан соң, дошманнары И.Ганнибалны Себергә җибәрәләр. Ул аннан качып кайта, үз авылында яшеренеп ята, кулга алынудан куркып яши.

Михайловскоеда гомер кичкән чакта Пушкин шулай ук ялгызлыгын, дусларыннан ераклашкан булуын авыр үткәзә, "Языковка" дигән шигырендә үзен биләгән уй-кичерешләрен "ерак Африкасы" турында хыялланган И.Ганнибал кичерешләренә тиңли. Овидий, Наполеон, Байрон, Мөхәммәт тә, Пушкин карашынча, шундый ук сөрген михнәтен татыган шәхесләр.

Пушкин И.Ганнибалда русларга чит булган башка мәдәният, үзгә рухи төзелеш иясен күрә, аны аңларга тели. Киң мәгънәдә, бу теләк—шагыйрьнең башка культуралар, шул исәптән Шәрекъ дөньясы белән киң аралаша башларга әзер булуы билгесе.

* * *

Пушкинның Шәрекъ темасына йөзе белән борылганын тагын бер вәзгыять аңлата: XIX гасырның беренче яртысында Россия белән Көнбатыш Европада Шәрекъ белән кызыксыну көчәйгәннән-көчәя бара. Россиядә ул чорда Казан университеты галимнәре ориенталистика фәнен алга чыгара, җәмгыятьтә шәрекъ проблемаларына кызыксыну уята. Казан университетында 20 нче елларда татар, гарәп, фарсы, монгол, әрмән телләре өйрәнелә, 30 нчы елларда болар янына төрек, кытай, манчжур һәм кайбер башка телләр өстәлә. Университет каршында Азия типографиясе ачыла, гарәп, монгол, тибет шрифтларында китаплар басыла. Казанда өстенлек иткән шәрекъ атмосферасы яшь Пушкинның лицей укытучысы И.Кайдановны да, Пушкин яратып йөргән драма, музыка, балет сәнгатьләрен дә, шәрекъ темасына урын биргән төрле журналларны да үзенә тарта. Турыдан-туры булмаса да, Казан Пушкинга билгеле бер йогынты ясамыйча калмаган. Пушкин Казанны күрә, аның Россия тарихына һәм мәдәниятенә ясаган йогынтысына югары бәя бирә, "Әрзерумга сәяхәт" дигән юл язмаларында: "Әрзерум белән Константинополь арасында, Казан белән Мәскәү арасындагы кебек, бер-берсен уздырырга тырышу күзәтелә", — дип кызыклы чагыштыру ясый.

Пушкин укыган Коръән китабын рус теленә тәрҗемә итүче (1790 елда нәшер ителгән) М.И.Веревкин да Казан белән бәйле шәхес булган. Михаил Иванович Веревкин 1759—1762 елларда Казан гимназиясе директоры булып эшли. Бу чорда шул гимназиядә Г.Р.Державин, С.Т.Аксаков, Н.И.Лобачевскийлар укый. Веревкин Казанда беренче театр ача, Болгар җиренә беренче археологик экспедиция оештыра; бу тикшеренүләрдә Г.Р.Державин актив катнаша, борынгы шәһәрнең планын төзи, төзелеш калдыкларын рәсемгә төшерә, җирдән акчалар һәм әйберләр казып таба.

М. В. Ломоносов Россиядә шәрекъ телләрен өйрәнергә кирәк дигән фикер уздыра. Шул фикергә нисбәтән, Веревкин әлеге гимназиядә татар телен өйрәнү мәсьәләсен күтәрә. "Здешний город есть главный целого царства татарского национального диалекта. Не позволено ли будет завести при гимназии класс татарского языка..." — дип, Петербург даирәләренә мөрәҗәгать итә. Соңарып булса да, 1770 елдан башлап, гимназиядә татар теле укытыла башлый. Казан шәһәре Веревкинда Шәрекъкә нисбәтән зур кызыксыну уята.

Веревкин Коръәнне А.Де Риэ ясаган французчадан тәрҗемә итә. Әйтергә кирәк, Казан галименең тәрҗемәсе Д.Кантемир, А.Колмаков тәрҗемәләреннән үзенең шигъриятлелеге белән аерылып тора. Пушкин тикмәгә генә аңа иярми. Арттырып җибәрмичә, шуны әйтеп була: Коръәнне шигъри үзләштергәндә Пушкин Веревкин белән иҗатташлык иткән.

* * *

"Коръәнгә иярүләр" бәйләме тугыз шигырьдән тора. 114 сүрәдән торган Коръән белән чагыштырганда шигырь бик аз булып күренергә мөмкин. Әмма шунысы характерлы: антик шагыйрьләр — Анакреонт, Овидий, Горацийга, италиялe Дантега, француз А.Шеньега, иранлы Хафизга, Библиягә ияргәндә Пушкин, кагыйдә буларак, бер-ике тезмә белән чикләнә. Бу юлы исә тугыз ияру. Шуна өстәп, Пушкинның башка әсәрләрендә, хатларында, көндәлек дәфтәрләрендә Коръәнне даими телгә алуын хисаплап чыгарсак, аның бу изге китапка аеруча

игътибарлы булуы турында сөйләргә хаклыбыз.

Иярүләрен Пушкин "ирекле" дип атаган. Бу ана иҗатында шәкел сайлауда берникадәр иркенлек биргән, ләкин сюжет, образ, мотивларда ул төп чыганактан тайпылмый. Мәсәлән, беренче иярүендә Пушкин 93 нче сүрә үзәгендә яткан хәл-әхвәлне хәтерендә янарта: ялгыз калган, өзгәләнгән, үз көченә дә, Тәнре ярдәменә дә ышанычын югалта башлаган Мөхәммәткә Алла ярдәмгә килә, Пәйгамбәрен ташламаска, җәбердән сакларга вәгъдә бирә һәм Алла сүзен гавамга таратырга тиешле булуын искәртә:

Нет, не покинул я тебя.
Не я ль в день жажды напоил
Тебя пустынными водами ?
Не я ль язык твой одарил
Могучей властью над умами ?
Мужайся ж, презирай обман,
Стезею правды бодро следуй,
Люби сирот, и мой Коран
Дрожащей твари проповедуй.

Тугызынчы иярүдә Пушкин 2нче сүрәдәге 261нче аятьнең сюжетына һәм мәгънәсенә таянган. Бер юлчы җимерелгән авыл янышнан узганда: "Алла моны җанландыра алмас",— дип шөбһәсен белдерә. Алла юлчыны элек үтертә, аннары терелтә һәм шуның белән үзенең тормышка, үлемгә һәм вакытка хуҗа булганын исбат итә. Пушкин юлчы образын һәм сюжет агымын бераз үзгәртә төшә, әмма аятьнең мәгънәсен саклый. Шигырьдә юлчы чүлдә йөреп адаша һәм эсселеккә, сусауга, тузанга түзә алмыйча, Аллага ризасызлык белдерә. Алла аның сусавын бастыра, ана куләгәдә ышык бирә һәм аны озак елларга йокыга талдыра. Картайган юлчы йокыдан уянып торгач, заяга узган вакытын кызганып, кычкырып еларга тотына. Алла моны күреп, вакытны кирегә бора һәм юлчыга яшьлеген һәм ышанычын кире кайтара.

Бәйләмдәге башка шигырьләр сюжет һәм мәгънә ягыннан түбәндәге төп нөсхәдәге сүрәләргә ярашалар: 2нче шигырь — 32нче сүрәгә; 3нче — 80 нчегә; 4 нче — 2 нчегә; 5нче — 21 нчегә; 24нчегә һәм 31нчегә; 6 нчы — 48 нчегә; 7 нче — 73 нчегә; 8 нче — 2 нчегә таянып иҗат ителгән.

Әмма Пушкин санап чыгылган сүрәләр белән чикләнмәгән, башка сүрәләрдән тема һәм сурәтләр алган, анализ күрсәтүенчә, утыздан артык сүрәгә таянган. Сан ягыннан чагыштырмача аз шигырьләр язып, шулар ярдәмендә Пушкин Коръәннең киң колачлы, бай эчтәлеген — Алланың кодрәтен, нәсихәтләрен, космологияне, әхлак кагыйдәләрен, сугыш батырлыкларын һ.б. — рус укучысына ирештерергә тырыша.

Пушкин шигырьләрендә, эчтәлектән тыш, Коръәннең башка яклары да, хосусан, композицион төзелеш, сәнгатьлелек сыйфатлары тиңдәшлек таба. Мәсәлән, "Коръәнгә иярүләр"дә, изге китаптагыча, Алла Пәйгамбәргә, сугышчыларга, юлчыга, юмарт һәм саран кешеләргә үз исеменнән, турыдан-туры эндәшә: Менә 8нче шигырь. Алла Мөхәммәтне үгетли:

Восстань, боязливый:
В пещере твоей
Святая лампада
До утра горит.
Сердечной молитвой,
Пророк, удали
Печальные мысли,
Лукавые сны !
До утра молитву
Смиренно твори;
Небесную книгу
До утра читай !

Пушкин шигырьләрендәге Алланың кешегә туп-туры мөрәҗәгате рус һәм Аурупа укучыларына көтелмәгән, чиктән тыш күренеш булып тоела. Тора һәм Евангелиедә — яһүдләрнең һәм христианнарның изге китапларында, — кагыйдә буларак, кемдер Ходай турында яза, сөйли, динчеләргә аның нәсихәтләрен житкерә. Коръәндә исә бөтенләй башка төзелеш. Монда Алланың туры сөйләме өстенлек итә. Коръән — Алланың үз изге сүзләре, аларны һәркем ишетә. Дингә инанучының күңеле Алла белән турыдан-туры аралашу шатлыгын кичерә. Бу алым исламның киң таралуына ярдәм итә, дингә инанучылар, руханилар арасында үзара махсус (хәзерге тел белән әйтсәк, демократик) мөнәсәбәтләр урнашуга гаять әһәмиятле сәбәп булды.

Аурупа тәрбиясен алган Пушкин Коръәннең бу сыйфатын гажәпләнеп кабул итә, аның тәэсир көченә, сәнгать кануннарына туры килгән сыйфатларына, ижади илһамлану өчен киң мөмкинлекләренә югары бәя бирә. "Коръәнгә иярүләр"дән соң бер ел узуга "Пророк" (Пәйгамбәр) исемле мәшһүр шигырендә туры сөйләм алымын бик иркен файдалана:

И бога глас ко мне воззвал:<br>
"Восстань, пророк, и виждь, и внемли,<br>
Исполнись волею моей,<br>
И, обходя моря и земли,<br>
Глаголом жги сердца людей".

"Пророк" шигыре Пушкин поэзиясендә аерым урын тота: ул шагыйрьнең ижади карашлары һәм тормыш позициясе шигаре кебек кабул ителә. Аннан да бигрәк, ул рус әдәбияты өчен программ әсәр. Ләкин Коръәннең бу шигырьгә ясаган йогынтысын рус әдәбият фәне күрмәмешкә салыша. Пушкин әсәрләренең соңгы (1977 елгы) академик басмасында "Пророк" шигыренә ясалган комментарийләрдә тик Библия мотивларын файдалану турында сүз алып барыла, Коръәннең йогынтысы исәпкә алынмый.

Коръәнне укыганда, Пушкин рус кешесе өчен күнегелмәгән әхлакый, эстетик, фәлсәфи кыйммәтләр системасын тәшкил иткән яңа дөньяга кергәнен сиземли, үзе ошбу мохитка гашыйк була, аның шул дөньяны укучыларына да якынайтасы килә. Рус шагыйре Коръәннең тагын бер үзенчәлеген—фикерләү ысулын, дөньяга карашлар структурасын отып ала һәм оста итеп чагылдыра. Күренекле ислам дине белгече Г. Грюнбаум, ислам һәм христиан мәдәниятләрен чагыштырып, беренчесендә бер башкалык — фикерләү "атомарлыгы"н ("атомарность") күрә. Ислам, барыннан да элек, дөньяны аерым элементлардан төзелгән кыяфәттә күзаллый, тәмамланган вакыйгаларга караганда, күбрәк аерым чагылышларга игътибар итә, дөньяның матдәләрен, күренешләрен, кешенең уй-кичерешләрен бер рәттә һәм бер арада урнаштыра. Мәсәлән, яхшылык-мактаулы тәгаен эшләр бердәмлеге, дөньяның матурлыгы мотлак идеалда булмыйча, әйләнә-тирәдәге предметлар, күренешләр, гамәлләрдә туплана: кеше боларны мантыйки-нисби рәвештә түгел, ә бәлки конкрет тулылыгында, хисси рәвештә тоемлый, үзләштерә.

"Коръәнгә иярүләр"гә кереш сүзендә Пушкин Коръән аятьләрендә, антларында төрле-төрле предметлар һәм күренешләрнең рәттән тезелеп китүенә ишарә итә. "Коръәннең башка урыннарында, — дип яза ул, — Алла бияләр тояклары, инжир жимешләре, Мәккә азатлыгы, гаделлек һәм бозыклык, фәрештәләр һәм адәм баласы һәм башкалар белән ант итә. Бу сәер риторик алым Коръәндә минут саен очрый". Пушкин бу ысулны файдаланып, рус укучысы хыялын уятырга тырышкан булса кирәк. "Коръәнгә иярүләр"дә бер рәткә тезү һәм контраст алымнары предметлар тигезлеген дә, рухи биеклекне дә күрсәтүгә хезмәт итә. Чын белән ялган, батырлык белән куркаклык, бүләк һәм жәза, юмартлык һәм саранлык, тыйнаклык һәм бушбугазлык, яшәү һәм үлем—бу төшенчәләр һәм Коръән эчтәлегендә, һәм Пушкин әсәрләренең лексикасында очрый. 6 нчы иярүнең байтак өлеше динамизм, хәрәкәт белән сугарылган аяусыз сугыш күренешеннән гыйбарәт, соңгы юлларда исә—тынычлык һәм ләззәтләнүгә кискен күчү:

Блаженны падшие в сраженье:<br>
Теперь они вошли в эдем<br>
И потонули в наслажденье,<br>
Не отравленном ничем.

Шулай да, Пушкин әйберләрне һәм күренешләрне санап чыгу һәм каршы кую белән чикләнми. Ул матди һәм рухи күренешләрнең күптөрлелеген — үз шигырьләренең ритмнары, рус теленең сыгылмалы көче, аятьләрнең пластикасы, гарәп лисанының аһәңлелеге ярдәмендә — искиткеч тәңгәллектә берләштерә.

Рус шагыйре яна шигъри калыплар һәм фикерләү рәвеше белән бергә, христианлыктан (рус аңыннан) үзгә булган әхлакый кыйммәтләр бердәмлелеген таба, мөселманнар өчен нигез үзәкне тәшкил иткән әхлакый төшенчәләргә тап була. Ислам өйрәтүенчә, батырлык югары сыйфат саналып, аның янәшәсенә юмартлык куела. Юмартлык, гади кунакчыллыктан битәр, сыеныр урыны булмаган фәкыйрьгә ярдәм кулын сузуны таләп итә. Юмартлык намус белән, саранлык түбәнлек белән тиңләштерелә.

Торгуя совестью пред бледной нищетою,
Не сыпь своих даров расчетливой рукою:
Щедрота полная угодна небесам.
В день грозного суда, подобно ниве тучной,
О сеятель благополучный,
Сторицею воздаст она твоим трудам.
Но если пожалев трудов земных стяжанья,
Вручая нищему скупое подаянье,
Сжимаешь ты свою завистливую длань;
Знай: все твои дары, подобно горсти пыльной,
Что с камня моет дождь обильный,
Исчезнут, господом отверженная дань.

Корьәннең әдәп-әхлак таләпләре шагыйрьнең әхлакый эзләнүләренә аһәңдәш иде, һәм ул аларны кискенләштерде, көчәйтте. Нәкъ Михайловское авылында, "Корьәнгә иярүләр"не иҗат иткән чорда, Пушкин әхлакый мәсьәләләрне алга чыгарып, "Саран пәһлеван", "Моцарт һәм Сальери" исемендә кечкенә трагедияләрен язарга ниятли (алар берничә елдан соң язылачак).

* * *

Пушкин Мөхәммәткә мөнәсәбәтендә христианнар аңына сыеша алмаган караш үстерә. Ул замандагы христианнарның күпчелеге Мөхәммәткә ничек караган? Янәсе, ул алдау һәм ирексезләү нәтиҗәсендә хакимияткә ирешкән һәм популярлык казанган ялган һәм мәҗүси пәйгамбәр.

Пушкинның Мөхәммәткә яңача карашы төрле сәбәпләр аркасында калыплана. "Корьәнгә иярүләр"дән күренә ки, Мөхәммәт Алланың кешеләргә юнәлтелгән сүзләрен тапшыручысы — арадашчы хезмәтен башкара. Рус шагыйре, бу очракта, Алла сүзен ишеткән мөселман кешесенә әверелә һәм мөселман кешеседәй уйлый башлый. Ләкин коры мантыйк кушканча фикерләгәндә, Пушкин Мөхәммәтне Корьән авторы дип санау ягына авыша. П. Вяземскийга язган бер хатында Пушкин Мөхәммәтне бөек шагыйрьләр Сәгъди һәм Хафиз белән янәшә куя. Пәйгамбәр белән шагыйрьне бер үк шәхестә тоташтыру, синтезлау Пушкин өчен табигый, аның дөньяга карашына яраша иде һәм шигырьләрендә гәүдәләнешен тапты. Мондый синтез Пушкинга үзе белән Мөхәммәт арасында чагыштырулар ясарга мөмкинлек бирә. Пушкинга Мөхәммәт рухы башка тарихи шәхесләр рухына караганда якынрак булып чыга. Пушкин П.Вяземскийга үзенең беренче әсәрләр җыентыгының язмышы турында болай дип яза (1824 ел, 29 ноябрь): "1820 елда мин үземнең уйдырмамны күчереп яздым һәм аны укучыларым өчен бастырып чыгарырга җыена идем дә, кульязмамны Никита Всеволжскийга карта уйнап оттырдым (әлбәттә, билгеле бер шарт белән). Шул чакта Мәккәдән Мәдинәгә качарга мәҗбүр булдым, минем Корьәнем кулдан кулга йөри башлады — әлегә кадәр бик нык ышанучылар аны көтәләр. Хәзер инде мин кульязманы эзләп табуны һәм сатып алуны энемә тапшырдым."

Пушкинның мөстәкыйль фикер йөртүче дуслары, мәсәлән, К.Рылеев, П.Чаадаев Пушкин белән Мөхәммәт арасындагы охшашлык турында ассызымлап әйттеләр. Рылеев һәм Чаадаев шагыйрьнең, шигъриятнең җәмгыятьтә югары урын тотканына

ишарәләп, Пушкинны пәйгамбәрләр, ягъни гражданлык үрләренә күтәрелергә чакыралар һәм бу мөнәсәбәттә Мөхәммәт исемен телгә алалар. "Син безнең Байроныбыз була аласың, — дип яза Рылеев. — Әмма, Алла хакына, Гайсә хакына, синең яраткан Мөхәммәтең хакына Байронга иярмә". Чаадаев "Коръәнгә иярүләр"не укып чыккач, хәйран кала һәм: "Пушкин бу көннән башлап Коръәнгә һәм Мөхәммәткә ияреpгә тиеш", — дигән фикергә килә. Пушкинга адресланган бер мәктүбендә (1828 ел, март—апрель айлары) Чаадаев мондый сүзләр әйтә: "Бу мескен юлдан язган Россиягә чиксез игелек китерә алуыгызга ышанам" һәм: "Сау булыгыз, дустым, Мөхәммәт үзенең гарәпләргә әйткән сүзләрен сезгә әйтәм — эх, белсәгезче! " — дип хатын тәмамлый.

* * *

Ничек итеп гарәп телен белмәгән, исламнан ерак булган үзгә мохитта тәрбияләнгән Пушкин Коръәнне тик тәржемәдә укып, аның мөндәрижәсен, рухын, калыпларын отып алуга ирешкән? Монда Пушкинның шигъри сиземләве мөһим роль уйнаган. Шуның белән бергә Пушкин башка халыкларның рухи халәтенә үтеп керү хасиятенә ия булган. В. Г. Белинский Пушкинны борынгы грек мифологиясендәге Протей исемле алла белән чагыштырган иде (риваять буенча, Протей арыслан, чуар юлбарыс, аккан су, агач, һ.б. кыяфәтен алу осталыгына ия). Мондый сыйфатка синестезия (бергәләп хис итү) дигән фәнни атама уйлап табылган.

Кайбер караламаларының кырларына Пушкин гарәп хәрефләрен язып куйган, чөнки аңа үз күзләре белән хәрефләрен күрү, мөкиббән киткән Сәгъди һәм Хафизларның язу рәвешен тою, гарәп сөйләменең аһәңен тыңлагандай булу кирәк булган. Пушкинның шәхси китапханәсендә француз, инглиз, рус һ.б телләрдә язылган китаплар саны шактый. Ул китапларда гарәп шрифтында язылган сүзләр дә еш очрый.

Кавказда йөргән чакта Пушкин чит телләр башка мәдәниятләр дөньясына эләгә, башка лисаннарга колак сала, аларны мөмкин кадәр кулланырга тырыша; юл күрсәтүченең төрек телендә сөйләшүен дикъкать белән тыңлый, сүзләрнең мәгънәсенә төшенә ("җәнүб сөргене" елларында ул төрек теленнән хосусый рәвештә дәресләр алган); сәяхәттә вакытында бер тукталышта татар телендә эчәргә су, икенче тукталышта төрек телендә атлар сораган. "Әрзерумгә сәяхәт" әсәрендә грузин, әрмән, инглиз, француз, латин, фарсы сүзләре очрый. Пушкин төрле телләр өйрәнүне хуп күргән.

* * *

"Коръәнгә ияpүләр"дә һәм башка "шәркый" әсәрләрендә Пушкин рус укучысы алдында Шәрекъ дөньясын ача, аңа бүтән мохит үзенчәлекләре белән танышырга мөмкинлек бирә. Христианнар, шул исәптән, рус халкы аңында Көнчыгыш гасырлар буена чит, Көнбатышка каршы куелган дөнья сурәтендә иде. М.Херасков "Россиядә" исемле поэмасында (1779) русларның Казанны яулап алуын менә ничек тасвирлаган: гуманлы христианлык мәҗүси, вәхши исламны җиңә, әллә нинди чит-ят нәмәрсәкәйне хаклы рәвештә бастыра. Ислам кылыч һәм алдау юлы белән кертелгән дин буларак бәяләнә. Исламның әхлакый, җәмгыяви кыйммәтләре көлке итеп сурәтләнә. Дөрес, XYIII гасырда башка рухтагы, чын гуман юнәлештәге язучылар да (Г. Р. Державин, Н.М.Карамзин) әдәбият мәйданына аяк басалар. Гарепне Шәрекъкә кискен рәвештә каршы кую тенденциясе дә көчсезләнә төшә. Әмма бары тик Пушкин гына "безнеке-чит" антиномиясен җиңеп чыгу юлын күрсәтте. Христиан мәдәнияте, Аурупа мохиты тышында урта гасыр аңына "чит планета" булып күренгән кызыклы рухи, матди дөньялар яши икән. Аларга нәфрәт күзе белән карамаска, аларга каршы сугыш ачмаска, киресенчә, аларны аңларга, дустанә мөнәсәбәт урнаштырып, үз күңел дөньяны киңәйтергә, яңа эстетик ләззәтләнүләр татырга кирәк. Дөнья мәдәниятләрен бәяләүдә Пушкин евроцентризм карашыннан кискен рәвештә читләшә.

Ислам — үз закончалыкларын саклаган төзек, бердәм мәдәният. Ул башка мәдәниятләр белән диалог алып бару өчен ачык, ярдәмчел, чөнки анда аерымлык

тик гомумилек белән бәйләнештә чын тәнгәллеккә ирешә. Пушкин исламның үзара аралашу алып бару мөмкинлекләрен шактый мул файдалана. "Коръәнгә иярүләр"ендә ул салкын күзәтүче. Коръән сюжетларын, идеалларын теркәп баручы булып калмый, аның битләрендә ул "үз" фикерләрен, кичерешләрен таба, аларны иҗатында үстерә. Шул ук вакыт, Пушкин Коръәндә яна образларга, яңа фикри ачышларга юлыга, шулар белән үзенең дөньяга карашын тулыландыра, иҗатына нигез итеп сала. Шәрекъ шагыйрьләре һәм Коръән белән иркен диалог алып бару нәтиҗәсендә, Пушкин иҗатында Көнбатыш-Көнчыгыш бердәмлегенә юл ачыла. Тора-бара Пушкин даирәсендә Шәрекъ белән кызыксыну көчәя башлый, Шәрекъ орбитасына шагыйрь үз дусларын: П. А. Вяземский, К. Ф. Рылеев, П. Я. Чаадаев, А. А. Бестужев, А. А. Дельвигны — тарта; Шәрекъ темасына бирелеп киткән О. И. Сенковскийга булышлык күрсәтә, үзенең "Современник" журналында Солтан Газый Гәрәйнең Кавказ халыклары тормышыннан язган этнографик новелла хикәяләренә урын бирә, ориенталист Н.Бичурин тәрҗемәләрен "Литературная газета"да бастыра.

* * *

Пушкинның Шәрекъкә нисбәтән иҗади планнары тулысынча үтәлми кала. Пушкин Шәрекъ буенча профессиональ белгеч түгел иде, көнчыгыш телләрен белүе, күбесенчә, көндәлек сөйләшү өчен генә ярашлы иде. О.Сенковский, Н.Бичурин һәм күп кенә башка ориенталистлар Шәрекъ телләрен һәм тарихын Пушкинга караганда күбрәк белделәр. Пушкинның Шәрекъ турында язганнары да артык күп түгел. Аның замандашы һәм әшнәсе А.Бестужевның Шәрекъкә мөнәсәбәтле әсәрләре сан ягыннан күбрәк. Шуңа да карамастан, гадәттән тыш сәнгатьле сиземләү һәм кеше хәленә кереп, уртаклашучан сыйфатка ия булу сәбәпле, Пушкин үзенең замандашларын һәм үз чорын узып китте. Ул Россиядә беренче булып Ислам даирәсен, мохитен, Шәрекъ мәдәнияты җәүһәрләрен үзе өчен ачып, укучыларына җиткерде, Шәрекътә гомумкешелек рухын күрде һәм аннан башка иҗатта диалог та, кеше хөрлеге дә мөмкин түгеллеген күрсәтте.

Бөек державачылык, өстенлек рухы белән агуланган шул чор рус җәмгыятенең күпчелеге Пушкин ачышларын кабул итмәде. "Коръәнгә иярүләр" әдәби тәнкыйть тарафыннан гына түгел, ә бәлки әдәбият белемендә дә үз вакытында тиешле бәясен ала алмады. Чорның Чаадаев, Гоголь, Белинский, Н.Страхов, Достоевский кебек алдынгы шәхесләре кагыйдәдән чыгарма иделәр.

Пушкин рус язучыларының чагыштырмача кечкенә, ләкин иң кыйммәтле өлешен Шәрекъкә кызыксынып карарга илһамландырды. Л.Толстойның "Хаҗи Морат" повесте, К. Леонтьев, И. Бунин, В. Хлебников, А. Платонов, Вс. Иванов һәм кайбер башка язучыларының Көнчыгышка багышланган әсәрләре — нигез ташларын Пушкин салып калдырган традицияләрнең дәвамы.

Шул ук вакытта бөек Пушкин башлап җибәргән шәрекъ традицияләре рус әдәбиятының агым суына коелган кечтеки инеш булып кына калалар. Рус әдәбияты,рус әдәби тәнкыйте, күбесенчә, Көнбатышка күз тота.

1880 елда Мәскәүдә Пушкинга һәйкәл ачу мөнәсәбәте илә Ф. Достоевский рус җәмгыятендә яңгыраш тапкан нотыгында: "Дөнья шагыйрьләре арасыннан тик Пушкин гына җаны-тәне белән башка, ят күренгән культурага бирелеп, аны үзләштерү хосусиятенә ия булды," — дип сөйләде. "Үз рухы чит халыклар рухына тәңгәл килү"ендә Достоевский "рус кешесенең тәкъдирен" күрде. "Чын рус кешесе булу өчен (моны ахыр чиктә ассызыклагыз) барлык бәшәриятнең туганы, барлык кешеләр өчен кеше булу лязим," — дип, ышанычын белдерде.

Пушкинның милли иҗади эшчәнлек программасын төзүенә гасыр ярым, Достоевскийның бу юнәлешне хуплап нотык сөйләвенә 100 елдан артык вакыт үтте. Рус әдәбияты бу программаны тормышка ашыра алдымы? Рус характеры гомумкешелек баскычына күтәрелә алдымы? Бу турыда күп бәхәсләшергә мөмкин, ләкин ахыр бәяне укучының үзенә калдырыйк.

**Җәмил САФИУЛЛИН,**
*КДУ профессоры*

# ДРАМАТУРГИЯ



*Соңгы вакытта республикабыз матбугаты битләрендә һәм сәхнәләрдә яшь прозаик һәм драматург Рәдиф Сәгъдинең әсәрләре еш күренә. 1994—1997 елларда «Идел» журналы битләрендә аның «Канга буялган алтыннар», «Соңгы көрәшү», «Каргыш», «Кыйммәтле килешү», «Ниһаять, көтмәгәндә...» исемле детектив повестьлары, «Адашканнар» исемле фантастик хикәясе дөнья күрде. Хәзер К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә Р. Сәгъдинең «Сынган беләзек» мелодрамасы зур уңыш белән бара. Моңардан тыш театрда аның балалар өчен язылган «Баһадурның бәхете», «Баһадурның яңа дуслары» исемле музыкаль әкиятләре куелган иде. Чаллыдагы Татар дәүләт яшьләр театры исә яшь драматургның «Финляндиядә рәхәт, ди...» исемле музыкаль комедиясен сәхнәләштереп, тамашачы хөкеменә тәкъдим итте...*

*Рәдиф Нәҗип улы Сәгъдиев 1957 елның 15 июлендә Казан шәһәрендә туа. Казан театр училищесының актерлар хәзерләү группасында һөнәр үзләштерә, армия сафларында хезмәт итә, Әлмәт театрында, төзелештә, берничә ел К. Тинчурин исемендәге театрда эшли. Бер үк вакытта, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультетында читтән торып укый. Бүгенге көндә ул—Казандагы Яшьләр театрының администраторы...*

*Р. Сәгъдинең «Сынган беләзек» мелодрамасы яшь авторның «Казан утлары»нда дөнья күрүче беренче әсәре.*

**Рәдиф Сәгъди**

## СЫНГАН БЕЛӘЗЕК

МЕЛОДРАМА

*Гомере буе Мифтахетдин исемле газиз улының сугыштан кайтуын өзелеп көтеп яшәгән, елый-елый күзләре сукырайган сөекле әбием Фәгыйләнең якты истәлегенә багышлыйм әлеге әсәремне.*

**Катнашалар:**

Мифтахетдин—Хафизның югалган әтисе.
Хафиз— Мифтахетдинның улы.
Маһирә—Хафизның хатыны.
Фәрдия—Хафизның кызы *(шул ук вакытта Фәгыйлә ролен дә башкара).*
Зиннур—күрше карты, Мифтахетдинның яшьлек дусты.
Диләрә—Мифтахетдинның икенче хатыны.

**Вакыйга безнең көннәрдә Татарстан авылларының берсендә һәм Швеция башкаласы Стокгольмда бара.**

## *Беренче пәрдә*

### Беренче күренеш

**Авыл өе. Хафиз белән Маһирә үзара сөйләшәләр.**

Хафиз. Нишләргә?..

Маһирә. Тагын нәрсәләр аласың?

Хафиз. Тальян гармун белән беләзек кисәген онытма! «Ачтан үлсәк үлдек, әмма бер әйберенне дә сатмадык!»—дип күзенә төртеп күрсәтермен мин аның. Ичмасам, сугышта беткән булса да яхшырак булыр иде. Ярый әле, әнкәй иртәрәк китеп котылды. Күтәрә алмас иде мескенкәем бу хәбәрне...

Маһирә. Шуны да онытма: «Илле ел ачлы-туклы яшәдек, өебез ишелергә тора...»—диген, бер дә җебеп калма! Җүнле кеше булса, кош теледәй генә булса да берәр хәбәрен күптән җибәргән булыр иде... Малаең Рамил общагада ята, аңа фатир алырга диеп җыйган акчага барганыңны онытма! *(Кызлары кайтып керә).*

Фәрдия. Нәрсә, әни, җыенып бетеп буламы? Уф, дәрестән көчкә ычкындым. Әти, мин сиңа список алып кайттым. Менә, әти, миңа кирәкле әйберләр исемлеге. Менә бусы—укытучыларга, бусы—иптәш кызларга...

Хафиз. Син генә җитми иде әле биредә... Нишләп дәресеңнән качтың?

Фәрдия. Качмадым ла, авыруга сабышып киттем. Әти дим, әти, быел бит минем дәүләт имтиханнары бирәсем бар, укытучыларга дигән исемлекне онытма инде, яме?! Анда шул безнең класска компьютер да, алгебра укытучысына бер күлмәк алырсың. Аннары—теге геометрия укытучысы Мансур Фазылычка—бер эшләпә, аның эшләпәсе искергән...

Хафиз. Тагын нәрсә?!

Фәрдия. Анда барысы да язылган! Минем үземә косметика, джинсовый итәк-күлмәк. Аннан чыгарылыш кичәсенә дә берәр нәрсә карарсың инде.

Хафиз. Акчаң булса, монда да әйбер тулып ята.

Фәрдия. Дәү әтигә әйт: «Сине оныгың бик ярата, бик күрәсе килә!»—диген... Шулай дисәңме?! Ул, соңгы сыерын сатып булса да, миңа бүләк алачак. Менә күрерсез!

Маһирә. Син генә исендәдер инде аның!.. Аннан... Швециядә нинди сыер асрасыннар инде. Анда безнең кебек авыллар юк, диләр бит—сөт белән каймакны Америкадан китерәләр икән...

Фәрдия. *(Көлә.)* Әнкәй, каян беләсең соң син барысын да?..

Маһирә. Аллага шөкер, беләм, сигез генә класс бетерсәм дә... Мәсәлән, Һиндстаннан чәй китерәләр, Африкадан апельсин, банан... көн саен телевизордан күрсәтәләр бит...

Фәрдия. Дөрес, әни, дөрес! Әти дим, онытма инде, яме?

Хафиз. Нәрсәне?

Фәрдия. Миңа дигән бүләкләрне!

Хафиз. Сорамыйм бер нәрсә дә! Сукыр бер тиен дә кирәкми. Барып, менә монда *(кулын йөрәк турына куя)* кайнаганны-тулганны гына әйтеп кайтам! Моңа хәтле ансыз яшәдек, моннан соң да яшәрбез!..

Маһирә. Гел киресен сөйлисең. Без бит сиңа, хәер сора, димибез. Алимент урынына бер ун-унбиш мең үз акчаларын бирсә, шул җитә. Әгәр акча бирсә, машинаны шуннан алып кайтырга кара! Анда безнең машиналарның поты бер тиен тора, ди. Акчаң җитәрлек булса, үзләрендә чыкканын ал, ничек әле теге ни малае утырып йөри, Э..май заводы директоры малае?..

Фәрдия. Ә, Галләм абый малае! Ул бит «Вольво» да! Ох, ты! *(җырлый)*

«Вольво»ларга утырып ла,
Дус кызларны тутырып,
Китәр идем Швециягә—
Калырлар күз тутырып!..
«Пи-би-бип» лә, «пи-би-бип», дип,
Чабар иде машинам...
Бер түгел, унбер шәп егет
Чыгар иде каршыма!..

Әти дим, әти! Ни... миңа косметика булмаса-булмас, тик машинасыз кайтма, яме?!

Хафиз. Алардан бер нәрсә сорамыйм да, алмыйм да, миңа берни дә кирәкми.

Маһирә. Соң, машина алам диеп, гомерең буе этләнден бит үзең! Дистә еллар буе җыйган акчаң янды. Инде үзең турында уйламасаң, хет, малаең турында уйла!

Фәрдия. Их, шул «Вольво»ларга утырып, урам буйлап узсаң! Тирә-як күршеләрнең күзләре ут булып янар иде. Завсклад Нурминең девяткасын да «выжт!» итеп кенә узып китәр идек.

Хафиз. Життеме, юкмы сезгә?! Әнә шул Нурмигә утырып йөрегез!

Маhирә. Утыртыр, бар!

Фәрдия. Теге юлы Казаннан кайтканда да туктамыйча узып киткән булды. Әти дим! Онытма инде безнен заказларны! *(Кызны чакыралар.)* Әни, мин иптәш кызларга гына кереп чыгам, яме!

Маhирә. Бар, бар, тиз бул! Көне буена юкка чыкма, әтиеңне озатасың бар!..

Хафиз. Тукта! Фәрдия, бу хатны укып бир әле!

Фәрдия. Укыдым бит инде!

Хафиз. Тагын укы!

Фәрдия. Әти!

Хафиз. «Укы!»—диләр сиңа!

Фәрдия. Әти! *(Хатны ала, укый.)* «Исәнмесез, туганнарым! Бу хатны мин кемгә багышларга да белмим. Кем дә булса исән-сау калды микән безнекеләрдән? Минем фамилиям—Закиров, исемем—Мифтахетдин. Сугышка киткәндә хатыным Фәгыйлә белән өч айлык улым Хафиз калган иде. Исәннәр микән алар? Фәгыйләнең үз фамилиясе—Вафина. Әгәр дә кем дә кем исән булса, зинһар, хәбәр итегез. Хатыным Фәгыйлә белән улым Хафизны—әгәр исән калсалар—үземә кунакка чакырам. Чакырам гына түгел, үтенеп чакырам: соңгы вакытта сәламәтлегем нык какшап китте. Гомерем дә күп калмагандыр, шуна күрә соңгы көннәремдә сезнең берәрегезне күреп, хәлегезне белеп үлсәм, тынычлап китәр идем бу фани дөньядан. Борчылмагыз: юл чыгымнарыгызның барысын да үзем түлим. Ходайдан сезнең белән күрештерүне сорап: Мифтахетдин Салих улы...»

Хафиз. Укып бетер!

Фәрдия. Әллә ничә тапкыр укыдым бит инде...

Хафиз. Тагын укы!

Фәрдия. Йә, Алла! Адресы шул бит инде: Швеция, Стокгольм! Урамы. Йорты... Бетте! Киттем, очтым гына!

Хафиз. Швеция! Каян барып эләккән соң ул анда? Аптырарсың да... 50 елга якын ни «здрастуй», ни «досвиданжә»... Зимагур дисәң, зимагур!

Маhирә. Менә минем туганнарны яманлый иден, үзеңнекен күр әнә—әтиең...

Хафиз. Булды, житте! Беркемгә дә тел тидерәсе булма.

Маhирә. Әнигә, Аллага шөкер, тел тидергәнем булмады, авыр туфрагы жинел булсын! Үзе дә мине какмады, кимсетмәде.

Хафиз. Бир әле тагын бер рюмка, янган йөрәкләрем басылмасмы, ичмасам?!

Маhирә. Эчмә инде, юлга чыгасың бар!..

Хафиз. Бәлкем, барып та йөрмәскәдер?

Маhирә. Ничек инде—бармыйсың? Ходай мондый мөмкинлекне гомергә бер генә бирә!..

Хафиз *(жырлый)*.

> Их, тала, тала, тала,
> Тала минем беләгем.
> Нигә тала, нигә яна
> Икән минем йөрәгем?

Әллә барырга инде?

**Зиннур керә.**

Зиннур. Әссәламәгаләйкүм, күршеләр! Йә, ни эшләргә булдың, Хафиз?

Хафиз. Вәгаләйкүмәссәлам! Белмим әле төгәл генә, Зиннур абый. Әллә инде... бармаска? Шулай да, минем урында син булсаң, нишләр иден?

Зиннур. Барыр идем, улым. Үз атаң бит, дөньяда кем белән ни булмас. Исән икән бит әле, әй...

Хафиз. Шулай дисеңме?

Зиннур. Шулай дим, Хафиз. Әгәр дә туган жиренә кайтасы килә икән, кайтсын! Дустың Зиннур сине көтә, беркайчан да онытмады, диген.

Маhирә. Кара әле, әгәр дә акчаң калса, Рамил кызына бирәр матур күлмәк алырсың! Үзебезгә дә тәмлерәк нәрсәләр алырга онытма!

Хафиз. Әйдә әле, Зиннур абый, тот әле минем белән!

Зиннур. Юк, энем, рәхмәт, мин аның белән дус түгел инде. Лимит бетте. *(Көлә.)* Тальян гармуныңны да аласыңмы, улым?

Хафиз. Алам, Зиннур абый, күрсәтеп исен китәрим әле үзенең!

Зиннур. Мифтахетдин төсе! Утыз тугызынчы елны Казанга барган жиреннән сатып алып кайткан иде. Молодец, энекәш, сакладыгыз!

Хафиз. Әнкәй саттырмады. Әтиең төсе диеп, кагылдырмады да!..

Зиннур. Яхшы гармунчы иде шул ул! Матур-матур бизәнү әйберләре дә ясый белә иде. Әниең дә яратты аны. Аннан өйләнештеләр...

Хафиз. Шуннан, шуннан?

Зиннур. Шуннан нәрсә, шуннан шул, печән өсте... Бер заман кырга авыл Советы рәисе Мөхәммәт абзый атын жанфәрманга чаптырып килеп житте.

Хафиз. Янгын-фәлән чыккан булганмы әллә?

Зиннур. Янгыннан да хәтәррәк хәбәр алып килгән ул. «Тиз булыгыз, авылга кайтыгыз, жыен була»,—ди.

Хафиз. Шуннан?

Зиннур. Шул инде. «Немецлар сугыш башлаган, ир-жегетләр әзер булсыннар!»—диде. Бер атна да үтмәгәндер, алып та киттеләр үзебезне.

Маһирә. Йә, Хода, инде безнең балаларны, оныкларыбызны саклый гына күр андый афәттән!

Зиннур. Әтиең белән бер жиргә эләктек. Анда безне стройда йөрергә, бер-ике тапкыр мылтыктан атарга өйрәттеләр. Шуннан—сугышка! Анда да бергә. Дүрт кешегә бер мылтык. Каршыда—баштанаяк коралланган немецлар. Без чолганышта калдык. Плен. Минем аяк яраланган иде. Әтиең шуны яхшылап бәйләде. Үзе миңа: «Бетүләребез шушы микән инде, яшьти?»—ди.

Хафиз. Ничек шулай тиз эләктегез соң сез?

Зиннур. Тиз түгел, улым. Башта безне самолетлар, танклар белән теткәләделәр. Бар янар әйбер яна, ут-төтен. Чын тәмуг инде менә! «Рус, сдавайся, рус, хенде хох!»—дип кычкыралар нимесләр...

Хафиз. Шуннан сезне кыйнап алып киттеләрме?

Зиннур. Безнең кай жиребезне кыйныйсың инде, улым? Без бит ул чакта, унсигез-егерме яшьлек малайлар. Шушы галәмәтләрне күреп, өнсез калганбыз. Сарык көтүе кебек. Өстәвенә, атналар буе юынмаган, бет баскан. Юньләп ашамаганлыктан, тәмам хәлсезләндек...

Хафиз. Каты яралыларны нишләттеләр?

Зиннур. Аларны, улым, ата бардылар. Мине әтиең карап, аякка бастырды. Стройдан каласың икән, шундук пуля аласың. Әтиең мине атна буе иңеннән төшермәде. Ял иткәндә яралы аяктагы чүпрәк-чапракны алыштыра, яхшылап бәйли иде. Шулай тәрбияләнә торгач, тернәкләндем, Аллага шөкер! Ахрысы, гомерем бетмәгән булгандыр инде... Бервакыт шулай, унай чакны туры китереп, качарга булдык. Нимесләр сизеп алып, безгә ата да башладылар. Кем кая чапканын белми. Менә шул мәхшәрдә әтиең белән аерылыштык та инде... Исән икән бит яшьти, исән!!!

Маһирә. Йөз тапкыр сөйләткәнең бар бит, борчып утырма олы кешене.

Зиннур. Борчымый ул мине, кызым, борчымый. «Сугыштан исән-сау әйләнеп кайтсам, улымны гармунда уйнарга өйрәтер идем!»—диеп хыялланган иде. Исән икән бит, исән!..

Хафиз. Малае иллегә житте. «Әпипә» көен дә уйный алмады.

Зиннур. Үзеләр шул, улым, сезне. Гореф-гадәттән үзеләр. Анысына сез генә гаепле түгел. Улың Рамил бераз шыгырдата бугай.

Хафиз. Әй, көймени инде ул уйнаган? Жыен килде-китте, өстәвенә урысча! «Ассалуди, былгаруди...»

Маһирә. Булды инде, оятсызланып утырма! Олы кеше бар...

Зиннур. Нишлисең инде, татарча сөйләшү харам саналгач... Чеп-чи татар авылларында вата-жимерә урысча укыттылар. Үзебезнең тәмле телебезне, үзәкләргә үтә торган мәңгелек көйләребезне юкка чыгарырга тырыштылар.

*(Жырлый. «Арча көе»).*

Арчаларга баруларым,
Тик синең өчен генә шул,
Тик синең өчен генә.
Януларым-көюләрем
Тик синең өчен генә!..

Хафиз. Рәхмәт, Зиннур абый, рәхмәт!

Маһирә. Хафиз дим! Хафиз!

Хафиз. Тагын нәрсә?

Маһирә. Рамил улыбызга джинсовый чалбар, хатынына французский духи... Э-э, үзенә бүрек тә алырга онытма!

Хафиз. Әй, туймас күз! Зиннур абый, сиңа нәрсә дә булса кирәкме?

Зиннур. Улым, дөресен генә әйткәндә, миңа бернәрсә дә кирәкми. Әгәр дә инде алай-болай мөмкин булса... Алып кайт әле әтиеңне!

Хафиз. Барыйм әле, карарбыз!

Маһирә. Ялтыравыклы күлмәк. Жон кофта. Кешедә булмаган яулык—күз явын алырлыгы кирәк!

Хафиз. Алланың кашка тәкәсе, ә?! Әллә әйбер чире йоктымы сиңа?!

Маһирә. Әллә минем кеше кебек киенеп йөрисем килмиме? Әллә мин кешедән кимме? Үтте инде гомерләрем әрәм. Әнә, күрше-күләнне балалары, кызлары, кияүләре киенләрә. Ходай миңа шунысын да жәлләде.

Хафиз. Нәрсә кирәк сиңа?! Әнә, идән асты тулы бәрәңге. Аша! Сыер, сарыкларың бар. Ачлыктан егылып ятканың булдымы? Ач күз!

Маһирә. Син, әнә, күршенә кара. Хан сарае кебек йорт салды. Әче тулы чит

ил мебеле. Ашаганнары бал да май.

Хафиз. Хәзер кеше таларга чыгыйммы инде?

Маһирә. Җүләр авызыннан—акыллы сүз! Кем куша сиңа кеше таларга? Аның кебек баю юлын таба белергә генә кирәк.

Хафиз. Кеше хисабына яшәргәме?

Зиннур. Балалар! Юк өчен шулкадәр тавышланмагыз. Һәркем үзенчә яши бит. Кем ничек булдыра...

Хафиз. Юк инде, юк, Зиннур абый! Ходай миннән барын да кызганган. Әни, мескен, мине кеше итәм диеп интектеинтекте дә, рәхәт күрмичә китеп барды. Аннары хатын дигәннен дә тавык милесен бирде...

Маһирә. Өйләнмә иден, алай бик акыллы булгач. Мин дә, бәлкем, җүнлерәк кешегә чыгып, адәмчә яшәгән булыр идем. Мин чыкмаган булсам сиңа, бөтен Сысысырны бетереп эзләсән дә, хатын таба алмый иден бит, имгәк!

Хафиз. Мин өйләнмәгән булсам, ирләр чырае күрмичә үлә иден!

Зиннур. Туктагыз әле, тукта, балалар! Берегезнең юлга чыгасы бар, икенчегезнең өй учагын саклыйсы... Юкка тавышланмагыз!

Маһирә. Менә газиз гомерем шулай әшәке сүзләр ишетеп үтте инде. Бер генә дә бәхетем булмады, Зиннур абый! (Елый.)

Зиннур. Тынычлан, килен, тынычлан!

Маһирә. Туйдым, Зиннур абый, кешегә карап яшәргә. Ичмасам кеше кебек яшәргә тырышса иде.

Хафиз. Туктыйсынмы, юкмы? Билләһи, Зиннур абый бар диеп тормам... Гомер буе тимәгәнне... чыгартасын.

Зиннур. Энем, тукта әле, кызма! Эти-әниләрегез белмәгәнне кыланмагыз. Сабыр булырга кирәк. Килен, син дә алай ирен белән ямьсез кыланма. Болай да...

Хафиз. Менә, Зиннур абый, Казанга документлар артыннан баргач, милиция кешесе нервыларны бетерде. Өйдә—бусы...

Зиннур. Ни ди соң?

Хафиз. «Бу хат берничә ел элек килгән булса, күрсәтә идем мин сиңа Швецияне!»—ди. «Сатлык җан малае!»—ди. «Кара аны, ди, анда баргач, бөек дәүләтебезне, не дай бух, мыскыл итеп кара...» «Кирәк булса, без сине Айдан да эзләп табарбыз!»—ди.

Зиннур. Хәзер дөньялар үзгәрде бит инде...

Хафиз. «Боздылар дөньяны ирек биреп»,—ди. «Ну, бер кайтыр әле ул заманалар!»—ди.

Зиннур. Әле дә шундый кешеләр бар икән. Ярар, энем, кайгырма! Хәзер дөньялар башка инде. Ярый, әтиегезгә күчтәнәчемне алып керим әле. Аннан син бит чит илгә барасын, галстук тагарга кирәк күлмәгенә. Килен, берәр галстук кара әле үзенә.

Хафиз. Кирәкми! Болай да таныйрлар әле, гомер буе такмаганны.

Зиннур. Ярый, мин хәзер, тиз генә.

Маһирә. Әйдә, Зиннур абый, озата чыгам. *(Китәләр. Хафиз әтисенең сурәте янына килеп тезләнә).*

Хафиз. Әти!.. Нишләп син 50 ел буена бер хәбәр бирмәден. Әнкәй синең исән икәнлегенне дә белми китте бит... Син мине гомер буена ятим иттен. Китегез, кит! *(Зиннур белән Маһирә керә).*

Зиннур. Кемне куасын?

Хафиз. Сине, әти, сине!

Маһирә. Хафиз, бу бит әтиен түгел—Зиннур абый!

Хафиз. Әле генә әтине күз алдына китергән идем. Сезнең кергәнне шәйләми калганмын.

Маһирә. Менә галстук, менә эшләпәң. Яле, тагыйк! *(Тагалар.)* Килешә. Нәчәльник кыяфәтләре кереп китте үзенә! *(Көлә.)*

Хафиз. Аны тагып кына акыл артса икән!

Зиннур. Менә кәрәзле бал. Зиннур дустың белән Сәрвәр апаннан, диярсен. Кайтсын! Туган авылын, туган җирен, дусларын-кордашларын сине көтәләр, диген. Исән чакта күрешеп калыйк!..

Хафиз. Чакырмаячакмын, Зиннур абый. Аны туган җире дә, туган авылы да кичермәячәк. Барып, әйтәсен әйтәм дә үзенә... Ярый, кузгалырга вакыт җитә бугай.

Маһирә. Бар әйберенне дә тыктым микән?

Хафиз. Сынган беләзек кисәген салдыңмы?

Маһирә. Салдым, салдым.

Хафиз. Тальянын?

Маһирә. Әй, Ходаем, гармун кала бит! *(Фәрдия очып кайтып керә.)*

Фәрдия. Уф, көчкә кайтып җиттем. Өлгердем. Әти, менә, кассеталар. Менә монысы—Илһам Шакировныкы. Монысы—Әлфия Авзалованыкы... Монысы... әбием җырлары! Әйтерсен бабайга! Монысын синең бәләкәч кызын Фәрдия яздырып калган диярсен, яме? *(Җырлый—Айдар Галимовның «Татарның бер газиз*

*баласыдыр» җырын башкара.)* Барысы да әсәрләнеп шул җырны тыңлыйлар. Аннары дәррәү кул чабалар.

Хафиз. Булдырдың, кызым!

Фәрдия. Әти дим, бая әйтергә дә оныткан, миңа «бикини» костюм алып кайт, яме.

Хафиз. Анысы нәрсә икән тагын?

Фәрдия. Ул инде теге ни... су коенганда кия торган кечкенә генә хатын-кызлар чалбары. Без, имтиханнарны биргәч, иптәш кызларым белән су коенырга төшәргә булдык.

Хафиз. Аңлашылды. Әнә, әниеннекен киеп төшәрсең!

Маһирә. Хафиз дим, алай сөйләшмә инде бала белән. Зур кыз бит инде ул хәзер.

Фәрдия. Дөрес, әни! Әти, без, мәктәпне тәмамлагач, театр училищесына укырга керәбез. Хәмдия белән. Шуңа күрә үзең аңлыйсың инде. Анда имтихан бирергә чәчәк кебек балкып-киенеп барырга кирәк.

Хафиз. Шул гына житмәгән иде! Йөр инде хәзер клубларда кеше көлдереп! Кемгә кирәк хәзер синең театрың?

Маһирә. Әтиең дөрес әйтә, кызым. Йөрмә кирәкмәгәнне уйлап. Хәзер хөкүмәткә театр да, артистлар да, эшчеләр дә кирәкми. Белмим, нәрсә генә кирәктер инде аларга.

Фәрдия. Әни, үзегез дә яшь чагыгызда спектакльләр куйгансыз бит.

Маһирә. Йөрсә, ул вакытта халык театрны үлеп ярата иде.

Хафиз. Ярар, булды. Әлегә театр-концертларны калдырып торыйк. Юлга чыгар алдыннан бер утырып алыйк. *(Утыралар, дога кылалар.)* Ярар, исән-сау торыгыз, хәер-догада булыгыз! (Кызын үбә, хатынын кочаклый.)

Фәрдия. Әти дим, кара аны, син дә, бабай кебек, берәр немкага өйләнеп кала күрмә!

Маһирә. Нинди немка булсын инде анда, швед маржасына, диген.

Фәрдия. Тот та өйлән, әти, шуңа, мин кунакка гына килеп йөрермен!

Маһирә. Котырт инде, бабаңның кайтмавы гына житмәгән! Бусы да шул каннан бит!..

Хафиз. Сезгә—кызык!

Маһирә. Бер дә атаңнан артык жирең юктыр әле.

Хафиз. Ярый, Аллага тапшырдык инде. Киттек! *(Музыка.)*

## Икенче күренеш.

**Стокгольмдә Мифтахетдиннәрнең заманча җиһазландырылган фатиры. Бүлмәдә Диләрә ялгызы. Ишек кыңгыравы чылтырый. Хафизның башы күренә.**

Хафиз. Керергә була микән?

Диләрә. Әйдәгез, әйдә! Рәхим итегез! Сезне кем дип белик?

Хафиз. Мин теге ни... Хафиз булам, Татарстаннан.

Диләрә. Хафиз?! Татарстаннан?!

Хафиз. Әйе. Мифтахетдинның улы, Казаннан!

Диләрә. Мифтахетдин улы, Казаннан!

Хафиз. Әйе!

Диләрә. Хафиз... Мифтахетдин улы!.. Йә, Алла! Зинһар, түргә узыгыз, рәхим итегез. Мифтахетдин! Мифтахетдин, дим!.. Һич көтмәгәндә... Аптырап калдым, гафу итегез.

Хафиз. Менә, килеп чыктым әле.

Диләрә. Бик шәп, бик яхшы булган! Рәхмәт, Хафиз балам, уз әйдә!

Хафиз. Мин озакка түгел, хәл белергә генә...

Диләрә. Ничек инде бик тизгә генә? Әтиегез бит гомере буе сезнең белән очрашуны көтеп яшәде.

Хафиз. Мин бит үтеп барышлый гына...

Диләрә. Ничек алай?! Безгә атап килмәдегезмени?!

Хафиз. Юк шул! Юл уңаеннан гына. *(Мифтахетдин күренә.)*

Мифтахетдин. Диләрәм, кем бар анда?

Диләрә. Беләсезме, Мифтахетдин, э-э, син бик борчылма. Бездә бер кунак бар.

Мифтахетдин. Кунак?!

Диләрә. Әйе. Еракта. Казаннан!

Мифтахетдин. Казаннан! Кем ул? Йә, Ходаем... Күнелем сизә, бу—бит... Бу бит... *(Озак карашып торалар.)*

Диләрә. Мифтахетдин, жан кисәгем, зинһар, артык борчыла күрмә. Әйе, бу—синең улың, Хафиз! Татарстаннан!

Мифтахетдин. Хафиз! Улым, Хафиз! *(Сыгылып төшә.)* Бу синме, улым?!

Хафиз. Әйе! Мин—Хафиз, авылдан...

Мифтахетдин. Йә, Хода, безгә шушы көннәрне дә күрергә насыйп иттең. Мең рәхмәт Сиңа! Улым... Хафиз!!

Диләрә. Тынычлан, зинһар.

Мифтахетдин. Ничек алай, улым? Хәбәрсез-нисез, дигәндәй. Алдан телеграмма суксаң, каршы ала идек.

Хафиз. Мин бит үтеп барышлый гына. Туристлар группасы белән килдек тә, менә... Колхозда яхшы эшләгән өчен путевка бирделәр дә... Шуннан, килгәч-килгән, тукта әле, сезне дә күреп китим, дидем.

Мифтахетдин. Ничек инде алай?! Син атап безгә килмәдеңмени? Ничек инде...

Хафиз. Әйе шул. Швецияне күрсәтергә алып килделәр. Матур икән.

Мифтахетдин. Соң мин бит, улым, сиңа бу илне үзем күрсәткән булыр идем. Диләрәм, бар, чәй өстәле әзерли тор әле...

Диләрә. Яхшы! *(Китә.)*

Мифтахетдин. Кайсы кунакханәгә урнаштыгыз соң, улым? Шалтыратып әйтергә кирәк!

Хафиз. Юк, юк, борчылмагыз, мин озакка түгел.

Мифтахетдин. Улым! Ничек инде озакка түгел! Күпме гомер көттем бит мин бу очрашуны! Хафиз! Койган да куйган Фәгыйлә икәнсең!

Хафиз. Бардыр инде.

Мифтахетдин. Улым, нишләп атап үземә килмәдең соң, нишләп? Мин бит синең бөтен юл чыгымнарыңны үзем түлим, дигән идем. Соң, ничек анда, авыл ничек, әниең?

Хафиз. Әйбәт. Барысы да үз урынында.

Мифтахетдин. Менә, улым, без шушында Диләрә апаң белән яшәп ятабыз инде. Үз өендәге кебек бул! Иртәгә, Алла боерса, шәһәргә чыгарбыз. Ә бүген, улым, рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк әле!

Хафиз. Балаларыгыз бармы соң?

Мифтахетдин. Бар! Улым Хафиз читтә яши.

Хафиз. Хафиз?!

Мифтахетдин. Әйе! Ул да Хафиз атлы.

Хафиз. Нишләп алай?!

Мифтахетдин. Бала туганчы ук Диләрәгә әйтеп куйдым—малай булса «Хафиз» диеп, кыз булса «Фәгыйлә» диеп атарга.

Хафиз. Ул хәзер кайда!

Мифтахетдин. Улым Финляндиядә. Кечкенә балалары бар.

Хафиз. Нишләп читтә яшиләр?

Мифтахетдин. Финляндиядә татар кызына өйләнде дә, шунда калды. Үзләренең кибетләре, әйбәт яшиләр.

Хафиз. Алайса, начар яшәмиләр?

Мифтахетдин. Аллага шөкер, татарлар тырыш халык бит... Шуның аркасындадыр инде, барыбыз да матур яшибез. Чит илдәге туганнарыбыз белән дә йөрешәбез.

Хафиз. Әйбәт, алайса!

Мифтахетдин. Аллага шөкер! Безнең турыда сонрак... Ничек анда, авылда?

Хафиз. Нәрсәсен сөйлисең инде аның. Хатын да, балалар, күрше Зиннур абый да бик күп сәлам әйтеп калдылар. Күчтәнәчләре дә бар.

Мифтахетдин. Зиннур исәнмени?! Аллага шөкер! Әниең?! Ул сәлам әйтмәдеме?!

Хафиз. Юк, әйтмәде... Ул бит хәзер... безнең белән яшәми.

Мифтахетдин. Тормыштадыр инде?

Хафиз. Әйе, Сугыш бетүгә бер командирга кияүгә чыкты да... Тормышлары әйбәт инде.

Мифтахетдин. Балалары бармы соң?

Хафиз. Бар! Бер малайлары, ике кызлары үсеп житеп, үз тормышларын үзләре күрәләр. Әнкәйнең ул яктан бәхете булды...

Мифтахетдин. Миннән хат килгәнне белдеме соң?

Хафиз. Юк... Борчыйсы килмәде инде, юк өчен...

Мифтахетдин. Анысы шулай инде. Фәгыйлә?! Тормышта да булгач... Ничек күрәсем килгән иде минем аны... Бер нишләп тә булмый... Үзең ничек инде, улым? Ни белән шөгыльләнәсең?

Хафиз. Әйбәт! Ике катлы йортым бар. Коттедж дип атала. Сигез сыерым, өч атым бар. Кечкенә генә сыр заводым. Әйбәт болай.

Мифтахетдин. Начар түгел икән. Югыйсә, безнең газета-журналлар әллә нәрсәләр язалар. Имеш, акча ала алмыйлар, күпчелек хәерчелектә, диләр... Хәзерге заманда нинди хәерчелек булсын? Әнә, бездә, булган әйберне кая куярга белмиләр.

Хафиз. Бездә дә шулай. Базарда бар да әйбер сата. Бөтен ил базарга әйләнде.

Мифтахетдин. Авыл ничек? Үскәндер хәзер?

Хафиз. Үсте. Бик нык үзгәрде. Ике мәчет салдык. Олысы, кечесе шунда йөри.

Мифтахетдин. Кит әле! Без кечкенә чакта мәчет манарасын кисеп төшергәннәре әле дә хәтеремдә. Яңа мәчетне кай төшкә салдылар соң?

Хафиз. Элеккеге урыныннан өстәрәк.

Мифтахетдин. Әйбәт урын. Дөрес эшләгәннәр. Аннан бөтен жиргә күренеп торадыр.

Хафиз. Әйе. Үзең читтә ничек шушындый тормыш төзи алдың соң?

Мифтахетдин. Ничек дип әйтим: барысын да үз көчем белән табарга туры килде. Аннан татарлар бер-берсенә нык булыша. Шул...

Хафиз. Ник кайтмадың син? Әни сине гомере буе көтте. Мин дә... Минем дә башка малайлар кебек: «Әтием кайтты! Күкрәге тулы орден-медальләр белән кайтты!»—диеп, бөтен авылга кычкырасым килә иде. Әтиемнең муенына асылынып, аның кочагына чумасым, аның белән горурланасым килә иде. Син көтеп тә кайтмагач, башка малайларның шатлыгыннан көнләшеп, гарьләнеп елый идем. Әнкәй, мескен, мине юатып: «Кайтыр, улым, кайтыр әтиең, елама... Ул—исән булырга тиеш. Ул—сатлык жан түгел, күңелем шулай сизә!»—дия торган иде. Менә сиздерми генә жаны белән сыкрый иде. Менә күз яшьләрен күрсәтмәде.

Мифтахетдин. Аңлыйм, улым!

Хафиз. Үз ишләре арасында ятим, сансыз булып йөргән баланы күз алдына китерә аласыңмы соң син! Бу әле бала чакта. Беренче сентябрьне түземсезлек белән көтеп алып, иртүк, алдан килеп беренче партага кереп утырдым. Ләкин мине: «Синә, әнә, артта да ярар, синең ишеләрне совет мәктәбенә бөтенләй кертмәскә кирәк иде дә бит»,—диеп, артка, мич янына кудылар. Аннан соң октябрят, пионер, комсомол... Хәзер ул сүзләрне бөтенләй белмәсәләр дә, безнең өчен галстук, значок тагып йөрү зур горурлык иде. «Сиңа бу хәрам»,—дип, галстукны тартып алдылар. Комсомолга кертмәделәр. Шулай да мәктәпне әйбәт бетердем. Зур хыяллар белән Казанга педагогия институтына юл тоттым. Имтиханнарны яхшы билгеләренә генә бирсәм дә, язмыш аны үзенчә хәл итте. Минем сатлык жан малае икәнлегем билгеле булган. Кызыл иренле, нечкә сыйраклы, тәссез-төссез бер маржа: «Как вы смеете, сатлык жан малаен институтка алырга, бу татарларга ирек бирсән, бөтен Рәсәйне сатачаклар», дип, акырды. Менә шул көннәрдән башлап мин көтүче инде. «Мифтахетдин—сатлык жан»,—дигән кара хәбәр, безнең өстә кара болыт булып, соңгы елларга кадәр сакланып килде.

Мифтахетдин. Авыр миңа, улым!

Хафиз. Авыр бугач, нишләп бер генә мәртәбә булса да хәбәр бирмәдең. Безгә ярдәм итмәсәң итмә, тик әнкәйгә синең исәнлегең кирәк иде.

Мифтахетдин. Аңлыйм, улым!

Хафиз. Юк, аңламыйсың, аңлаган булсаң, кайтыр идең.

Мифтахетдин. Ярамый иде.

Хафиз. Димәк, син, чыннан да, сатлык жан?

Мифтахетдин. Белмим, улым. Сатлыкмы мин, түгелме, үзең уйла. Чолганышта калдык. Плен. Минем белән Зиннур абыең да эләкте. Берничә иптәш белән үзебезнекеләр ягына качтык. Шунда Зиннур абыең белән бер-беребезне югалттык. Үзебезнекеләр озак тикшереп тормады, алып та киттеләр. Юлда бергә хезмәт иткән малай эләгеп, менә, кешегә сиздерми генә: «Без сезне атарга алып барабыз»,—ди. Мин ышанмыйм. «Не вру»,—ди. «Урман янына житкәч, кач! Мин читкә атармын»,—ди. Шулай итеп мин бер иптәш белән качтым. Калганнарның язмышын белмим. *(Читтә тыңлап торган Диләрә керә.)*

Диләрә. Юк, Хафиз, синең әтиең сатлык жан була алмый. Ул бит сезне, туган илен, туган жирен сакларга киткән жегет. Ләкин сугыш афәте адәм балаларын төрле язмышларга дучар итә... Әтиегезне урман эчендә, яртылаш үле килеш табып алдым. «Әни», «Фәгыйлә», «Хафиз»,—диеп саташкан сүзләреннән, аның татар егете икәнлеген аңлап алдым. Мин аны өебезгә алып кайтып, бер ай буена тәрбия кылдым. Ниһаять, ул аякка басты. Финляндиядә калу куркыныч булганга, без аны Швециягә озаттык. Анда үзебезнең татарлар аша эшкә урнаштырдык. Ул бик тырыш кеше булып чыкты. Сезне, туган илен нык сагынса да, түзде. Ана, уйлап-нитеп тормый «сатлык жан» исеме тагылу сәбәпле, туган жиренә кайту, үлем белән бер тигез. Юк, синең әтиең сатлык була алмый.

Хафиз. Нинди дә булса хәбәр биреп була иде бит. Шул гомер!

Мифтахетдин. Беренчедән, сезне куркыныч астына куясым килмәде. Икенчедән—үземне... КГБның кулы озын иде ул чакларда.

Хафиз. Ни өчен үзебезнекеләр атарга теләделәр?

Мифтехетдин. Сталин әмере белән, кем пленга эләгә—шул сатлык җан, дигән тамга салынган иде ул чакта. Башкаларга сабак булсын, янәсе.

Хафиз. Нигә хәзер яздың?

Мифтахетдин. Әйе, яздым. Туган яклардан җылы җилләр исә башлагач, яздым. Аннары, яшисен яшәгән, ичмасам, исән булсалар, күреп үлим, дидем. (Елый.) Улым, минем Фәгыйләгә әллә кайчан әзерләгән бүләгем бар. Кайткач шуны тапшыра алмассыңмы миннән? Килешер микән?

Хафиз. Нинди бүләк?

Мифтахетдин. Менә, үз куллларым белән ясадым. Беләзек! Сугышка хәтле берне ясаган идем, ялгыш сындырдым. Яңасын ясарга сугыш комачаулады. Алып кайтып бир, улым! Соңгы истәлегем булыр!

Хафиз. *(Укый.)* «Кадерлем Фәгыйләгә—Мифтахетдиннән»... Юк!! Булмый.

Мифтахетдин. Нишләп, улым!

Хафиз. Чөнки ул... вафат!

Мифтахетдин. Вафат?!

Хафиз. Әйе! Мин алдадым сезне. Әнкәй тормышка чыкмады. Сине, күңеле сизгәндер инде, исән тоя иде. «Кайтыр-кайтыр!»—дия иде. Иң авыр чакларда да, ачлы-туклы яшәсәк тә тальян гармуныңны да, беләзек кисәген дә саклады. Менә алар. Менә монысы аның җырлары, оныгың Фәрдия яздырып калган.

Сынды беләзеккәем, өзелде үзәккәем,
Сине көттем гомерем буе,
кайтмадың, бәгырькәем.

Күнелкәйләрем сизәдерләй,
тик ничек түзәләдер,
Бер ялгызым аны сагынып,
көннәрем үтәләрдер.

Аланнарга барган саен, тукталам агач саен,
Үсеп житте дә саргайды без утырткан ак каен.

**Карт сынган беләзекне ала. Йөрәгеп тота. Сәхнә караңгылы-яктылы булып ала—күзаллау башлана.**

Мифтахетдин. Фәгыйлә!

Фәгыйлә. Мифтахетдин!

Мифтахетдин. Фәгыйлә! Бу вакытта нишләп йөрисең, курыкмыйча!

Фәгыйлә. Син булганда кемнән куркыйм инде мин. Ә син үзең нишләп йөрисең?..

Мифтахетдин. Кич җиттеме, минем йокым кача. Аңламыйм, нишләп шулай икән ул? Менә шуңа күрә йолдызлар санарга чыгам.

Фәгыйлә. Шул гынамы?

Мифтахетдин. Син нәрсә көткән идең?

Фәгыйлә. Ярый, алайса, син саный тор! Мин кызлар янына кич утырырга барыйм әле.

Мифтахетдин. Фәгыйлә дим!

Фәгыйлә. Тагын нәрсә?

Мифтахетдин. Әйдә икәү генә кич утырыйк инде.

Фәгыйлә. Алай бик ялварып сорагач, утырыйк, әйдә.

Мифтахетдин. Беләсеңме Фәгыйлә... э-э-э... ни бит инде.

Фәгыйлә. Нәрсә «ни бит?»

Мифтахетдин. Теге шул, ни инде.

Фәгыйлә. Шуның хәтле пешмәгәнсең диеп уйламый идем. «Теге бит инде»... «Ни бит инде»...

Мифтахетдин. Минме пешмәгән? Оялам гына мин. Хәзер әйтәм... Э-э-э...

Фәгыйлә. Әйтсәң, әйт инде, йокым килә башлады.

Мифтахетдин. Мин бит синсез бер генә көн дә яши алмыйм.

Фәгыйлә. Мин дә, Мифтахетдин...

Мифтахетдин. Фәгыйлә! Йом әле күзләреңне?

Фәгыйлә. Йомдым!

Мифтахетдин. Кулыңны суз!

Фәгыйлә. Менә...

Мифтахетдин. Мәхәббәтебез истәлеге булсын. Аны сиңа атап ясадым.

Фәгыйлә. Нинди матур беләзек! Рәхмәт сиңа.

Мифтахетдин. Әллә бераз кысанрак булган инде.

Фәгыйлә. Юк, юк, кысыбрак торсын. Синең йөрәк җылыңны күбрәк тоярмын.

Мифтахетдин. Юк, алай кысып торгач булмый инде. Яле, зурайтыйк әле бераз. *(Ялгыш сындыра.)*

Фәгыйлә. Ай, хараплар иттең, Мифтахетдин!

Мифтахетдин. Кайгырма, Фәгыйлә! Мин сиңа тагын да матуррак итеп ясармын.

Фәгыйлә. Кирәкми иде каерырга! *(Югала.)*

Мифтахетдин. Мин сиңа яңасын ясадым Фәгыйлә! Фәгыйлә! *(Сыгылып төшә.)*

Диләрә. Мифтахетдин! Мә, эч әле! Эч! *(Җырлый)*

«Аланнарга барган саен, тукталам агач саен.
Үсеп житте дә саргайды без утырткан ак каен...»

## Икенче пәрдә

**Авылда Хафизлар йорты. Фәрдия белән Маһирә күренә.**

Фәрдия. Әни дим! Әни! Әти кайта бит, өйләнмәгән, кире кайта... Синеке була. Бернинди швед маржасына да өйләнмәгән!

Маһирә. Әй, кызым, уйнама әле нервыда!..

Фәрдия. Әни дим, әни, бәлешләрең көя түгелме соң! Сүндеримме газыңны?

Маһирә. Сүндер, кызым, сүндер! Әй Аллам, кулымнан эш китте. *(Фәрдия чыга.)*

Фәрдия. Әни дим, әни... Әнә бер машина килә безгә таба!

Маһирә. Кайтып та җиттеләр. Минем өстәлләрем дә әзер түгел. Йә, Алла!

Фәрдия. Җитәләр, килеп җитә теге машина... Юк, алар булмады... Узып киттеләр.

Маһирә. Ярар, очраган бер машина белән тынычлыгымны бозма әле!

Фәрдия. Бозмыйм, әни, бозмыйм! Аңламыйм, әни, шушындый көнне ничек боегып утыра аласың син! Бабай кайта бит безгә кунакка! Нинди искитмәле хәл! Гомер буе бер күренмәгән бабай! *(Җырлый.)*

Бабай, кайт инде тизрәк безгә—
Өзелеп көтә оныгың өйдә!
Кочаклап алып: «Бабам!»—диярмен,
«Сагындым!!!»—диеп, башым иярмен.

Маһирә. Йә, кешеләр кайтыр алдыннан улап утырма әле.

Фәрдия. Их, әнкәй, сәхнәгә чыгып җырлыйсы иде. Барысы да сиңа кул чаба. Чәчәкләр!.. Шулар арасында танышбелешләр, классташлар.

Маһирә. Сөйләмә әле кирәкмәгәнне!..

Фәрдия. Нишләп кирәкмәсен? Иптәш кызлар, малайлар: «Әнә бит ул үзе, бер класста укыган идек!»—диеп мактанышачаклар. Автограф сораячаклар.

Маһирә. Бик исләре китәр инде.

Фәрдия. Соң, тыңлап бетер инде. Хисләремнән аерасың.

Маһирә. Ташла ул, хыялларыңны! Хәерче булып яшисең киләме гомер буе?

Фәрдия. Зато даны ни тора! Мәсәлән, мин теге «Диләфрүзгә дүрт кияү»дәге Диләфрүз кебек! *(Җырлый.)*

«Син алсу таңлар булсаң,
Мин бөдрә таллар булсам,
Таллар таңны аңлаган күк,
Серемне аңлар булсаң...»

Маһирә. Кызым, Диләфрүз роленә бөтенләй бармыйсың инде. Кая инде бу гәүдән белән? Сиңа бит теге «Чөгендер Наһар»лары гына бара!..

Фәрдия. Бар Диләфрүзләр, Галиябанулар да нәфис булмый бит инде, минем кебек таза-тулы гәүдәлеләре дә була.

Маһирә. Кит, кит! Бар, әнә, гөлләргә су сип.

Фәрдия. Әни дим! Тукта инде. Әйдә, алайса, син имтихан алучы бул, мин укырга керүче.

Маһирә. Миңа нишләргә соң?

Фәрдия. Әйтәсең: «Фәрдия Хафиз кызы, рәхим итеп җырлап күрсәтегез әле!»—диеп.

Маһирә. Яле, Хафиз кызы, рәхим итеп җырлап күрсәт әле!

Фәрдия. Җырлый Хафиз кызы Фәрдия! Үземнең җыр, үземнең сүз. *(Җырлый.)* Йә, ничек?

Маһирә. Ярый инде. Миңа барыбер җиткерә алмыйсың. Менә, өйрән!

Кыр казлары артыннан,
Биеклеккә тартылам.
Хыялыма китәр идем
Кыр казлары артыннан.

Йә, ничек?

Фәрдия. Синең җырдан тавыкларга шок булып, ничек күкәй саласыларын да оныттылар!..

Маһирә. Алар минем матур тавышыма сокланып кына тыңдылар бит, кызым. Йә, ярый! Тагын нәрсә эшли аласың?

Фәрдия. Ашыйм да, кереп йоклый алам. Сиңа тагын имтихан алырга?! Башка бер ни дә эшләмим.

Маһирә. Йә, инде, кызым! Шаярттым гына бит инде. Йә, тагын берәр һөнәреңне күрсәт әле!

Фәрдия. Ярый, алайса, биеп күрсәтәм. *(Икәүләшеп бииләр.)* Йә, ничек, әни?

Маһирә. Әйбәт!

Фәрдия. Ничәле куясың?

Маһирә. Бию—«бишле»! Җырыңа—«дүрт». Минем белән начар сөйләштең, телеңә—«икеле». Шулай итеп конкурстан үтмәдең, кермәдең артистлыкка!..

Фәрдия. Барыбер керәм!

Маһирә. Тукта әле, тукта, бу ни бу, ә?! Бирнәгә диеп алып куйган материалымны хараплар гына иткәнсең бит. Йә, Ходаем!

Фәрдия. Әни дим, әни! Газ

плитәсендә нәрсәдер яна!

Маһирә. Яндырырмын мин сиңа, ирдәүкә, маржа! Кара син аны, ә, карап кына торткан күлмәклекне кисеп, нәрсә тегеп куйган.

Фәрдия. Әни дим, эшли башлагач, тагын да матуррагын алып бирермен. Зинһар, тавыш чыгарма, бөтен авыл жыелмасын!

Маһирә. Җыелсалар соң, бик исем китте инде. Булды, житте, бар, әнә, мунча иданнәрен юып чыгар. Әйтмәгән саен...

Фәрдия. Киттем, әни! Синең белән боегып утырганчы... *(Зиннур керә.)* Әйдә уз, Зиннур бабай. Сәрвәр әбинең хәле ничек?

Зиннур. Аллага шөкер, бер килеш!

Фәрдия. Ярый алайса, мин очтым! Эшләр күп. Әнә, Зиннур бабайдан үрнәк ал, ичмасам. Егетләр кебек! Их, бабай! *(Үбә дә китә.)*

Зиннур. Үтте дә китте инде ул. Их, яшь чаклар, яшь чаклар... Көтәсеңме, килен?

Маһирә. Кайта, ниһаять! Ярты ай Швециядә гулять итте дә... Ни хаты, ни хәбәре булмады. Инде атасын да ияртеп кайта.

Зиннур. Кайтсыннар гына, кызым! Кайтсыннар! Исән генә була күрсеннәр, диген...

Маһирә. Моннан алып киткән акчаны эчеп кенә бетермәгән булсалар ярый инде. Гомер буе сукыр бер тиен бирмәгән атасын ияртеп кайта. Әй, ыштансыз да инде бу безнең Хафиз!

Зиннур. Әллә ничек тәмсез итеп сөйлисең, килен. Бер дә килешми. Илле яшеңне тутырасың бит.

Маһирә. Их, Зиннур абый! Ничә еллар буе сыер-бозаулар сатып җыйган акчалар янды.

Зиннур. Безнекеләр дә янды. Акчадамыни бәхет?! Мунча яктыңмы соң?

Маһирә. Үзе ягар әле, кайткач. Чәнчелеп китсен, әнә, этисе белән. Җүнле карт булса, шушы көнгә хәтле хәбәрсез яшәр идеме ул?

Зиннур. Дөньяда төрле хәл була, Маһирә. Әшәкеләнмә. Һич уйламаганда яшьлек дустым Мифтахетдин белән күрештерә мине Ходай! Бу бит үзе бер бәхет. Карчыкка аш-су әзерләргә куштым. Килен, сездән соң безгә керерләр, яме?!

Маһирә. Керерләр, керерләр. Зиннур абый! Мондагы аракы бетсә, сезгә дә керерләр. Сездәге бетсә, кая барырлар икән?

Зиннур. Табылыр, аңа калса. Булды, житте. Әнә табыныңны әзерлә. Кеше көлкесенә калдырма. Хафизны да, безне дә. Әгәр инде сиңа сыймыйлар икән, тотам да үзебезгә алып чыгам. Ояты үзенә булыр!

Маһирә. Чык кына, жаным, бар!

Зиннур. Чыгармын да! *(Китә.)*

Маһирә. Сиңа сөйләргә җиңел. Син бит Швецияләрдә качып, гаиләсенә бер тиенлек ярдәм күрсәтмичә яшәмәгән. *(Урамда машина тавышы.)* Монысы шулар бугай! Әйе, әйе, машина безнең турыга туктады. Кайттылар. Бер Ходаем, әшәке телемнән саклый күр! *(Хафиз керә.)*

Хафиз. Нишләп каршы чыкмыйсың, Маһирә?!

Маһирә. Соң, кайткан кеше үзе керә инде ул!

Хафиз. Син нәрсә, әллә сагынмадыңдамы?

Маһирә. Кит әле, кит! Кеше күрмәсен! Монда хәтле кайткач, кире китмәссез әле.

Хафиз. Мә, алып куй әле әйберләрне! *(Видео һ. б. әйберләр суза.)*

Маһирә. Нәрсә соң ул?

Хафиз. Әти белән Диләрә апа бүләкләре. Менә монысы видеомагнитофон. Вата күрмә!

Маһирә. Харап икән, бу жүләргә бер радио кисәге биргәннәр дә, шул житкән.

Хафиз. Син ни сөйлисең. Хәзер эткәй керә бит, бар, каршы ал үзен!

Маһирә. Әллә сихерләп кайтарганнар инде моны.

Хафиз. Әй, чүпрәк баш! Акылсыз баш! Үзеңне ияртеп барасы калган.

Маһирә. Шул гына житмәгән. Йорт-жирне ташлап! Сыер-сарыгыңны кем караган булыр иде. Ичмасам, Рамилдән оялыр идең. Нәрсә алып бирдең син аңа? Ни белән булыштың? Тулай торакта ята, ике баласы белән...

Хафиз. Әйттем бит мин аңа, кайт та яшә шушында, диеп. Бар, этине каршы ал! Тиз бул! *(Мифтахетдин керә.)*

Мифтахетдин. Исәнме, Фәгыйләм, туган жирем, авылым!!! Исәнме, туган туфрагым, нигезем!! Исәнме, кушкаеным! Син ничек зур булып үскәнсең! Исәнме, кызым?!

Маһирә. Исәнме, эти, әйдә узыгыз.

Мифтахетдин. Рәхмәт, балам! Димәк, әле безнең йорт исән!

Хафиз. Исән, эти, исән! Веранда белән чолан ясап куйдым да, житте. Йортны синең төсең итеп сакладык.

Маһирә. Яңасын салырга кулымнан килмәде диген, дөресен сөйлә!

Хафиз. Миңа житә. Әнә, малаеңа кирәк икән, эшләсен. Ятмасын Казанда җүләр сатып!..

Маһирә. Үз балаң бит!

Мифтахетдин. Әле минем оныгым кайтмадымыни?

Маһирә. Кайта, кайта. Бер иптәше артыннан әйтеп җибәрдем. Кайтыр, Алла боерса!

Мифтахетдин. Ярар! Исән-сау кайтсын. Юынып алыйм әле, улым!

Маһирә. Әйдә, әти, әйдә, Менә, җылы су тутырып куйдым комганга. Мә, Хафиз! *(Комганны иренә бирә, Хафиз әтисенә су салып тора.)*

Мифтахетдин. Булды, балалар, рәхмәт. Әйдәгез әле, бер дога кылыйк! *(Барысы да дога кылалар.)*

Маһирә. Әти, менә бирегә—түргә утыр!

Мифтахетдин. Рәхмәт, кызым! Минем сезнең белән сөйләшәсем бар. Аллага шөкер, исән-имин кайтып життек. Менә мин илле елга якын үз илемне, гаиләмне күрми яшәдем.

Маһирә. Безгә дә бик авыр булды, әти. Улыгыз бик тырыш. Ат урынына эшләде ул. Тик бер нәрсә дә ала алмады.

Хафиз. Ни сөйлисең син, Маһирә? Иң яхшысы—әнә, табыныңны кара!

Мифтахетдин. Сөйләсен, улым, сөйләсен. Мин бит үпкәләмим. Нәрсә генә сөйләсәгез дә, мин—бәхетле! Мин—сезнең белән!. Хәтта ышанып та бетә алмыйм.

Маһирә. Гомере буе машина алырга хыялланды...

Хафиз. Маһирә!

Маһирә. Гомере буе көтүен көтте. Иң авыр, иң зур файда китерә торган эшләрдә эшләде. Ник үзенә уңай ягы булсын.

Хафиз. Маһирә дим!

Маһирә. Нәрсә «Маһирә!» Әнә, бер нәрсә эшләми, кеше талап яткан адәмнәр әллә ничә машина, әллә ничә йорт салды. Син улың Рамилгә дача салырга да булыша алмадың. Тегесе әтисенә үпкәләп ята.

Хафиз. Ничек булышмыйм, ди. Әнә келәт бурасын биргән идем. «Нәрсәгә миңа иске бура?»—дип алмады. Яңа кирәк аңа...

Мифтахетдин. Рәхмәт, улым! Бай яшәмәсәң дә намуслы булып калгансың, кешелегеңне югалтмагансың!

Хафиз. Шулай була күрсен, әти!

Маһирә. Әй, әти! Намустан тун тектереп булмый шул хәзер. Гомер буе намуслы булып яшәдек. Тун юк!

Мифтахетдин. Картың алды, кызым, үзеңә тун, алды. Бар әле, улым, алып чык әле Диләрә апаң җибәргән әйберләрне! *(Бүләкләрне чыгаралар.)* Менә сиңа, кызым, бездән күчтәнәч!

Маһирә. Нинди матур күлмәк! Нинди матур яулык. Чын шуба! *(Кия.)* Йә, Аллам! Минем бит мондый затлы тунны төшемдә дә күргәнем юк иде. Кая гына барырмын икән соң мин аны киеп! *(Елый.)*

Хафиз. Йә инде, Маһирә! Казанга килеңең янына киеп барырсың.

Мифтахетдин. Юкка кайгырма! Елама, килен! Теләгән җиреңә киярсең. Улым! Син гомерең буе машина алырга хыяллангансың. Менә, улым, бу сиңа чек. Теләсәң, машинаң да була, өй дә сала аласың. Житә!

Хафиз. Әти! Син нәрсә! Мин сезнең акчагызга калганмы?

Мифтахетдин. Улым! *(Кочаклый.)* Җан кисәгем! Әгәр дә хәлемнән килсә, мин сезне алтынга күмәр идем. Мин сезнең алда түләп бетерә алмаслык бурычлы!..

Хафиз. Ялгышасың, әти! Минем бәхет—сине исән-сау күрү. Шуңа күрә акча биреп рәнҗетмә мине. Рәнҗетмә.

Мифтахетдин. Бернинди «рәнҗү-рәнҗетү» дигән сүзләр булырга тиеш түгел. Миңа Ходай акчага сатып алып булмаслык яхшылык эшләде.

Маһирә. Рәхмәт, әткәй! (Чекны ала.) Нишләп Диләрә апаларны да алып кайтмадыгыз соң?

Мифтахетдин. Диләрә апаңа озын юллар килешми шул. Кан басымы. Быел тагын да начарланып китте.

Маһирә. Алайса, терелгәч кайтсын. Хафиз,бар әле, холодильниктан шешәләрне алып кил, утырма әле авызыңны ачып. Әтине сыйла! Әйдә әле, әти, утыр, аша! Менә катык, өчпочмак, гөбәдия!..

Мифтахетдин. Шешәләре кирәкми. Андый әйберләр белән дус түгел. Менә катык, өчпочмак, гөбәдия ярап куяр.

Хафиз. Әти, бәлкем әз генә...

Мифтахетдин. Син миңа карама. *(Кызы керә.)*

Фәрдия. Кая, бабай?! Күрсәтегез әле миңа бабакаемны!..

Мифтахетдин. Фә-гый-лә-ә-ә!..

Фәрдия. Юк, бабам. Мин Фәгыйлә түгел, мин Фәрдия!

Мифтахетдин. Фәрдия, кызым... Син—койган да куйган Фәгыйләм инде!..

Фәрдия. Бабай, исән-сау кайтуың белән сине! Әтием, бәгърем, син дә исән-сау кайттыңмы? ! *(Үбә, кочаклый.)* Бабай, нишләп шулкадәр озак кайтмыйча тордың. Синең монда минем кебек матур оныгың

барын белмәденмени? Бабам!

Мифтахетдин. Юк шул, белмәдем, кызым! Син бит коеп куйган әбиең икәнсең, ләбаса. Тукта әле, менә минем сиңа бүләгем бар. Мин аны әбиеңә диеп ясаган идем... *(Беләзекне бирә.)*

Фәрдия. Беләзек... Нинди матур!! Рәхмәт, бабаем! Әбием йокларга яткан саен синең турыда сөйли торган иде. Ул шундый чибәр, озын буйлы, кара бөдрә чәчле, кара мыеклы, чем кара күзле, дия иде. Син бөтенләй үзгәргәнсең, бабай! Чәчләрең агарган. Ап-ак икән...

Мифтахетдин. Шулай шул, кызым! Әбиең соңгы тапкыр мине күргәндә шулай идем.

Фәрдия. Әби сине шуның хәтле ярата иде. Синең бер әйбереңә дә кагылдырмады. Барысын да сандыгыннан чыгарып сыйпап утырыр иде дә, янадан таслап алып куяр иде. Үзенең күзләреннән яшьләр тамар иде. Әбием минем!

Мифтахетдин. Шулаймы, кызым!

Фәрдия. Әйе, бабай! Аңа ияреп мин дә жылый идем, менә хәзер дә күңелем тулды. Әбиемне сагындым! Ул бит мине мәктәпкә киткәндә берәр конфет биреп озата, кайтканда жимешләр салган чәйләр пешереп каршы ала иде. Сине сагынып жырлар жырлый иде.

«Сынды беләзеккәем, өзелде үзәккәем...
Сине көттем гомерем буе,
кайтмадың, бәгырькәем...»

Мифтахетдин. Бәләкәчем минем!

Фәрдия. Әбием, жанкисәгем! (Елап чыгып чаба.)

Мифтахетдин. Кызым! *(Зиннур керә.)*

Зиннур. Вакытсыз кергәнгә үпкәләмәгез! Йөрәгем түзмәде. *(Жырлый.)*

Без авылны чыккан чакта,
күтәрелде томаннар...
Исән булсак, бер кайтырбыз
Сау булыгыз, туганнар!

Ишетәсеңме, син уйнаган көй?

Мифтахетдин. Ишетәм. Мин уйнаган, син жырлаган көй.

Хафиз. Нигә мин ишетмим соң?

Маһирә. Мин дә!

Мифтахетдин. Зиннур дустым! Зиннур, син бит бу?!

Зиннур. Шул үзе инде, Мифтахетдин, жан кисәгем! Ялгышмадың!

Мифтахетдин. Зиннур! *(Кочаклашалар.)* Бер дә үзгәрмәгәнсең бит, Зиннур кордаш!

Зиннур. Кая инде үзгәрмәгән? Ике күз белән сине көттек. Ышанып та житеп булмый. Маһирә килен дә юлдан күзен алмады. Саулыклар ничек соң, Аллага шөкерме?

Мифтахетдин. Ярыйсы, Зиннур, ярыйсы... Үзеңдә ни хәлләр?

Зиннур. Үзем ярыйсы, кызлар озатырлык әле. Тик карчык кына картаеп китте. Кызлар янына чыгармый. *(Көлешәләр.)*

Мифтахетдин. Тукта, тукта, син бит Сәрвәргә өйләнгән идең бугай.

Зиннур. Шул үзе инде. Атасы «Чәүкә» диеп тормадым, өйләндем кызына! Әйбәт карт иде үзе дә, туксанга житеп дөнья куйды. Без карчык белән, Аллага шөкер, исән-саулар әлегә. Әйдәгез, безгә керәбез. Сәрвәр көтеп калды, чәйләре суынмасын. Тагын әллә нәрсәләр маташтыра шунда. Кулына кош тотканмыни?!

Маһирә. Тукта әле, тукта, үзебездә дә утырмаган.

Мифтахетдин. Бар алып кер әле үзен, Зиннур!

Зиннур. Керер әле, табын әзерлисе бар.

Мифтахетдин. Алып керергә кирәк иде! Зиннур минем сиңа күчтәнәчем бар иде. *(Түбәтәй белән намазлык суза.)*

Зиннур. Рәхмәт, дустым! Миңа синнән башка берни дә кирәкми!

Мифтахетдин. Әбусы—Сәрвәргә! *(Шәл бирә.)*

Зиннур. Үзең бирерсең. Әле ишек бусагасын таптап бетерер. Рәхмәт, Мифтахетдин! Онытмаганың өчен рәхмәт!

Мифтахетдин. Онытылмый икән ул! Картайган саен күбрәк искә төшә...

Зиннур. Рәхмәт сиңа, дустым! Дустым гына түгел, туганым! Мин бит сугыш беткәнче лагерьда булдым. Аяк төзәлгәч немесләргә дуңгыз карадым, балта остасы, умартачы идем. Өйгә кайтсам, син немесләргә сатылгансың диеп, тагын 10 елга төрмәгә. Менә шулай итеп үтеп китте инде гомерләр дә. Тик синең гаиләң, үз туганнарым кебек якын миңа. Хәлдән килгәнчә булыштым. Инде менә малаең белән үзара йөрешеп, якын итеп яшәп ятабыз, үзебезчә.

Мифтахетдин. Рәхмәт сиңа, Зиннур кардәш, бик зур рәхмәт.

Зиннур. Күпме гомер үтеп киткән! Ә барысы да кичә генә булган кебек. Кулыңны сузсаң тотарлык кебек. Тик барысы да кире кайтып булмаслык үткән гомер...

Маһирә. Сезнеке түгел, безнеке дә үтеп бара инде, Зиннур абый.

**Зиннур.** Сезгә картаерга иртәрәк әле, балалар! *(Күз яшен сөртә.)*

**Хафиз.** Әти, әйдә, кунагыңны өстәл янына чакыр. Әйдә, утыр әле, Зиннур абый.

**Мифтахетдин.** Утыр, әйдә, дустым! Тальяныңны гына алып кермәгәнсең.

**Зиннур.** Алдым! Килеп, ишек төбендә калдырган идем, алып бир әле шуны.

**Маһирә.** Хәзер, Зиннур абый... *(Бирә.)* Менә.

**Мифтахетдин.** Онытмадыңмы уйнауны?

**Зиннур.** Юк. Тик барыбер сиңа житкереп булмады.

**Мифтахетдин.** Мин бөтенләй онытып бетердем. Әйдә, уйна әле.

**Зиннур.** Кайсысын?

**Мифтахетдин.** Әгәр мөмкин булса, безнең яшь чактагысын. Әнә теге—ярышып уйный идек ич әле!

**Зиннур.** Яхшы!

**Мифтахетдин.** Уйна, дустым!

**Хафиз.** Уйна әле, Зиннур абый!

Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем:
Кайда икән яшьлегем, дип,
Шул юллардан эзләдем.

Олы юлның тузанында
Югалттым эзләремне.
Их, кайтарып алыр идем
Узган гомерләремне.

**Сәхнә яңадән караңгы-яктылы булып ала—Мифтахетдин саташа.**

**Мифтахетдин.** Фәгыйлә?! Мин кайттым бит!.. Соңлап булса да, кайттым!!!

**Фәгыйлә.** Күрәм, Мифтахетдин... Мин сине гомерем буе көттем!

**Мифтахетдин.** Мин рәхмәтле сиңа. Гомер буе тугры булганың өчен.

**Фәгыйлә.** Башка кешегә алыштыра алмадым сине...

**Мифтахетдин.** Илле ел буе мин юлда идем, Фәгыйлә!

**Фәгыйлә.** Көттем, Мифтахетдин. Урамда берәр гармун тавышы ишетелсә дә, йөгереп чыга идем.

**Мифтахетдин.** Илле ел буена шулай көттеңме?

**Фәгыйлә.** Илле ел буена. Син, Мифтахетдин, бик матур жырлый идең. Синең моңлы тавышыңны сагындым.

**Мифтахетдин.** Юк, Фәгыйлә! Ул тавышлар юк инде. Күңел ыңгырашуы белән жан әрнүе генә калды...

**Фәгыйлә.** Булсын, булсын, Мифтахетдин! Синең тавышыңны ишетәсем килә.

**Мифтахетдин.** *(Күкрәк тавышы белән әрнеп жырлый.)*

Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, жәйләрең...
Исән булсам, бер кайтырмын
Язлар кебек әйләнеп!

Кушымта:

Хуш, авылым, сау бул.
Сәламнәр көт,
Таң жилләре искәндә.
Мин жырлармын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә...

**Фәгыйлә.** Күңелең тулы сагыш икән синең, Мифтахетдин. Син аргансың, бәгырем! Сиңа ял кирәк. Яле, өстеңдәге күлмәгеңне сал әле, чистасын ки. Мин аны, илле ел элек юган булсам да, тузан бөртеге дә кундырмыйча сакладым. Мә, ки!

**Мифтахетдин.** Рәхмәт, Фәгыйлә!..

**Фәгыйлә.** Табынга утыр әле. Аша әле бу өчпочмакларны. Син бит мин пешергән ризыкларны ярата идең. Илле ел элек пешерсәм дә—суынмадылар. Алар да—минем йөрәк жылысы...

**Мифтахетдин.** Рәхмәт, Фәгыйлә! Гомерем «нишләп теге беләзекне сындырдым икән» дип үкенеп үтте. Гафу ит мине!

**Фәгыйлә.** Сынган беләзек ул—безнең авыр язмышыбызның чагылышы гына. Мин ул сынган тормышыбызның ядкарен гомерем буе саклыдым. Чөнки ул синең төсең иде!..

**Мифтахетдин.** Рәхмәт, Фәгыйлә!..

**Фәгыйлә.** Сине күрдем. Китәм!

**Мифтахетдин.** Китмә әле, Фәгыйлә!..

**Фәгыйлә.** Мин киткән инде, Мифтахетдин... Аннан кайтып булмый.

**Мифтахетдин.** Тукта, Фәгыйлә!! Мин бит сиңа тагын да матуррак беләзек ясаган идем. Менә ул!

**Фәгыйлә.** Нинди матур беләзек!..

**Мифтахетдин.** Әллә тагын беләзеген кысамы, жан кисәгем?

**Фәгыйлә.** Юк, юк! Монысын бирмим...

**Мифтахетдин.** Тукта, мине калдырма! Мин дә синең белән барам. Минем сине тагын югалтасым килми. Ал мине дә үзең белән...

**Хафиз.** Әткәй!

**Фәрдия тавышы.** Бабам минем!

*Пәрдә.*

1996 ел. Казан.

# ШИГЪРИЯТ



## Клара Булатова

### ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Әни!
    Әни!
        Әни!
            Мин әлләни
Игелекләр сиңа кылмадым.
Күп рәнҗеттем сине...
                И, рәнҗеттем
Агымына ияреп дөньяның.

Күп әрнеттем сине үскән чакта,
Тыңламыйча кайчак сүзеңне.
Күп әрнеттем хәтта олыгайгач,
Синнән олы санап үземне.

Киңәшеңне тотмый күп ялгыштым,
Кире кагып синең сүзеңне.
Мин бит сине түгел,
                сине түгел—
Рәнҗеткәнмен, әни, үземне.

Нинди бала җирдә шатлык күрсен,
Тыңламаса газиз анасын?..
Хак Тәгалә берүк саклый күрсен,
Минем хәлгә улым калмасын.

* * *

«Мәхәббәтнең кадерен бел яшь чакта,
Яшьтән сакла аның сафлыгын,
Кадерен бел аның олыгайгач та,
Һәм бәхетле булыр картлыгың».

Киңәш бирү җиңел кешеләргә,
Акыл сатып була яшьләргә.
Тик үзеңә менә шул бәхетне
Саклар өчен ничек яшәргә?

* * *

Безнең халык гомере буйларына
Юлдаш иткән җырны үзенә.
Колак салган аның моңнарына,
Мәгънә салган һәрбер сүзенә.

«Җырның ертыгы юк»,—дисәләр дә
Ертык җырны кабул итмәгән.
Ертыклары, бүленеп үлчәүләрдә,
Тарих сынавыннан үтмәгән.

Һәр күңелдә, телдә җыр туадыр,
Телдән-телгә күчеп яшәргә
Хакы булган моңлы, чын олы җыр
Мирас булып кала яшьләргә.

Уртак хисләр, якты, затлы моңнар
Югалмыйча яши гадәттә.
Әнә шундый яшәү хаклы җырлар
Туып калсын иде Әлмәттә.

* * *

Очрашудан күпме качып йөрдем,
Әрнермен дип авыр сүз әйтеп.
... Ник очрадың бүген, безнең җирнең
Кысанлыгын тагын искәртеп?

* * *

«Китаплардан шагыйрь фикер урлый».
Юк, урламый! Җыя ул аны.
Мәңгелектән акыл кайтарганның
Һичкемгә дә булмас зыяны.

Укып алган, тапкан белемнәрен
Үз каләме аша үткәреп,
Кешеләргә бүген җиткерә ул
Тарих төпләреннән күтәреп.

* * *

Безне нигә ирексезләп
Рәсәйләргә теркиләр?
Чит чанага утырырга
Яратмаган төркиләр.

Кем йөргәндер өчлек җигеп?
Бабам йөргән пар атта.
Кемдер нидер яши сөеп—
Татар парны ярата.

—Бабайлардан килгән сана:
Пар атымны җигәрмен.
... Чанасына утырсам да
Җырлый алмыйм көйләрен.

* * *

«Алма агачыннан ерак төшми».
Шушы хакыйкатькә
Каршы килеп, менә сыңар алма
Төшкән бик еракка.

Ерак төшкән, читкә тәгәрәгән,
Әллә кая киткән.
Агачыннан читкә киткәннәрне
Тормыш аяр микән?

* * *

Кызулый ел агышы,
Йөрәккә хәнҗәр кадады
Соңгы кәккүк тавышы.

Сызланмаган көннәр юк,
Питраудан Покраугa кадәр
Кемнәр исән, кемнәр юк...

Нигәдер җилле әле...
Ничек булса да дөньядан
Китәсе килми әле.

* * *

Изгелегең гөнаһ белән бергә...
Бәлки әле шуның өчендер
Шактый кыска яшәгәндә җирдә
Байтак озын гомер кичердең.

Үз чорыңның каһәрләнгән йөген
Хәтереңә җыеп барасың...
Хак-Тәгалә ярлыкасын инде
Җиргә ялгыш ингән баласын.

* * *

Тау-диңгезләр гизеп йөргән чакта,
Күңелләре тулган көннәрдә
Болытлар да туган якка кайта
Күз яшьләрен җиргә түгәргә.

Син аларны токымсыз зат димә.
Алар да бит туган кайдадыр.
... Яшь түгәрдәй нигезләрен җирдә
Таба алмас җанга, һай, авыр...

* * *

Үлембикә!...
Тукта, монда үтмә!
Килмә, килмә минем ишеккә.
Кысылса да сулыш бу читлектә,
Көтмим әле сине ничек тә.

Сыкрап-сыктап кайбер көннәр үтә,
Авыртулар төшә җелеккә.
Булгалыйдыр, әйе, Үлембикә,
Кайчакларда түзеп-түзеп тә.

Түземлекнең чиге бетеп китсә...
Сабыр канатларын сындырып,
—Ник килмисең диеп, Үлембикә,
Кеше дәшә сиңа сыгынып.

Әмма ләкин бу узгынчы халәт,
Бу—саташу кеше аңында.
Гаҗизлектән айнып киту белән
Ул яшәүне тели тагын да.

Ул яшәүдән һаман өмет итә
Мәңге көнгә ашмас бәхетен.
Читләтеп үт әле, Үлембикә,
Алынмасын әле ләхетем.

Бу гомернең әле җаным барда,
Көнлек түбәнлектән ычкынып,
Бар тавышка яңгырар җырлары бар
Биеклеккә очар кош булып.

Һай, Иреккә Җирдә ниләр җитә...
Җан омтыла аңа ничек тә.
«Чык читлектән!»—диеп, Үлембикә,
Тик син килмә минем ишеккә.

Килмә әле, килмә, Үлембикә.

## Бию көе.

Әй, җор бала, җор бала!
Бигрәк җор шул бу бала,
Бигрәк шук шул бу бала—
Кем булыр бу җор бала?

И, җор булсын, шук булсын,
Мут булсын ла, ут булсын.
Елап җебеп тормасын,
Егет җебек булмасын!

Әй, җор булсын, җор булсын,
Киләчәге зур булсын.
Ут уйнатсын, уйнасын.
Тик тәүфыйксыз булмасын.

И, җор бала, җор бала,
Бик газиздер бу бала,
Җанында иман булсын,
Бәхетле утлан булсын!



Тәүфикъ Әйди

# ҮЗ ҖЫРЫБЫЗ—ҮЗӘКТӘ

КАЗАКЪСТАН—миллəттəшлəребез күплəп яши торган дəүлəт. Казакъ халкы белəн рухи кардəшлегебез, бер ата-баба оныклары булуыбыз, телебез һəм гореф-гадəтлəребез якынлыгы бəхəссез. Төрле өлкəлəрдə хезмəттəшлек итүебез, əдəбият-сəнгать байлыкларыбызны уртаклашып яшəвебез дə күптəннəн килə. Монда илленче елларга кадəр татар мəктəплəре яшəде, заманында татар милли-мəдəни җəмгыятьлəре, клубларыбыз, милли матбугатыбыз, профессиональ театрыбыз эшлəве дə яхшы билгеле. Əмма тоталитар совет режимы «бердəм совет халкы»н барлыкка китерү максатыннан тора-бара татар милләтенең дə тамырын корыту юлын сайлады—Казакъстан татарлары бик күп казанышларыннан мəхрүм ителде. Бары үзгəртеп кору, хөррият һəм хəбəрдарлык дəвере канат җəйгəч кенə, миллəттəшлəребез яңадан баш калкытып, югалтуларын барлап, үзен миллəт буларак саклау һəм үстерү юнəлешендə хəрəкəт кылырга кереште. Симəй (Семипалат), Чымкəнт, Алматы шəһəрлəрендə милли матубгат, башка күп кенə шəһəрлəрдə үзешчəн сəнгать җанланды; мəктəплəргə татар телен кайтартырга, милли-мəдəни җəмгыятьлəр корып, үз мөнфəгатьлəрен кайгыртырга тотынды. Радио-телевидениедə татарча тапшырулар киңəйде, татарлар тормышына багышланган китаплар да басыла башлады. Шуларның икесе—«Дусларымның уйлары һəм моңнары» дигəн күмəк җыентык һəм Г. Хəйруллинның «История татар» хезмəте əле яңарак кына дөнья күрде.

Беренче җыентыкның өчтəн ике өлешендə шулай ук Г. Хəйруллин шигырьлəре урын алып тора. Бу җыентыкта Заһит Шакиров шигырьлəре һəм Галибə Сəйбулатова ноталары белəн җырлары да урнаштырылган. Матур тембрлы тавышка ия җырчы, Татарстанның атказанган мəдəният хезмəткəре Галибə Сəйбулатова Кытайда туып-үскəн миллəттəшебез; аның мəнə инде утыз елдан артык Казакъстанда һəм аннан читтə татар җырын даими яңгыратуы миллəттəшлəребез өчен зур əһəмияткə ия—ул тарихи ватаныбыздан еракта туган телебез һəм моңыбызны яшəртə.

Заһид Шакиров белəн Гриф Хəйруллин—Башкортстаннан. Заһит Шакиров заманында Минзəлə дəүлəт театрында һəм Татар дəүлəт

жыр һәм бию ансамблендә хезмәт иткән, озак еллар шигырьләр язу белән мавыккан. Бу мавыгу Башкортстанда туып-үскән Гриф Хәйруллинга да хас икән. Җыентыкны төзүче Әхмәдулла Әбүзәр китапка русча һәм татарча кереш сүз язган, җыентыкны Казакъстандагы милләттәшләребез тормышын сурәтләгән фотолар белән бизәгән. Яхшы кәгазьдә бер мең нөсхә белән басылган бу матур китап татар диаспорасына гына түгел, бөтен халкыбызга кадерле бүләк—милләттәшләребез аны бастыру чыгымнарын да үзләре күтәргән.

Югарыда телгә алынган ике китап та Казакъстандагы милли-мәдәни җәмгыятьләребез файдалансын һәм халкыбызга таралсын, аның милли аңын күтәрү, туган мәдениятенә ихтыяҗын канәгатьләндерү максатында кулланма булсын өчен чыгарылган.

Гриф Хәйруллинның «Татарлар тарихы» хезмәте гадәти гыйльми китапларга охшамаган. Ул киң катлам укучыларга тәгаенләнгән, фәнни нигезе ачык күрсәтелсә дә, ялыктыргыч цитаталар, вак-төяк детальләр белән чуарланмаган. Әмма аның тагын да әһәмиятлерәк үзенчәлеге шунда ки—империя рәсми тарихчыларына хас булган шовинистик карашлардан мөмкин кадәр арынуында.

Автор тарих өлкәсендә яңалыклар ачуны дәгъва итми, әмма халкыбызның үткәненә үз бизмәне белән якын килә, диаспорабыз турында күпләргә билгеле булмаган мәгълүматлар да китерә. Аны туган телебездә зуррак тираж белән бастырып чыгару да бик файдалы булыр иде, билгеле.

Татар диаспорасы тормышы катлаулы: анда күтәрелешләр дә, кире чүгүләр дә күзгә ташлана. Бу хәлләр Казакъстанга да хас. Шушы хакта белдекле кеше белән әңгәмә корыр өчен мин Алматы шәһәрендә яшәүче Гриф Тимерзаһит улы Хәйруллин белән очраштым.



*Гриф Хәйруллин*

Гриф Башкортстанның Дүртөйле районы Казаклар авылында туган, күрше Миңештәдә, шагыйрь Нажар Нәҗми туып-үскән вылда җидееллык мәктәпне, аннары Бөре педучилищесын тәмамлаган. Мәктәптә укыткан, бераздан Бөре пединститутында белем алган, шуннан соңгы тормышы Төркестанга бәйләнгән: Ташкент өлкәсенең урыс мәктәпләрендә балаларга белем биргән, директор булган. Шул ук вакытта белемен күтәрүен дә дәвам иткән—Ташкент өлкә педагогия институтында сабак бирә башлаган. Төп белгечлеге—математика. Саннар теориясе. Аның беренче ун гыйльми хезмәте шушы тармакка багышланган. Ул шушы институтта декан дәрәҗәсенә җиткән. 1976 елда исә Алматыга күчеп килгән. Монда ул хезмәт тәрбиясе һәм аның тарихы белән кызыксынып киткән, 1992 елгы докторлык диссертациясе нәкъ менә шушы мәсьәләләрне өйрәнүгә багышланган. Профессор Г. Хәйруллин Акмеология фәннәре академиясенә һәм Мәгълүматлаштыру академиясенә академик итеп сайланган. Хезмәт юлын ачыклагач, мин аңа:

— Шундый җитди галим хәлендә, ничек шигырь яза башладыгыз?— дип беренче соравымны бирдем.

— Күңелдә хисләр куәтле булгангадыр инде,—диде ул көлемсерәп.— Инде икенче җыентыгым да әзер. Профессиональ шагыйрьләр, бәлки, минем әсәрләремә югартын гына карар. Даһилыкка дәгъвам юк, хисләрем кәгазьгә түгелә, укучылар гаеп итмәс дип өметләнәм.

— Гриф әфәнде, ә тарих белән күптәннән кызыксынасызмы?

— Бик күптән, әмма миңа галим буларак башка өлкәгә кереп китәргә туры килде. Шулай да тарихи хезмәтләрне гел укыштыра килдем. Безне бит мәктәптә үк: «Татар-монгол бик начар халык, изүче!» дип өйрәттеләр. Бу билгеләмә безне рәнҗетә торган нәрсә

иде. Ирексездән күңелдә: «Мин ничек шундый начар явыз халыктан килеп чыкканмын икән?»—дигән фикер туа иң инде.

Төбенә төшеп карасаң, халкым бер дә андый булмаган икән ләбаса. «Татарлар тарихы» шушы хакта. Икенче китабымның өзер кульязмасы «Татар халкының традицион мәдәнияте» дип атала.

— Сез бу темага ничек алындыгыз? Хезмәт тәрбиясе белгече үз темасын тырышыбрак тикшерсә, дәрәҗәсе тизрәк үсәчәк, ул бар яктан да күбрәкне отачак. Ә татар темасын күтәргән өчен Сезгә берәү дә эш хакын түләми, аны монда берәү дә эш планына кертми, рәсми җитәкчеләр рәхмәтен ишетү дә мөмкин түгел.

— Шул, әлеге дә баягы, җан өрнүеннән килеп туган хикмәт инде ул. Чөнки нинди генә китапны, хәтта соңгы дәвердә Казанда басылганнарны күздән кичерсәгез дә, халкыбыз тарихы дөрес, объектив сурәтләнмәвен күрәчәксез. Әйтик Равил Фәхретдиневнең мәктәп дәреслеге күптән түгел генә кулыма килеп әләкте. Ярый, ул профессиональ тарихчы. Ул күп белә, мин аның белән ярышмыйм. Мин профессиональ тарихчы түгел. Тик шулай да, менә мин, читтән карап торган татар баласы, аның язмасында урыс дәүләтеннән күпмедер курыкканлыкны сизәм. Мине шул нәрсә рәнҗетә.

— Димәк, Сезнең концепция безнең традицион тарихчыларныкыннан аерыла?

— Әйе. Ә икенче яктан караганда, Мирфатыйх Зәкиевне алыгыз. Бик матур нәрсәләрне эзләп тапкан иң ул. Биармия турында. Аның бу фаразына ышанганлыктан, мин аны үз китабыма да керттем. Безнең архивларыбызны, язмаларыбызны гасыр арты гасыр юк иткәннән соң, хәзер күп нәрсәне дөрес дип исбатлавы кыен нәрсә. Шунлыктан, мин үзем кайсы фикерне дөрес дип санасам, күңелемә якын итеп тойсам, китабыма шуларны керттем, әлбәттә.

— Евроцентризм Азия халыкларын дөньякүләм әһәмияткә, кыйммәткә ия халыклар дип кабул итәргә теләми, һәр нәрсәгә үз карашларын тага. Моның урыс һәм башка милләт галимнәренә дә тәэсире зур булды. Татар белгечләре дә урыс уку йортларында укыгач, Европа гыйлеме тәэсирен кичерде. Сез, Гриф әфәнде, мондый тәэсирләрдән арынырга уйлагансыз. Фикерегезчә, бу эш ни дәрәҗәдә барып чыкты?

— Мин китабымны Татарстан өчен түгел, Төркестанда яшәгән милләттәшләрем өчен яздым. Чөнки мондагы татарлар хәле Татарстандагылар хәленнән дә кыенрак. Кайсы гына дәүләт үзендәге бөтен милләтләрне тигез хокуклы дисә дә, бу мөмкин эш түгел. Утопия бу. Бер генә мисал китерим: Татарстанда бер миңгә якын казакъ бар. Шулар: «Татарстанда казакъ теле дәүләт теле булсын»,—дип таләп итә аламы? Юк. Без монда күбрәк, әмма без дә «Казакъстанда татар теле дәүләт теле булсын!—дия алмыйбыз. Димәк, без дә казакъка караганда аз гына булса да түбәнрәк баскычка төшәбез түгелме соң? Мин шуны биредә һәрвакыт сизеп торам. Шуның өстенә, Татарстаннан килгән китаплар да: «Бөек урыс мәдәнияте генә әгълә, шул гына безне күтәрде»,—дип торса, мин ничек яшәргә тиеш? Минем балаларым кем булып йөрер? Ул йә эреп бетәчәк, йә үз теленнән, милләтеннән ваз кичеп, татар исемен онытып, аннан оялып яшәячәк.

— Бу китапны язу Сезгә, беренчедән, әле чын милли тарих язылмаганлыктан, икенчедән, милли мәркәздән еракта яшәгәнлектән, бик кыен булгандыр?

— Миңа Мәскәү китапханәсе ярдәм итте, шунда казыну булышты. Бүгенге урыска дәгъвам юк—аны 500 ел буе: «Син—бөек халык!—дип ышандырып килсәләр, әллә нинди акыллы кавем дә бозылыр иде. Аннары, бүгенге урысның моннан 500 ел элек яшәп киткәннәргә ни катнашы бар? Шунлыктан, урыс дигәндә, мине дөрес аңлавыгызны үтенәм. Урыс язучылары, урыс тарихчыларының бик матур кимәлдә язылган китаплары да бар. Худяковны гына алыйк. Соловьевта да, Карамзинда да менә дигән урыннар бар. Алар шул-

вакытта да күп нәрсәне курыкмыйча язганнар бит. Нигә шуларның рациональ фикерләрен кулланмаска? Шунлыктан, бу татар өчен генә җаны әрнеп язган икән, дип әйтерлек җирләрдә мин урыс тарихчыларына мөрәҗәгать иттем. Аларның гыйбарәләрен китердем.




— Китабыгызны актарганда, Сезнең байтак гыйльми хезмәтләрне файдалануыгыз күренә. Бу тарихи тикшеренүме?

— Юк, мин татар гаммәсен агарту, бөтенләй белмәгәннәргә, һичьюгы, башлангыч мәгълүмат бирүне күздә тоттым.

— Таррак темага әтрафлы тикшеренү уздыру белән бергә, киң катлам укучыларга сезнеке кебек гомуми мәгълүмат бирердәй кулланмалар бастыру да әһәмиятле. Киләчәктә зур галим булып үсәргә тиешле яшьләребезгә дәрт, һәвәслек йоктыра торган китаплар да кирәк. Димәк, Сез бер бушлыкны тутыргансыз, моның өчен без Сезгә рәхмәт яуды-рырга тиешбез. Хәзер тарихчыларыбызга карата күңлегездә йөргән фикерләрегезне дә әйтсәгез иде. Чөнки Сез гади укучы гына түгел, күп хезмәтләр белән танышканлыктан, тарихыбызның деформацияләнүен яхшырак тоясыз, алардан арыну өчен галимнәргә җәмәгатьчелек басымы да кирәк.

—Бездә яхшы үрнәкләр дә бар. Мисалга, Әбрар Кәримуллинны алыйк. Аның язганнарын бик рәхәтләнеп укырга, алардан файда табарга мөмкин. Чөнки ул дәлилләп, исбатлап яза. Былтыргы бер мәкаләсендә мөхтәрәм галимебез: «Татар халкы саны 20 миллионнан ким булмаска тиеш»,—диде. Төп белемем буенча математик булганлыктан, мин бу мәкаләне бик игътибар белән укып чыктым, хатасын эзләдем, әмма тапмадым—чыннан да ышандырырлык итеп язган. Казакъстанны гына алып карасак та, яртылаш татарларны әйтмим дә инде, саф татар булып та казакъ дип исәпләнеп йөргәннәре дә дөнья тулы. Кытай чиге буендарак Лепсе дигән бер авыл бар. Элек-электән татар авылы ул. Анда ата-бабаларыбыз 200 ел элек үк килеп урнашкан булганнар. Бер риваять буенча, аны солдат хезмәтеннән котылырга теләгән миллəттәшләребез барлыкка китергән. Артларыннан эзләп тинтерәтмәсеннәр өчен, урыска, казакъка хезмәткә ялланып, шуларның фамилияләрен дә алганнар. Мин шул Лепсе авылыннан килгән бер студентымнан аптырап: «Фамилиягез урысча, исемегез татарча, ничек була инде бу?»—дип сорадым. Ә ул миңа: «Мин бит урыс фамилияле татар малае»,—дип җавапланды. Андый милләттәшләрне дә исәпләсәк, Ә. Кәримуллин әйткәннәр дөрес булып чыга. Кыскасы, татар тарихын дөрес итеп яктыртучылар да бар.

—Казакъстан татарларына әйләнеп кайтсак, аларның монда милләт буларак киләчәге ничегрәк?

—Четерекле сорау. Казакъстандагы хәл башка җирләрдәгегә охшаштыр инде. Үз илендә, үз халкы арасында яшәмәгән кеше, этник төркем һәрвакыт йотылу хәвефе астында, аның саклануы өчен мөһим шарт—кайдадыр көчле тарихи ватаны, дәүләте булу. Татарстан үз милләтен кайгырта белә торган куәтле дәүләт булса, читтәге татарлар да югалмас иде. Шундый Татарстан булмаса, мондагы милләттәшләр озак сакланмас. Бу—табигый хәл, мондагы кешеләргә яки дәүләткә бәйле хәл түгел. Чөнки монда башка тел өстенлеге, бүтән менталлитет (уйлау, ышанулар үзенчәлеге) хөкем сөрә, торабара кеше шуңа ияләшеп, күнегеп китә, әкренләп йотыла да. Бәхетебезгә, Татарстан бар; мин ике милли корылтаебызга да бардым, төрле яктан җыелган милләттәшләр белән күп әңгәмә

кордык. Финляндиядә һәм АКШта берәр мең татар бар икән, алар исемдә генә ич инде, алар татарның төп өлешенә кушылып күп ярдәм итә алмый. Кайдадыр күбрәк тупланып яшәүчеләр татар мәдәниятен үстерүгә дә мулрак өлеш куша ала. Мисалга, Башкортстанны гына алыйк. Рәсми исәп буенча алынган 1, 2 миллион татар Татарстан белән тыгыз элемтәдә яшәсә икән, игелеге дә барыбызга тияр иде. Юк шул...

— Казакъстанда да татарның гомуми саны күп. Сәяси ирекләр ачылды, кайбер богаулар алып атылды. Әмма татарның уяну хәрәкәте соңгы берничә елда сүлпәнәя башлады кебек. Казакълар сезгә булышырга теләмиме, әллә моңа дәрманнары җитмиме?

— Казакъларга рәнҗү кыен. Үзләрен шушы дәүләтне төзүче халык дип хисаплый башлагач, телләрен дәүләт теле дип игълан иткәч, әлбәттә, алар үз телләрен гамәлгә куяр өчен көрәшергә мәҗбүр. Үзләре өчен көрәшкәндә, кеше кайгысы кештәктә, дигәндәй, аларның башка халыкларга игътибары да, ярдәме дә булмаячак. Кыргызстанда да, Үзбәкстанда да шул ук хәл. Шунлыктан мондагы татарлар якындагы ун елда гөрләп үсеп китәр дигән өметем юк. Милләттәшләребезнең бер өлеше тарихи ватанына кайтып китүе дә табигый нәрсә мондый шартта. Соңгы 5—6 елда, рәсми исәп буенча, 320 меңнән 280 меңгә калганбыз инде. Бу—зур кимү. Калучылар исә, милләтебезне сакларга тырыша. Һәр өлкәдә диярлек милли-мәдәни үзәкләр оешты, радио-телевидение тапшырулары ачылды, анда туган телебездә сөйлибез, җырлыйбыз, китаплар да бастырырга тырышабыз, сабантуйлар оештырабыз. Башка халыклар да сабантуй бәйрәмебезнең хәмер кулланмыйча, күңелле узуын күреп соклана, без дә үзебезнең барлыгыбызны бөтен Казакъстанга күрсәтәбез. Гәзитләребез финанс кыенлыгы аркасында әлегә тукталып тора, «Фикер»нең редакторы—мин үзем, былтыр бер генә санын бастыра алдык. Радиода бик әйбәт тапшырулар башлаган идек, анда тәҗрибәле белгечебез Фаягөл Гыйбадуллина эшли иде. Былтыр аның белән атна саен 5—7 минутлык татар теле дәресләре бирдек—берь еллык программаны мин үзем әзерләгән идем. Атнасына өч мәртәбә утызар минутлык тапшыруларыбызның икесе—беренче программада, берсе «Чалкар» программасында яңгырый иде. Концертын да, әдәби тапшыруларны, яңалыкларны да эфирга чыгара идек. Казакъстан бәйсезлеген ныгыта барганда, «бөтен радио-телевидение тапшыруларының яртысыннан күбрәге казакъча булсын», дигән хөкүмәт карары чыгарылды. Кайбер җитәкчеләр шуны гамәлгә ашырыр өчен бик җиңел юл тапты—бүтән телләрдәге тапшыруларны кысып, казакъчаны киңәйттеләр. Урысчасы да кысылды, уйгыр, әзәри тапшырулары киметелде, татарның «Чалкар»дагысы гына калды. Хакимияткә мөрәҗәгать итеп карадык, мин үзем шушы мәсьәлә буенча форсаты тигән саен чыгыш ясыйм—файдасы гына күренми. Мөрәҗәгатьләребезгә кайвакыт көлке җаваплар килә: «Сезгә бирсәк, башка милләтләр дә сораячак, ә без аларга бирә алмыйбыз! Янә бер җавапларында: «Хәзер Татарстан үсеп килә, алар ярдәм итсен!»—диелгән.

—Татар милли-мәдәни җәмгыяте президенты Морат Кәримов Назарбаев янына да, Шәймиев янына да кереп йөри ич, мәсьәләне хәл итә алмыймы?

—Мин рәсми рәвештә аның урынбасары. Казан кешесенә барысын да сөйләп булмас. Татар мәсьәләсен хәл итүгә ул катнашмый шул.

—Мин аның белән Алматыга элек килүемдә үк танышкан идем. Морат Кәримовнең татарны оештыра торган кеше түгеллегенә тәмам ышанып киттем. Ул 5—6 галимне һәм берничә югары дәрәҗәле түрәне янына җыеп, шуларның башлыгы булып күзгә чалынса, алар исеменнән тегендә-монда югары җитәкчеләргә юл сапса, шул җитә икән. Калган татарларда аның эше юк икән! Мин сездә күреп сөйләшкән барлык татарлар: «Морат Кәримов Татар милли-мәдәни җәмгыятенә ихлас хезмәт итми, эшне тиешенчә алып бара алмый,

үзе өчен генә тырыша торган кеше, аннан милләт зыян гына күрергә мөмкин,—диделәр. Сез нигә шундый кешене татар җәмгыяте президенты итеп тотасыз?

—Аны җәмгыятьтән читләштерү мөмкин, әмма башка халыклар алдында татарның яманатын сатасыбыз килмәгән иде. М. Кәримов милләттәшләребезне бер-берсенә каршы куя, шуның белән тагын да күбрәк зарар китерә. Әмма оештыру мәсьәләсе күпләрне канәгатьләндерми, ул якын арада хәл ителми калмас.

—Гриф әфәнде, Казакъстанда милләттәшләребезне татарча укыту мәсьәләсе хәзер ниндирәк хәлдә тора?

—Якшәмбе мәктәпләрендә тел, дин өйрәнү күпмедер бара. Хәзер Талды Курганда 3 сыйныфыбыз бар. Шәһәрнең үзендә. Саф татар класслары түгел, алар яртылаш кына. Калган яртысын, классына карап, корея, казакъ, урыс тәшкил итә. Шуларда телне өйрәтергә тырышалар. Җыр-бию дәресләрен татарча уздыралар. Алматыдагы 39 нчы мәктәптә 4 классыбыз бар. Дәресләр татар телендә алып барыла. Эшнең алга китмәве—милләттәшләребезнең шәһәрдә чәчелеп яшәвеннән килә. Автобуста бер бару балалар өчен дә 15 тәңкәгә төшә, күпләр шундый еракка түләүле итеп баласын йөртергә кыенсына. Балалар аз җыйнала.

—Ә сез интернат-мәктәп оештырырга тырышмадыгызмы? Атнасына бер тапкыр гына илтү, алып кайту бәлки күпләргә җиңелгә килер иде. Анда барлык фәннәрне дә бары татарча гына укыту да шарт түгел. Бәлки шулай татар мәгарифе Казакъстанда да аякка басып китәр иде?

—Мәсьәләне болай күтәргәнебез юк. Аның матди нигезе булырга тиештер. Казакъстанда икътисади чүгү һаман тукталмаган әле. Минем хәзерге хезмәт хакым, мәсьәлән, Русия акчасында исәпләсәк, 50-60 сум. Андый акчага беркайчан да эшләмәгән идем! Шушы нәрсә хәлебезне ачык күрсәтә. Мондый шартларда милли мәгариф нишли ала соң?

—Мәҗбүри урта белем бирү гамәлгә ашырыламы?

—Конституциябез буенча гарантияләнә ул, ләкин чынлыкта эшкә ашырылмый. 9 еллык уку бар. Казакъстанда мәктәпләр саны кими бара. Төрле киңәшмәләрдә катнашкалап торам, шуларның төп темасы—казакъ телен дәүләт теле сыйфатында өйрәнү. Җыйналган саен шул мәсьәлә тикшерелгәч, берсендә түзмәдем: «Дәүләт теле булгач, без нигә аны өйрәнергә үгетләргә тиеш?»—дидем. Бездәй картларга ябырылырга кирәкми, урысларны җәфаламыйк. Мәктәпләрдә исә тиешенчә укытырга кирәк. Рәсми исәп буенча, хәзер балаларның 12—20 проценты мәктәпкә йөрми. Шуннан соң нәрсә көтәргә була? Кимчелекнең күбесе—авылда, анда исә казакълар күпчелекне тәшкил итә.

—Казакъстан ССРның бай республикасы иде кебек. Икътисад шул кадәр түбән тәгәрәдемени?

—Алматыдагы завод-фабрикаларның күпчелеге эшләми. Поршень заводы, машина төзү заводы бар иде—ябылганнар. Туку фабрикасы яртылаш кына хәрәкәттә. Үзара элемтәләр өзелү, комплектлаучы детальләр килмәү, чимал җитмәү кебек сәбәпләрдән башланды чүгү. Җитештергән малны сату да кыенлашты. Халыкара хезмәттәшлекнең дә нәтиҗәсе күренми. Теге-бу җитештерү учагы сатыла, аның акчасы кая китә—белмибез. Халыкның тормышын яхшыртуга булышмады бу алыш-биреш. Кентау, Җаңатас, Ленгер элек гөрләп торган шәһәрләр иде. Шуларның халкы хәзер ачлыктан нәмаешка чыга. Караганда тирәсендәге Саран, Абай да нинди сәнәгать калалары иде. Хәзер, өйтүләренчә, анда яшәүчеләр фатирларын ташлап китә. Эш юк. Шахталар ябыла. Чит ил байлары монда тагын да баер өчен килә, алар баеган саен мондагылар фәкыйрьләнә бара.

—Казакъстанда кемнәр тизрәк күтәрелә: казакъмы, башкалармы?

—Икътисади яктан казакъ халкы тиз генә күтәрелә алмас. Урыс-яһүд активрак. Татарлар да җанлырак. Тарихи традиция диган

нәрсә дә бар ич әле. Заманында Абай: «Без татарлар кебек сәүдә итә белмибез, һөнәрле түгел»,—дип дөрес язган. Югарыдагы җитәкчеләр казакътан булу, сәүдәдә казакълар арту белән генә Казакъстан үсә алмый. Эшчәнлекләренең нәтиҗәсе Казакъстанны күтәрмәгәч, хөкүмәтне дә мактап булмый. Хәер, мин икътисадчы түгел, бәлки барысын да белеп тә бетермимдер. Хәл бер яхшырыр, чөнки һәр система үз-үзен саклар өчен көрәшә. Халык та соңгы чиккә җиткәч, яшәр өчен тырмаша башлый. Ул чиккә якынайдык бугай инде.

—Аның каруы Казакъстанда милләтләр арасында татулык бар шикелле?

—Урыс, украин, немеснең дәгъвасы казакъка каршы юнәлмәгән. «Телебез кыерсытыла»,—дип шауларга мөмкин. Элек беренче булган телнең икенче урынга чигенүе ансат кына бармый. Ләкин таләпләрнең төп өлеше—икътисадка бәйле. «Нигә хезмәт хакы вакытында түләнми? Нигә ризык, газ җитешми? Нигә кичке унбердә урам утлары шәһәрләрдә дә сүндерелә?..»

—Гриф әфәнде, Казакъстанда казакъ халкы өлеше артамы?

—Казакъларда күп балалы гаиләләр әле дә бар. Аларның артуына ышанырга мөмкин. Ләкин алдагы елларда халык саны бик тиз үсмәс. Казакълар чит җирләрдән Казакъстанга җыйналыр дигән исәп бар иде, әмма, икътисадка бәйле рәвештә, бу исәп тә акланмады. Кайтканнарның да бер өлеше кире китә.

—Казакъ телендә югары белем алу киңәяме?

—Күбәя. Казакъ бүлекләренә казакъ телен белүче башка милләт вәкилләре дә керә. «Хәзер урысларга Казакъстанда югары белем алу кыенлашты»,—дигән дәгъвалар ишетелгәли. Кыен булса, казакъ телен өйрәнергә кирәк. Билгеле, югары уку йортларында укыту казакъ теленә күчерелгәндә, сыйфат ягы бераз төшә инде. Чөнки әзерлекле галим-укытучылар да, дәреслек-кулланмалар да җитешми. Төркестан шәһәрендә Төрек-казакъ университеты ачылды, төрле шәһәрләрдә төрек-казакъ лицейләре эшли башлады, Алматыда алар өчәү бугай.

—Гриф әфәнде, Сезнең өчен иң актуаль мәсьәлә нидән гыйбарәт?

—Ерактагы бер бабай болгата шунда, димәсен иде укучы бу әңгәмәбезне. Мин халкымның табигый яшәвен телим. «Милләтче» дисәләр дисеннәр, мин башка халыклар үсешенә дә каршы түгел ич. Әмма минем тугыз онытым бер заман: «Безнең картәти шундый иде»,—дип татарча сөйләсеннәр иде. Татарлыгыннан оялмыйча, кыенсынмыйча яшәсеннәр, үз җырларыбызны җырласыннар иде!

«Дусларымның уйлары һәм моңнары» җыентыгында Гриф Хәйруллинның «Фирдәүскә» дип багышланган бер шигыре бар. Анда мин:

Моңлы җырлар белән мине
Син үзеңә караттың.
Шифа булды йөрәгемә,
Шуңа сине яраттым.

Еллар үтә, ә мин һаман
Сокланам җырларыңа.
Сокланам да, шатланам да
Дөньяда син барына,—

дигән юлларга тап булдым. Фирдәүс—Грифнең хатыны, Кытайда туып үскән җырчыбыз, шәркый төркестанда бик билгеле булган, әсәрләре Казан матбугатында да дөнья күргән шагыйрь һәм драматург Рәхим Сәфәргалиевнең кызы. Алматыда татар үзешчән сәнгатен яшәтүгә күп көчен һәм сәләтен багышлаган Фирдәүс әле дә җырлый. Ире генә түгел, ул үзе дә укучылар игътибарына бик лаек шәхес.

— Алматыда яшәсәк тә, үзебезнең татар икәнлекне бервакытта да онытмыйбыз,—ди ул.—Татарлык хисләребез үлми. 1968 елда Равил Гозәерев белән Алматыда беренче мәртәбә «Яшьләр» татар

жыр-бию ансамблен корган идек. Ике-өч ел буе бөтен җирдә концертлар куеп, халкыбызны сөендереп йөргән идек. Тик ул вакытта безгә юл бирергә теләмәделәр. Күп еллар үткәч, Равил шушы эшкә яңадан җигелде—«Сарман» коллективын оештырды. Инде бу ансамбль дә ун ел яши, конкурслар лауреаты булды, «Халык ансамбле» исемен казанды, дипломнары күп. Алматыда тагын «Якташлар» дигән ансамбль дә бар, «Алсу» төркеме дә яши. Былтыр татар коллективлары Алматыда җыенысы унлап концерт куйды. Шәһәребездә безне яраталар, заллар тулы була. «Сарман»да 30 лап кеше катнаша. Элек танышу клублары да кечәләр оештыра иде, шулар ярдәмендә дистәләп татар гаиләсе корылды, икътисади чүгү аркасындамы, соңгы вакытта аларның эшләре бераз сүлпәнләнде әле.

—Киләчәктә Алматының татар сәхнәсенә яшьләр килерме? Профессиональ сәнгатькә кемнәрне үстереп бирдегез?

—Бер пианист кызыбыз Казанда уздырылган конкурста катнашты,—диде Фирдәүс ханым.—Икенче урынны алып кайткан иде, әмма монда эш табылмаганлыктан, ул кызыбыз АКШка китте. Яшьләр дә татарча җырлар, дип уйлыйм, «Алсу» ансамбле яшьләрдән генә тора ич.

—Сезнеңчә, Казакъстан татарларына иң кирәк эш нәрсә ул?

—Радиотапшырулар. Безнең язмаларыбыз анда аз түгел, әмма тапшыру вакыты кыскартылгач, халык туган көйләрен, туган телен ишетүдән мәхрүм калды. «Чалкар» программасы начар ишетелә, татарча тапшырулар Казакъстан радиосының беренче программасында яңгырарга тиеш. Халыкка иң кыска һәм уңайлы аралашу чарасы, милли утны югалтмау чарасы—радио.

Язманы төгәмамлаганда мин шуны өстәргә тиешмен: Гриф Тимерзаһит улы Хәйруллин бик җитди кеше—гыйльми һәм укыту эшләренә муеннан күмелүенә карамастан, «Сарман» җыр-бию ансамбленең һәр концертында катнаша-җырлый, хәтта үз көйләрен дә башкара. Алтмышын тутыруына карамастан, төсе-кыяфәте әле яшьләрчә. Без аннан халкыбыз шатлыгына күпне көтә алабыз, аңа барлык ниятләрен тормышка ашыруын телибез.

*Алматы—Казан.*

---

## Бездә кунакта — «Идел» журналы

Яшьләр журналын чыгару өчен күпъеллык көрәш ничек барган, аның башында кемнәр торган, аларга нинди катлаулы юллар узарга туры килгән? Алдагы сандагы язмалар хәтеребездә әнә шул онытылмас хатирәләрне җанландырыр.

«Идел» журналы редакциясе әзерләгән махсус сәхифәдә «Казан утлары»н укучылар ун ел дәвамында яшьләр мәҗмугасында дөнья күргән иң яхшы әсәрләрдән өзекләр белән танышырлар, ша - Ярыш мәзәкләреннән авыз итәрләр.

Кыскасы, журналыбыз битләрендә без тагын бер кат яшьлегебезгә әйләнеп кайтырбыз.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында җитди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?**

## Рифат Сверигин:

**1**. Соңгы ун-унбиш елда әдәбиятыбызның казанышы дип саналырдай байтак кына әсәрләр иҗат ителде. Шуңа күрә, әдәбият ярлыланды, саекты дияргә җирлек юк сыман. Матур, зәвыклы, тирән мәгънәле әсәрләрнең бүген дә язылып һәм басылып торган көне. Тик соңгы вакытта аларны табып алу, күрү-күрсәтә белү ягы шактый ук кыенлашты. Яңа әсәрләрнең чиксез ташкынында бүген «каймагы» да, «сөте» дә, «суы» да (суның да төрлесе була)—барысы бергә кушылып, аралашып ага. Бүген төп кыенлык сепаратор булмауда—ягъни әдәби тәнкыйть дигән нәрсәнең үз функцияләрен, вазифаларын башкарудан бөтенләй читләшүендә. Бүгенге әдәбиятның күпләргә тоташ бер соры, төссез масса кебегрәк күренүен шунын белән генә аңлатып була торгандыр.

Әмма, теләгәндә, бик яхшы әсәрләрне аерып алырга мөмкин. Ләкин шунысы бар: кичә начар язган кеше бүген кинәт кенә яхшы әсәр язып китерә алмый. Чөнки әдәби әсәр иҗат итү инде формалашкан шәхеснең таланты, гражданлык һәм кешелек дәрәҗәсе белән бәйләнгән була. Шуңа күрә мин анкетадагы беренче сорау бераз үзгәртебрәк, борыбрак куелган тәкъдирдә җиңелрәк җавап бирер идем. «Кайсы әсәрләрне әдәбият казанышы дип саныйсыз?» дигән сорау «кемнәрнең әсәрләрен?» дип бирелгән очракта мәсәлән.

Проза өлкәсендә берничә исемне атар идем. Бу исемлекнең иң өстенә башкалардан үзгәрәк әдип—Фәнис Яруллинны куяр идем. Ни өчен үзгәрәк? Аның прозасын шигърияте белән бәйләнештә генә аңлап була. Шулай булгач, бу әдип

турында сөйләгәндә үзәккә жанр мәсьәләләрен түгел, ә шәхес мәсьәләсен куярга кирәк. Әдип һәрвакыт үзе булып—халык, милләт, җәмгыятебезне борчыган заман, тормыш проблемаларын йөрәгә аша үткәрүче, кичерүче һәм сынмас, буйсынмас рухлы олы шәхес булып кала. Аның 1994-98 елларда дөнья күргән өч томлык сайланма әсәрләренен, «Серле дөнья», «Җан авазы», «Көн сулышы», «Яз гөлләре», «Көзге моң» исемле җыентыкларынын әлегә бөтенләй өйрәнелмәгән, тикшерелмәгән гаять бай эстетик дөнья икәнлеген әдәби җәмәгатьчелек белми диярлек. Күпләр, кызганычка каршы, бүген дә Фәнис Яруллинны шәхси фаҗигага юлыккан һәм шул турыда үзенен «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен язып чыккан кеше дип кенә күз алдына китерәләр. Ә мин аны заманыбызнын актуаль иҗтимагый-эстетик мәсьәләләрен кыю күтәрүче буларак, Лев Толстойларга тиң олы зат дияр идем. Әмма җәмәгатьчелеккә, укучыларга моны исбат итеп бирәсе бар әле.

Без күзәтә торган чорның тагын бер зур язучысы, әлбәттә—Миргазыян Юныс. Ул җәмгыятебез, илебез, милләтебез тәнендәге яра-җәрәхәтләрне тоз сибеп, дезинфекцияләп, начар җирләрен кисеп ташлап, хирургларча дәваламакчы була. Тик тәненә пычак тидергәнне кем яратыр икән соң? Хакыйкатьне, күзенә карап, ярып салучыларны бүгенге заманда кемнәр үз итеп, күтәреп алыр? Уңай җавап табуы кыен. Күрәсең, андыйлар булсалар да, бик аз очрыйлар. Авторның «Соңгы сулыш» исемле әсәре зур кыенлыклар белән генә дөнья күрде, башка хезмәтләре дә басыла алмыйча ята. Ә Миргазыян Юныс әдәбият дөньясында үтә дә хөр фикерле, югары хәзерлекле, тормышның һәм сәнгать-әдәбиятның күп тарафларыннан яхшы хәбәрдар, кыю, гадел һәм дөреслекне, кемнең кем булуына карамастан, ярып әйтүдән курыкмый торган гали зат булып кала бирә. Әдәби җәмәгатьчелек М. Юныс хезмәтләрен әлегә күрмәмешкә салыша. Шулай да мин XXI гасырга аяк баскач, әдәби кыйммәтләрне яңадан барлау үткәрелер, объектив-гадел бәяләр бирелер һәм бу әдипне иң олы классик язучылар рәтенә кертерләр, әсәрләрендәге эстетик-иҗтимагый хәзинәләрне бөртекләп өйрәнерләр дип ышанам.

Соңгы елларда гаять нәтиҗәле эшләп тә, иҗатының олылыгына туры килешле тирән, әтрафлы бәя алып житкермәгән өченче зур әдип диеп, һичшиксез, Әхсән Баянны күрсәтергә кирәк. Әлбәттә, язучының олы гомер биеклеген—юбилеен җәмәгатьчелек матур гына билгеләп узды. Тик бу юлы сүз ул турыда бармый, борчыган нәрсә шул—әлегә бу әдипнең эшчәнлеген интуитив, якынча һәм субъективрак бәяләүдән ары киткәнебез юк. Ә бит Әхсән Баянов—әдәбиятны һәм тормышны, чын сәнгать әһелләренә генә хас булганча, үзенчә, кителмәгәнчә, яңача аңлаучылардан. Ул әдәби чараларның гел яңаларын, моңа кадәр күпләргә билгеле булмаганнарын, таушалмаганнарын кулланырга ярата. Гомумән, бу әдипнең сәнгатьчә фикерләве башкаларның галәтләнелгән, күнегелгән фикерләвеннән ике-өч баскычка өстәрәк тора, алданрак йөри. Кая алай гына булсын! Хәтта махсус хәзерлекле әдәби тәнкыйть тә, үзенең исән һәм житез чагында да, бу ачышлар артыннан өлгерә алмады, еш кына искергән, консерватив үлчәмнәр-бәяләмәләр белән мавыгып, үзе дә ялгышлар җибәргәләде. Ә Әхсән Баянов иҗатындагы проза, лирика һәм драма күренешләренең үзенчәлекле үзара үрелеше, прозасындагы мәгънәле шигърият, әдәби детальләр һәм символларның функцияләре, әлегә башка бер язучыда да күренмәгән юмор бизәкләре, автобиографик жанр формасын үстерүгә керткән өлеше—болар һәркайсы тәфсилле өйрәнүне, аңлатуны сорый. Минә монысы гасыр азагындагы әдәбиятның без әлегә кадәр күреп, аңлап, бәяләп житкермәгән өченче энҗесе булды.

Әдәби эзләнүләр, ачышлар юлыннан нык атлап килүче прозаиклар турында сөйләгәндә Рафаэль Сибат исемен дә телгә алыйк. Аның «Исабәт» дип аталган романы соңгы елларның иң кызыклы ачышларыннан берсе булды. Инде шактый ук тәҗрибә туплаган бу әдип үз эзләнүләрен туктатмас, яңа, матур, мәгънәле әсәрләре белән гасыр бусагасыннан атлап керер дигән өметтә калабыз.

Олы әдипләрдән Әмирхан ага Еникинең «Кояш баер алдыннан» әсәре, Нурихан Фәттахның үзе генә белгән һәм тапкан юллагы махсус һәм максатчан эзләнүләре, мәрхүм Мөхәммәт Мәһдиевнең повестьлары һәм романнары тәмамланып килүче бу гасыр ахырындагы татар әдәбиятының иң гүзәл казанышлары дип аталырга хаклылар.

Соңгы 15 елда шулай ук Нәбирә Гыйматдинова, Мәгъсум Хуҗин кебек язучыларның үз иҗат йөзләре, стильләре, юнәлешләре ачыкланды һәм өр-яңа төсләр белән балкыды.

**2.** Туксанынчы еллар әдәбиятындагы иң уңай, күркәм күренешләр дип түбәндәгеләрне саныйм:

— ил, милләт, кешелек язмышы өчен борчылып яшәү гаме белән сугарылган әсәрләрнең дөньяга килүе;

— тирән эчтәлекле, мәгънәле, тыгыз фикерле әсәрләр язылу;

— яңа әдәби табышларга, ачышларга бай, мул хисле әсәрләрнең иҗат ителүе.

Мондый уңай сыйфатлар чагылган әсәрләрне анкетаның беренче пунктында исемнәре аталган әдипләр иҗат итте.

Ә ошап җитмәгән яклар: укучының зәвыгын үстермичә, киресенчә, минминлеккә, тупаслыкка, битарафлыкка, зәвыксызлыкка өйрәтә, чакыра торган яисә һәркемгә күптән мәгълүм булган гомуми әйберләрне зур ачыш рәвешендә купшы, ясалма фразалардан корамалаштырып әсәр дип тәкъдим итү. Мисалларын китереп тормыйм, кызганычка каршы, түбән зәвыклы, дөресрәге зәвыксыз әсәрләргә вакытлы матбугат, нәшриятлар бик зур урын бирәләр. Акчасын түләсәләр, һәр нәрсәне әдәбият дип атап, матбугатта бастыру заманасы килде. Бу—әлегә нәкъ менә туксанынчы елларга гына хас күренеш. Аңа кадәр гасыр дәвамында, мондый хәлнең күренгәне юк иде. Киләсе гасырда да ул булмасын иде.

**3.** Әдип җәмгыятьтә үзенә тиешле урын алсын өчен, ул, иң беренче нәүбәттә, үзе намуслы, гадел, иманлы булырга, үзем өчен дип түгел, ә халкым, милләтем, хаклык өчен дип эшләргә һәм яшәргә тиеш. Икейөзлелек, әдәбият мәйданын үз-үзенә карьера, реклама сыйфатында файдалану күренешләре алдагы гасырда юкка чыксын иде. Ә моңа, чын тәнкыйть үз урынына кайтарылмаса, ирешү бөтенләй мөмкин түгел.

---

## 1999 jьlnьꞑ ikence jartьsьnda cəcmə əsərlər

Ytkən jьlnьꞑ azaƣьnda həm bьjьl redaksiəbezgə jazucьlardan bajtaq cəcmə əsərlər kerde. Alarnьꞑ iꞑ jaxşьlarь inde bьjьl uq ƶurnal uqucьlarƣa təqdim itelə başladь. Jьlnьꞑ ikence jartьsьnda da uqucьlarьbьz həm surətləngən vaqiƣalarь, həm jazьlьşь belən gaçəjep qьzьqlь əsərlər belən tanьşa alacaqlar.

Jьl azaƣьna qədər **Nur Əxmədiefneꞑ** "Ambiraq jəki qara qajьn qajƣьsь", inde mərxym **Ənəs Ƣəliefneꞑ** "Cigengəndə", **Barlas Kamalnьꞑ** "Dəmber Danial", **Nurulla Ƣarifnьꞑ** "Məmeş Birde" povestləre, **Mansur Wəlineꞑ** "Məxəbbət maçaralarь"nьꞑ ikence kisəge belən tanьşьrlar dip əmet itəbez. Ə ajьruca zur kyləmle əsərlərdən **Kamil Kərimofnьꞑ** "Qom səƣəte", **Marat Əmirxanofnьꞑ** "Təqdir" romannarь təqdim iteləcək. Bolardan tьş ta redaksiə planьnda "Tatar xikəjələre xəzinəsennən" digən rubrikada jazucьlarьbьznьꞑ iꞑ jaxşь qьsqa kyləmle əsərləre, bygenge ədiplərneꞑ bajtaq xikəjələre bar.

Фатих Урманче

# БОРЫНГЫ МИФ ҺӘМ БҮГЕНГЕ ШИГЫРЬ

*Күренекле галим Фатих Урманче күптән түгел үзенең «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь» дигән зур фәнни эшен тәгәлләде. Унлап өлештән торган бу хезмәтнең баштагы ике бүлеген укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

## Беренче бүлек

Нибары берничә ел элек шигъриятнең асыл табигатен, дәрәжәсен билгеләү ярыйсы ук җиңел иде: әсәрнең актуальлеген, ул елларда язылганча, «социалистик реализм һәм коммунизм идеалларына җавап бирүен яисә бирмәвен» ачыклыйсың да, мәсьәлә хәл ителгән дип санала иде. Кызганычка каршы, шигърият, поэзия кебек нечкә күренешкә болай килүнең никадәр чикләнгән юл булуын бик күпләр аңламый, дөресрәге—аңлыйсылары да килми иде. Хәтта алай гына да түгел әле! Һәрбер әсәрне: шигырьме ул, поэмамы, әлеге таләпләр нигезендә бәяләү ифрат та уңайлы иде—һич тә уйланып, эзләнеп, тикшеренеп торасы юк. Әлеге катып калган тезисларның бер-икесен үзләштерәсең дә, конкрет әсәрне шул калыпка саласың: сыйса—яхшы, сыймаса—димәк, ул чын шигърият түгел.

Торгынлык елларын, без төрлечә хурлыйбыз, билгеле. Ләкин ул елларда безнең әдәбият белемендә Хатип Госман, Гали Халит, Ибраһим Нуруллин, Гази Кашшаф, Нил Юзиев кебек корифейлар әдәбият белеменең һәм әдәби тәнкыйтьнең төп мәсьәләләрен, төп авырлыгын үз җилкәләренә күтәреп, бу юнәлештә туктаусыз эшләп, әдәбиятны да, әдәби тәнкыйтьне дә кирәкле фәнни һәм иҗтимагый югарылыкта тоталар иде. Ни кызганыч, хәзер ул олы зыялыларның берсе дә юк. Күрәсең, чын әдәбият белемен дә, әдәби тәнкыйтьне дә алар үзләре белән алып китте.

Безнең көннәрдә әдәбият фәненнән, чын шигъriяттән ерак торган социалистик реализм кануннарының барысы да челпәрәмә килде, берсе дә калмады. Бәлки, шуңа күрәдер, әдәби тәнкыйть тә шактый сүрелеп, гомумән бетүгә йөз тотты. Моңа һич тә гаҗәпләнәсе юк. Социалистик реализм дип аталган аждаһаның төп үзенчәлеге дә шунда иде ки, ул акрынлап кешенең фәнни-теоретик фикерләү сәләтен юкка чыгара. Тәнкыйтьтә яки әдәбият белемендә эшләү мөмкинлеге калмагач, социалистик реализм һәм коммунизм рухында тәрбияләнгән һәм күзгә күренеп торган тәнкыйтьчеләрнең кайберсе публицистикага, икенчеләре прозага күчте.

Әдәбият белемендәге һәм әдәби тәнкыйтьтәге катлаулы күренешләр барыннан да элек җәмгыятьтәге зур тарихи процесслар белән бәйләнгән. Бер селтәнүдә элеккеге Советлар Союзының яртысы диярлек «кителеп төште». Дүрт ярым гасыр коточкыч колониаль империя булып яшәгән Русия колонияләрен югалта башлады. М. С. Горбачев әйтмешли, «процесс пошел!». Бик күп империяләрнең тарихы күрсәтүенчә, әгәр берәр империя үзенең таркалу чорына аяк басса, бу процесс котылгысыз рәвештә дәвам итә һәм ахырына житмичә туктамый. Заманында нинди көчле империя булса да, күрәсең, киләчәктә Русияне дә тарих өчен гадәти шул ук язмыш көтә.

Әлеге каршылыклы, киеренке процессларның төрле халыклар өчен уңай яклары да булды. Соңгы елларда казакъ, кыргыз, үзбәк, грузин, әрмән, бигрәк тә литва, латыш, эстон халыклары тулы мөстәкыйльлеккә ирештеләр. Әлегә Русия составында калган татар, башкорт, Кавказ халыклары да кайбер уңышлар яулап алды. Һәрхәлдә, билгеле бер дәрәҗәдә, сүз һәм вөҗдан ирегенә ирешелде.

Илдә барган ифрат та каршылыклы үзгәрешләр турында беренчеләрдән булып

шагыйрьләр язып чыкты. Әле кырыс торгынлык хөкем сөргән чорда, 1968 елда ук, олы буын шагыйрьләреннән Гамил Афзал, ул елларда катгый тыелган темаларның берсен алып, үзенең «Сөембикә сылу» дигән гаҗәеп матур шигъри легендасын иҗат иткән иде. Татар халкының тарихи фаҗигасен үзендә туплаган бу изге ханбикә исеме белән бәйле легенда шундый ук моңсу юллар белән тәмамлана:

Кайда күнел сынык,
Кайда күнел боек,
Сөембикә йөри
Моңлы бәет булып.

1979 елның 2 октябрендә (ә 2 октябрь Казан ханлыгы җимерелеп, татар халкы тарихының коточкыч фаҗигагә дучар ителгән көне!) язылган шигырендә Равил Фәйзуллин болай дигән иде:

Таш уала... Чәчри тамчы...
Империяләр таркала...
Шәһәр булып күтәрелә ком-балчыклар.
Агач тамырлары, тармакланып,
ерагая үзәгеннән...
Атлый Кеше яшәү-лабиринттан
үзенә генә язган юл белән...

## Мәсьәләнең асылы. Төп максат

Заманалар кырыс бер юнәлеш алган елларда татар әдәбияты, аеруча милли шигърият, үзенең йөзен югалтмады гына түгел, шактый зур һәм күзгә күренеп торган житди уңышларга да иреште, безнең әдәбият өчен бөтенләй яна күп кенә проблемалар күтәрде һәм аларны заманча хәл итте; шагыйрьләрнең теле баеды, матурайды, чын милли мөхиткә, милли рухка якынайды. Шуның белән бергә гомер-гомергә әдәбият галимнәрен һәм тәнкыйтьчеләрне борчып килгән гаять катлаулы бер сорау янадан калкып чыкты: ничек бәяләргә соң чын шигърият әсәрен, шигырь һәм поэмаларны, гомумән, бүгенге көн шигъриятен?

Бу сорауга җавап бирү өчен барыннан да элек, күрәсен, шагыйрьнең беренче шартлар белән чикләнмәгән шигъри осталыгын аңларга кирәктер. Алай дисәң, шунда ук: «Ә нәрсә соң ул шигъри осталык?» дигән зәһәр бер сорау калкып чыга. Аңа бер генә җөмлә белән: «Шигъри осталык—ул барыннан да элек Аллаһе Тәгалә тарафыннан мул итеп бирелгән илаһи талант!» дип кенә җавап бирергә мөмкин. Һәм бу, һичшиксез, дөрес булачак! Чөнки, әгәр чын талантың юк икән, шигъри осталыкка, илаһи бер дәрәҗәдә торган әсәр иҗат итү хасиятенә өйрәнеп булмый. Дөресен әйткәндә, моның кирәге дә юк! Чөнки аның нәтиҗәсе шагыйрьнең үзе өчен генә түгел, гомумән җәмгыять өчен дә бик тә кызганыч чыгачак!

Әмма шигъри осталыкка өйрәнеп булмаса да, аның үзен аңларга тырышу кирәктер. Чыннан да, нәрсә соң ул шигъри осталык? Аның төп атрибутлары нидән гыйбарәт? Иҗади тамырлары кайда?

Искәртелгәнчә, «үзгәртеп кору» дигән мәхшәр башланып, безнең «ватылган чор, җимерелгән заманга» килеп кушылу дәвамында бүгенге шигърият ифрат та җитди үзгәрешләр кичерде һәм кичерә. Шул ук вакытта шигъриятнең бик борынгыдан килгән һәм беркайчан да күләгәгә күчми торган тотрыклы сыйфатлары булуын да онытып булмый. Шуларның берсе, ә бәлки беренчеседер дә—халык иҗаты белән бәйләнеш.

Тик, конкрет әсәрләрне күзәтүгә күчкәнче, тагы берничә методологик мәсьәләгә тукталып үтәргә кирәк. Билгеле булганча, халык иҗаты һәм әдәбият багланышлары әлегә кадәр фольклор белгечләре тарафыннан өйрәнелми. Бу хакта күбрәк язучылар, шагыйрьләр, журналистлар яза һәм әйтергә кирәк, алар рухланып, илһамланып, еш кына хәтта шапырынып яза. Бу үзе—конкрет материалны рәтләп белмәү галәмәте! Икеләнмичә әйтергә мөмкин: хәзерге әдәбиятның халык иҗаты белән бәйләнеше хакында язучы шагыйрь, драматург, журналистларның күпчелеге фольклорның

табигатен, андагы сюжет кору закончалыкларын, бик борынгыдан килгән һәм безгә аңлашылып та җитмәгән шигъри үзенчәлекләрен белмиләр һәм белергә дә теләмиләр. Чөнки моның өчен дистәләгән еллар буе халык иҗатын, шул иҗат белән турыдан-туры бәйләнгән бик борынгы тарих, мифология, гореф-гадәтләр, караш-ышанулар белән нисбәтле бик күп чыганакларда казынырга кирәк. Шунсыз күтәрелгән мәсьәләне хәл итеп булмый.

Халык иҗаты һәм әдәбият бәйләнешләрен өйрәнүнең икенче һәм җиңел юлы— язма әдәбият әсәрләреннән мәкаль-әйтемнәр, такмак-такмазалар, җыр-бәетләр яисә аларның төсмерләре, кисәкчәләре «чүпләнеп алына» да, шул нигездә язма әдәбият әсәренең халык иҗаты белән бәйләнеше турында сөйләнелә. Мәсьәләне болай өйрәнүне гомумән кирәкми дип булмый. Әмма бу—әлеге катлаулы проблеманы өйрәнүнең беренче этабы, шактый җиңел һәм примитив юлы. Бу юлдан бару өчен махсус хәзерлек тә, озак эзләнүләр дә, тирән һәм киң эрудиция дә кирәкми. Димәк, чын мәгънәсендәге фәнни эзләнүләрдә бу юл белән генә чикләнеп булмый.

Сүз методология турында бара икән, мәсьәләнең тагы бер ягына игътибар итми мөмкин түгел. Мәгълүм ки, кешелек тарихының тәүге чорларында шигъри әсәрләр башта телдән иҗат ителеп, гасырлар, мең, ун мең еллар дәвамында халык күңелендә саклана. Димәк, шигъри сәнгать, шигъри осталык барыннан да элек халык иҗаты әсәре рәвешендә формалаша һәм бернечә мең ел буена халык телендә генә йөри. Поэзиянең барлык унай сыйфатлары, барлык атрибутлары барыннан да элек халык иҗатында формалаша. Борынгы Шәрекъ чыганаклары күрсәтүенчә, язма поэзиянең иң борынгы һәм тәүге үрнәкләре—ташка күчерелгән мифологик хикәятләр, төрле изге йолалар һәм тантаналы вакыйгалар белән бәйләнгән ритуаль гимннар, мәкаль-әйтемнәр, дастани-эпик формулалар, алла-алиһәләрнең, эпик каһарман дәрәҗәсенә күтәрелгән патша-фиргавеннәрнең, сугышчан яугирләрнең батырлыкларын җырлауга багышланган дастаннар, тарихи риваятьләр һәм легендалар һәм, ниһаять, бихисап дини догалар... Шулай булгач, халык иҗаты белән турыдан-туры бәйләнеш—чыннан да язма поэзиянең тәүге, иң борынгы һәм безнең көннәргә кадәр уңышлы дәвам итеп килгән б е р д ә н б е р һ ә м т о т р ы к л ы с ы й ф а т ы.

Мәгълүм ки, әдәбият белемендә тарихилык дигән принцип бар. Чөнки һәрбер чорның үз үзенчәлекләре, үз кануннары, үз таләпләре була. Телиме моны шагыйрь, юкмы—аның әсәрләре чор таләпләренә дә җавап бирергә тиеш. Моны һәрбер талантлы шагыйрь белә, аңлый, үзенең әсәрләрендә истән чыгармаска тырыша. Ә социалистик реализм дигән нәрсә әнә шул тарихилык принцибын актуальлек дигән икенче бер принцип белән алыштырып, әдәби әсәрләрнең, гомумән художество иҗатының җанын суырып алды. Нәтиҗәдә, коммунизмның бөек төзелешләре, Ленин-Сталин образлары, колхозлашу, илне индустрияләштерү һәм башка әллә нәрсәләр хакында сансыз күп шигырьләр, поэмалар барлыкка килде, басылып чыкты, халыкка таратылды. Алар гади укучының аңын томалады, бутады, әдәбиятны табигый юлдан аерып, тар марксизм-ленинизм кысаларына китереп кысты. Ягъни, ул милли әдәбиятның һәм сәнгатьнең иҗади үсешенә әйтеп бетергесез зур зыян салды. Бер көнлек таләпләр нигезендә иҗат ителгән сансыз күп шигырьләр, поэмалар барлыкка килде. Бүгенге көндә аларның иң зур күпчелеге әдәбият тарихыннан төшеп калу куркынычы астында тора.

Шул ук вакытта мәсьәләнең гаять тә җитди тагы бер ягын истән чыгарып булмый. Чын һәм һичшиксез талантлы, илаһи бер көч белән иҗат ителгән шигърият аерым бер чор таләпләреннән күп өстен тора. Аның көндәлек тормыш мәшәкатьләренә, бүгенге көн актуальлегенә артык «катнашы» булмый. Ул—әгәр шулай әйтеп булса, изге дога яки изге китап кебек мәңгелек. Бирелә бернинди арттыру юк. Дөнья әдәбияты тарихында бу—күптән танылган хакыйкать. Соңгы елларда ул безнең шигъриятkә дә тирән үтеп керә башлады. Моның конкрет бер дәлиле—безнең көннәрдә шигъриятkә Ислам тәгълиматы һәм Ислам мифологиясе зур һәм ифрат та көчле ташкын булып керде. Бу исә аерым шигырьләрдә генә түгел, китап исемнәрендә үк ачыктан-ачык күренеп тора. Мөдәррис Әгъләмов җыентыгы «Иман тәрәзә шакый» дип атала (Казан, 1996), Разил Вәлиев—«Сүзләрдән—дисбе» (Казан, 1996), Рәдиф Гаташ—«Бу—сиңа кылган догам» (Казан, 1997) һ. б. ш. Иҗатлары белән шушы ук фикерләрне Зөлфәт, Лена Шагыйрьҗан да яклап чыктылар. Харрас Әюп җыентыгының («Җәяүле буран», 1996) керешендә Зөлфәт болай яза: «Шагыйрь кичергәннәрне сезгә дә кичерергә язсын. Сүзем матур булсын өчен генә әйтүем түгел—Изге Коръән дә пәйгамбәребезгә шигырь булып иңгән ләбаса!»

Шул ук рухтагы фикерләр Равил Фәйзуллин шигырьләрендә дә аз түгел:

Булган Яшьлек, булган чын Ярату
һәм Янару булган һәрдаим.
Нәселемнен ни догасы өчен
бүләк иткән Сине Ходаем!

Хәер, соңгысы инде—махсус күзәтүне таләп иткән проблема. Әлегә әйтергә теләгәнебез шул: һәрбер даһи шигырь яки поэма—Вакыттан өстен, һич югы—Вакыт белән бер дәрәҗәдәге мәңгелек. Димәк, бүгенге шигъриятнең чын мәгънәсен, асыл табигатен аңлау өчен аны татар халык иҗатының һәм язма әдәбиятның Кол Галидән башлап, Мөхәммәдъяр, Кандалый, Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев иҗатлары аша Һади Такташ, Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәргә кадәр үткән юлын да истә тотарга кирәк. Бәлки, шул очракта әлеге тарихилык принцибы да сакланыр.

Билгеле булганча, борынгы фольклор белән бәйләнеш һәрбер талантлы язучы һәм шагыйрь иҗатында ифрат та тирәнгә яшеренгән. Бу бәйләнешләрне ачыклау өчен әһәмиятле һәм дәвамлы эзләнүләр, тикшеренүләр алып бару таләп ителә. Күп кенә әсәрләрнең, роман, повесть, поэма һәм шигырьләрнең, алардагы аерым персонажларның, образ, символ, янәшәлекләрнең халык иҗаты белән бәйләнгән булуын еш кына әлеге әсәрләрнең авторлары—язучы, шагыйрьләр үзләре дә белмиләр. Хәтта бу хакта уйланмыйлар да. Мондый очраклар (тулаем алганда—алар бик күп!) әдәбиятның бик борынгыдан килгән тотрыклы традицияләре белән бәйләнгән. Аларның барлыкка килеп, формалашуы бик борынгы чорларга карый һәм гадәттә ыруглык җәмгыяте мифологиясеннән килә.

... Күтәрелгән мәсьәләнең «эченә кереп киту» өчен, сүзне теоретик һәм методологик яссылыктан конкрет әсәрләргә күчерик. Сүз нигездә хәзерге татар шигъріяте турында барачак. Кемнән башларга соң сүзне?—дип тә аптырап торасы юк: Ренат Харис, Роберт Миннуллин, Зөлфәт, Харрас Әюп, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Әгъләмов, Рәдиф Гаташ... Саный башласаң, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзиевлардан соңрак үсеп чыккан, бүгенге көндә талантлары чәчәк ату дәрәҗәсенә күтәрелгән шагыйрьләр байтак кына.

Шулай да без конкрет сүзне, Наис Гамбәрнең һичшиксез объектив билгеләмәсенә таянып, «чорыбызның күренекле шагыйрьләреннән берсе булган Равил Фәйзуллин» шигъриятеннән башлар идек. Моның берничә житди сәбәбе бар. Мәгълүм ки, берәр мәсьәлә буенча фәнни фикер йөртү өчен, барыннан да элек конкрет материалның, чыганакларның мөмкин кадәр күп һәм тулы булуы таләп ителә. Бу яктан Равил Фәйзуллин поэзиясе—чыннан да иң кулай өлкә. Соңгы елларда, 1990 елдан соң гына да аның 8 китабы басылып чыккан. (Җәя эчендә генә булса да әйтеп үтик: безгә билгеле мәгълүматларга караганда, әлегә кадәр шагыйрьнең барысы 35 китабы дөнья күргән).

Равил Фәйзуллин китаплары арасында—шагыйрьнең зур күләмле, матбугатта ифрат та югары бәя алганы—дүрттомлык. Мөдәррис Әгъләмов сүзләре белән әйтсәк, «Аждаһалар аягүрә баскан» безнең көннәрдә дүрттомлык чыгару—һәръяктан унган затка, чын талант иясенә генә насыйп була торган бәхет!

Икенчедән, Равил Фәйзуллин иҗаты—хәзерге татар милли шигъриятенең аерылгысыз һәм иң житди өлешләреннән берсе. Өченчедән, басылып чыккан китаплары, аеруча әлеге дүрттомлык күрсәтүенчә, аның иҗаты хәзерге татар поэзиясенең ифрат та әһәмиятле үзенчәлекләрен чагылдыра. Равил Фәйзуллин иҗатын өйрәнү—бүгенге татар поэзиясенең асылын аңлау юнәлешендә житди адым ясау дигән сүз. Мәсьәлә шулай куелган икән, димәк, дүртенчедән, биредә сүз бер генә шагыйрь иҗаты турында бара алмый. Конкрет күзәткәндә, Равил Фәйзуллинның каләмдәшләреннән Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов һ. б.ның иҗатларына да мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк. Чөнки башкача бүгенге татар шигъриятенең милли асылын аңлап та, аңлатып та булмаячак. Саналган һәм саналмаган дистәләрчә шагыйрьләрнең әсәрләре белән танышканда, бигрәк тә аларны жентекләп, тырыша-тырыша, кат-кат укыганда, телисеңме моны-юкмы, үзеңне дә билгеле бер дәрәҗәдә шагыйрь һәм фикер иясе итеп сизә башлыйсың: синең дә халыкка, Җиһанга, Дөньяга нәрсәдер әйтәсең килә башлый...

Биредә тагы бер искәрмә кирәктер: укучылар игътибарына тәкъдим ителгән бу фәнни-популяр очерклар циклында сүз тик югары шигърият дәрәҗәсендә торган

классик әсәрләр турында гына барачак. Лена Шагыйрьҗан бик дөрес әйткәнчә, «шигырьнен әйбәт булмаска хакы юк!» Аннан соң безнең максат—бүгенге шигъриятькә бәя бирү түгел, ә бәлки, аны аңларга тырышып, борынгы һәм бик борынгы мифология, соңгырак чорларда оешкан фольклор белән бәйләнешләрен ачыклау. Димәк, урта кул әсәрләр игътибарга алынмаячак...

## «Җил тамырын кисәр кылыч юк!»

«Үзгәртеп кору» дигән чор башланып, «демократия» мәхшәренә килеп керүебездән соң да шактый Вакыт узып, өстебездән төрле Җилләр исеп үтте. Күрәсең, киләчәкнең нинди буласын күптән аңлаган Равил Фәйзуллин 1994 елда «Бу көн» дүртьюллыгында түбәндәгечә язды:

> Еланнар терелгән көн...
> Сират күперен чыкмый гына
> акчалыларга җәннәткә
> юллама бирелгән көн.

Нибары дүрт юл! Безнең көннәрнең гомуми күренеше! Бу хакта үз фикерен үтемле итеп әйтү өчен шагыйрь дөнья мифологиясенең иң популяр һәм серле, нигездә явызлык символы булган Елан, дөресрәге—еланнар, Ислам мифологиясеннән килгән һәм кешенең бу дөньядагы яшәү рәвешен һәм теге дөньядагы язмышын билгеләүче сират күпере белән җәннәт образларына мөрәҗәгать итә.

Мәгълүм ки, Җил дә, Вакыт та төрле халыклар мифологиясенең төп категорияләреннән. Алар бер-берсе белән тыгыз бәйләнгәннәр: Җил—Вакытсыз булмый; Вакыт—Җилсез булмый. Нәкъ шуңа күрә алар халыкара мифларның мәңгелек персонажларына әйләнгәннәр дә! Борынгы Шумерда, мәсәлән, безнең эрага кадәрге III меңъеллыкта ук Җир белән Күк арасын Лиль-Йил дип атаганнар. Димәк, Җир белән Күк арасындагы барлык җанлы һәм җансыз затлар, анда булган һәм буласы хәлләр-вакыйгалар, андагы яз—җәй—көз—кыш яисә көн һәм төн әнә шул Лиль-Йил сүзенә сыеп беткән.

Вакыт та, Җил дә—кулга тотып карап булмаган рухи һәм чын мәгънәсендәге тирән фәлсәфи-мифологик категорияләр. Төрле халыклар мифологиясендә Җил—искиткеч кодрәткә ия булган, дөресен әйткәндә, Алла дәрәҗәсендә торган илаһи җанлы бер зат буларак сурәтләнә. Татар халык иҗатында, бигрәк тә мәкальләрдә, ул шулай ук гәүдәләнә: «Җил исми яфрак селкенми», «Җил чәчсәң, давыл урырсың», «Җиле булгач, бураны булыр» һ. б. Ягъни, Җил ихтыярын кеше берничек тә үзенә буйсындыра алмый, шарты туры килсә, аннан качып кына котыла ала... һәм мондый карашларның барысы да борынгы, бик борынгы мифологиягә нигезләнә. Шушы мәгълүматларга караганда, Җил кайвакыт кешенең рухына һәм җанына тәңгәл бер категория буларак гәүдәләнә. Димәк, аерым очракларда ул шактый тыныч, хәтта битараф бер күренеш булырга мөмкин. Икенче бер мифларда Җил—дөньяны яратучы көч рәвешендә сурәтләнә. Борынгы Мисыр мифларында Һава һәм Җил алласы Шу—Күк белән Җирне барлыкка китерүче. Борынгы һинд мифларында сөйләнгәнчә, Җил—ул Брахманың сулышы, Дөньяны барлыкка китерүче һәм юкка чыгаручы көч. Антик Греция белән Рим мифлары буенча, Җил Җиһанның дүрт ягы, елның дүрт фасылы, төрле үсемлекләрнең үсүе яки корып кибүе белән бәйләнгән. Иудаизмда Яхвеның сулышы (Җил) дөньядагы барлык атрибутларның барлыкка килүен яисә юкка чыгуын оештыручы булып сурәтләнә. Кайбер халыклар мифологиясендә Җил коточкыч җимерү, юкка чыгару көченә ия. Ул Җир астында яши. Шул ук вакыт Җил нинди дер шатлык, яхшылык, бәхет символы да булырга мөмкин. Җил—Җиһандагы яктылыкны барлыкка китерүче. Тик шуны да әйтеп үтик: Җил, Һава ул—төрле фәрештәләр дә, Иблис, Шайтан, Җен-Пәриләр дә яши торган мохит.

Күренүенчә, Җил—Җиһанның аерылгысыз атрибуты. Мифологик персонаж буларак, ул бик күп төрле, еш кына капма-каршы вазифалар үти. Җил образы безнең хәзерге шигъриятта да шул ук сыйфатларга ия. Тик бер, ифрат та мөһим нәрсәне һәрвакыт истә тотарга кирәк: борынгы һәм бик борынгы мифологиядә сүз нигездә

Җиһан, Күк, Җир, кешелек һәм табигать дөньялары, аларның барлыкка килүе һәм юкка чыгуы кебек эре фәлсәфи-мифологик категорияләр турында барса, шигъриятьтә сүз барыннан да элек Дөньядагы Кеше язмышы хакында бара. Тик Җил өчен моның һич тә әһәмияте юк... Шулай да Равил Фәйзуллин шигъриятенә әле генә күрсәтелгән мифологик ноктадан якын килеп карыйк.

Барыннан да элек аның шигъриятендә Җил—шатлык, яз символы булып килә. Әйтик, «Язгы халәт» шигырендә:

Күктә күренеп алды сөйгәнемнең
зәңгәр яулыгы!
Килеп китте җилдә җир җиләге исе!
... Үзләренә бакмасам да,
шәүләләреннән күренә
яшь җаннарның яз теләгән дәртле көче.

Яз җиле белән бергә яшьләргә яңа мәхәббәт тә килә. Аны инде нәкъ менә шул яз җиле алып киләдер сыман:

Өметләндек: җырыбыздан
илләр куаныр диеп.
... Комга рәсемең ясадым—
җилләр юаныр инде!

Шул ук яз җиле—мәхәббәт—шатлык комплексы «Ачык тәрәзәле яз көне» (1963) шигырендә тормышның гүзәл бер мизгелен чагылдыра һәм аеруча тирән, чыннан да серле шигъри-мифологик мәгънә ала:

Җилфер-җилфер язгы җил искәндә,
Болыт булып очып китәр сыман,
туй күлмәге кебек ак пәрдә!

Зәңгәр күктә—Кояш тәхетендә
минем күзләр өчен пәйда булыр
фәрештәдәй
сылу
сын-гәүдәң...

Тирән, чиста һәм изге мәхәббәт хисләрен яктыртуда шагыйрьгә шифалы Җил образы еш кына ярдәмгә килә һәм шигырьнең төп мәгънәсен, матур яңгырашын тәэмин итүне «үз өстенә ала». Әйтик, «Көньяктагы рәсемең» (1989) шигырендә:

Утырасың диңгез буенда
тезләреңне кочаклап.
Дулкыннар көенә, яраткан
шигъри юллар кабатлап.
Чәчләреңне кояш ягына
иркәләп җил тараткан...

... Бәлки, шушы күренеш өчен
тәңре сине яраткан?

Биредә Җил билгеле бер дәрәҗәдә рәссам-скульптор буларак та гәүдәләнә. Шул ук фикер шагыйрьнең «Баю» (1978) шигырендә дә кабатлана сыман: «Җил ясаган бөек рәсемнәрне кыя-ташлардан күчерәм хәтеремә».

Кайвакыт Равил Фәйзуллин шигырьләрендә Җил битарафлык символы булып килсә, аның нинди дер моңсулыкка, күңелсезлеккә дәшүе дә сизелеп куя. Мәсәлән, «Көз—көз инде...»дә (1989):

Җилләр ни тарафка иссәләр дә,
Һаваларда ташкын—бер якка:
китә кошлар янә көньякка...

Гомумән, Җилнең моңсулык, күңелсезлек символы булып килүе халык

жырларында да, безнең хәзерге шигърияттә дә шактый киң таралган күренеш. Равил Фәйзуллин шигъриятендә дә бу шулай. Исеменнән үк күренеп торганча, «Ишеттем мин бер борынгы карттан...» (1979) шигырендә, мәсәлән:

«Ташулардан—талга эленеп калган
иясез бер яулык шикелле,
калдым кибеп
Дөнья куагында...

Үтте гомер талгын җил белән!»

«Җилгә каршы түкермә, битеңә төшәр» дигәндәй, кайчагында Җил кеше язмышын кире якка борып куярга да мөмкин... Бер дүртьюллыгында шагыйрь «Үпкән-кочкан—җилгә очкан...» дигән эпиграф бирә. Карап торсаң, чынлыкта мәсьәлә бөтенләй башкача хәл ителә икән:

Очуын очкандыр да...
тик җилләр кире китереп
янә бәгъремә сипкән!
Хәтеремә янә чиккән.

Шагыйрь әсәрләрендә, мәсәлән, «Бер күзәтү» дүртьюллыгында, Җил-язмыш фәлсәфәсе дә чагылып китә:

Таяну кыен ятим үскәнгә,—
сынаган бар яшен-картын да:
җил кая иссә—ул шул якка ава,
кайда жылы—шуна тартыла...

Равил Фәйзуллинның аерым шигырьләрендә Җил—искиткеч кодрәт көченә ия булып, билгеле бер мәгънәдә мәҗүси алла дәрәҗәсенә күтәрелә:

Җилне җигеп буладыр да,
тик Илне җинеп булмый!..

«Туктармы?» (1983) шигырендә мондый фикер уздырыла:

Җил исүеннән туктармы,
җилкән корганга карап?
Чирәм үсүдән туктармы,
очын кырганга карап?

Су—хәрәкәттән туктармы,
буып куйганга карап?
Адәм көрәштән туктармы
иреген тыйганга карап?..

Тулысынча сорау җөмләләреннән торган бу шигырь Җилнең төп сыйфатларын атап үтүдән башланып, чирәмгә, суга күчә һәм кыю адәм баласының иң әһәмиятле үзенчәлекләреннән берсен күрсәтү белән тәмамлана. Шигырьнең эмоциональ яңгырашы, искән Җил көче кебек, көчәйгәннән-көчәя бара һәм әсәрнең ахырында иң югары ноктага күтәрелеп, туктый.

Шулай да Җилнең иң җитди сыйфаты—аның бер нәрсә белән дә чикләнмәгән җимерү көче. Нәкъ шуңа күрә шагыйрь әсәрләрендә еш кына Җил—фаҗига янәшәлеге барлыкка килә. Әйтик, «Гомеремнең кырыгында» (1982) шигырендә:

Җәйге урман кебек.
Рәхәт! Рәхәт!!
Һәм ямансу.

... Тиздән җилләр
ала башлар
яшәү төсен...

Биредә әле бернинди дә фаҗига юк. Ул якында гына—читән артында тора кебек. «Урылган кыр уртасында...» (1983) шигырендә дә шул ук хәл:

Ямансу кыр уртасында
бер сабак солы калган.
Игенченең хезмәтеннән
сынар уч җылы калган.
Җилләр хөкеменә җәйнең
бер нәни сыны калган...

Шуңа якын хисләр шагыйрьнең «Туган як дигәндә...» (1977) алтыюллыгында да чагы-лып китә: «Искә төшә: Тегермәнлек үрен менгән чакта мәңге җилдә калган каеннар...»

Тик җилгә якынрак килгән саен аның җимерү көче арта. Фаҗига чыннан да якынлаша сыман. Мәсәлән, «Биеклектә» (1976) шигырендә:

Кыя—текә. Җилләр йолка,
кузгала таш... Кая басыйм?
Колакта өн: менгәнсеңме—
«Егылам!»...—дип,
ярдәм сорап кычкырма син!..

Димәк, Җил—фаҗига, Җил—үлем янәшәлекләре дә әледән-әле үзләрен сиздереп торалар. Моңсулык, узган гомер фәлсәфәсе, котылгысыз үлемнең янәшә торуы «Оя» (1979) шигырендә аеруча ачык яңгырый:

Агач башына корсам—
җил тузгытыр оямны.
Җирдә корсам—җәнлек-җанвар
харап итәр дөньямны...
Канатлар җилгә тарта.
Тәпиләр җиргә тарта.
Җанда борчылу арта...

Шуңа якын фаҗига фәлсәфәсен шагыйрьнең «Әле...» дүртьюллыгында да күрергә мөмкин:

Төз сыннарны безнең сыгылдырыр
җилләр йөри булыр бик ерак!
Әле үлән булып үсеп тора
беркөн тәнне басар туфрак...

Әмма Равил Фәйзуллинның әлеге мәсьәләгә багышланган иң көчле, тирән фәлсәфи-мифологик эчтәлеккә ия булган шигыре «Җил—Вакыт ул...» дип атала (1963). Ул—югарыда әйтелгән фикерләрнең барысын да раслап тора:

Җилләр шатлык алып киләләр.
Җилләр картлык алып киләләр.
Җилләр диннәр алып киләләр.
Җилләр чирләр алып киләләр...
Җилләр алар шундый: теләсәләр—
әллә ниләр алып киләләр!
Җил—Вакыт ул, белми тынычлык!
Җил тамырын кисәр кылыч юк!

## «Вакыт кына мәңге тантанада»

Китерелгән шигырьдәге «Җил—Вакыт ул» гыйбарәсе тирән фәлсәфи-мифологик мәгънәгә ия. Чөнки, Вакыт та төрле халыклар мифологиясенең төп категорияләреннән. Гадәттә ул табигать (кыш—яз—җәй—көз) һәм гомер (туу—яшәү—үлем) дип, төрле «кисәкләр»гә бүленә. Халык мифологиясендә Вакытның уңай һәм тискәре сыйфатлары булырга мөмкин. Яхшы Вакыт—тормыш, начар Вакыт—үлем белән бәйләнгән. Аерым очракларда Вакыт кеше өчен бик куркыныч бер категориягә әйләнә. Равил Фәйзуллин гыйбарәсенә мөрәҗәгать итсәк, мәңгелек «Вакыт эчендәге Вакыт»ның кеше өчен иң афәтле, фаҗигале мизгелләре төн уртасыннан таң атканчыга яки кыш уртасыннан (21 декабрьдән) яз башланганчыга (21 мартка—Нәүрүзгә) кадәр дәвам иткән Вакыт. Вакытның төп сыйфаты һәм аның уңай, тискәре якларга үзгәрүе дә галимнәр әйтүенчә, табигать һәм кеше тормышындагы кискен, хәлиткеч үзгәрешләр чигенә туры килә.

Вакытның күрсәтелгән фәлсәфи-мифологик сыйфатлары безнең халык

мәкальләрендә дә билгеле бер чагылыш таба: «Вакыт акча түгел, югалтсаң—таба алмассың», «Вакыт комны ташка, ташны комга әйләндерә», «Вакытның дилбегәсе юк», «Вакытың үтте—бәхетең китте».

Равил Фәйзуллин Вакытның тирән фәлсәфи-мифологик мәгънәсен бик яхшы аңлый һәм бу мәсьәләгә аеруча игътибарлы. Күрәсең, шуның белән бәйле рәвештәдер, аның шигырьләрендә Вакытның бик күп фәлсәфи-мифологик үзенчәлекләре чагылыш таба. «Теләсәң нишлә» дүртьюллыгында, мәсәлән, сүз битараф Вакыт турында бара:

Җир чәчәкле. Җилләр талгын.
Күкләр аяз. Кемнәргәдер дөнья—иртә яз.
Теләсәң нишлә: көл, ела язга карап.
Вакытка барыбер, ул—битараф.

Бу очракта махсус әйтеп үтик: битараф Вакыт талгын Җил белән бергә йөри... Тик шулай да Вакыт бик сирәк очракларда гына битараф була. Түбәндәге дүртьюллык нәкъ әнә шул хакта сөйли. Бу шигырьдә Вакыт—тарих категориясе алгы планга чыга:

Тиз чигәбез телдән, тарихтан...
Чүккәнбез Бүгеннең тәхетенә...
Вакытның хәтере шәп аның!—
бик тиз онытырлар безне дә...

Мифология һәм мәкальләрдәге кебек, Вакытның кадерен белү, аны һичшиксез ихтирам итү, аңа буйсыну—Равил Фәйзуллин шигъриятенең төп сыйфатларыннан берсе:

Без дә бу дөньяда кунак кына...
Ә кунак рәхәттә яшәргә тиешле!
Тик шунсы бар: Вакыт-чаманны бел! Җирдә
артык булып әрсез яшәү һич килешми!

Шагыйрь тарафыннан 1990 елда язылган алтыюллыкта да шул ук фикер уздырыла кебек:

Кирәктер карау да
таулардан—талларга.
Вакыттыр җандагы
дәрманны барларга.

Вакыт шундый зур, илаһи көчкә ия икән, аны җиңеп буламы соң? Әйе, була!—дип җавап бирә Равил Фәйзуллин. Әмма моның өчен нык ихтыяр көче, даими тырышлык, үз халкына чиксез бирелгәнлек кирәк. Тик шул очракта гына тарихи шәхес Вакыт эчендәге Вакыт киртәләрен ватып, үзенең исемен халык күңелендә мәңгеләштерә ала, Вакыт кысаларын җиңеп чыга. Безнең халыкта андыйларның саны аз түгел. Нәкый Исәнбәткә багышланган сигезьюллыгында шагыйрь әнә шул хакта сөйли:

Яу-дауларны күргәннәр күп,
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп,
Вакыт-яу—иң-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны!

Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
шанлы исемен алып кала.

Күрүебезчә, үзләренең шигъри-эстетик һәм фәлсәфи-мифологик вазифалары ягыннан Җил һәм Вакыт категорияләре бер-берсенә ярыйсы ук якын торалар. Җил кебек үк, аерым очракларда Вакыт та якынаеп килгән фаҗига символы булырга мөмкин. Әйтик, «Гомеремнең җәйге ягында» шигыренең түбәндәге юлларында:

Ник вакытсыз, Язмыш,
ташлыйсың җаңга
Мәхәббәтнең утлы канатын?

Шагыйрьнең 1972 елда язылган бер әсәрендә шул ук хис-фикер тагы да көчлерәк, тәэсирлерәк яңгырый:

Бер вакыты житкәч кай җирдә дә
пәрәвәз җепләрен җил өзә.
Әй авыр, кайтмаска киткәнгә—
«Озак йөрмә, тиз кайт!»—дип кул изәү...

Аерым очракларда, борынгы мифологик карашларны турыдан-туры кабатлангандай, шагыйрь В а к ы т - А л л а тәгъбирен кулланудан да баш тартмый. Айдар Хәлимгә багышланган бер сигезьюллыгында (1968), мәсәлән:

«Бу юлларны сагынырбыз әле!
Тик кайтылмас бүтән менә...»
Әйе, сагынырбыз. Вакыт—Алла.
Ә без бары кеше генә...

Шуна якын фикер шагыйрьнең 1985 елда язган бер шигырендә дә бар:

Вакыт өчен нәрсә Адәм гаме!
Һәр үзгәреш аңа—дәреслек!
Гаҗәепмени Атлантида хәлен
аңлый алмый икән Эверест...

Әмма ни генә әйтсәк тә, Вакыт—бик борынгыдан килгән ифрат та катлаулы фәлсәфи-мифологик категория. Аның төп сыйфаты: Вакыт ул—мәңгелек. Димәк, аңа бу Җиһанның барлык атрибутлары сыеп бетә, шатлык, бәхет кенә түгел, кайгы-хәсрәт тә, бихисап фаҗигаләр дә. Чын шагыйрь-философ буларак Равил Фәйзуллин мәсьәләнең бу кырыс ягын да читләтеп үтми, төгәлрәк әйткәндә, аңа кат-кат мөрәҗәгать итә. Әйтик, шагыйрьнең түбәндәге бишьюллыгында үлем турында сүз дә юк кебек:

Орден-медальләргә, «йолдыз»ларга
сау тән кирәк! Таза күкрәк!..
Колакларны иркәләтеп чыңлар өчен
Вакыт кирәк
бәрхет мендәрләргә күчкәнче...

Орден-медальләр бәрхет мендәрләргә тик кеше үлгәч кенә күчә. Моны һәркем белә. Димәк, шигырьдә сүз һичшиксез үлем турында бара. Ә инде шагыйрьнең «Эх...» (1979) сигезьюллыгында сүз турыдан-туры үлемгә күчә:

Эх, бу Вакыт! Җирдә катлам булып,
һәрбер буын яңа гөл булыр...
Без китәрбез. Язмыш көчендә:
нинди үлем килсә—шул булыр...

Вакытның фаҗигале роле «Син әлегә яшьрәк бит!..» (1995) шигырендә дә ачыктан-ачык күренеп тора:

Күзгә кара төндә тамды күз яшем.
Нидән тамды?
(Ак кәгазьдә йолдыз чагылды).
Искә алдыммы—
Вакыт—беләк-чукмар булып
тетеп, сытып киткән Гомерне?

Шулай да шагыйрь Вакытны тирән мәгънәгә ия булган фәлсәфи категория дип ешрак кабул итә һәм аның күп төрле вазифаларын күрсәтеп үтә. Бу очракта мисалга «Вакыт» (1958) шигырен алырга мөмкин:

Алай үтелгән вакыт...
Болай үтелгән вакыт...

Яшәп үтелгән вакыт,
яшьнәп үтелгән вакыт—
бүтәннәр бәхете өчен
сарыф ителгән вакыт!

Дөньяда төрле вакыйгалар, хәлләр, шатлыклар, фаҗигаләр булырга мөмкин. Тик Вакыт кына беркайчан да үзгәрми. Шагыйрьнең берьюллык шигырендә әйтелгәнчә, «Вакыт кына мәңге тантанада». Димәк, ул—изге Вакыт безнең хәзерге язмышның да кодрәтле хуҗасы. Хәзерге барлык фаҗигаләр ахыр чиктә шул ук

Вакыт—Чор—Заман кодрәтеннән килә... Илдә башланган коточкыч вакыйгалар уңаеннан 1993 елның 18 сентябрендә Равил Фәйзуллин үзенең иң көчле шигырьләреннән берсен язып, безнең—илнең—халыкның йөрәкләрен туктаусыз әрнетеп торган бик күп сорауларга җавап биргән иде:

Көтмәдекме безне баскан
басымның басылуын?
Җанга, рухка, һәр фикергә
юлларның ачылуын?

Әйе, бу юлларда татар халкының дүрт ярым гасырга сузылган фаҗигасе, михнәте, хәсрәте, моң-сагышы, шул ук вакытта якты хыяллары, зур өметләре чагыла. Өзекнең эмоциональ яңгырашында да шул ук нәрсә сизелә: беренче ике юлда гына да б а с ижегенең өч тапкыр кулланылуы, *б, д, т* тартыкларының кат-кат кабатлануы шул ук б а с ы п  б е т е р е р г ә интегү галәмәтен чагылдыра булса кирәк. Берара «әлеге якты өметләр тормышка ашамы икәнни?»—дигән өметсез һәм иләмсез зур сорау да калка:

Көттек. Көттек... Ниһаять,
күзләр шәрран ачылды.
Күз алмасына шәп-шәрә
чынбарлык кереп тулды.

Ак каен да, яфрак коеп, шәрә калгач, җәйге гүзәллеген югалта. Чәчәк, үлән, яфрак корыгач, көзге кара җир дә! Адәм баласы турында инде әйтеп тә торасы юк! Шигырьдә дә бит сүз Вакыт, Чор, Заман кебек тирән фәлсәфи-мифологик категорияләр турында бара! Еллар-гасырлар дәвамында шапырынкы, купшы, асылда мәгънәсез сүз-җөмләләр белән аннан-моннан капланып, ябылып торган гайре табигый чынбарлыкның бер чите генә ялангач калгач та, «күзләр шәрран» ачыла, әлбәттә:

Империя коллыгында
гел күнеккәч искегә,
«Демократия»сеннән дә
юылмаган ис килә.

Төрле халыкларның бик борынгы мифларыннан билгеле булганча, кайчандыр Җиһанда гомуми тәртипсезлек—тәүге хаос хөкем сөргән. Әле Ай, Кояш, Йолдызлар да, Җир, Кеше һ. б.да булмаган: Җиһанда бернинди калыпка сыймаган, канунга буйсынмаган Җил һәм Вакыт, Су һәм Һава гына булган... Русиядәге бүгенге хәлләр әнә шул тәүге хаос чорын хәтерләтә:

Әче төтене заманның
күзләрне ачыттыра!
Яхшыга да, Яманга да
капкалар ачык тора.

Без яшәгән чор үзенчәлекләрен, дөресрәге—каршылыкларын кырыс, кискен сүзләр белән сөйләп чыкканнан соң шагыйрь үз шигъриятенең төп төшенчәләреннән берсе булган Вакыт категориясенә әйләнеп кайта һәм тирән мәгънәле йомгак ясый:

Ә Вакыт ашыктыра...

Бу тәгъбирнең чын мәгънәсен аңлау өчен Равил Фәйзуллинның бөтен иҗатын, әнә шул күзлектән карап бүгенге татар поэзиясен җентекләп өйрәнеп чыгарга кирәк. Әлегә без бу эшкә керешәбез генә...

Сиксәненче еллар уртасында башланган үзгәртеп корунын бернинди уңай ягы булмады дип раслау дөреслеккә туры килмәс иде, әлбәттә. Әлеге хәрәкәтнең иң зур һәм мөһим казанышы ул—барыннан да элек, сүз һәм вөҗдан иреге. Бу исә әдәбиятның үсешенә һичшиксез уңай йогынты ясады. Ул әле дә дәвам итә. Язучылар һәм шагыйрьләр совет чорында катгый тыелган темаларга иркенләп мөрәҗәгать итә башладылар. Шуның уңай нәтиҗәсе буларак хәзерге әдәбиятка зур һәм көчле ташкын булып, түбәндәге проблемалар килеп керде. 1. Татар халкы, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыклары тарихы. Бигрәк тә татар халкының урыс колониаль державасы тарафыннан яулап алынгач күргән фаҗигаләре. 2. Татар ханнары, ханбикәләре, милли батырлары—Сафа

Гәрәй, Сөембикә, Нурсолтан, Идегәй, Чура батыр һ. б. 3. Дүрт ярым гасыр дәвам иткән көчләп чукындыру һәм аның корбаннары. 4. Колониаль сәясәтнең совет чорында тагын да әшәкерәк формаларда дәвам итүе. 5. Дини тәгълиматның һәм Ислам мифологиясенең янадан торгызылуы. 6. Бүгенге көннәр мәхшәре: матди һәм рухи хәерчелек, җинаятьчелек, фәхишәлек.

Илдә хөкем сөргән гаделсезлек, байларның, бигрәк тә дәүләт чиновникларының череп баюы, ярлыларның хәерчеләнүе турында ләм-мим сүз әйтергә ярамый иде бездә. Чөнки Советлар илендә барысы да ал да гөл булырга тиеш иде... Хәзер исә барысы турында да язарга мөмкин шикелле.

Зур һәм катлаулы проблемаларның әдәбиятка, бигрәк тә бүгенге шигърияткә килеп керүе аның диапозонын киңәйтте, проблематикасын һәм ышандыру көчен арттырды, конфликтларын да соң дәрәҗәдә кискенләштерде. Хәзерге татар шигъриятендә әлеге проблемаларның чагылышы турында махсус очерклар да язып булыр иде. Бәлки, киләчәктә алары да языла. Әлегә исә, очеркның исеме таләп иткәнчә, шушы мәсьәләләрнең Равил Фәйзуллин иҗатында чагылышына тагын бер күз йөгертеп чыгыйк.

Аның «Казан алды» (1991) шигыре игътибарга лаек. Ул Казан ханлыгының һәм Казанның коточкыч тарихи фаҗига корбаны булуы, тик шуңа карамастан татар халкының милли азатлык өчен көрәшкә янадан күтәрелүе хакында болай яза:

Теге чакта, Казан аугач,
дошман әйткәндер: «Бетте!..»
... Таш ярып гөлләр шикелле
яшь буын үсеп чыгасын
шәһитләр белми китте...

«Айну, яки тарихи махмыр» (1994) шигырендә шул ук Вакыт, шул ук Тарих һәм Заман проблемалары күтәрелә:

Кайта татарлар, кайталар
ата-баба җиренә.
Күзләрендә өмет булса,
хәсрәтләре иңендә.

Колониаль держава хакимлеге татар халкына санап бетергесез фаҗигаләр алып килгән: аларны туган җирләреннән «җәһәннәмгә куганнар», чиркәүләр халыкны көчләп чукындыру белән берөзлексез шөгыльләнгән:

... Җирләр киткән. Геннар кипкән.
Боз утырган бәгырьгә.
Тик илбасар «дуслыгы» да
түгел икән мәңгегә!

Баскынчылар күпме генә тырышсалар да, халыкның ифрат та тирәнгә яшеренгән гүзәл сыйфатларын юкка чыгара алмаганнар:

«Малым түгел, гомрем әрәм,
читтә үткән—яшьлек җәл!
Калган нәселемә килсен
Туган җиремдә әҗәл!»

Ватылган чор, җимерелгән заман—безнең көннәр мәхшәре турында шагыйрь еш һәм күп яза. «Әлмәттә» җир тетрәү! (1989) әсәрендә ул әлеге вакыйганың сәбәбен ачыкламакчы була һәм изге Җирнең тынычсызлануын түбәндәгечә аңлата. Җир таланган, көчләнгән, чирле булып калган, өсте шешә ватыклары белән капланган, чишмәләр тозда эреп, дегетләнеп беткән, тәненә меңәрләгән скважиналар үткән, өстендә үскән иген исә ярымагу булган...

буыннар вагая барып
зәгыйфь алмаш тусын да,
бакый гомер туган җырлар
капылт онытылсын да,
шушы мәхшәрләрне данлап

кемдер язып торсын да...—
бер тетрәп куярсын шул!

Илдәге мәхшәр шагыйрьне һәрвакыт борчый, уйландыра. 1994 елда язылган бер шигыренең эпиграфы итеп ул С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» сүзләрен ала. Шуна җавап рәвешендә болай ди:

Мин бүген сөйләшмим әле,
уйлана торган көнем.
Белмим бит нигә әйләнер
Илем, Телем һәм Динем...

Ниһаять, Равил Фәйзуллинның Заман мәхшәре сурәтләнгән һәм көчле сарказм белән сугарылган «Белая горячка» (1995) шигыренә тукталып үтик:

— Без яшибез, без яшибез
самый Бәхет илендә!
Типтереп калыйк әле
ике «дәүләт» телендә!

Акыл, диләр,—көчтә!
Тозлы кыяр—өстә!
Дәүләтчелек—төштә!
Кануннар—аста...
Селәгәй малайлар
менеп басты башка!

Ифрат та үзенчәлекле, аерым юллары төрле-төрле шигъри үлчәмдә язылган бу әсәр тулаем алганда гаять көчле сәяси сатира булып янгырый:

Суырылган теш хәлендә карт-коры ветераннар.
Ясалып бетмәгән ясалма дебиль балалар.
Ә сауларын... «кайнар нокталар»га салалар!

Руханилар ботарлаша берсен-берсе
(Мәккә ташы—«Лобное место» түгел дә бит...)

Хәерченең калтыранган сул кулында—тиен акча,
уң кулында—шәфәкъ нуры...

Әнә шундый коточкыч мәхшәрдә калган гади халык, бигрәк тә яшьләр арасында битарафлык, җинаятьчелек, эчкечелек тамыр җәя:

«Уятмакчы булсаң халык күңелләрен»—
барып кайт син Салмач ягына...

Илдәге шундый шартлар үзләреннән-үзләре барлыкка килми, әлбәттә. Бик борынгы мифологиядәге «тәүге хаос» бүген кемнәр өчендер кирәк, файдалы. Әлегә очы-кырые күренмәгән мәхшәр барыннан да элек өстен, хаким даирәләр өчен кирәк. Кирәк кенә түгел, бик тә файдалы! Шагыйрь дә моны яхшы аңлый:

Яшь Тукайлар!
Тамагыгыз туяр иде—хет башкортча иҗат итсәгез!
.....................................................................
Җиңү бәйрәмнәрен үткәрәбез! «Җиңелгәннәр» акча бирсәләр...
.....................................................................
Урак-чүкеч берлегендә хәзер урак кына һаман ура шул...
.....................................................................
Ике-өч катлы коттеджлар витражында—
юксылларның, сабыйларның күз яшьләре...

Дөрес, Равил Фәйзуллинның кайбер шигырьләрендә өмет чаткылары да бар. Әйтик, «Борчылуда туган ышаныч» (1987):

Бүген без дә—үзгәрештә,
Янарышта һәр күңел!
Гасыр ахыры булса да,
Заман ахыры түгел!

Бу сүзләр моннан ун ел элек язылган. Ниндидер өметләр бар кебек чагында... Әмма мәрхәмәтсез Вакыт—ун ел—әлеге өметләрнең барысын да йотты. Без ватылган Чор, җимерелгән Заман дәверенә килеп кердек. Өстән, астан һәм тирә яктан тик рәхимсез Җилләр генә исә... Ә Вакыт мәңге тантанада!..

# ХАЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

Татар халкының гасырлардан килгән моңы, җыр культурасы бар. Аларны күңелләргә кереп калырдай итеп башкарып, саклап, буыннан-буынга тапшырып килгән талантлы җырчылары да бик күп. Гасыр башыннан алып, иң күренеклеләрен генә санаганда да, алар берничә дистәгә җитә: Камил Мотыйгый, Бабаҗан, Фатыйма Гомәрова, Фәттах Латыйпов, Асия Измайлова, Гөлсем Сөләйманова, Фәхри Насретдинов, Усман Әлмиев, Азат Аббасов, Сөләйман Йосыпов, Фәридә Кудашева, Әлфия Авзалова, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров вә гайре, вә гайреләр. Әлбәттә, бу исемлекне алга таба тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Шушы күренекле җырчыларыбыз йолдызлыгында Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Хәйдәр Бигичев үзенең кабатланмас тавышы, үзәк өзгеч моңы, йөрәктән чыккан җырлары белән иң кадерле урыннарның берсен тота. Аның иҗаты гаҗәеп күпкырлы.

Бездә җырчыларны, гадәттә, опера һәм халыкчан (эстрада) төрләргә бүлеп йөртәләр. Теоретик планда нигезләнмәсә дә, мөгаен, бу бүленеш яшәргә хаклыдыр. Чөнки башкаручылар иҗатында әлеге юнәлешләрнең йә беренчесе, йә икенчесе өстенлек ала. Әйтик, күп очракта опера җырчылары халык җырларын башкарырга алынмаска тырышалар. Һәм, киресенчә, эстрада җырчылары опера сәнгатенең катлаулы арияләренә беркайчан да диярлек мөрәҗәгать итмиләр. Хәйдәр Бигичев исә җыр сәнгатенең әнә шул ике юнәлешен дә бертигез осталык белән инләп, Опера театрында да, эстрада сәхнәләрендә дә бердәй зур уңыш казанган, сирәк очрый торган зур талантларның берсе иде.

Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай үзенең «Халык әдәбияты» дигән хезмәтендә милли көйләрне башкарган чакта тавышның йомшак булуы, бераз уен коралы авазына охшашлыгы, иреннәрнең мөмкин кадәр аз, каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачылып, мыек астыннан гына җырланырга тиешлегенә игътибар итә. Шул рәвешле җырлаганда гына гасырлар төпкеленнән килгән милли көйләребезнең моңы тыңлаучыларга югалмыйча килеп җитәр дип уйлый ул.

Әйе, XX йөз башында эстрада сәнгате тар, кысан сәхнәләрдә, берничә дистә тамашачы сыярлык кечкенә генә залларда әле туып кына килгән, профессиональ белем алган җырчыларыбызның бөтенләй диярлек булмаган бер чорында язылган бу фикерләр шул заман зыялыларының зәвык таләпләрен чагылдыра.

Бүген инде башкаручылар алдына куела торган бурычлар шактый үзгәрде. Хәйдәр Бигичев классик опера партияләрен дә, халык җырларының тетрәндергеч моңнарын да киң күкрәк, тулы сулыш, көчле, сыгылма тавыш белән тамашачыга җиткерә ала торган, үз иҗатында халыкчан башкару традицияләрен дөнья вокал сәнгатенә нигезләнгән Италия бельканто мәктәбе алымнары белән тулыландырган, баеткан, киң диапазонлы җырчы иде.

Горький (хәзер Түбән Новгород) өлкәсе Краснооктябрьск районындагы Чүмбәле авылы колхозчылары Габбас ага һәм Рәшидә апа гаиләсендә 1949 елның 16 июнендә дөньяга килә Хәйдәр. Гаиләдә җыр-музыка даими яңгырап торса да, кечкенәдән музыка сәнгате, иҗат дөньясы турында хыялланып үсми ул. Авылдагы дистәләрчә яшьтәшләре кебек үк, бик иртә әтисенең кул арасына керә башлый. Урта мәктәптә укыган елларында ук комбайнчы Габбас аганың алмашчысы булып эшли, йорттагы бетмәс-төкәнмәс эшләрне башкара: утын кисә, су китерә, мал-туар карый. Ә җыр?.. Әлегә җыр күңелнең иң ерак почмакларына яшеренгән. Бары тик хисләрнең иң кайнаган, сабыр савытының чайкалган чакларында гына дөньяга бөреп чыга ул. Күңеле гаять күтәренке булып, йортта берьялгызы калганда, туган якның гаҗәеп гүзәл

кырларын, болын-урманнарын гизеп, табигать матурлыгыннан йөрәк ташыганда. Гаиләдә, мәктәптә, авылда, әлбәттә, аның жырлаганын беләләр. Алай гына да түгел, өйгә кунак килгәндә, мәктәп кичәләрендә, жыен-сабантуйларда сорап жырлаталар. Башкаручы буларак Хәйдәр яшьтән үк халкыбызның «озын көй» дип аталган жырларына тартыла. Шуңа күрә дә татарның кайгы-хәсрәт, моң-сагышын чагылдырган «Туган тел», «Кара урман», «Тәфтиләү» кебек жырлары аның



башкаруында аеруча еш, отышлы яңгырыйлар.

Профессиональ сәнгатькяр булу теләге Хәйдәрдә, бәлки, кыска гына вакыт дәвамында «Москонцерт»ның Сөнгать Жәләлетдинов житәкләгән бригадасында, авырып киткән жырчыны алыштырып, район авылларында концертлар биреп йөргән вакытта туа башлагандыр. Кинәттән килеп чыккан әлеге сәфәр яшь жырчыга беренче зур уныш ләззәте китерә. Йөзләгән тамашачы сыярлык залларны тутырган райондашлары, әйтерсең лә, аннан жырчылар һөнәре буенча тәүге имтиханны кабул итәләр, алдагы зур ижатка үзләренең фатихаларын бирәләр. Шул ук вакытта беренче зур чыгышлар Хәйдәрне житди уйлануларга этәрә. Үзе сайлаячак һөнәрнең никадәр авырлыгын, биредә табигать биргән сәләт кенә житмәвен, унышка бары тик зур хезмәт куеп, туктаусыз эш нәтижәсендә, тырышлык, сабырлык, эзләнүләр аша гына ирешеп булырын ул акрынлап булса да төшенә башлый.

Сәхнә сәнгате белән инде шактый житди «авырган» егет Германиядә армия хезмәтен үткән вакытта да жырдан аерылмый. Солдатлар арасында үткәрелгән үзешчән сәнгать көчләре смотрында Рөстәм Яхинның «Китмә, сандугач!» жырын башкарып, ул жиңү яулый һәм тиздән армия жыр-бию ансамбленең хор группасы солисты итеп күчерелә. Тыңлаучылары рус, татар, немец тамашачылары булганга, биредә Хәйдәргә төрле халыклар жырларын, төрле телләрдә башкарырга туры килә.

Армиядән соң урнашырга эш эзләп йөргән егетне көтмәгәндә «Москонцерт» бригада житәкчесе Сөнгать ага очрата. Мәскәү заводларының берсенә урнашырга жыенуын ишетеп, ул Хәйдәргә сәләтен жиргә күммәскә, укырга киңәш итә һәм аны Казан консерваториясе ректоры Нәжип Жиһанов белән очраштыра. Инде имтиханнар вакыты үткән булуга да карамастан, «Тәфтиләү»не башкарып үзләрен әсир иткән егетне консерваториянең хәзерлек курсларына кабул итәләр.

1971 елның 1 сентябреннән башланган уку-өйрәнү еллары киеренкелек, зур тырышлык, үҗәтлек белән үз өстендә даими эшләү шартларында үтә. Вокал буенча педагогы Казан дәүләт консерваториясе профессоры Галина Ластовка житәкчелегендәге дәресләр аның үзенчәлекле сирәк тавышына көчле яңгыраш, сыгылмалылык, киң сулыш өсти. Биредә яшь жырчы үзенең алдагы ижаты өчен драматик тенор тавышына язылган опера партияләре әзерли, бер үк вакытта республика башкаласында уза торган концертларда актив катнаша, радио, телевидение аша чыгышлар ясый. Студент вакыттан ук халык арасында киң танылу алган егетне укуы тәмамланганчы ук М. Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына солист итеп эшкә алалар. Бу инде зур ижат өчен киң юл ачылды дигән сүз. 1977 елда була бу. Ә консерваторияне Хәйдәр 1978 елда тәмамлый.

Илнең иң алдынгы ижат коллективларыннан саналган М. Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Хәйдәр Бигичевка баштан ук зур өметләр баглыйлар, килү белән үк диярлек үтә җаваплы, спектакль тукымасында үзәк урын

тоткан төп партияләрне тапшыра башлыйлар. Бу аңлашыла да. Яшь солист опера артисты алдына куела торган бөтен таләпләргә дә тулысынча җавап бирә ала. Кабатланмас тембрга ия, киң диапазонлы, гаҗәеп көчле, бай аһәңле, тигез яңгырашлы, сыгылмалы тавыш дисеңме, белькантога нигезләнгән, бөтен нечкәлекләренә кадәр чарланган башкару осталыгы мәктәбеме, яки зифа буй-сын, мәһабәт гәүдә, үзенә генә хас ирләрчә мөлаемлык бөркелгән түгәрәк йөз, кара бөдрә чәчләр дисеңме—болар бар да яшь солистны опера сәхнәсенең романтик каһарманнарын башкару өчен коеп куйган артист идеалына якынайта. Аның турында күпләр: «Махсус заказ буенча әзерләсәң дә болай ук булмас шикелле!»—диләр. Тагын боларга Хәйдәргә хас хезмәт сөючәнлек, тырышлык, ихтыяр ныклыгы, максатчанлык кебек сыйфатларны да өстәсәк, татар опера сәнгатенең нинди иҗатчы белән баюын аңлау кыен булмас.

Опера артистына катлаулы музыкаль партияләрне төгәл башкару гына җитми. Аңа тагын драма сәхнәсе мастерларына хас актерлык осталыгы да кирәк. М. Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында беренче рольләре булган Самат (Х. Вәлиуллин—«Самат»), Җик Мәргән (Н. Җиһанов—«Алтынчәч) Галимжан (Җ. Фәйзи—«Башмагым») партияләрен башкарганда, вокал-җыр ягыннан сүз тидерерлек булмаса да, яшь артистка әнә шул соңгысы—актерлык осталыгы җитенкерәми. Әлегә ул сәхнәдә үзен иркен тоталмый, аңа табигыйлек, җиңеллек, пластика өстендә эшләргә кирәклеге сизелә. Кимчелекне Хәйдәр үзе дә тоя һәм үзенә генә хас үҗәтлек, тырышлык белән аннан котылу юлларын эзли башлый. Нәтиҗә озак көттерми: Н. Җиһановның «Җәлил», Ж. Бизеның «Кармен», М. Мусоргскийның «Борис Годунов» операларында ул башкарган Җәлил, Хозе, Ялган патша партияләре вокал ягыннан да, актерлык осталыгы таләпләреннән чыгып бәяләгәндә дә үзләренең камиллекләре белән аерылып торалар.

Опера театры сәхнәсендә утыз еллап эшләү дәверендә Х. Бигичев берничә дистә партия башкарды. Алар арасында, татар, рус композиторлары әсәрләре белән беррәттән, дөнья классикасы җәүһәрләреннән саналганнары да шактый. Ул иҗат иткән онытылмас якты образлардан Дж. Пуччининың «Чио-Чио-сан», «Тоска», П. Чайковскийның «Пики дамасы», Дж. Вердиның «Отелло» операларыннан Пинкертон, Герман, Отелло кебекләре дөнья опера сәнгатенең алтын фондына кертелергә хаклы. Бату Мулюковның Мәҗит Гафури повесте буенча (Гәрәй Рәхим либреттосы) куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсындагы Закир образы өчен Х. Бигичев 1984 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә лаек булды.

Опера сәнгате Хәйдәр Бигичев иҗатының бер ягы булса, аның икенче, шулай ук зур әһәмияткә ия, җитди игътибарга лаек ягы—эстрада сәнгате. Ул чын мәгънәсендә халык җырчысы, халкыбыз җырларын, татар композиторларының әсәрләрен тулы, тигез, лирик-драматик тавыш белән илһамланып, йөрәкләрне тетрәндерерлек итеп башкаручы иде. Татар халкының ул җырлаган «Яңа кара урман», «Яз да була», «Гүзәлем», «Кыр казы», «Озата барма», Л. Батыр Болгари—М. Галиевның «Кайту», Р. Хәсәнов—З. Насыйбуллинның «Күз күреме», Р. Хәсәнов—Р. Ханнановның «Ялгыз аккош күлләрдә», Р. Хәсәнов—М. Шиһаповның «Әйләнеп кайтыгыз», С. Сәйдәшевның «Наемщик» драмасыннан Батырҗан ариясе, Р. Яхин—Г. Зәйнәшеваның «Китмә, сандугач», Р. Яхин—Г. Мөхәммәтшиннның «Керим әле урманнарга» кебек җырлары Татарстанның һәм Русия Федерациясенең авыл-шәһәр тамашачылары, татар диаспорасы яши торган якын һәм ерак чит илләр тыңлаучылары тарафыннан яратып каршыланды.

Хәйдәр Бигичев тормыштан бик иртә, илле яше дә тулмаган килеш, иҗатының иң югары ноктасында чагында китте. Үзе белән күңел тулы моңнарын, бик күп башкарылмаган опера партияләрен, халкыбыз җырларын алып китте. Әмма җырчы калдырган гаҗәеп бай иҗади мирас безнең белән. Җирдә татар халкы дигән милләт яшәгәндә ул кешеләр күңелендә мәңге сакланыр.

**Гали АРСЛАНОВ,**
*сәнгать фәннәре докторы, профессор*

Равил
Фәйзуллин

# НАРАСЫЙ ХӘКИМ



*Рәссам Әхсән Фәтхетдинов.*

Җәмгыятьне гел бимазалап, мәшәкать тудырып, Кеше дигәннең кешелеклелеген кытыклап тора Ходайның талантлы дигән бәндәләре. Холык-фигыльләре, эш-гамәлләре, уй-максатлары белән һич кенә дә гомумкыпаларга сыймый үзләре. Яшәү рәвешенә үзгә карашлары; төсләр дә алар өчен җиде-сигез генә түгел, мең дә бер балкышта; авазлар да алар өчен мең дә фәлән аһәндә... Шул ук бер Кояш, шул ук тулган Ай астында яшибез ләбаса! Ә Дөньяны танып-белеп аңлаулары бүтәннәрнекеннән бөтенләй үзгә! Күз күреме бүтән, күңел тоемы бүтән... Аралаша-аралаша яшәгәч, күрә-күрә, ишетә-ишетә иҗатларының кайбер серләренә төшенгәч, гаҗәеп бер гүзәл Дөньялары ачыла да куя! Бу Дөнья—гаҗәпләндерә дә, сокландыра да, сискәндерә дә... Шуңа күрә Ходай тарафыннан талант мөһере сугылган шәхесләр белән санлашырга туры килә. Хаким түрәгә дә, гап-гади хезмәт иясеюксылга да, таш бәгырьле тәкәббер бәндәгә дә, нарасый күңелле изге җанга да. Әйе, санлашырга туры килә!

Рәссам Әхсән Фәтхетдинов турында (аның алтмыш еллык юбилее килеп җиткән икән!) бер-ике кәлимә сүз әйтергә теләп кулыма каләм алгач килгән өзек-өзек уйлар бу. Күрәсең, юкка түгелдер. Әхсән дә бит югары кимәлдәге талант иясе. Ул да бит бүгенге дәрәҗәле мөнбәренә авыр һәм газаплы юл үтеп, танылу-танылмау баскычлары аша күтәрелгән шәхес. Искә төшерик: әле моннан 15-20 еллар элек кенә аны югары даирәләрдә зур сәнгать вәкиле итеп санамыйлар иде. Һәрхәлдә рәсми яктан шулай булды. Аның СССР Рәссамнар Берлегенә фәкать 1983 елда, 44 яшендә генә кабул ителүе шуны раслый. Сәнгать белгече С. М. Червоннаяның (ул татар рәсем сәнгатен пропагандалауда күп хезмәт куйган галимә) шул елларда чыккан «Художники Советской Татарии» дигән библиографик белешмә китабын актарып карагыз. Анда сез Ә. Фәтхетдинов исемен иң ахыргы биттә, кечкенә генә белешмә рәвешендә күрерсез. Ә Әхсәннән күпкә, шактый күпкә яшь рәссам егетләр—Ш. Шәйдуллин, В. Аршинов, З. Гимаев һәм тагын бүтәннәр берничә бит урын алып, портрет-сурәтләре белән бик иркен утыралар бу китапта. Бу мисалны алар лаек түгел дип китерүем түгел, алар да сәләтле рәссамнар, чагыштыру өчен генә искә алуым. Ә бүген? Ә бүген исә, торгынлык чорындагы замандаш байтак апофеоз шәхесләр арткы планда тонykланып калганда, Әхсән Фәтхетдинов иҗаты, аның шәхесе мәйданыбыз уртасына чыкты. Бүгенге татар милли сәнгатен аның иҗатыннан башка күз алдына китерү кыен. Күпләрнең—сәнгать белгечләренең дә, гади халык вәкилләренең дә—фикере уртак: Әхсән Фәтхетдинов—уникаль сәнгать әсәрләре тудырган олуг рәссам. Бу коры комплиментарь сүз түгел, әйтелгәнне расларлык дәлилләр күп. Ул—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984). Ул—Республикабызның иң абруйлы—Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1993). Ул—әлегә республикабызда даими эшләп килүче бердәнбер шәхси галерея иясе (1997 елны ачылды)... Гомумән, Түбән Кама шәһәре, аның интеллектуаль дөньясы турында сүз чыкса, ирексездән

Әхсән Фәтхетдинов бу каланың рухи символы булып күз алдына килә. Әйе, Кеше белән, талант иясе Кеше-Шәхес белән санлашырга туры килә. Соңарып булса да. Дөнья бу!

Кайсы яктан, кайсы туфрактан сон ул? Иҗат юлы ничек? Хезмәтләре нидән гыйбарәт? Башкалардан нәрсә белән аерылып тора да, милли сәнгать үсешенә нинди өлеш керткән? Болар—табигый сораулар. Хәл кадәри шуларга җавап эзләп карыйк, мәгълүматлар укучыларыбызны да кызыксындыра дип ышаныйк. Татарстанда туып-үскән егет ул. Тумышы—Чирмешән (ул вакытта Первомайский дип йөртелгән) районының Урманасты Үтәмеш авылыннан (милли җанлы икенче бер рәссам Канәфи Нәфыйков та шул төбәктән). Ишле гаиләдә үскән Әхсәннең малай, үсмер чаклары ничек үткәндер, анысын белмим, әмма Табигатьнең бөек сереннән кече яшьтә үк әсәрләнеп йөрүе турында үзе сөйләгәннәре истә. Табигатьнең нәни бер өлешен генә булса да,—үлән-тирәкме ул, кошмы, болыт-төтенме—үзе ясап тудырырга ният итмә кели бит бу малай! Кул астына эләккән кәгазь кисәгенә ниндидер сызыклар сыза, сурәтләр төшерә, таякларны юна-юна сырлар уя, шакмак, такта кисәкләрен бергә укмаштырып нидер төзи...

Һөнәри белемне Әхсән Фәтхетдинов—Түбән Тагил педогогия институтының сәнгать-графика факультетында ала. Институтны тәмамлагач, берничә ел Әхсән Урал якларында эшли. Укыту белән дә шөгыльләнеп ала, иҗатка да ыргымнар ясап карый. Әмма... Әмма нидер җитми бит күңелгә! Торган җир үз түгел, мохит, барыбер, чит, ят... Аратирә артистлар килеп, татар моңнарын ишеттергәндә, Казаннан алдырган татар китапларын, газет-журналларын укыганда, күңелдә аңлатып бетермәслек сагыш, хатирәләр зилзиләсе, җирсү... Ниһаять, 1969 елда Әхсән тәвәккәлләп, хатыны Таисия белән, Татарстанга кайта. Ул вакытта үзенең колачы, үсеш темпы белән бөтенсоюзга яңгыраган, яшьләр каласы дип дан алган Түбән Камага килеп төпләнә бу яшь гаилә. Әйе, төпләнә. Тамырларын тирән җибәргән, ябалдашларын колачлы итеп мәгърур җәйгән имән шикелле, биек һәм бөек булырга кайтып төпләнә Әхсән. Түбән Камада 30 ел гомер. Иҗатчы өчен тулы бер дәвер. Үксегән чаклары да, иҗат һәм яшәү шатлыгыннан күк катларына менәрлек үсенгән чаклары да булгандыр. Һәрхәлдә, бүгенге милли сынлы сәнгатебезнең асыл бер өлешен тәшкил иткән әсәрләрне шушы шәһәрдә иҗат итте Әхсән.



*«Аккош күле иясе»*
*шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов.*

Сәнгать белгечләре Әхсән Фәтхетдинов әсәрләрен гадәттә берничә төркемгә бүлеп карыйлар. **Агачка уеп ясалган декоратив бизәкләр** (балалар бакчалары, аэропорт, кунакханә диварларындагы бизәкләр). **Нәкыш сәнгате** («Тукай шигырьләре», «Түбән Кама җирендә», Хәсән Туфан, Бакый Урманче, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов портретлары). **Агачтан ясалган декоратив скульптура сыннар** («Сак-Сок», «Таһир белән Зөһрә», «Ияләр», «Кабер ташлары», «Шүрәле», «Интеккәннәр» цикллары. **Монументаль язу үрнәкләре** (Түбән Камадагы төрле корылмалар (муз. училищесы, хастаханә, техникум һ. б.) диварларындагы бизәкләр.

Сәнгать фәненнән караганда мондый бүленеш дөрестер, һәм кирәктер дә. Ә бит көндәлек тормышта, үзара гадәти сөйләгәндә болай классификацияләп тормыйсың. Иҗатчының хәтерендә калган берничә төп эшен исенә төшерәсен

дә, ул эшләрнең материалына, сәнгати «чыраена» карап Останың төп асыл сыйфатын үзенчә шәрехлисең. Ә. Фәтхетдинов—агаччы. Агач җанлы Оста. «Агач җанлы» дигәнне гадәти сөйләмдәгечә бер яклы анламыйк, «бала җанлы» дип әйтәбез бит әле. Бу очракта әнә шул мәгънәдәрәк аңлашылсын. Авторның күп санлы гүзәл сыннарына карап, аларга Әхсән үз җанын биргән, ә агачларның җаны Әхсәнгә күчкән дип әйтә алмыйбызмыни («Каберенә агач үссә, ул—аның җаны булыр...)? Нәкыш портретларының рамнарына гына игътибар итегез, алтын йөгертелгән академик багетлар түгел, һәрберсе агачтан, берсе-берсен кабатламас, әсәрнең органик өлеше булып, эчтәлекне тирәнәйтүче детальләр алар. Дөнья сәнгатендә Әхсәнгә кадәр гомер кичеп үткән аналоглар да бар барын: Эрзья (Нефедов С. Д.) С. Коненков, Б. Урманче... Урманасты Үтәмеш егетендә генә түгел, уйлап баксаң, Табигать кочагында үскән безнең һәрберебездә күпмедер «агачлык» бар бит. Агач бишектән башлап ләхет уемындагы такталарга кадәр... Балачакта авыл өендәге сәкедә чалкан килеш түшәмдәге ботак киселешендәге сурәтләрне карап ятмадыкмени? Нинди генә, нәрсәгә генә охшаганнары булмый иде аларның! Үзенә күрә бер галерия. Түшәм галериясы. Кыскасы, Әхсәнне Агач кеше итте, Оста итеп дөньяга танытты. Икесенә дә рәхмәт! Шагыйрь Зөлфәт Әхсәнгә багышланган шигырендә тикмәгә генә болай дип язмагандыр:

... Остаханәңдә мин, Әхсән,
Өнсез булдым.
Кешене син бакый иткән бит...
Син—җан табигате генә түгел,
Табигатьнең җаны икән бит!

Ә. Фәтхетдинов сәнгате киң даирәгә 80 еллар башында таныла башлады. Казанда үткән беренче күргәзмәсе (1978) әле дә хәтердә. Рәссамнар өчен күргәзмә дигәннәре зур нәрсә. Биючегә мәйдан-сәхнә кирәк булган шикелле, рәссамга үз эшләрен кеше күзенә күрсәтү лазем. Яшьләр Үзәгендә (хәзерге «Ак барс» банкы бинасы) оештырылган иде ул күргәзмә. Күбрәк нәкыш әсәрләре—портретлар, пейзажлар, график эшләр, шулай ук, бүгенге зур мирасның башлангычы—агач сыннар да бар иде анда. Казанлылар яратып калды Әхсәнне. Дуслары күбәйде. Язучылар, журналистлар үз итте. Арада, әлбәттә, сәнгатькярләр дә байтак иде. Фотохудожник—Риф Якупов, композитор Шамил Шәрифуллин, бөек Бакый Урманче... Переферийдән килгән рәссамга рәсми «классик»лар тарафыннан өстәнрәк, бераз түбәнсетеп тә караучылар булмады түгел... Әмма татар милли сәнгатенең (агач җаны аша) бу төре үсешен ныклап башлап җибәрүче нәкъ Әхсән булачагына ышанучылар күбрәк иде. Дөрес, сынлы сәнгатьнең теге яки бу жанрында техник яктан заманча иҗат итүче сәләтле рәссамнар байтак. Алар, йә С. Петербург, йә Мәскәү мәктәбен үтеп, бер төрле тәрбия, бер төрле идеологик юнәлеш алып үскән рәссамнар. Алар кайда да Псковта да, Уфада да, Магаданда да рәхәтләнеп яши, үзләре үткән мәктәп курсы рухында иҗат итә алалар (мисалы ерак түгел: Бондюг егете Әмир Мәҗитов әллә ничә еллар буе Ярославль рәссамнар берлегене җитәкләде, хәтта Казанга кайтып та шул дәрәҗәле хезмәттә булды. «Чайка», «Барабанщик», «Сигнал» кебек бөтенсоюзга киң таралган әсәрләр авторы булса да, мин аны чын мәгънәсендә милли рәссамыбыз дип таный алмыйм). Бәлки, осталыкның теге яки бу хикмәтендә, Әхсән кемнәрдәндер калышадыр. Нишлисең, ходай кемгә буй, кемгә уй биргән ди. Миллилеге белән, беркемне дә кабатламый торган үзенчәлеге, алынган теманы философларча хәл итүе белән, ахыр чиктә, Әхсән дигән шәхес булуы белән алдыра ул! Һәм ничек кенә әле!

1993 елда Әхсән Фәтхетдинов Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Рәссамнар берлегенә әгъза булып керүенә нәкъ 10 ел үткәч. Шул елның яз башында Казан милли мәдәният үзәгендә гаять бай күргәзмәсе оештырылган иде аның. Вәт күргәзмә дисәң дә күргәзмә иде ул! Бусы инде—без теләгән (күпләр теләгән!) Әхсән иде. Жанрлар төрлелеге ягыннан дисеңме, осталык, камиллек ягыннанмы, җаныбызда сыкрап яткан рухи катламнарны ачып күрсәтү ягыннан дисеңме... Бу күргәзмәдә иҗатының үзәген билгеле торган төп цикл-төркем эшләре куелган иде.

«Шүрәле»ләр. Алар—үзе бер дөнья. Чиста, пакь дөнья. Шүрәлеләрнең

берсе, бәлки, автор үзедер әле! Ул да, безнең кылган гамәлләргә карап-карап тора да, хилафлыкларыбыз өчен бетереп үк ташламый, сынап-сынап карый да, аптырагач, шаяра, кытыклый, көлә... Ә «Интеккәннәр» циклы? Нинди генә йөз-чырайлар юк ул сыннарда! Алар—безнең үткән тормыш, безнең бүгенгебез. Әле яна гына, 26 апрель—Шигырь бәйрәме көнендә, Камал театрында Түбән Камаларның тантаналы концерт кичәсендә, сәхнәдән торып Әхсән болай диде: «Минем ул сыннарның чытык, ямьсез йөзләренә карап гаҗәпләнмәгез, тормышларыбыз рәтләнеп китеп, хәлләребез яхшыргач, аларның да йөзләре үзгәрер, аларга да нур кунар...» Уйландыргыч сүзләр.

«Ияләр» циклы, мөгаен, Әхсән Фәтхетдиновнең төп гомер хезмәтедер. Нинди генә ияләрнең иясе булмады ул! Җир иясе, күк иясе, урман иясе, зират иясе, чишмә иясе, юл иясе, су иясе, йорт иясе, абзар иясе, капка иясе... Алар әллә ничә дистәгә җыйнала. «Ияләр» хакында матбугатта күп язылды. Абруйлы язучылар да, үз эшләрен камил белгән сәнгать белгечләре дә. Р. Шаһиева, Г. Сөләйманова, И. Саттаров, Р. Хисмәтуллин, Э. Гаделов, Д. Вәлиева... Рәссамның «Ияләр»ен төрлечә бәяләделәр, аларның тууын төрлечә фаразладылар. Ислам дине кабул ителгәнгә кадәрле чорны, мәҗүсилек дәверен чыганак итеп күрсәтүчеләр булды. Берәүләр аның бу әсәрләрен «коммунизм төзү чорындагы» ялган рәсми сәнгатькә протест билгесе итеп тә карадылар. Еретик рәссам дип мохер сугучылар да булды. Ни генә булса да, хаклы шауладылар, хаклы бәхәсләштеләр, хаклы бәяләделәр. Хаклы рәвештә Тукай премиясен бирделәр. «Иясез шатлык» булу бер нәрсә, ә һәр нәрсәнең, табигатьтәге һәр җанлының үз иясе булуы кирәк бу дөньяда! Ияле булсаң, кадерең була. Кадерсез булу яман ул...



*«Кабер ташлары» циклыннан бер фрагмент*

Бу урында Әхсән Фәтхетдинов белән минем шәхси иҗади мөнәсәбәтләр турында да берничә сүз әйтү кирәк булыр. Әхсән иҗатының бер зур өлешен «Кабер ташлары» дигән цикл алып тора. «Татар иле» газетасында (№ 6, март, 1993 ел) мондый юллар язылган иде: «Ә. Фәтхетдинов иҗаты соңгы елларда чын-чынлап чәчәк ату чорын кичерде. Равил Фәйзуллин шигырьләренә нигезләнеп иҗат ителгән «Кабер ташлары» рельефлы скульптуралар төркеме татар халкының кире кайтмас югалтулары һәм газаплары өчен тирән борчылу хисләре белән сугарылган. Бу—татар зиратының символик образы, анда халкыбызның тормышка

ашмаган хыяллары» кумелгән. Кешеләрнең рухи байлыгын, вөжданын һәм хәтерен саклап калу өчен безгә әле бик күп эшләр эшләп өлгерергә кирәк. Һәм шигырьләр—шагыйрь иҗат иткән эпитафия, бередә бигрәк тә дулкынландыргыч янгырыйлар...» А. Шакиров.) Сүз—берничә юллык кыска шигырьләремне Әхсән кулы белән агачка уеп язылган әсәрләр турында. 50 гә якын шигырь чокылган куна-такталар алар. Дөрес, мин беркайчан да кайчандыр кабер ташларына (бу очракта агачка) уерлар дип иҗат итмәдем. Кыска шигырьләр—минем стихиям, бәлкем, асылымдадыр әле. Әмма олуг Останың һәрбер сүземне, һәрбер хәрефемне ырмау пычак белән агач бәгыренә уеп утыруын күз алдына китерик әле! Ничә көннәр, ничә айлар... Шагыйрь өчен, әйтәсе дә юк, зур бәхет инде бу. Шунсы да мәгълүм: бу әсәрләр куелган күргәзмә кешеләргә нык тәэсир итә икән. Сүзләре дә, эшләнеше дә, агач булуы да... Гомумән дә уйландыра—зираттагы кабер ташлары нинди булырга тиеш? Һәрхәлдә сурәт яки һәйкәли сыннар рәвешендә түгелдер. Сурәт белән таш кую безнең мөселман традициясе түгел. Борынгы ташларда сурәт юк бит. Фотокүчермәдән кеше сурәтен ташка иңдерү соңгы чор, сәвит чоры галәмәтләре, ул гына да түгел, мәҗүси-христиан традицияләре. Уйлансаң уйланырлык: Чыңгыз ханның кабере нәмәгълүм (инде гасырлар буе эзлиләр), Л. Толстойның каберендә сурәт-мазар юк, Истанбулдагы Г. Исхакый каберендә дә фәкать язулар гына... Борынгы төрки ядкарь—Күлтәгин ташларында да уйма язмаларны гына күрәбез. Сабый хәким—Әхсән Фәтхетдин төрлесен уйлап, киләчәккә карап уйгандыр ул сүзләрне.

Әхсән белән даими аралашып яшәгәнгә егерме биш еллап. Байтак гомер. Хәзер күрше белән күрше, туган белән туган юньләп аралашып яшәмәгән заманда Әхсән миңа хатлар яза (Тапшырылмаган хатлар түгел, тапшырылган хатлар!). Ә ул хатлар хатлар гынамы соң әле!—кайберләре бер амбар кенәгәсе чаклы—машинкада 70-80 биткә житкәннәре бар. Алар миндә 40 тан артык. Менә боларны укысаң, Әхсәннең җанында ниләр уйнаганын беләсез инде! Ул әле рәссам гына түгел, шагыйрь дә, әдип тә, философ та. Ходай боерган булса, ул хатлар (бераз өлеше генә булса да!) матбугатта бер күренер әле.

Сүз дә юк: Әхсән кебек намусны компас итеп алган шәхесләргә бу тормышта, безнең мөхиттә яшәү жинел түгел. Алар бәргәләнә, өзгәләнә... Ниндидер язылмаган кануннар бардыр инде: кемнәргәдер авыр булганда, кемнәргәдер жинел була... Әмма, барыбер, бүген өзгәләнгәннәргә иртәгә жинеллек киләчәк... Әхсән үткән юлга, тормышына, иҗатына карап шулай уйлыйм. Дөньяда үзеңнән яхшырак кешеләр барын тою яшәтә безне, турайта, өметләндерә, шактый ук унган күзләребезне киләчәккә төбәтә.

Журналыбыз тышлыгында сез Әхсән Фәтхетдиновнең «Сугыш еллары атлары» дигән сынының фоторепродукциясен күрәсез. Редакциягә жибәргән хатында аның мондый сүзләре бар: «Соңгы зур күләмле «Ай шәүләсе астында» дигән эшемдә Иңләрне бергә жыйдым. Жир өстенә аларны, күккә сибелгән йолдызлар кебек чәчтем, сиптем. Алар арасында байлар-ярлылар да, патшаколлар да юк, алар—тигезләр. Бу картина—үзем тудырган, үземә якын булган бер дөнья». Синең дөньяң безнең өчен дә бик зур Дөнья Әхсән туган! Озак, бәхетле яшәп, игелекле иҗатың белән сөендереп тор гел.

*Май. 1999 ел.*

# ҮТКӘННӘРДӘН САБАК АЛЫЙК

## РУСЛАР ӨЧЕН ОЕШТЫРЫЛГАН ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЛАРЫ ТАРИХЫННАН

**1992** елда кабул ителгән «Татарстан халыклары телләре турында»гы закон нигезендә, татар теле рус теле белән бер дәрәҗәдә дәүләт теле булып игълан ителде. Халкыбыз өчен гаять әһәмиятле әлеге вакыйгадан соң җиденче елыбызны яшибез. Бер караганда, Закон үтәлә дә кебек: татар гимназияләре, көллиятләре, балалар бакчалары ачылды, югары уку йортларында татар группалары барлыкка килде, мәктәпләрдә татар теле дәресләре күбәйтелде, төрле оешмаларда татар теле курслары эшли башлады... Болар барысы да — бик куанычлы һәм күптән көтелгән хәлләр. Ләкин татар телен чын мәгънәсендә дәүләт теле итә алдык дип әйтергә әле бик ерак, чөнки алда саналган эшләрнең кайберләре, зур күтәренкелек белән башланса да, авырлыклар алдында туктап кала, яисә формаль рәвештә, күз буяу өчен генә эшләнә...

Бу мәкаләдә безнең максатыбыз — татар телен гамәлгә кую эшенең хәзерге вакытта гаять зур авырлык белән баруын, гаепле оешмаларны яки җитәкчеләрне тәнкыйтьләү түгел, бары тик узган тарихыбызга күз ташлап, хәзерге чорга охшаш күренешләрне эзләп табу, алардан үрнәк яки сабак алырга тырышу. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, без, Татарстан республикасының Милли архив материалларына таянып, 20-30 еллардагы татар теле курсларының эшчәнлегенә тукталырбыз.

Әйе,бу өлкәдә уңышсыз тәҗрибә тарихыбызда булган инде. 1921 елның 25 июнендә татар телен рус теле белән бер дәрәҗәдә дәүләт теле итеп игълан иткән Декретка кадәр үк, шул ук елның 24 маенда Татарстан Халык комиссарлары Советы (СНК) президиумы утырышында Мәгариф комиссариатына өч атна эчендә татар теле курслары ачарга тәкъдим ителә *(Татарстан республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар (20-30 еллар). - Казан: Мәгариф, 1998. - 207 б.).* 25 июньдәге Декретның 4 маддәсендә дә телләгән хезмәткәрләр өчен татар теле курслары оештыру турында сүз бара. *(Сборник Декретов, Постановлений, важнейших Циркуляров и других материалов в области РТЯ. - Казань: Изд. ЦК по РТЯ, 1925. - 88 с.).*

Шул вакыттан алып Татарстанның күпчелек үзәк оешмаларында, Халык комиссариатларында һәм кантоннарда рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү курс-түгәрәкләре оештырыла башлый. 1923-1924 елларда бу эш аеруча җанлана . *(Отчет ЦИК и СНК ТССР к 5-му съезду Советов. - Казань: Изд. ЦИК и СНК, 1925. - 310 с.).*

1924 елның 23 декабрендә Татар телен гамәлгә кую Үзәк Комиссиясе (ТТГК ҮК) тарафыннан татар теле курс-түгәрәкләренең төп нигезләре игълан ителә. Курсларны оештыру эше баштарак, бигрәк тә 1921 елгы беренче декрет һәм карарларда Мәгариф комиссариатына тапшырылган булса, соңрак исә бу эш белән гомуми идарә итү вазифасын Казандагы ТТГК Үзәк Комиссиясе башкара.

Курс-түгәрәкләр учреждение, предприятие хезмәткәрләрен татар сөйләм теленә, язарга, укырга, эш башкарырга һәм, гомумән, татар телендә телдән дә, язмача да үз фикерләреңне иркен бирә алуга өйрәтү максатында төзеләләр. Дәресләрдә сөйләшү методы өстенлек алып торырга һәм оешма юнәлешендә эш алып барылырга тиеш була.

Тиз вакыт эчендә һәм артык көч түкмичә генә татар теле өйрәнү теләге белән килгән рус хезмәткәрләре, билгеле инде, беренче авырлыклар алдында ук аптырап калалар. Үзәк Комиссиянең түбәндәге аңлатмасы андыйларга бик яхшы җавап була алыр иде: «Татар теле дәресләре, түгәрәк утырышларында атнага 3-4 сәгать шөгыльләнеп, бу дәресләр күпме генә дәвам итсәләр дә, бөтенләй таныш булмаган

телне практик максатларда куллана алырлык дәрәҗәдә өйрәнү һич мөмкин түгел. Татар теле — өйрәнү өчен бик ансат тел, ләкин бу рәвешле аны да өйрәнеп булмый. Бу курс-түгәрәкләр бары тик берникадәр күләмдәге сүзләр, аларның дөрес әйтелеше, фразаларның дөрес конструкциясе, телнең грамматикасы, шулай ук язу, уку һәм эш алып баруның трафарет формалары белән таныштыру өчен генә хезмәт итә алалар. Сөйләшә алуга килгәндә исә, бу бары тик телне игътибар белән, дәвамлы рәвештә һәм тырышып, баш күтәрмичә өйрәнгәндә, шактый күп практика һәм сөйләшү, уку һәм язу булганда гына мөмкин. Шуңа күрә тел белән гамәли яктан танышу тыңлаучының үзендә житди теләк, вакыт һәм тел өйрәнү өчен шартлар булганда гына мөмкин. Киресенчә булганда, ел күзәтелгәнчә, бу түгәрәкләр бары тик вакытны һәм акчаны бушка туздыру булып кына калалар».

Шуның нәтиҗәсе буларак, Комиссия фикеренчә, татар телен өйрәнү һәм курсларга йөрү беркем өчен дә мәҗбүри рәвештә үткәрелә алмый. Курслар житди теләк һәм татар теленә өйрәнү мөмкинлегенә ия кешеләргә ярдәм итү өчен генә оештырылырга тиеш була. Ләкин, кагыйдә буенча шулай булса да, рус хезмәткәрләренең татар телен өйрәнүгә бик салкын карауларын күреп, кайбер комиссариат һәм оешмалар татар теле өйрәнүне мәҗбүри итеп куялар. Мәсәлән, Кун тресты (Таткожтрест) 1924 елның 31 гыйнварендә шундый боерык чыгара: «Игътибарга алынмаслык сәбәпләр белән курсларга йөрмәгән хезмәткәрләргә җәза биреләчәк: беренче тапкыр дәрес калдырган өчен — каты шелтә, икенче тапкыр — бер көнлек хезмәт хакын Кызыл Һава флоты файдасына алып калу, өченче тапкыр — Татарстан үзәк башкарма комитеты (ТҮБК) карарына буйсынмаган өчен, бу хезмәткәрне эшеннән азат итү хакында трест идарәсенә һәм профсоюзга мөрәҗәгать итү». Трестта эшләүче һәм татар теле курсларына мәҗбүри рәвештә йөрергә тиешле 68 кеше исемлеген китереп, Кун тресты тагын ике боерык чыгара.

Эчке эшләр комиссариаты шулай ук 1924 елда барлык хезмәткәрләрнең дә мәҗбүри рәвештә татар теле өйрәнергә тиешлеге, начар йөргәннәргә эштән азат итүгә кадәр дәрәҗәдә административ җәза биреләчәге турында боерык игълан итә.

Болардан тыш, Хезмәт комиссариаты һәм Мәркәз ветеринария идарәсе дә хезмәткәрләр өчен татар теле курсларын мәҗбүри итеп куялар.

Бары административ чаралар ярдәмендә генә зур уңышларга ирешеп булмаячагы ачык аңлашылса да, шунысы кызык: Үзәк Комиссиягә бирелгән мәгълүматларда нәкъ шул комиссариат һәм оешмалар хезмәткәрләргә татар теле өйрәтү буенча чагыштырмача алгырак сафта торалар. Шулай ук Элемтә идарәсе, Финанс комиссариаты, Тегү тресты идарәсе һәм Металл трестында эшләр яхшырак куелган була. Кайберләренә аерым-аерым тукталып үтик.

Элемтә идарәсендә татар теле курслары 1924 елда оештырыла. 1925 елның 1 гыйнварена 50 кеше түгәрәк исемлегендә санала. 1925-26 уку елында 2 группадан торган курслар эшли: башлангыч һәм дәвам итүчеләр өчен. Беренче группага — 8, икенчесенә 30 кеше язылган була. Татар теле өйрәнүчеләр атнага ике тапкыр икешәр сәгать күләмендә шөгыльләнәләр. «Дәресләр шактый уңышлы бара, тыңлаучылар кызыксынып һәм яхшы йөриләр, белемнәре дә канәгатьләнерлек. Татар телен өйрәнүче руслар киләчәктә җирле халык белән татарча шактый җиңел аңлаша алырлар дигән өмет бар»,— дип хәбәр итәләр Элемтә идарәсеннән.

Бүгенге көн өчен уйландырырлык мәгълүмат: 1926 елның 1 июненә элемтә оешмаларында эшләүче рус хезмәткәрләренең 97се татарча белә: 20се укый, яза һәм сөйләшә ала, 77се — сөйләшә генә белә.

Алда әйтеп үтелгән Кун трестында 1924 елда 36лап кеше татар теле курсларына йөри. «Нәтиҗә яхшы, руслардан байтак кына кеше укый, яза һәм сөйли беләләр»,— дип мәгълүмат бирелә.

Финанс комиссариатында эшләүчеләр өчен дә татар теле курслары эшли. 1924 елгы мәгълүматлар буенча, анда 42 кеше йөри һәм араларында укый-яза белүчеләр күренә башлый. Нәтиҗә яхшы, ләкин «җаваплы хезмәткәрләр укуларын дәвам итә алмаячаклар». 1925 ел башына 23 кеше татар теле өйрәнә. 1925-26 уку елында курсларга 17 кеше языла һәм аларның 11е атнага ике тапкыр даими рәвештә дәресләрдә катнаша.

Хезмәт комиссариатында 1924 елга кадәр үк татар теле курслары була. 1925 елда ул 2 группага бүленә: 1) әлифбадан башлап Тимофеев дигән кеше 18 хезмәткәрне

укыта һәм 2) азмы-күпме әзерлекле 12 тыңлаучы белән укытучы Рәхимова шөгыльләнә.

Эчке эшләр комиссариатында 1925 ел башына 32 кеше татар теле түгәрәгенә йөри. 1925-26 уку елы өчен түгәрәк 27 октябрьдә генә оештырыла. Дәресләр атнага ике тапкыр, иртәнге сәгать 8 дән 9 га кадәр үтә. Язылган 20 кешенең 12 се һәр дәрескә йөри. Хезмәткәрләр белән махсус чакыртылган укытучы шөгыльләнә.

Металл тресты идарәсендә, 1925 елгы мәгълүматлар буенча, 2 ел дәвамында, күбесенчә кыш көннәрендә, татар теленә өйрәтү курслары эшли. Аерым түләү белән укытучы итеп хезмәткәр Ф. Ибраһимов чакырыла. Хезмәткәрләрнең кайберләрре шактый зур уңышларга ирешә, гомумән алганда, татар теле белән танышу үтәләр.

Тегү тресты идарәсе һәм фабрикалары хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү өчен, 1924 ел ахырында бирелгән мәгълүматлар буенча, көндәлек курслар эшли. Идарә хезмәткәрләре курсы 3 группага бүленә һәм аларга барлыгы 60лап кеше йөри. Дәресләр уңышлы үтә: йөрүчеләр инде татарча укый, яза һәм хәтта азрак сөйләшә дә алалар.

Калган комиссариат һәм оешмаларда исә татар теле курслары бер ачылып, бер ябылып, сүлпәнлек белән генә эшли. Аларга язылучы рус хезмәткәрләренең саны күп булмый, дәресләргә йөрүчеләр исә тагын да азрак санны тәшкил итәләр. Кайбер комиссариат һәм оешмалар эшчәнлегенә күзәтү ясау бу фикерне расларга ярдәм итәр.

Сәламәтлек саклау комиссариатының үзендә, сметада акча каралмавы сәбәпле, татар теле курслары ачылмый, аның каравы 1925 елда Медторгта оештырыла. 20 кеше язылган булса да, дәресләргә 5 кенә кеше даими йөри. Нәтиҗәдә, комиссариат каршындагы татар телен гамәлгә кую комиссиясе, татар теле өйрәнүнең кирәклеген аңлатып, циркуляр хат белән чыгарга мәҗбүр була.

Халык хуҗалыгы Советында (ТСНХ) 1925 елга кадәр «башка кайбер комиссариатларда мондый курсларның берәр реаль нәтиҗә бирмәве» һәм «татар теле өйрәнергә теләүчеләр булмау» сәбәпле, курс оештырылмый. Болар гына да түгел, курс өчен сметага кертелгән акчаны Финанс комиссариаты кабул итми һәм бу эш өчен акча бөтенләй бирелми. Шулай да, татар теле өйрәтү өчен, укытучы Мөштәриев чакырыла. Дәресләр 4 айдан артык дәвам итәләр, ләкин 2 генә кеше укыганлыктан, укытучы алга таба да эшләүдән баш тарта. Шуннан соң курслар туктала. Сорашу нәтиҗәсендә, 6 кеше татар теле өйрәнергә теләк белдерә һәм аларны башка берәр оешмадагы түгәрәккә кушарга карар бирәләр.

Иҗтимагый тәэминат комиссариаты: «руслар өчен татар телен гамәлгә ашыру курслары дәвам итә, ләкин фәкать 8 генә кеше йөри. Наркомат тарафыннан һичбер төрле ярдәм күрсәтелми» дип белдерә.

Коммуна хуҗалыгында 1924 елга кадәр курслар ачылган булса да, берәү дә йөрмәгәнлектән, киредән япкannар. «Красная Татария» газетасы мәгълүматы буенча, 1924 елның май башында газета каршында курслар ачыла, Үзәк Комиссиядән укытучы чакыртыла. Курсларга 37 кеше йөри. 28 октябрьдәге санда исә бу курслар тәнкыйть ителә: дәресләрне иртән сәгать 9га кадәр генә үткәрергә мөмкинлек бар, чөнки кич белән җаваплы хезмәткәрләр һәрвакыт диярлек төрле утырышларда булалар. Курсларда барлыгы 60 җаваплы хезмәткәр укырга тиеш булса да, фактта 12 генә кеше татар теле өйрәнә. Түбән хезмәткәрләрдән курска 40 кеше язылган, 17се генә дәресләргә йөри.

Халык комиссарлары Советында 1924 елда руслар өчен татар теле курслары булган, ләкин атнасына ике генә көн йөргәнгә, нәтиҗә начар, 1925 елда инде курслар бөтенләй оештырылмый.

Җир эшләре халык комиссариатында 1924 елда «курслар булган, нәтиҗә күренми, йөрүче аз».

Эшче-крестьян инспекциясендә: 1924 елда курслар бөтенләй булмаган, 1925 елның 25 ноябрендә башланачак курсларга 6-8 кеше язылган, ләкин инспекция алдан ук контингент даими булмаячак, чөнки хезмәткәрләр еш кына ашыгыч эш белән кантоннарга чыгып китәләр, дип искәртә.

Татторгта 1924 елның 13 ноябренә татар телен өйрәнергә теләүче 82 кеше курсларга языла, 1925 елның 1 январенә бу сан 60 ка кала.

Урман трестында 1924 елда татар теле курслары булган, ләкин ул 5 кенә ай дәвам иткән.

Гомумсоюз Текстиль синдикатының Казан бүлегендә 1925 елның декабреннән

1926 елның язына кадәр татар теле түгәрәге эшли. Акча түләп, укытучы чакыралар. Ләкин эш нәтиҗәләре бик начар була. Сәбәпләре: чагыштырмача аз вакыт эшләве, укытучының озак вакытлар авыруы. «Бу түгәрәк кирәк һәм күздән алып Мәскәү ризалыгы белән янадан эшкә керешәчәк»,— дип хәбәр итә трест мөдире.

ВКП(б) Өлкә комитетында да 1926 елның 1 октябреннән җаваплы партия хезмәткәрләре өчен атнасына 2 тапкыр 3әр сәгать күләмендә татар теле түгәрәге ачылырга тиеш була, ләкин түгәрәкнең алдагы язмышы билгеле түгел.

1924 елның 4 сентябрендә «Красная Татария» газетасы Татстрахта татар теле түгәрәге эшли башлавы турында хәбәр итә. Атнага 4 сәгать күләмендә 3 группа татар теле өйрәнә. 1925 елда исә 12 кешелек түгәрәк оештырыла һәм аны Үзәк Комиссия тарафыннан Татстрахка тәрҗемәче булып җибәрелгән Бакиров җитәкли, 1 мартта татар теленең нигезләрен өйрәнү тәмамлана. Белемнәрен дәвам итәргә теләүчеләрнең саны аз булу сәбәпле , соңрак курс өчен акча бирелми һәм хезмәткәрләр үз акчаларына укуларын дәвам итәргә мәҗбүр булалар.

Газета редакцияләре, нәшрият хезмәткәрләре дә татар теле өйрәнү эшеннән читтә калмый. 1924 елда «Красная Татария», «Новая деревня» газеталары хезмәткәрләренә аларның редакторы тарафыннан 3 ай эчендә татар теле һәм язуы нигезләре белән танышырга тәкъдим ителә.

Үзәк туберкулез диспансерында 1925 елда татар теле түгәрәге оештырыла һәм хезмәткәрләрнең яртысы дәресләргә йөри.

Һава флоты дуслары җәмгыятендә дә 1924 ел ахырында регуляр рәвештә татар теле дәресләре барганлыгы мәгълүм. Түгәрәкне җәмгыятьнең агитация секциясе җаваплы сәркатибе Садыйков җитәкли.

Хәтта төрмәдә дә (Центрисправдомда) татар теле түгәрәге эшләгән! 1925 елның 1 гыйнварена, мәсәлән, 27 кеше (тоткыннар һәм надзирательләр) өчен 3 укытучы татар теле дәресләре алып барган.

20 елларда шулай ук Юстиция комиссариатында, Татсоюзда, Урман трестында, Совет сәүдә хезмәткәрләре клубында, Үзәк эшче клубында, Дәүләт банкы һәм Татар банкында, Татпищетрестта, Тышкы сәүдә халык комиссариатының Казан өлкә идарәсендә, Артиллерия полкында рус хезмәткәрләре өчен татар теле түгәрәкләре эшләве мәгълүм.

Күренгәнчә, барлык комиссариат һәм учреждениеләрдә дә диярлек, төрле нәтиҗәләр белән булса да, татар теленә өйрәтү курс-түгәрәкләре эш алып бара. Бары тик Татар статистика идарәсе һәм Дәүләт сәясәт идарәсендә (ГПУ) генә курсларның ачылуы мәгълүм түгел.

Кантоннарда да, шәһәрләрдәге кебек үк, татар теле курс-түгәрәкләре ачыла. Ләкин алар турында мәгълүмат бик аз. Булганнары да курслар файдасына сөйләми. 1924 ел эшчәнлеге буенча бер-ике мисал китерик.

Мамадыш кантонында руслар өчен татар теле курсларының бертөрле дә нәтиҗәсе күренмәгәнгә, аларны юк итеп, аның урынына 25 кешегә 2 айлык совет эшчеләре хәзерләү курсы ачылган.

Лаеш кантонында «ни руслар өчен вә ни дә булса татар эшчеләре хәзерләү өчен бертөрле дә курс ачылмаган, аны кирәксенгән кеше дә булмаган».

Минзәлә кантонында руслар өчен татар теле курсы ачылса да, аның һичбер төрле нәтиҗә бирмәгәнлеген канткомиссия үзе үк әйтеп бирә.

Чистай кантонында руслар өчен ачылган татар теле курслары бер төрле дә нәтиҗә бирмәгәннәр. Рус хезмәткәрләре тарафыннан курска йөрү сон дәрәҗәдә начар булганга, 5 апрельдән курсны ябарга мәҗбүр булганнар.

Күренгәнчә, кантоннардагы татар теле курсларының хәле, шәһәрдәгеләргә караганда да начаррак булган.

Курс-түгәрәкләрдә руслар татар телен өйрәнсен өчен, ничә сәгать вакыт таләп ителгән соң? Гыйльми Үзәк тарафыннан билгеләнгән чикләр буенча, уртача хәзерлеккә ия руслар татар теленә өйрәнсен өчен, 400 сәгать вакыт кирәк: татарча иркен укый һәм яза белү, оешмага килүчеләрне кабул итү өчен җитәрлек күләмдә сөйләшә алу, язуларның гомуми эчтәлеген аңлау максатында 200 сәгать һәм татар телендә иркен рәвештә төрле язулар, докладлар төзү өчен тагын өстәмә 200 сәгать. 1925 елның 1 декабрендә татар теле түгәрәкләре эшчәнлеге турында Казанда җыйналган киңәшмәдә татар теле курсын башка милләтләргә урта күләмдә бирер өчен 400

сәгатьнең аз булуы ассызыклана, иң кимендә 550 сәгать чамасы вакыт билгеләнә. Ләкин Гыйльми Үзәк каршындагы фәнни-педагогик комиссия тарафыннан төзелеп, 1926 елда басылып чыккан «Татар булмаган җаваплы хезмәткәрләр курслары өчен татар теле программасы»нда исә 8 ай дәвамында, атнасына 6 сәгать шөгыльләнеп, ягъни 192 сәгать вакыт эчендә татар теленә өйрәнергә мөмкин дип саныйлар. *(Программа по татарскому языку для курсов ответственных работников не-татар. — Казань: Изд. ЦК по РТЯ, 1926 - С. 14).* Күренгәнчә, русларга татар телен өйрәтү өчен житәрлек вакыт күләмен билгеләү өлкәсендә дә бу чорда төрлелек хөкем сөрә.

Гаять күп сандагы түгәрәкләр эшчәнлеген контрольдә тоту, билгеле, авыр була. Алар һәрберсе аерым-аерым эш алып баралар, укытучыларның да һәркайсы үзенчә, булдыра алганча укыта. Җитмәсә, кайбер оешмаларда татар теле дәресләрен алып баручыларның «укытучы»лыгы татарча сөйләшә һәм яза алулары белән чикләнә, ә русларга татар теле укыту методикасын, рус аудиториясе үзенчәлекләрен белмәүләре исә исәпкә алынмый. Мәсәлән, 1924 елда Тышкы сәүдә халык комиссариатының Казан өлкә идарәсендә татар теле укыткан Галиев Әхмәд — «политехника институты студенты, русларга бер дә татар теле укытканы юк». Шул ук елда Күн трестында укыткан Локманов Фазыл — шулай ук югары уку йорты студенты, үзе үк: «татар телен һәм язуын урта дәрәҗәдә беләм»,— дип күрсәтә; 1923 елда Киез итек фабрикасында татар теле укыткан Маликов Латыйф — моңа кадәр балалар бакчасында эшләгән һ. б. Мондый мисалларны күпләп китерергә булыр иде.

Төрлесе-төрле жиргә сибелгән һәм артык күп сандагы түгәрәкләр эшчәнлеген оешканрак итү максаты белән, 1925 ел ахырында аларны территориаль билге буенча район курсларына берләштерергә, бары тик зур оешмаларда гына мөстәкыйль түгәрәкләр калдырырга карар кылына. 1926 елда Казанда — 13, кантоннарда 14 түгәрәк оештыру күздә тотыла. Ләкин 1927 елгы хисапта: «узган ел 45ләп түгәрәк эшләде»,— дип күрсәтелә. Димәк, түгәрәкләр саны әле бер ел эчендә генә кыскартылып бетми, ә 1927 елда исә аларның саны 6-7гә генә кала. Ләкин тагын каршылык: бу елда ике телне дә белмәүче хезмәткәрләрне татарлар яки ике телне дә белүчеләр белән алмаштыру планы кабул ителгәннән соң, «чын күнеленнән» татар теле өйрәнергә теләүчеләр саны күбәя һәм аларны укытып бетерү өчен элеккеге кебек күп санлы курслар һәм өстәмә чыгымнар таләп ителә. Әмма, бер яктан, инде түгәрәкләр саны азайган, икенче яктан, бу вакытта аппарат чыгымнарын кыскарту кампаниясе башлану нәтиҗәсендә, күп учреждениеләр үз сметаларыннан түгәрәкләр өчен дә акча бүлеп бирергә теләмиләр.

Эрерәк түгәрәкләр үз эшчәнлекләрен аклаганмы соң? Моны белү өчен, 1929 елга күз ташлыйк. Бу елда барлыгы 22 курс-түгәрәк эшләгән һәм аларда 597 кеше татар теле өйрәнгән. Мәгариф комиссариатында төзелгән тикшерү комиссиясе 80ләп кешенең татар теле буенча белемнәрен тикшерә һәм аларның бары 1сенә генә унай бәя бирелә! Бу сәер нәтиҗәне азрак йомшарту йөзеннән булса кирәк, «ләкин икенче елда шул 80 кешенең 60ы тикшерүне уңышлы үтә алачак»,— дип хәбәр ителә. 1930 елгы докладта исә артык җәелмичә, бер җөмлә белән генә курсларны 35 кеше бетереп чыгуы турында әйтеп үтәләр. Димәк, түгәрәкләрнең санын киметү, аларны районнар буенча берләштерү дә көтелгән нәтиҗәләргә китерми.

Татар теле курс-түгәрәкләре белән идарә итү 1925 ел ахырында Мәгариф комиссариатына тапшырыла. Бу елларда русларга татар теле өйрәтү өчен махсус программа һәм дәреслекләр чыгарылу, югары квалификацияле укытучыларны туплау, Татар педагоглары җәмгыятендә махсус секция төзү түгәрәкләр эшен азрак алга җибәрергә ярдәм итә. Ләкин, гомумән алганда, 20 елларның барлык документларында да диярлек татар теле курс-түгәрәкләренең беренче реаль нәтиҗәләргә китермәве ассызыклана. Күп еллар дәвамында эшләүләренә карамастан, аларда укып чыккан рус хезмәткәрләре татарча сөйләшә һәм оешмаларда татар телендә эш алып бара алмыйлар. 1927 елгы 3 сессия докладында әйтелгәнчә, «... татарча бер сүз дә диярлек белмиләр, йә сүгенү сүзләрен генә беләләр» *(Доклад ЦК по РТЯ «О положении дела по РТЯ и перспективах на 3-й сессии ЦИК ТССР 6 созыва 12—13 марта 1923 г. — Казань: Изд. ЦК по РТЯ, 1927. - С 68).* Шулай да бу сүзләр, гомумән алганда, дөрес булса да, югарыда унай яктан телгә алынган оешма хезмәткәрләренең барысына да «бер сүз дә татарча белми» дигән бәяләмә бирсәк, аларның тырышлыкларын санга сукмау булыр иде.

30 елларда да хәл яхшырмый. Дөрес, бу елларда таркау түгәрәкләрне берләште-

реп, бер үзәккә туплау юнәлешендә омтылыш ясап карала. 1933-34 елларда ТҮБКның Оештыру бүлеге каршында рус хезмәткәрләренә татар теле өйрәтү Үзәк курслары ачу турында положениеләр игълан ителә. Анда курсларны 2 еллык итеп оештыру, шул вакыт эчендә 320 сәгать күләмендә программа материалын үтеп бетерү турында сүз бара. Моннан тыш, эре предприятиеләрдә һәм районнарда Үзәк курсларның турыдан-туры идарәсе һәм контроле астында эшли торган 35 кешелек мөстәкыйль группалар оештырылырга; Курсларга татар халкы белән тыгыз бәйләнештә торган хезмәткәрләр тартылырга һәм бу оешмадагы татар эшчеләре гомуми санының 10 процетын тәшкил итәргә; курсларны бетергәннәр Үзәк квалификация комиссиясе тикшерүе аша үтеп, аларга таныклама бирелергә һәм андый кешеләр татарлар белән алмаштырылмаска; укытучыларның хезмәт хакы техникум укытучылары белән тигез булырга; курслар үзләренең штамп һәм печатенә ия булырга тиеш була.

Ләкин русларны татар теленә өйрәтү Үзәк курслары 1932-33 уку елында да эшләгән булырга тиеш, чөнки бу чорга караган берничә документ сакланып калган. Аларның беренчесе Үзәк курсларның эчке тәртип кагыйдәләренә багышланган. Бу кагыйдәләр буенча, уку елы 1932 елның 1 октябреннән башланып, 1933 елның 1 июнендә тәмамланырга тиеш була. Каникул вакытлары да билгеләнә: кышкысы — 20 январьдан алып, 1 февральгә кадәр; җәйгесе — 1 июньнән 1 октябрьгә кадәр дип тәгаенләнә. Дәресләр алты көнлеккә ике тапкыр 18 сәгать 30 минуттан 21 сәгатькә кадәр дәвам итәргә тиеш була. Курсларның ял итү көннәре бик кызык билгеләнә: һәр айның 6 , 12 , 18 , 24 һәм 30 числолары.

Педагогларның саны һәм исемнәре 1932/33 еллар өчен күрсәтелми, ләкин бурычлары бик ачык билгеләнә. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) дәрескә 5 минут алдан килергә; 2) укыту һәм эш планнары булырга, аларны уку-укыту бүлеге мөдиренә тапшырырга; 3) һәр курсантның өлгерешен һәм дәрескә ничек йөрүен билгеләп барырга; 4) үзенең группасындагы дисциплина өчен җавап бирергә; 5) яхшы дәреслекләр сайлануга җавап бирергә һәм кирәкле дәреслекләр исемлеген завучка үз вакытында тапшырырга; 6) педагогик һәм курсларның башка җыелышларында катнашырга; 7) дәресләрнең булу вакыты һәм сәгате турында төгәл мәгълүмат тапшырырга һәм дәрес өзелгән өчен җавап бирергә; 8) курслар администрациясе белән мөнәсәбәтләре эш буенча гына булырга тиеш һ.б.

1932-33 елларга караган икенче документ — Үзәк курсларның төрле оешмалар белән төзегән килешүләре. Бу уку елы өчен курслар 12 октябрьдән 10 февральгә кадәр 53 оешма белән килешү төзи. Оешмаларның күбесендә татар телен өйрәнергә теләүчеләр саны күп түгел: 2-3тән алып 15кә кадәр, ләкин кайберләрендә 25-30, хәтта 55 кеше саны китерелә. Килешүдә оешманың ничә сум акча түләргә һәм кайчан түләп бетерергә тиешлеге күрсәтелә. Бу елда бер курсант өчен түләү 65 сум исәбенә дә билгеләнә.

Ләкин килешү төзелгән 53 оешманың бары 16сында гына татар теле түгәрәкләре эшләгән булырга тиеш, чөнки исемлектә шуларның гына астына сызылып, курсантлар саны буенча нәтиҗә ясала. Ул оешмалар түбәндәгеләр: Мәгариф комиссариаты, Казан дәүләт университеты, Татар коммунистик университеты, Татполиграф, Милиция, Татторг, Татсоюз, Райпо, Татснабсбыт, Язу машиналары заводы, «Урак һәм чүкеч» заводы, Татжилсоюз, Дәүләт банкының Татарстан өлкә конторасы, 40 нчы завод, «Красный Восток» сыра заводы һәм Тимер юлчылары профсоюзы. Аларда барлыгы 470 кеше татар телен өйрәнә.

1932-33 елларда да русларга татар теле өйрәтүдә каршылыклар дәвам итә. Оешмалар тарафыннан бирелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, укытучылар үзләре үк дәрескә килмиләр яки соңга калалар; алар тарафыннан укучыларны кызыксындырырга тырышу күзәтелми; укытучылар еш алмашына (тимер юл эшчеләре профсоюзында, мәсәлән, 4 айга 3 укытучы алмашынган); курсантлар группаларга бүленми, шуның нәтиҗәсендә, бөтенләй татарча белмәүчеләр белән бераз-бераз яхшы укый һәм аңлый торганнар да утыра; курслар администрациясе тарафыннан тиешле күзәтү булмый, кимчелекләр турында хәбәр иткәндә дә, моңа әһәмият бирелми; 1933/34 уку елы өчен килешү төзү турында алдан хәбәр ителмәгән һ.б.

1933-34 елларда Үзәк курсларның ТҮБКның Оештыру бүлеге каршында эшли башлавы эшкә аз булса да уңай йогынты ясый, чөнки ТҮБКның авторитеты нәтиҗәсендә татар телен гамәлгә кую эшеннән читләшергә тырышкан, төзелгән

килешүләрнең шартларын үтәргә теләмәгән кайбер оешмаларның каршылыклары җимерелә.

1933-34 уку елында Курслар практик эшкә 15 августта гына керешәләр. 1 октябрьгә кадәр татар теле өйрәнүчеләре саны 300 кешене тәшкил иткән 25 оешма белән элеккеге килешүләр яңартыла, 215 кеше исәбенә 16 яңа килешү төзелә.

Бу еллар өчен Курслар штаты һәм укытучылар саны да билгеле. Куслар белән 3 кешедән торган аппарат идарә итә: курслар мөдире Бикчәнтәев Ш., инструктор-оештыручы Сәлимов Х. һәм эш башкаручы Гладышев В. Штатта 8 укытучы билгеләнә. Алар арасында күренекле татар язучысы һәм шагыйре Г. Кутуй, тел галиме Л. Җәләй дә бар. Сакланып калган документлар буенча, Г. Кутуй турында оешмалар уңай фикердә була. Мәсәлән, Казан тимер юлчылар профсоюзы Г. Кутуйның, башка укытучылардан аермалы буларак, укучыларны кызыксындырырга тырышуын, ләкин, кызганычка каршы, башка җиргә күчерелүен хәбәр итәләр. Г. Кутуй һәм Л. Җәләйдән тыш, бу вакытта курсларда КДУ укытучысы, доцент К. Хәмзин, доцент Галиев, татарлаштыру секторында эшләүче Бадамшин, безнең өчен таныш булмаган Тләшова, Еналиев, Зоричев кебек укытучылар татар теле укыталар. Мәсәлән, милиция һәм Татснабсбытта — Г. Кутуй, КДУда — Хәмзин, Татсоюзда — Л. Җәләй, Дәүләт банкында — Еналиев, Элемтә идарәсендә — Галиев, Мәгариф һәм Финанс комиссариатларында — Тләшова, «Красный Восток» сыра заводында Бадамшинның укытуы мәгълүм. Гомумән алганда, укытучыларның 60%ы — югары белемле, алар арасында доцентлар һәм ассистентлар була; 30%ы — урта белемле һәм 5 елдан да ким булмаган укыту стажына ия; 10%ы — түбән белемле, ләкин тәҗрибәле һәм зур педагогик стажлы.

Милициянең курслар белән төзегән килешүеннән күренгәнчә, бу елларда оешмалар өчен түләү бер курсантка 45 сум исәбенә билгеләнә һәм 20 кешегә килешү төзелеп, тагын 10-15 кешелек резерв күздә тотыла. Резерв өчен акча түләнми һәм алар, башкаларның дәресләргә катнашу-катнашмауларына бәйсез рәвештә, татар теле түгәрәкләренә йөрергә хокуклы булалар.

КДУда исә 21 кеше татар теле өйрәнергә тиеш була, алар арасында канцелярия һәм китапханә эшчеләре күпчелекне тәшкил итә.

Курслар эшендә бу елларда ТҮБКның ярдәме бик зур булса да, авырлыклар дәвам итә. Әгәр оешмалар курсларны, аларның администрациясен гаепләгән булса, курслар исә үзләренең хисапларында оешма җитәкчеләренең татар телен гамәлгә кую эшен аңлап һәм бәяләп житкермәүләрен, алай гына да түгел, курсларга нинди дер кимсетүле, санга сукмый торган мөнәсәбәттә торуларын күрсәтәләр. Учреждениеләрдә бервакытта да татар теле өйрәнү өчен акча булмый: яки ул сметада каралмый, яки югары инстанцияләр тарафыннан кабул ителми. Шулай ук оешмалар татар теле өйрәнү өчен, йә уку мөмкинлеге булмаган, йә эшендә татар теле кирәк булмаган кешеләрне билгелиләр (предприятие җитәкчеләре, кучер һәм каравылчылар). Шуларның нәтиҗәсе буларак, түбәндәге каршылыклар күзәтелә: дәресләргә начар йөрү, контроль булмау, техник проблемалар (бина, ут, җиһаз булмау), экстрен җыелышлар, өстәмә эшләр белән дәресләрне өзү һ.б. Хезмәткәрләрнең дәресләргә аз йөреп, эшнең нәтиҗәсе булмавын сылтау итеп, оешмалар акча түләүдән баш тарталар, моның белән курсларның матди хәлен дә начарайталар, укытучыларның кызыксынуын да бетерәләр.

Күренгәнчә, нинди генә омтылышлар ясап карасалар да, курслар эше уңышка китерми. Курслар оешмаларны, оешмалар исә үз чиратларында курсларны гаепли-гаепли, 30 еллардагы татар теле түгәрәкләре эшчәнлеге дә ахырына якынлаша. 1934 елдан соң алар турында бөтенләй мәгълүмат юк. Бу вакытларда Сталинның милләтсез һәм бер телле җәмгыять төзү идеясе тормышка ашырыла башлау, караңгы шәхес культы нәтиҗәсендә татар телен гамәлгә кую эше, шул исәптән, түгәрәкләр дә, әкренләп онытыла, юкка чыга.

20-30 елларда русларга татар теле өйрәтү теләге белән оештырылган курс-түгәрәкләрнең уңышка ирешә алмау сәбәпләре бик күп. Югарыда алар азмы-күпме чагылыш тапты инде. Аеруча әһәмиятлеләрен төркемләп, түбәндәге тәртиптә китерергә мөмкин:

1. Курсларның нәтиҗәсе булмауга китергән иң зур сәбәпләрнең берсе — руслар тарафыннан кызыксыну һәм теләк булмау, тарихи хәтернең саклануы. Моңа кадәр

дә татар телен файдаланмыйча яшәгән һәм хәзер дә аның кирәк булмавын күреп торган рус хезмәткәрләре бу телне өйрәнүне мәгънәсез һәм файдасыз бер эш дип саныйлар.

2. Ике телне дә белүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру, ягъни матди яктан кызыксындыру турында күп сөйләп, карарлар кабул итсәләр дә, гамәлдә бу эш тормышка ашырылмый кала. Эшкә алганда яки азат иткәндә татар телен белүчеләргә өстенлек бирү хакындагы карарлар да тулысынча кулланылмый.

3. Матди яктан кызыксындыру һәм башка бик күп шартларны тудыруга киртә булып торган зур сәбәп — акча булмау. Мәскәү бу эш өчен акча бирми, ә жирле бюджет ул елларда бик ярлы була. Шулай ук кайбер оешма житәкчеләре дә түгәрәкләр ачу һәм укытучы чакыру өчен акча бүлеп бирергә теләмиләр.

4. Русларга татар теле өйрәтү өчен белемле, методик әзерлекле һәм тәжрибәле укытучылар житешми. 30 елларда исә аларның булганнары да шәхес культы корбаны була.

5. Укытучыларның һәркайсы үзенчә укыта, уртак программа һәм дәреслекләр (бигрәк тә баштагы дәвердә) бөтенләй булмый.

6. Түгәкләрнең эшчәнлегенә житәрлек контроль булмый, алар белән идарә итү, оештыру эшләре кулдан-кулга күчеп йөри.

7. Дәресләр кичен, сигез сәгатьлек авыр эш көненнән соң уздырыла, ә хезмәткәрләргә исә эш сәгатеннән тыш та оешма хезмәтләрен башкарырга, жыелыш, лекцияләргә барырга кирәк була.

8. Аеруча оешма житәкчеләре, жаваплы хезмәткәрләр дәресләргә йөрергә вакыт таба алмыйлар, күбесенчә техник хезмәткәрләрдән торган түгәрәкләрнең исә шул сәбәпле авторитеты булмый.

9. Дәрескә йөрүчеләрнең составы гел алмашынып тора. Бу укытучының эшен дә бик нык авырайта, укытуның нәтижәлелеген дә киметә.

10. Кайсы хезмәткәрнең мәжбүри рәвештә татар теле өйрәнергә тиешлеге төгәл билгеләнми, «татар халкы белән тыгыз бәйләнештә булган» дигән гомуми сүзләр белән генә чикләнелә.

11. Түгәрәкләрнең күпме вакыт дәвам итүе, укытылачак сәгатьләр саны, дәресләрнең башлану һәм тәмамлану көннәрен билгеләүдә дә төрлелек хөкем сөрә.

12. Ят һәм авыр язылышлы гарәп язуы да русларның татар телен өйрәнүендә авырлык тудыра һ. б.

Бик кызганыч: тарих кабатлана. Бүгенге көндә дә, Телләр турындагы законны тормышка ашыруның бер тармагы буларак, республикабызның төрле оешмаларында русларны татар теленә өйрәтү курслары эшли башлады. Ләкин әкренләп, укуның бертөрле дә нәтижәсе күренмәгәч, аларның кайберләре эшчәнлеген туктатты, дәвам иткәннәре дә сүлпәнлек белән генә эшли. Түгәрәкләрнең уңышка ирешә алмау сәбәпләре дә нәкъ 20-30 еллардагы кебек үк, бары тик заман һәм кешеләр башка. Алда саналган сәбәп һәм киртәләрне булдыра алганча юкка чыгарып, татар телен гамәлгә кую эшен формаль нәрсә итеп караудан туктамасак, 20-30 еллардагы уңышсыз тәжрибә тулысынча кабатланырга мөмкин.

**Зоя КИРИЛЛОВА,**
*Казан дәүләт университетының татар теленә өйрәтү кафедрасы аспиранты.*

**Нурмөхәммәт Хисамов**

# МӨБАРӘК ТӘСБИХНЫҢ БЕР БУЫНЫ

Әдәбият галиме ул популяр зат түгел. Эстрада алкышлары күбрәк шагыйрьләргә һәм мәзәк остасы булган кече жанр әһленә насыйп. Галим исә, үз һөнәренә тулысынча тугры икән, узгынчы шөһрәткә бөтенләй битараф була. Шау-шулар дөньясына чумып, фән эшләп булмый. Әмма иҗат әһле, сәнгатькярләр дөньясы һәрвакыт гыйлем иясен үзенең эстрада мәнфәгатьләренә тартырга тырышкан. Шулар даирәсенең мәгълүм бер төркемен данлауга күчкән гыйлем иясен фани дөньяның алдагыч бизәкләренә төргән, эстрада лаврларыннан аларга да өлеш чыгарган. Гомерләрен фәнни иҗатка багышлап, безнең күз алдында бакый дөньяга кичкән гали затларның берсе дә андый алкышларны күрмәде һәм моны трагедия дип тә санамады. Вафатларыннан соң да зур үкенүләр, вөҗдан газабыннан тирән уфтанулар сизелми. Чөнки аларның хезмәт мирасы гаять бөек, кылган эшләренең мәгънәви тамырлары тирән. Шунлыктан аларны инләү һәм төшенү өчен Вакыт кирәк. Ә... шул ук Вакыт мирас һәм эшчәнлекнең, бай һәм катлаулы шәхесләрнең бик күп кыйммәтле төсмерләрен юып та узачак. Шунлыктан аларны теркәп, тарихта беркетеп калдыру—кичектергесез намус бурычы хисапланырга тиеш.

Менә ул, бу галәмнән кичеп, Ясәвиләр, Кол Галиләр, Мәрҗаниләр, Җәмал Вәлидиләр, Гали Рәхимнәр сафына барып кушылган затлар: Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госман, Гали Халит, Ибраһим Нуруллин һәм Нил Юзиев. Аларның берсе дә академик түгел. Дөрес, Нил ага мөхбир әгъза иде. Аның вафаты, Ибраһим Нуруллинныкы кебек үк, җан әрнеткеч үкенечле булды. Алар бик иртә киттеләр. Әмма бу бишәү гәүдәләндергән әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть тарихта беркайчан кабатланмас олуг дәвер булып кала.

Минем әле язарга алынган могътәбәр каһарманым—ул Хатип ага Госман. Былтыр аңа туксан яшь тулды. Матбугат бу вакыйганы билгеләп тә үтте. Аерым алганда, күләмле бер язмада мәрхүмнең батыр рухы, педагогик эшчәнлеге яктыртылды. Хәлбуки Хатип ага күпкырлы, киң колачлы талант иде. Холкы белән гаять катлаулы, Шекспир характерлары сыман көчле һәм кискен гайрәткә ия, әдәби осталыкка һәм гыйльми намуска, гражданлык кыюлыгына һәм фидакярлеккә карата максималистларча таләпчән галим булды. Аның көйдергеч тәнкыйтен һәм нәфрәтен татып калган кешеләр аны гомергә кичермәделәр. Аның эстетлыгына, эрудиция һәм теоретик зирәклегенә гашыйк кешеләр аны остаз итеп, изге зат күреп тәкъдирлиләр. Шуларның берсе, әлбәттә, мин.

Хатип ага, дәрәҗәләре югары булса да, конъюнктурадан өстен торып, милләткә, республикага киң колачлы фидакяр хезмәтне үзенең иман эше иткән шәкертләрен, дусларын дөньясын онытып ярата, хөрмәтли, данлый иде. Андый бәхетне өзлексез татыган кешеләр ул чактагы вице-премьер Мансур Хәсәнов, мәгариф министры вә академик Мирза Мәхмүтов һәм Хатип ага тарафыннан «фәннең рыцаре» дип аталган профессор Рәфыйк Нәфигов булды. Ул заман яшь галим хисапланган Фатыйх Урманчиев белән Миркасыйм Госмановка Хатип ага зур өметләр баглады.

Галимнең истәлегенә тел-теш тидерүдән ерак торган киң гаммә бар: ул— аның меңләгән студентлары.

Мин университетка килгәндә, инде монарчы да язганымча, Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Мөхәммәтшин, Мансур Крыймовлар хакында беркадәр хәбәрдар идем. Алар турында укытучым—Такташ шәкерте, шагыйрь, көйче, гармунчы һәм рәссам Абдулла ага Абязов сөйләгән иде. Уналты яшьтән Байрон белән «авырган», Такташка гашыйк, Маяковский һәм Назыйм Хикмәт рухында шигырьләр язган, Гаяз Исхакый һәм Әхмәтзәки Вәлиди хезмәтләреннән беркадәр мәгълүматлы, Мәрҗани һәм Риза Фәхретдиневне ихтирам итүче, Илья Эренбург белән хатлар алышкан, кайбер шагыйрьләр белән якыннан таныш, шигырьләрем һәм мәкаләләрем матбугатта чыккан бер егет идем. Өйдәге «Шура» журналы төпләмнәрен әтиебез гомер буе гаиләдә кычкырып укыды. Бала һәм яшүсмер колагына аз булса да эленеп калгандыр. Әмма Хатип аганың беренче лекциясен тыңлагач, үземне гаять фәкыйрь һәм кечкенә итеп сиздем. Дөнья мәдәнияте ничаклы серләрне үзенә җыйган, дип хәйран калдым. Шул ук халәтне барлык сабакташларым да кичерә иде.

Хатип ага үзенең язма хезмәтләрендә киң карашлы теоретик буларак даһилыкка якын ачышлар һәм гомумиләштерүләр ясаса да, ул башлыча үзенең лекцияләрендә тиңдәшсез галим һәм сәнгатькяр булды. Аның шигърият хакындагы лекцияләре шигъриятнең үзеннән дә гүзәлрәк иде. Әдәбият фәненең кайсы гына төшенчәсен ачуга алынса да, ул дөнья поэзиясеннән Вергилий яки Данте, Шекспир яки Һете, Шиллер яки Һәйне, Пушкин яки Фет иҗатлары аша узган системаны тасвирлап бирә, әлбәттә инде Тукайны йә Такташны сөйли, борынгы юнан, Рим, Көнбатыш Аурупа, урыс, украин, лях, латыш, үзбәк, әзәрбәйҗан шагыйрьләренең гүзәл әсәрләреннән озын-озын өзекләрне яттан укый. Нәтиҗәдә татар әдәбият галиме татар студентларына дөнья шигъри сәнгате бай һәм аерылгысыз бербөтен дигән төшенчәне бирә, киң карашлы эрудитлар тәрбияли. Галимнең шул чактагы йөзен, чыраен күрсәгез! Андый рухланган гүзәл йөзне мин бүтән беркайда, бер җирдә һәм беркемдә күргәнем булмады. Беренче лекциясеннән мин аңа тәмамән әсир булдым, бүген дә шул халәттә калам. Гаять киң эрудицияле кызыклы галимнәр бар. Әмма аларның әңгәмәсе файдалы булса да, корырак була. Хатип ага лекциясенә мин могҗиза итеп карый идем. Хикмәт аның шагыйрь дә булуында икән.



*Профессор Хатип Госманны университет проректоры Миркасыйм Госманов 75 яшь тулу уңае белән котлый. 1983 ел.*

Бервакыт студентларның фәнни түгәрәгендә—Хатип ага тәкъдиме белән мин аның рәисе идем—мөхтәрәм остазыбыз үзенең гыйльми иҗат тәҗрибәсен уртаклашты. Элек шигырьләр язуын сөйләде, кайбер әсәрләрен укып та күрсәтте. Күтәренке рухлы романтик шигырьләр... «Мин шагыйрь була алмадым»,—диде ул аннары, уфтанулы аһәң белән һәм шигърият галименнән таләп ителгән сыйфатлар турында сөйләп китте. Ләкин Хатип ага шигырь укыса да, шигърият хакында сөйләсә дә, йөзләренә һәм тавышына илаһи рухлану төсмере чыга иде. Аналитик акыллы, киң колачлы теоретик, шигъри иҗат тәҗрибәсен узган, шагыйрь табигатьле титан, сәнгати матурлыкның тирәндә яткан серләрен тугызынчы дулкын биеклегенә күтәреп, аудиторияне сихерли, гүзәллеккә сугара.

Мин 1981—82 уку елында инде фән кандидаты булып, «Татар әдәбияты тарихы»ның борынгы дәверен яктырткан 1 томын редакцияләп бетергәч, Фәннәр академиясе стажеры булып Ленинград университетының Көнчыгыш факультетына киттем. Гарәп һәм фарсы филологиясе буенча дәресләрем программасын төзегәндә, кафедра лаборанты Яна Александровна А. А. Болдыревның фарсы әдәбияты лекцияләренә йөрергә тәкъдим итте. «Монсы сезгә филармония урынына»,—диде. Чыннан да мәрхүмнең дәресләре йотылып тыңларлык күркәм иде. Әмма Хатип ага лекцияләрен тыңлап үскән кешене берни белән дә гаҗәпләндерә алмыйсың.

Алтмышынчы елларда язучыларның Тукай клубында бер әдәби җомга Бакый ага Урманчыны Тукай бүләгенә тәкъдим итүгә туры китерелде. Бөек рәссам һәм сынчының «Дәрдмәнд» сурәтен эшләүдәге талантлы уңышын яктыртып, Хатип ага шагыйрь иҗатын бәяләүдә уннарча елларга сузылган ялгыш карашларны сүтте, аның әсәрләрен укып анализлады. Совет идеологиясенең нәфрәт объекты булган шагыйрьнең капиталистлыгына кагылып: «Аның гүзәл шигъри таланты янәшәсендә капиталистлыгы фәкыйрь, хәерче бер нәрсә. Ә шигъри мирас байлыгы мәңге югалмас алтын хәзинә»,—диде. Язучылар рәхәтләнеп кул чапты. Тәнәфестә Фатих Хөсни, Хатип аганы биленнән кочып: «Сине әдәбият фәненә җибәреп, галим иткәндә ничаклы дөрес эшләгәнбез!»—диде. Әдип үзе дә илленче еллар матбугатында Дәрдмәндне яклап кыю мәкалә белән чыккан кеше.

1958 ел. Җәмгыятьтә XX съезд һәм Хрущев идарәсенең шактый бәрәкәтле җылысы хөкем сөргән чор. Без—якташым һәм сабакташым Шәйхи Садретдинов белән дүртенче курс студентлары. Икәү киңәштек тә, беребез Сәгыйть Рәмиев иҗатын, икенчебез Дәрдмәндне тикшеренү темасы итеп бирүен сорарга Х. Госман янына киттек. Хатип ага безнең тәкъдимгә бик сөенеп кушылды. Шушы темага—курс эше, аннары диплом эше яздык. Шәйхи «Рәмиевче», мин «Дәрдмәндче» булып киттек. Диплом яклаганда, Әхмәт Исхакны оппонент итеп чакырдык. Мәгәр ул минем хезмәткә кискен каршы чыкты. «Шушы буржуаз шагыйрьне Тукай белән янәшә куясыз!»—дип гаепләде. Оппонентлыкны әдәбият кафедрасының яшь укытучысы, факультетның декан урынбасары Мансур Хәсәнов үз өстенә алды һәм диплом эшенә, дипломчының үзенә үтә юмарт, югары бәя бирде. Соңрак язмыш шушы вазгыятьне фән өчен иң югары кимәлдә, докторлык яклаганда, кабатлады: Дөнья әдәбияты институтында минем хезмәтнең беренче оппоненты академик Мансур Хәсәнов булды. Хатип ага да бик канәгать булып, аспирантурага чакырачагын әйтте, һәм ике елдан, район газитен калдырып, мин аның аспиранты булдым. Безнең арада үтә җылы, яратулы мөнәсәбәт дәвам итте. Бу хәл миннән өлкәнрәк курс аспирантлары М. Мәһдиев белән Ф. Миннуллинның бераз эчләрен пошырганын да сизә идем.

Шигырьләр язып, матбугатта бастыруымны һәм нәшриятка җыентык туплап тапшыруымны белгәч, Хатип ага миңа суына башлады. Бу суыклык әкренләп ачуга һәм үчегүгә күчте. Аңа тугрылыкны үземнең әхлакый гамәлем иткән минем өчен бу хәл гаять газаплы иде, яраткан өч улым һәм гаиләм булуга карамастан, вакыт-вакыт хәтта яшисем килмәгән чаклар да булды. Хикмәт бары шунда иде: Хатип аганың өмет баглаган шәкертендә үз «ялгышларын» күрәсе килмәгән, берниндн «чит мавыгуларсыз» бары үзенең гыйлеменә хезмәт иттереп, фән үрләренә тиз күтәрәсе килгән.

Безнең дуслык тирән һәм төпле нигездә булганлыктан, мөнәсәбәтләребез соңрак иске эзенә кайтып төште. Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор

бүлегендә Кол Гали әсәренә багышланган монографиямне тикшергәндә, Хатип ага Лобачевский скверында мине көтеп утырган. Чыксам—ашыга-ашыга каршыма килә: «Тикшерү ничек узды?»—ди. Мин тирән рәнҗү белән: «Хезмәтемне аңламадылар!..»—дидем.—Бары ике кеше: Нил абый Юзиев һәм Флора Әхмәтова төшенеп һәм хуплап сөйләде. Дөрес, Курбатов «бездә әле мондый монументаль хезмәт язылганы юк иде»,—дип бәяләмә җибәргән, ләкин аны укуны кирәк тапмадылар»,—дидем. Хатип агам: «Бу—сезнең бәхетегез, димәк, хезмәтегез озын гомерле булыр»,—дип юатты. Нил Юзиев аның гомер буе яраткан шәкерте булып калды.

Менә «Әдәбият тарихы»ның 1 томын редакцияләргә дип, мине әдәбият бүлегенә чакырып алдылар. Дөньямны онытып, илһамланып эшләп йөргән чагым. Хатип ага Лобачевский бакчасына чакырып чыгарды. Пенсиягә киткән. Мине университетка кодалый: «Лекцияләр курсымны тулысынча Сезгә бирәм, докторлык эшләү өчен барлык шартлар да тудырылачак, кафедра мөдире Альберт Яхинның Сезгә мөнәсәбәте бик яхшы»,—ди. Бу—минем өчен көтелмәгән тәкъдим иде, уйлану өчен бер атна вакыт сорадым.

Бер атнадан шул ук урында очрашабыз. «Ничек?»—ди Хатип ага беренчи кереш сүзсез һәм түземсезләнеп: «Нил абый зур ышаныч белән мине чит сектордан чакырып алды, дирекциянең мөнәсәбәте үтә яхшы, фатир чиратым да якын...»—дип башлаган идем, Хатип ага үзе дәвам итте: «Мин бу хакта нык уйландым да, әгәр Сез чын кеше икән, риза булмассыз, дидем»—ди.

«Хатип ага, Сез мине чын кеше дип санагыз»,—дидем житди дә, бераз шаярып та. Профессор кызгану белдерде, сүз шунда төкәнде.

Еллар узды. Ринат Мөхәммәдиев Хатип аганың «Шигърият гомере» дигән китабына «Казан утлары» өчен рецензия язуымны үтенде. Биш көн эчендә хезмәтне укып, рецензияне язып чыктым. Галимнең олы талантына һәм аналитик куәтенә сокланып, илһамланып яздым. Автор классик әдәбияттан яңа әдәбиятка күчеш күперләрен барлый, зирәк гомумиләштерүләр ясый, ачышларында әледән-әле даһилык чигенә килеп чыга. Мәкаләне «Бөек яңарышның чишмәләре» дип атадым. Хатип ага, аны журналда укыгач, яныма килеп, канәгатьләнүен белдерде, үзе турындагы язмалардан беренче тапкыр шулай җан рәхәтлеге алуын әйтте, бәяләмәнең исемен мактады. Дөрес, язма кемнәрнеңдер эчен дә пошырды...

Хатип ага белән соңгы мәгънәви әңгәмәбез минем «Бөек язмышлы әсәр» дигән китабым чыккач булды. 1984 ел, Кол Галинең 800 еллыгын бәйрәм итүгә нәкъ бер ел үткән. Телефоннан сүз куешкач, китапны алып, остазымның өенә киттем. Багышлау язмасын укып, китапны игътибар белән актарып чыккач, күзләрен кыса төшеп, йөзенә илһамлы алсулык йөгертеп, минем өчен көтелмәгән, әмма онытылмаслык сүзләрен әйтте:

— Нинди бәхет: миннән соң Сез бар! Тик миннән каттый васыять—Сезгә: үзегездән соң шәкертләр калдырыгыз. Ләкин шагыйрьләр алыгыз. Сез үзегез шагыйрь булганга, шигырьләр серен эчтән төшенеп язасыз...

Шулай итеп, безнең остаз-шәкерт коллизиясенең, гайрәт чигүдән соң янә рухани кардәшлеккә кайтуның диалектик спирале шигырь тикшерү өчен шагыйрь булуның да кирәклеген тануга кайтып төште.

Юк, юк, Хатип Госманга җуелмас ихтирамым һич тә аның миңа җылы мөнәсәбәтенә генә бәйләнмәгән. Ул миңа үтә тискәре карашта чагында да әле аны яратудан туктамадым. Моны Хатип агага төрле елларда якын торган даирә кешеләре яхшы белә: Марсель Бакиров, Альберт Яхин, Ринат Мөхәммәдиев, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Галимҗан Гыйльманов, Җәмил Зәйнуллин моңа һәрвакыт шаһитләр.

Хәлбуки һич кенә дә бөекләр ялгышмый дигән сүз түгел. 1979 елда Дөнья әдәбияты институтында минем кандидатлык диссертациясен тикшергәндә, Г. Ломидзе, Р. Юсуфов, З. Османова һәм Х. Күроглы кебек олы галимнәр, хезмәтемне тулаем хуплаганнан соң, Кол Галине «Көнчыгыш ренессансы» дигән төшенчә белән бәйләгән өчен нык кына тәнкыйтьләделәр. Асылы белән антик сәнгати кыйммәтләргә әйләнеп кайтуны күздә тоткан саф Аурупа мәдәни күренешен, терминның яңгыравык булуына кызыгып, Шәрекъ әдәбиятына карата куллануны бөтенләй нигезсез, диделәр. Чөнки Шәрекъ инсаният (Көнчыгыш һуманизмы)—

Аурупа Ренессансыннан иртәрәк туган, аңардан баерак һәм уникаль күренеш. Аның чагылыш сыйфатларында Аурупа Ренессансына охшаш типологик билгеләр булса да, үзенең икътисади, сәяси һәм мәдәни алшартлары белән дә, нәтиҗәви үсеше белән дә Шәрекъ Инсанияте кабатланмас үзенчәлеккә ия. Мин хөрмәтле оппонентларыма дәлил итеп академик Н. И. Конрад тәгълиматын китердем. «Даһи булса да, бу очракта Конрад ялгышкан»,—диделәр. Мәсьәләне махсус өйрәнә торгач, аларның хаклыгына ышандым.

Хатип аганың җитди ялгышы татар шигъриятендә гаруз бөтенләй булмаган, дигән карашны уздыруында иде. Аннары исә икенче ялгышка тайпылды: янәсе гаруз төрки шигъриятнең үз табигатендә юк бар. Бу хата фикернең безнең өчен аяныч нәтиҗәсе шунда булды ки, без әле хәзер дә классик шигырьне дөрес ритмик тынышлар белән укый белмибез. 1986 елда Тукайның 100 еллыгы уңае белән ясаган фәнни докладта, галимнең исемен әйтмичә генә, бу карашны тәнкыйтьләп чыктым. Хатип ага бер ел рәнҗеп йөрде. Әйе, аның шәхесендәге чагылыш гаммасы гаять бай һәм катлаулы иде.

Урта гасыр шигъри мирасын халыкка кайтаруның авыр һәм колачлы эшләрен, үзенең тирән белеме һәм кодрәтле абруе белән Хатип ага башлады һәм юлга салды, аспирантура аша шушы өлкәнең белгечләрен әзерләде. Камил Дәүләтшин, Хатыйп Миннегулов, Әнвәр Шәрипов, Нәҗип Исмәгыйлев—шушы исемнәр үзләре генә дә галимнең күркәм мирасы була ала. Мине исә мәрхүм профессор XX йөз башы татар лирикасы белгече итеп тәрбияләп чыгарды. Минем әүвәлге тикшеренү өлкәм Тукай, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев шигърияте иде.

Әдәбиятның зур программ тарихы языла башлаганчы, Х. Госманның «Татар поэзиясе антологиясе»нә кереш, яки «Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны» кебек концептуаль платформа сызган күләмле тикшеренүләре кирәк булды. Галим гомеренең соңгы елларына чаклы кызыклы, яңарып, сафланып тора торган шәхес булды. Чөнки ул гомер буе өйрәнде, дөнья әдәбиятына, бөтендөнья әдәбият фәненә, гыйльми яңарышка карата үзен тикшеренүче теоретик итеп кенә түгел, комсызлык белән гыйлем эстәүче шәкерт итеп тә тойды. Бу мәгънәдә ул барлык буыннар өчен өлге булып кала. Аның иң соңгы фундаменталь хезмәте төрки-татар шигыренең ритм-калып-сәнгать тамырларын ачкан һәм нигез үзенчәлекләрен яктырткан «Төрки-татар шигырь төзелеше» дигән китабы булды. Бүгенге шигъриятта гайрәтле каләм тибрәтүчеләрдән Әхсән Баян, Равил Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗан, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт, Разил Вәлиев, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Рифә Рахманнар сафы турыдан-туры Хатип аганың матурлык мәктәбеннән юл алган. Мәңгелек пантеонга керү өчен бу абруй үзе генә дә җитәр иде.

*1999, 3 гыйнвар*

**Галиәсгар Камал**

# ИСТАНБУЛ МӘКТҮБЛӘРЕ

## VII

Бу көннәрдә таралган хәбәрләрдән берсе икенчесенең хилафындадыр (киреседер). Бүген кичкә таба Балкан хөкүмәтләре илә Төркия арасында солых ясалган имеш дигән хәбәрләр таралган шикелле, чаталар (чата—чета, четник—партизан отряды, фетнәчеләр) илә Төркия гаскәренең аллагы фиркаләре арасында сугышлар башланган имеш дигән хәбәрләр дә таралды. Хәтта кичә кич илә Чаталжадан туксан кадәр мәҗрух килгән дигән хәбәрләр дә ишетелде.

Шунлар илә бәрабәр бу көн иртә илә һәм кичә кич чыккан гәзитәләрдә Төркия тарафыннан Лондонга киткән мөрәххәсләрдән: «Без бунда дәхи унбиш көнгә кадәр калып солых хакында мөзакәрә итәчәкмез»,—дигән хәбәрләр дә күренде. Истанбул гәзитәләрен укып, хәлнең хакыйкатеннән хәбәрдар булу һич мөмкин түгел. Гәзитәләрдә бер-берсенә хилаф булган хәбәрләр бик күп.

Хәзерге көндә һич шик кыйлмыйча сөйләнәчәк бер сүз бар исә, ул кәнеж төрек «Иттихад вә тәрәккый» фиркасенең галәбәседер (җиңүедер). Хәзерге көндә әфкяре гомумия кәнеж төрекләр тарафына авышкан шикелле, хөкүмәт тә анлар тарафына күчә башлады.

Арада бер өченче фирка тәшкил итәргә теләп йөргән Лотфи Фикринең «Тәнзыймәт» исемле гәзитәсе туктатылып, үзе хәрби хөкемгә бирелде. Кичә Солтан Мөхәммәд, Сәгыйд пашаны үзенең хозурына дәгъвәт итеп, берничә сәгатьләр киңәштә булды. Бу эшкә төрекләр, Камил паша кабинетының игътибардан төшеп, яңа кабинет тәшкил итүнең ишарәсе дип карыйлар. Сөйләүләренә караганда, вәли гаһед (патшаның үзе урынына тәхеткә утырачак варисы) шаһзадә Йосыф Гыйззетдин илә Камил пашаның аралары тәмам бозылган. Әгәр дә Камил паша садрел-әгъзам (баш вәзир) булып калса, Йосыф Гыйззетдин вәли гаһедлеген ташлаячакны игълан иткән. Халык арасында хәзерге көндә Камил пашаның бер кыйммәте дә калмады... Камил пашага һәркем мәмләкәтне сатучы бер кеше дип карый.

Көзге вә кышкы көннәрдә Истанбулның һавасы никадәр тиз алмашынучан булса, Төркиянең сәясәт галәме дә шулкадәр үк тиз алмашынучандыр. Бүген иртә илә булган хәл кичкесенә охшамый.

Бу көн мин Чаталжадан кайткан бер йөз башы забит (офицер) илә күрешеп, андагы гаскәрләрнең хәлләрен сораштым. Минем сөальләремә каршы ул кеше ошбу түбәндәге сүзләрне сөйләде:

- Безнең Чаталжадагы гаскәрләрнең хәлен бик яхшы дип әйтеп булмый. Чөнки бундагы безнең гаскәрләрнең иң күбесе истихкямнәрдә (хәрби ныгытмаларда) чатырлар астында яталар. Һавалар юеш, кичләр салкын, әтраф бычрак вә баткак. Чатырларның эчләре дә юеш. Хәзерге көндә гаскәрләрнең ашамак эчемлекләре мөкәммәл, һәркөн Истанбулдан бер поезд илә яна вә

---

Ахыры.Башы журналның 4 санында.

йомшак икмәк килеп тора. Шулай булса да, суыклык һәм юешлектән гаскәрләр хили зәхмәт чигәләр. Гаскәрләрнең һәммәсен авылларга җирләштерү мөмкин түгел, чөнки Истанбул илә Чаталҗа арасында авыллар гаскәрләрне җирләштереп бетерерлек дәрәҗәдә күп түгел. Гаскәрләрнең сыйган кадәресе авылларга җирләштерелде, ләкин ике йөз ун мең гаскәрне бу авылларга җирләштереп бетерү мөмкин түгел, шул сәбәптән гаскәрләрнең күбесе чатыр астында яшиләр. Дошман тарафыннан булган гаскәрләрнең микъдары, бердән, безнекенә караганда аз, икенчедән, ул тарафларда карьяләр күп булганлыктан, дошман гаскәренең әксәре карьяләргә җирләштерелгән. Безнең тараф салкынлыктан зәхмәт чиккән шикелле, анларның гаскәриләре ашау юклыктан зәхмәт чигәләр дип сөйлиләр, асылы ничектер, белмим,—диде.

Бу көнгә кадәр Төркия гаскәрләре эчендә вак-төяк сәүдәгәрләр ашамак-эчмәк нәрсәләр илә сәүдә кыйлып йөриләр иде. Бунлар полиция идарәсеннән иҗазәт (рөхсәт) алып китеп, анда иркенләп сәүдә кыйлалар иде.

Соңгы көннәрдә бунлардан берникадәр кешеләрнең болгар гаскәренә качырып азык ташыганлыклары мәгълүм булды, һәм Болгариягә азык ташучылардан тугыз адәм тотылып, гаскәри мәхкәмәгә (хәрби трибунал) бирелде. Шул сәбәптән, хәзер мөхарәбә мәйданына (сугыш мәйданына) вак-төяк сәүдәгәрләр җибәрелми. Бундагы сәүдәләрнең һәркаюсы зур кулларга бирелде. Әгәр дә бер кеше бу җирләргә барып сәүдә кыйлу ирадәсендә (теләгендә) булса, иң әүвәл өч йөз лира кадәр залук салып главный штаб идарәсеннән рөхсәт алырга мәҗбүрләрдер. Бу рөхсәт тә әминиятле (ышанычлы) кешеләргә генә биреләдер. Болгария гаскәрләренә азык качыручыларның әксәре Төркия тәбагасы булган (Төркия гражданы булган) греклар икән, араларында Болгариядән качып килгән болгар гаскәриләре дә бар.

Кичә чыккан Төркия гәзитәләрендә Әдернәгә азык кертелә башланганлыгы язылды. Әгәр дә ике арада чаталар илә атышулар башлаганлык хәбәре дөрест булса, бу хәбәрләргә ышанып булмый.

Бу көн Солтан Ришад мөхарәбә мәйданындагы гаскәрне карап кайту өчен Чаталҗага китте. Кичкә таба чыккан хәбәрләрдә Сәгыйд пашаның садыре-әгъзам булып, Мәхмүд Шәүкәт пашаның бөтен гаскәргә камандирлык итәчәге сөйләнде.

Венада сәфир Хөсәен Хилми паша Истанбулга чыккан. Бәгъзе кешеләр аның садыре-әгъзам булуын ихтимал тоталар.

Бүген Истанбулга берникадәр болгар әсирләрен китереп, Анатолия тарафына озаттылар. Буңар караганда, ике арада аз-маз булса да мохадәгаләрнең (алдашу-хәйләләшүләрнең) башланганлыгы ихтимал тотыла.

Чаталҗага гаскәр күндерү тукталды. Анда китә торган поездлар фәкать азык һәм сугыш ярагы ташу илә генә мәшгульләрдер. Хәзерге көндә килгән гаскәрләрнең һәммәсе дә дип әйтерлек Кәлибулигә озатыла. Кәлибулигә гаскәри булмаган кешене җибәрмиләр. Юлчылар фәкать Чанаккалага гына бара алалар. Көн саен дип әйтерлек Истанбулга хаҗилар кайталар. Отелләр (номерлар) һәм ханәләр һәркаюсы хаҗилар илә тулы. Одессага китә торган пароходлар хаҗиларны бик сайлап кына алалар. Хаҗиларның һәммәсе дип әйтерлек Төркестан, Кашгар, Иран вә гайре җирләрдән килгән кешеләрдән гыйбарәттер. Бунларның пычраклык, тәмизсезлек вә игътибарсызлыкларын һич сөйләп бетерерлек түгел.

Истанбулдагы дәллял вә симсарларның (маклер һәм агентлар) хаҗиларны талауларына тәмам ис китәрлекдер. Мәсәлән, Истанбулдан Одессага кадәр өченче класс билеты алты сумдыр. Хәлбуки, симсарлар хаҗилардан унсигезәр сум каералар. Әле бу пароход билеты тугърысында гына шулай. Әгәр дә анлар Истанбулга чыкканнан соң берәр нәрсә алачак булсалар, анларның эшләре бөтенләй харап. Ике тиенлек тәсбих анлар өчен ике грош (12 тиен), кырык тиен тора торган номер сиксән тиендер. Дәлялләр соңыннан сатучы яки номер тотучы илә файданы көлешә-көлешә бүлешәләр. Казан яки Кырым әтрафыннан килгән хаҗиларга дәлялләр ул кадәр илтифат та итмиләр һәм анларны үзләре теләгән дәрәҗәдә алдый да алмыйлар.

Әүвәл заманда Истанбулда акча алмаштыру мәсьәләсе дә зур бәла иде. Сарифлар (акча ваклаучы, акча алмаштыручылар) халыкны теләгәнләренчә алдыйлар иде. Хәзерге көндә күзе ачык кешеләр каршында бунларның әһәмиятләре

калмады. Чөнки хөррият булганнан соң кәнеж төрекләр вак акчаны бик кубәйткәннәр, әүвәлдә «мәтәлилек» дип тәгъбир ителә торган вә бик зурлары беленми торган бакыр акчалар урынына ак мәгъдәннән (металлдан) эшләнгән матур акчалар йөри. Дүртенче көн Төркиянең акчалар сугыла торган зарбханә (монетный двор)ны барып карадым... Бунда акча суга торган унике данә машина бар, һәркаюсы электрик илә хәрәкәт итәләр. Әүвәлдә машиналарны Англия яки Франциядән китерәләр, хәзер төрекләр үзләре ясыйлар. Читтән килгән иске машиналарны таратып куйганнар, яңадан төзәтеп эшкә кертәчәкләр. Шунда хезмәт итә торган төрекләрдән берсе алтын үлчәр өчен бер үлчәү ихтирагъ иткән (уйлап тапкан). Бу үлчәү мыскалның туксан алтыдан бер өлеше булган долянең дүрттән бер өлешеннән үлчи аладыр.

Зарбханәнең мөдире Габдрахман бәк (Кырым татары)ның сөйләвенә караганда, әүвәлдә бунда хезмәт итүчеләрнең күбесе әрмәниләр булганнар. Хәзерге көндә фәкать өчесе әрмәни булып, калган һәммәсе дә мөселманнардыр. Элек Истанбулда телефон юк иде, хәзер хөкүмәт даирәләре һәм полиция идарәләренең һәркаюсында телефоннар булган шикелле, зур тиҗарәтханәләренең дә һәркаюсында телефоннар бар. Хәзерге көндә дә һәр җирдә телефон ясап яталар...

## VIII

Актык дәкыйкаләр якынлашты. Бу мәктүбне язган заманда Төркия илә Балкан хөкүмәтләре арасында яңадан сугышлар башлануга фәкать алты гына сәгать калды. Балкан хөкүмәтләре Әдернәне, Ак диңгездәге атауларны һичбер шарт һәм кайдсыз (шарт һәм язу-беркетмәсез) үзләренә алырга телиләр, төрекләргә бу хакта ультиматум бирделәр. Әгәр Төркия бу көн өйләдән соң сәгать дүрттә ризалык җавабы бирмәсә, сугышырга башлаячаклар. Төркиянең бу шартларга һичбер разый булу ихтималы юк. Хосусән, кәнеж төрекләр Төркия өчен зур хурлык булган бундый солыхка риза булырга һич теләмиләр. Шул сәбәптән сугыш башлану ихтималы бик куәтледер.

Көн-төн һич туктаусыз Чаталҗага гаскәр, азык һәм сугыш яраклары ташып торалар. Ике-өч көн бундан мөкаддәмдә Германиядән берничә батарея туп килде. Аларның да һәммәсен Чаталҗага озаттылар.

Төркиянең сугыш пароходлары да һәркаюсы эштә. Бер тарафтан Ак диңгездә Греция пароходларына каршы торган шикелле, икенче тарафтан да Болгариягә читтән ярдәм килмәсен өчен Варна лиманын (Варна портын) саклыйлар.

Соңгы көннәрдә гаскәр өчен уңайсызлык баш күтәрде. Бу көнгә кадәр Истанбулда һавалар җылы һәм кояшлы иде. Егерменче декабрьгә каршы төндә һава бердән-бергә алмашынып китеп, салкынланды. Егерменче декабрьгә каршы төндә дүрт дәрәҗә кадәр суыклык булып, сулар катты. Шул көннән бирле аз булса да суыклык дәвам итә һәм һәркөн дип әйтерлек ягмурлар ява.

Һаваның начарлануы гаскәргә бик зур тәэсир итте. Гаскәр арасында авыруларның артуына сәбәп булды. Бу көннәрдә Чаталҗадан меңнәрчә хәстә гаскәриләр Истанбулга килә башладылар. Соңгы көннәрдә бушап килә торган хәстәханәләр яңадан гаскәриләр илә тула башлады. Һавалар суыклану сәбәпле холера азайса да, ревматизм, дизентерия кеби хасталыклар көннән-көн артып бара.

Болгарлар Әдернәне куәт илә алмаганлыкларыннан хәзер, прокламацияләр таратып, халыкны үзләренә каратырга тырыша башладылар. Болгария аэропланнары Әдернә шәһәренең өстенә килеп төрле вәгазь һәм нәсыйхәтләрдән гыйбарәт булган прокламацияләр тараталар. Иттиляфчылар соңгы көндә хили какшадылар. Аларның солых тарафдарлары булулары вә иттихадчылар (кәнеж төрекләр)нең сугыш тарафдары булулары аркасында, әфкяре гомумия бөтенләй кәнеж төрекләр тарафына авышты. Төрекләр Әдернәне кулларыннан ычкындырырга бер дә теләмиләр, ахыр сулуларына кадәр көрәшергә хәзерләнәләр. Төрекләр хәзер үзләрендә мөттәфыйкъ (союздаш, фикердәш) дәүләтләргә каршы торырлык куәт хис итәләр. Шул сәбәптән бу көн кич Истанбулда туп тавышларының ишетелә башлаулары ихтималдыр.

## IX

Хәзерге көндә солых булачакмы, юкмы—Истанбулда һичкем белми. Шулай да булса янадан сугышларның башлануын фараз кыйлып булмый. Истанбулда һавалар тәмам бозылды. Кичләрдә кар ява, көндезләрдә ягмур явып бөтен урамнарны былчыракка батыра. Һәр жирдә юешлек һәм салкынлык хөкем сөрә. Һаваның начарлыгы әһалигә (халыкка) дә бик начар тәэсир итә. Бундан берничә көн элек үзләрен бик нык һәм куәтле дип фараз кыйлган вә сугыш тарафдары булган төрекләр бу көн солых тарафдары була башладылар.

Безнең Русиядәге суыкларга караганда бундагы суыклар бик аз булса да, бездәге шикелле таза итеп салынган мичле өйләр булмаганлыктан, суык өйләрдә яшәүче адәмнәрнең хәлләре бик начардыр. Суыклык аркасында инфекция, дизентерия һәм ревматизм хасталыклары бу жирләрдә бик күптер. Һавалар соңгы көннәрдә бик бозылды. Бик каты шималь (төньяк) давыллары исә.

Берничә көн бундан мөкаддәм «Русское общество»ның пароходларыннан «Синиус» исемле пароход илә өч йөз илле кадәр хажи Феодосиягә киткәннәр иде. Истанбул бугазының агызында (Куакта) өч көн карантинда утырганнан соң диңгезгә чыкмышлар исә дә, пароходлары дулкыннарга тәхәммел итә (дулкыннарга түзә) алмаган. Кайсының башлары ярылып, кайсыларының куллары имгәнеп, кире Истанбулга кайттылар. Хәзерге көндә бунлардан әксәре үзләренең Одессага дип алган билетларын ташлап, Румания юлы илә качып китәләр.

Одессага мөселманнан һичкем кабул ителми. Феодосиягә дә пароход китми. Шул сәбәптән хажиларның бунда калганнары Батумига китәргә мәжбүрләр. Анда киткәндә дә хажилар үзләренең «обратно» дип алган билетларыннан файдалана алмыйлар. Чөнки «Русское общество» пароходларында хезмәт итүче берничә билетчы румнар илә Истанбулдагы симсар һәм номер тотучылар бер кинәштә булып хажиларны талыйлар. «Сезнең бу билетларыңыз эшкә ярамый»,— дип, яңа билет алдыралар. Бундан өченче класс бителы 5 сум 80 тиен кадәр генә исә дә, анларны—18 сумга, икенче класс билеты 14 сум гына исә дә, анларны 26 сумларга кадәр хажиларга саталар. Аның өстенә дә... «Бу көнге пароходта урын»,— юк дип, хажиларны берәр атна утыртып, номер хуҗаларына файда иттертәләр. «Русское общество»ның бундый эшләргә бер дә дикъкать итмәве тәэссеф (кызганыч, үкенечле) бер хәлдер.

Югарыда Истанбул әтрафында һаваларның бик начар икәнлегеннән бәхәс иткән идем. Һаваның бундый начар булуы гаскәрләргә дә бик начар тәэсир итә. Гаскәр арасында хасталык көннән-көн артып бара. Өйләр эчендә—бераз гына булса да жылылык бирә торган мангаллар янында утыра торган кешеләр арасында хасталыклар күп булганнан соң, салкын һавада, былчырак һәм юеш жир өстенә корылган чатырлар астында утыра торган гаскәр арасында хасталыкның күп булачагы табигыйдер.

Өченче көн «Мәжидия» крейсеры, томаннан истифадә итеп, Грециянең Шира атавына кадәр барган һәм анда Грециянең «Македония» исемле бер крейсерын батырып һәм андагы күмер депо (склад)ларын тупка тотып, хили тәләфат биргән (күп төрле зыян-югалту). Бу муаффәкыять (уныш, жиңү) төрекләргә гүзәл тәэсир бирде һәм анларның рухларын күтәрде.

Мохарәбә мәйданына гаскәр, әрзак (азыклар) һәм сугыш яраклары күндерү һәмишә дәвам итә. Көн саен Истанбулдан Чаталжага бер поезд икмәк китеп тора.

Кичә алтынчы урдуны пароходлар илә Бандырма һәм Кәлибулигә күндерделәр. Безнең номерда тора торган һәм гаскәр вә әрзак күндерү илә мәшгуль булган йөзбашы бер әфитсәрнең сөйләвенә караганда, хәзерге көндә Чаталжада ике йөз илле мең, Чанаккалада сиксән мең, Кәлибулидә дә йөз мең кадәр гаскәр бар. Дүртенче көн Чаталжага Германиядән яңа килгән туплар илә өч поезд ат күндерделәр. Шулай ук кичә Чанаккалада да бер пароход илә сыгыр һәм үгезләр күндерелде. Анатолиядән һәр көн көтү-көтү атлар килеп тора. Әгәр бундан соң сугыш башланса, төрекләр үзләренең жиңәчәкләренә тәмам ышаналар.

Әдернәдән килгән телеграмнарда анларның бирешергә ниятләре юк икәнлеге анлана һәм азык вә сугыш яракларына ихтыяжлары юк икәнлеге күренәдер.

Истанбулда тәэссеф ителәчәк бер нәрсә бар исә, ул да—хөкүмәт идарәсен үз кулларына алу, яхуд та үз кулларында калдыру өчен ике партия арасында булган көрәшләрдер. Хәтта өченче көн кич садрел-әгъзам Камил пашаның жанына касд итү кадәр дә (һөҗүм итү кебек) бер эш булган. Шул сәбәптән Истанбулда идарәи горфия (военное положение) дәхи дә куәтләнде. Әүвәлдә идарәи горфия кич сәгать уннан башлана иде, хәзер кич сәгать тугыздан сон урамнарда йөрү мәмнугдыр (тыелгандыр).

Төркиядә бунын өстенә янадан бер унгайсызлыклар вөҗүдкә килергә тора.

Сонгы көннәрдә Әрмәнстан һәм Сурия мәсьәләләре мәйданга чыкты. Бу вилайәтләрдә булган халыклар да үзләренә автаномия телиләр. Шул сәбәптән Төркия бу тарафларга да гаскәрләр күндереп, үзенең куәтен бүлергә мәжбүрдер.

## X

Истанбул гали күренешкә кереп бара. Әүвәлдәрәк христианнарга тәҗавезләр булу (һөҗүмнәр булу) куркусы илә башларына фәс кигән кешеләрнең күбесе, фәсләрен салып, эшләпә, силиндр вә катилүкләрен киделәр. Сонгы көннәрдә атлар да күбәйде. Анатолиядән бик күп атлар китерелде. Мин килгән көннәрдә күренгәнияр илә жилкәләре чиләнгән атлар хәзер бер дә күренми. Гаскәрләрнең атлары һәркаюсы таза. Бер-ике көннән бирле гаскәр күндерү эшләре дә азайды. Чөнки сугыш булган тәкъдирдә дошманнарга янә каршы торырлык гаскәр тәкмил ителде (булдырылды). Гаскәр арасында холера хасталыгы да тәмам бетте. Хастаханәләрдә мәҗрухлар бер дә калмады. Гаскәрнең мадди жәһәтләре яхшыланган шикелле, мәгънәви жәһәтләре дә бик яхшыланды. Хәзер гаскәрдә дә, халыкта да сугышка иштиһа (караш-кызыксыну) бик зурдыр. Янадан сугыш булган тәкдирдә дошманнарны җинәчәкләрендә төрекләр шөбһә итмиләр. «Хәмидия» пароходының Шира атаулары янында зур эшләр күрүе төрекләрне бик шатландырды. Төрекләрдә «Хәмидия» пароходының командиры Рәүф бәкне бик мактыйлар, анын берничә мәртәбәләр күрсәткән каһарманлыкларын бик мәдех итәләр. Узган шимбә Чанаккала бугазының тышында булган дингез сугышларында һәр ике тараф көймәләрендә дә хили һәлакәт һәм зарарлар булган. Грециянең бронинос, крейсер һәм минаносларында зур зарарлар булган шикелле, Төркиянен «Тургуд рәис» илә «Барбарос Хәйретдин» пароходларында да хили зарарлар булган. «Барбарос Хәйретдин»нең гувәртә (палуба)сы бераз жимерелгән, шулай да булса сугыш сафыннан чыгарлык дәрәҗәдә түгел. Һәр ике тарафтан да үлгән һәм жәрәхәтләнгән кешеләр күп булган. Мәжрухларны Рәшид паша исемле хастаханә пароходы илә Терсанә хастаханәсенә китерделәр. Гәзитәләр һәр нә кадәр 70 кадәр генә мәҗрух килде дип язган булсалар да, асылда мәҗрухлар ике йөздән зиядәдер (артыктыр). Бу сугышта ике тараф та, бер-берсен артыннан кумыйча, кире чигенергә мәҗбүр булдылар. «Хәмидия» крейсере командирынын каһарманлыгын һич мактап бетерә алмыйлар. Япаялгыз үзе генә Юнан суларына барып, андагы Шира лиманын тупка тотып, бер крейсерне батырды һәм күмер деполарына күп зарарлар китерде. Юнаннар Солониктагы гаскәрләрен пароходларга төяп дингез тарикы (юлы) илә Ягая тарафларына күчермәкче иделәр, ләкин «Хәмидия» пароходының тәҗавезләреннән куркып, гаскәрен корыдан күндерергә мәҗбүр булды.

Төркия Әдернәне бирергә һич разый булачак түгел иде һәм сугышырга да тәмам хәзер иде, ләкин Русиянең эшкә килеп катнашуы вә: «Болгариягә Әдернәне бирмәсәнез, житди эшкә керешәчәкмез»,—дип тәһдид итүе, анын өстенә, Итилафы мөсәлләс (Өчлек берлеге. Антанта. 1904-07, 1919 елларда гамәлдә булган Россия, Англия, Франция арасындагы берлек) әгъзаларының Русиянең бу хәрәкәтенә разый булулары вә бу хәрәкәткә каршы иттифакы мөсәлләс әгъзаларының да сөкүт итүләре Төркияне хәвефкә төшерде. Төркия хөкүмәтен каушатты. Әүвәлдә сугыш тарафдары булып язып килгән һәм мөттәфикъ (союздаш, фикердәш) хөкүмәтләргә бер карыш йир бирергә разый булмаган гәзитәләр сонгы нота бирелгән көннән башлап солых тарафдары була башладылар. Кичә чыккан «Аклам» гәзитәсе буны ачыктан-ачыкка язды: «Мадамки Русия безгә каршы төште,

Мадакмки итилафы мөсәлләс әгъзалары аның тарафдарыдыр, Иттифакы мөсәлләс (Германия, Австрия-Венгрия, Италия катнашында төзелгән өч держава берлеге. 1882—1914 елларда гамәлдә була) әгъзалары да безнең файдамызга тавыш бирмиләр, безнең өчен үзләренең кәефләрен бозмыйлар, безгә дустлык күрсәтмиләр, шулай булып торганнан соң, безнең ул кадәр куәтле зур мәмләкәтләргә каршы тору ихтималымыз булмаганлыктан, аларның сүзләрен тыңламый чарамыз юктыр. Әгәр без анларның киңәшләрен тотмыйчы сугышсак һәм ул сугышта галиб булсак та, дәвале мөгаззама безнең файдамызга һичбер эш эшләмәячәк һәм дә үзләренең морадларына муафикъ рәвештә безгә хөкем итәчәкләр. Әгәр дә (Хода күрсәтмәсен!) без җиңелеп куйсак, ул заманда безнең мөкәллифләремез (җавап алучыларымыз) бездән дәхи дә артыграк нәрсәләр таләп итәчәкләрдер. Безнең хәзерге көндә һичбер дуст дәүләтләремез юктыр. (Әгәр булса, без анларга ышанып, бәлки, бер эш күрә алыр идек.) Дустларымыз булмаганнан соң, алты зур дәүләтләрнең кәефләрен җибәреп, янадан сугыш башлау безнең өчен файдалы булмаячактыр»,—ди.

Дәүләтләр тарафыннан тәкъдим ителгән нотага каршы Төркия хөкүмәте үзенең җавабын иртәгә бирергә тиештер. Бу нотага җавап бирү хакында киңәш өчен Төркия хөкүмәте Мәҗлесе әгъян (дәүләт җитәкчеләре мәҗлесе) әгъзаларыннан, шаһзадәләрдән һәм төрле эш башында булган зур мәэмурлардән гыйбарәт булган бер «Мәҗлесе миллия» ясады. Төрекләр бунларны хили тәнкыйть итәләр. «Бу эш канун әсаси һәм мәшрутият кануннарына мохалиф (төп закон һәм конституция законнарына каршы) бер эштер. Буңа итәгать итү безнең өчен лазем булачак бер эш түгелдер»,—диләр.

Ләкин хөкүмәт буна карамады. Кичә Мәҗлесе миллия җыелды, ләкин хәзергә кадәр нәтиҗәсе мәгълүм булмады. Гәзитәләрнең язуларына караганда, нотага каршы биреләчәк җавап лаихәсенең мәтенендә (проектының текстында) Әдернә шәһәре хосусый бер идарә илә идарә ителә торган бер шәһәр булуга һәм дә Бәхре сәфид (Ак диңгез. Төрекләрдә Урта диңгез шулай атала.) атауларының автономияле җирләр булып калуына ризалык күрсәтелә имеш.

Истанбул вә әтрафында һавалар гаять начар, юеш вә ягмурлы булганлыктан, гаскәрләрнең хәлләре бик уңгайлы түгелдер. Бу көнгә кадәр мөһаҗирләрнең Анатолиягә урынлаштырып жителә алмаганнары чатырлар астында яшиләр иде, хәзер анларның һәммәсе Әдернә капусы әтрафындагы җамигълар илә солтан Әхмәд җамигъларына җирләштеләр. Мәйданда хәзер бунларның бала-чагаларын һәм йорт әсбабларын төяп, үгезләр җигеп килгән арбалары гына калды. Бунда килгәннән соң үгезләрен дә яхшы бәһаләргә сатып бетерделәр. Бунларга хөкүмәттән һәркөн икмәк һәм он бирелеп тора. Кырык кәлисә, Лүләбургаз, Чиркәскөй, Чүрлү һәм Чаталҗа мөхарәбәләрендә булган бер меңбашының сөйләвенә караганда, Чаталҗаның аргы ягындагы авылларның һичберсендә һичбер мөселман калмаган: һәркаюсы кайда качып киткәннәр. Мөселманнар калмаган шикелле, ул тарафларда һичбер хайван да калмаган. Әүвәлдә сөттән ясала торган нәрсәләрнең һәркаюсы шул тарафлардан, хәтта Болгариядән килә икән, хәзер ике араны мөхарәбә мәйданы бүлгәнлектән, бундый нәрсәләр һич килми. Әүвәлдә укасы җиде-сигез грошка сатыла торган пинир (сыр)лар хәзерге көндә унсигез-егерме грошка җитте. Ул тарафлардан куй килмәү сәбәпле, итнең дә кадагы кырык тиен булды.

Бу көннәрдә Әнвәр бәкне күрү максаты илә ханәләренә киттем. Үзен өйдә тугъры китерә алмадым исә дә, атасы илә бер ярты сәгать кадәр мөзакәрәләрдә булындым (сөйләштем). Әнвәр бәккә бер дивизия гаскәрне командовать итәргә биргәннәр. Әгәр сугыш булса, Чаталҗа мөхарәбәләрендә иштиракь итәчәк (катнашачак). Әнвәр бәкнең Шәех Сәнүси кызына никахланган дигән хәбәрләр ялган икән. Сәнүсинең һичбер кызы юк икән. Шулай да, гәрчә пәдәре тәсдыйк кыйлмаса да (атасы расламаса да), әгәр солых булса, Әнвәр бәкнең янадан Траблискә китәчәген сөйлиләр.

Әнвәр бәк Наполеонга тәкълидне (ошауны, иярүне) сөя торган бер кеше булса кирәк, чөнки без утырган бүлмәсендә Наполеонның төрле вөсгатьләрдә (муллыкта, иркенлектә) төшерелгән кыяфәтләре бик күп.

## XI

## Төркиядә зур үзгәреш

Мәҗлесе миллия җыелганлыгы хакында узган мәктүбтә язган идем. Мәҗлесе миллиянең дә Әдернәне һәм атауларны биреп килешү ягында булганлыгын да бераз аңлаткан идем. Мин ул мәктүбне почтага биргән заманнарда Вәзирләр шурасы (министрлар советы) кинәш мәҗлесендә иделәр. Бу мәҗлес—актык мәҗлес иде. Аннарның ни сурәттә җавап бирәчәкләре дә әүвәлдән үк билгеле иде. Ягъни алар Әдернә һәм атауларны биреп булса да килешү тарафында иделәр һәм шул көн өйләдән соң сәгать дүрттә Австрия сәфиренә җавап та бирәчәкләр, эш тә бетәчәк иде. Гәрчә электән Иттихад фиркасенә мәнсүб адәмнәр вәзирләр кабинетын алмаштырырга тырышалар икән дип ишеткән булсам да, бу көн солыхнамәгә имза итәчәкләренә шөбһә итми идем. Шул сәбәптән узган мәктүбне рус почтаханәсенең яшигенә салган вакытымда, бу мәктүб инде минем актык мәктүбем булыр, киләчәк почта пароходы илә Русиягә китәрмен, дип хәтеремә килде. Почтаханәдән чыгып ашханәгә, аннан да номерыма килдем. Анда үземнең белгән бер аркадашым илә бер сәгать кадәр сөйләшеп утырдым. Утыра торгач, колагыма «Садыре әгъзам», «Әнвәр бәк» дигән сүзләр ишетелә башлады.

«Тукта әле, карыйк, нәрсә сөйләшәләр икән»,—дип тышка чыктым, анда: «Бабыгалидә (госманлы дәүләтендә хөкүмәт урнашкан йорт; (Олугъ йорт—Высокая Порта) хәзер кыямәт! Камил пашаны хәзер урыныннан төшерәчәкләр, Әнвәр бәк Мабейингә (төрек солтаны сарае) киткән»,—диделәр.

Тиз генә номердан чыгып Бабыгалигә йөгердем. Мин барганда Бабыгали урамы һәм Бабыгали ишек алды бөтенләй халык илә тулы иде. Аздан ун мең кадәр халык бар иде.

Бабыгали бинасының баскычларының ике тарафларына ике мәшрутият флаклары күтәргәннәр, хатиблар каты-каты нотыклар сөйлиләр.

Халыклар да: «Яшәсен Әнвәр бәк!»—дип кычкыралар. Бер-бер артлы тәкбирләр әйтәләр.

Бер автомобиль килде исә: «Иштә Әнвәр бәк килер. Яшәсен Әнвәр бәк! Яшәсен милләт! Яшәсен мәшрутият!»—дип кычкыралар.

Мин бу вакыйгаләрнең тәфсыйлатын аңлату өчен Әнвәр бәк илә Бабыгалинең эченә кергән кешеләрнең сүзләрен нәкыль итәчәкмен (сөйләячәкмен).

Мин бу вакыйгадән соң Әнвәр бәк илә эчкә кергән өч кеше илә күрешеп сөйләштем. Аннар миңа вакыйгане ошбу түбәндәге рәвештә хикәят иттеләр.

Төрек милләте Кырык Кәлисә мәгълубиятеннән (җиңелүдән) бирле хәзерге хөкүмәт ияләренең эшләреннән мәмнүн түгел иделәр. Ничек итеп булса да бу кабинетны күздән төшерергә уйлыйлар иде. «Иттихад вә тәрәккый» фиркасенең әсхабе (хуҗалары, әгъзалары) дә бу фикер илә мәшгуль иде. Иттихадчылар бер айдан бирле бу кабинетны ничек итеп истигъфа кыйлдыруның (хезмәттән азат итterүнең) юлларын уйлап, аның хакында тырыштылар. Соңгы һәфтә эчендә бу иҗтиһад дәхи дә куәтләнде. Хәтта узган һәфтәдә берничә (кеше) Садыре әгъзам Камил пашага кереп, аның истигъфа итүен таләп иттеләр. Ул заман Камил паша үзенең хәйләкәрлеге илә котылып калды.

Аннан соң иттихадчылар янадан яхшырак уйлашып, үзләренә бер план тәртип иттеләр. Бабыгали әтрафында сакчылык ләвазимен әда кыйла (хезмәтен башкара) торган гаскәриләрнең һәммәсен иттихадчылардан куйдылар.

Бабыгалигә якын йортларның тәрәзәләренең һәрберсенә дә тәмам коралланган дүртәр-бишәр адәмнәрне җирләштерделәр. Соңра бу эшләр тәмам булгач, бүген өйләдән соң ике ярым сәгатьтә Әнвәр бәк, сабикъ дахилия вәзире (элекке эчке эшләр вәзире, министры) Тәлгать бәк, Җамал бәк, хөррият вакыйгаләрендә Әнвәр бәк кадәр үк каһарманлык күрсәткән Мостафа Нәҗип бәк һәм Төркиянең иң мәшһүр хатибларыннан саналган Нажи бәк, Нур Госмания җамигъсы янындагы «Икъбал» кыйраәтханәсенә (уку залына) килеп, бер-берсе илә күрештеләр. «Иттихад вә тәрәккый» фиркасенә мәнсүб адәмнәргә

дә әүвәлдән шифрлы телеграммалар илә хәбәрләр бирелгән иде.

Иштә, тәмам ике ярым сәгатьтә Әнвәр бәк атка атланып, башкалары да җәяү уларак Бабыгалигә хәрәкәт иттек. Бабыгалигә барып җиттек. Аның ишек алдына кердек. Андагы гаскәриләр һәммәсе иттихадчы булганлыктан, безгә һичбер төрле мәмнугат күрсәтмәделәр.

Аннан уздык. Без, Әнвәр бәк илә унбиш кеше, баскычлардан югары чыгып, Бабыгалинең ишеген ачтык. Нәкъ шул заманда Садарәт йаурларыннан (баш вәзир адъютантларыннан) Нәфиз бәк (Арнаут гыйсъяннарыннанда, Албан баш күтәрүләрендә иң әүвәл башлап алга чыккан бер кеше) илә садарәт йаурларыннан Тәүфыйк бәк безгә каршы ата башладылар. Без дә анларга каршы аттык. Анларның икесен дә җиргә төшердек, фәкать анларның аткан җәдрәләреннән безнең хөррият каһарманнарыннан Мостафа Нәҗип бәк вафат булды.

Соңра без янә алга таба атладык. Шул заман револьвер тавышларын ишетеп тышка чыккан Бәхерия назыйры (хәрби диңгез флоты башлыгы) Назыйм паша, безгә каршы револьверын чыгарып, Әнвәр бәкне үтерергә теләде. Безнең программамызда үзләре модафәга итмәгән (каршылык күрсәтмәгән) тәкъдирдә һичкемгә җәдрә ашату маддәсе юк иде. Ләкин ни эшләмәк кирәк, әгәр без атмасак, ул атып Әнвәр бәкне үтерәчәк иде. Шунын өчен без сабыр итә алмадык, бердән атып, Назыйм пашаны үтердек. Ул үлгәч, башкалары йомшардылар. Әнвәр бәк анларның каршысына килде. Анлар да унике адәмнән гыйбарәт иде, шул дәкыйкадә Әдернә һәм атауларны биреп солых ясарга имза итәчәкләр иде. Австриянең сәфире дә шунда җавап алуны көтеп тора иде. Әнвәр бәк килеп, солых могаһәдәсе (солых договоры, килешү) хакында язылган бу кәгазьләрне кулларыннан алып җыртып ташлады. Һәм үзләренә истигъфанамәләрен (эштән азат итүне сорап) язарга әмер итте. Бичара картлар курыктылар, үзләренен истигъфанамәләрен яздылар. Әнвәр бәк ул истигъфанамәләрне алды да тышка чыкты, соңра Бабыгалине саклый торган командирны чакырып: «Хәзер һәммә эш бетте, сез рәхәт булыныз, халыкны голуянга китермәңез (халыкны шомландырмагыз). Мин хәзер килермен»,— диде. Һәм дә халыкка хитаб итеп: «Сез монда бераз мине көтеп торыгыз, мин Мабейингә китеп, аннан сезгә яңа бер Садыре әгъзам китерәчәкмен»,—дип, автомобильгә утырып сарайга китте. Бу вакытта Бабыгалинең алдында берничә мең халык бар иде. Һәркаюсы иске вәзирләргә нәфрәт итәләр иде, хәтта харижия вәзире (тышкы эшләр вәзире) әфәнденең янагына да менеп төшкән кешеләр булгалады»,—дип сөйләде.

Иштә, шул вакыйгадән соң халык арасында яңа бер рух кузгалды. Һәр тарафтан тәкбир тавышлары ишетелә башлады. Халыкның кайсы җылый, кайсы шатлана, төрле-төрле хатиблар баскычка чыгып хәйрәтле (хисчән) нотыклар сөйлиләр.

Бер заман «Иттихад вә тәрәккъый» фиркасе тарафыннан тәнбиһнамәләр (кисәтү хатлары) таратыла башлады. Ул тәнбиһнамәләрдә мохтәсарән (кыскача) ошбу сүзләр язылган иде:

«Без Траблистә италияннарны җиңеп сугышкан бер заманда Шимали Арнаутлыкта берникадәр явызларнын хөкүмәт хилафына (хөкүмәткә каршы) кабызган явызлык утларын сүндерер өчен җибәргән гаскәрләремез арасыннан бәгъзе бер әфитсәрләрнең ачыктан-ачык гасыйларга (фетнәчеләргә) иярүләре һәм Җәнүби Арнаутлыкта (Көнья Албаниядә) шул ук максуд илә кораллары илә качып китеп, безнең харижи сугышларымыз эченә дахили сугышлар арттырулары безне хафага төшерде. Шул заманнарда Сәгыйт паша кабинеты куәтсез саналып, аның урынына Мохтар паша кабинеты тәшкил ителде. Бу кабинет ясалгач, һәркем рәхәтлек башланыр дип өмид иткән иде. Ләкин бу кабинет та гасыйларга каршы бер эш тә эшли алмады. Аның эш күрә алмавыннан файдаланып, гасыйлар иң әүвәл Приштинә, соңыннан Эскүбкә кереп, хөкүмәт мәэмүрләрен урыннарыннан төшерү шикелле азгынлыкларда булдылар. Хөкүмәт буңларга каршы бертөрле тәдбирләрдә дә булмады.

Шул сәбәптән хөкүмәтемезнең бу йомшаклыгы анларның иштиһаларын (теләк, аппетит) тагын да бер кат арттырды. Әхмәд Мохтар паша кабинеты,

бунларга каршы берсүз сөйләмәү өстенә, мәшрутият канунnарына хилаф уларак Мәҗлесе мәбгусанны (депутатлар мәҗлесе, парламент) да таратты. Хасиле (нәтиҗәсе) генә, Төркиянең ул замандагы кабинеты үзенең дошманнары каршында куәтсез икәнлеген билфигыль (чынлыкта) күрсәтте. Ул заманнарда шундый гафләтләр (гамьсезлек) эшләделәр ки, Балкан хөкүмәтләре безнең илә сугышлар өчен дип гаскәр хәзерләгән бер заманнарда безнең вәзирләремез йөз егерме мең кадәр низами (регуляр) гаскәрләремезгә Рум иленнән (Төркиянең Европа өлешеннән) өйләренә кайтырга рөхсәт бирделәр.

Әгәр дә сугыш башында бу гаскәрләр илә дошманга каршы торган булсалар иде, безнең галиб булучылыгымызда һичбер шөбһә юк иде. Шул ук вакытта хөкүмәтебез янадан бер ахмаклык күрсәтте: Рум иле рәдифләрен (Европа өлешендәге запаста торган гаскәриләрне) җыеп маневрлар ясап маташты. Русия Болгариягә язга кадәр сугыш башламаска киңәш биргән булса да, Болгария, без мондый уңгайлы заманны тагын күрә алмабыз, бундый кабинет янадан кайчан булыр, дип, сугыш башлады.

Безнең әүвәлдән үк Балкан хөкүмәтләренә каршы хәзерләнеп куйган планнарымыз бар иде. Ләкин Мохтар паша кабинеты илә аннан соң килгән Камил паша кабинеты буңа игътибар итмәделәр. Анлар фәкать үзләренә мохалиф (каршы) булган фирка кешеләрен тәүкыйф (тоткын) итү белән генә мәшгуль булдылар.

Габделхәмид заманындагы шикелле хафияләрне (шымчыларны, агентларны) вөҗүдкә китерделәр. Сугыш мәйданында да кулыннан бер эш килми торган командирлар куйдылар. Чаталҗа сугышында без галиб булган булсак та, анлар, ана карамыйча, мөтарәкә ясап (вакытлы килешү ясап), солых гакыд итү өчен (солых төзү өчен) Лондонга вәкилләр күндерделәр. Лондонда булган мәҗлесләрдә дә безнең мөрәххәсләремез (вәкилләребез) йомшаклык күрсәттеләр. Шул сәбәптән безнең дошманнарымызның күңелләре үсеп, бездән күп нәрсәләр сорый башладылар. Камил паша кабинеты да моңар ризалык күрсәтте. Әгәр дә без бераз сабыр иткән булсак, безнең Әдернә дә, атауларымыз да кулдан киткән булачак иде. Без буна сабыр итә алмадык. Шуның өчен һәрбер бәлане күз алдымызга алып мәйданга чыктык».

Таратылган прокламация шуннан гыйбарәт иде. Халык буны бик яратып укыды. Һәр тарафтан хәзерге вәзирләр кабинетына нәразыйлык изһар итelә иде (ризасызлык күрсәтелә иде).

Бер заман автомобильләр тавышы ишетелә башлады. Әнвәр бәк килде. Халык аны тәмам күкләргә очырачак дәрәҗәдә күтәреп, кул чабып: «Яшәсен Әнвәр бәк!»—дип каршы алдылар.

Әнвәр бәк: «Шат булыңыз! Хәзер кабинет алмашынды, Мәхмүд Шәүкәт паша Садыре әгъзам булды. Бундан соң дошманга арка бирмәмез»,—дип, берникадәр сүзләр сөйләп, Бабыгалигә кереп китте. Аннан соң Мабейин кятибләре (Солтан сарае секретарьләре) килеп, эчкә кереп, солтанның ирадәсен (карарын) укыдылар. Анлардан берничә дәкыйкадән соң янә бер автомобиль илә Мәхмүд Шәүкәт паша Бабыгалигә килде. Халык аны янәдән бик зур шатлыклар илә каршы алдылар. Аны кочакладылар, үптеләр, кул өстендә Бабыгали эченә керттеләр. Соңра Шәүкәт паша янәдән чыгып, берникадәр халыкка кыскача бер нотык сөйләгәннән соң, анларның таралуларын үтенде. Халык та итагать итеп (буйсынып) таралды. Халык таралганнан соң Мәхмүд Шәүкәт паша төн буена кабинетны алмаштыру хакында киңәшләр илә мәшгуль булмыштыр. Бүген иртә илә чыккан гәзитләрдә вәзирләр кабинетының тәмам үзгәргәнлеге күренде.

Хәзерге Төркия кабинеты ошбу әләмнәрдән гыйбәрәттер.

Садыре әгъзам һәм хәрбия вәзире (баш вәзир һәм хәрби министр)—мәшһүр Мәхмүд Шәүкәт паша; Шураи дәүләт рәисе (дәүләт советы рәисе)—принц Сәгыйд Хәлим паша; Дахилия назыйры (эчке эшләр министры)—Хаҗи Гадел бәк; Харижия назыйры (тышкы эшләр министры)—сабикъ Афина сәфире ( Афинадагы элекке илче) Мохтар бәк; Бәхрия вәзире (хәрби диңгез флоты министры)—Черексулы Мәхмүд паша; Галлия вәзире (хокук министры)—сабикъ Истанбул валисе (губернаторы) Ибраһим бәк; Малия назыйры (финанс

министры)—диване мөхасәбат рәисе (финанс бюджет идарәсе рәисе) Рәфгат бәк; Вәкыф назыйры (дәүләт милке министры)—Хәйри бәк; Тиҗарәт һәм зирагать (сәүдә һәм авыл хуҗалыгы) назыйры—сабикъ Айдин вилайәте валисе Җәлал бәк; почта вә телеграф назыйры—сабикъ Сарай вә хан мөтасаррифы (управляющий) Шакири бәк; Нәфәка назыйры (көнкүреш тәэминаты министры)—Бәсария әфәнде; Шәйхелислам Фәтваи (дини эшләр башлыгы, фәтвалар бирүче)—Әмин Әсгад әфәнде.

Кабинет алмашынганнан соң җараян (үзгәрешләр хәрәкәте) башланды. Төркия хөкүмәте Әдернә илә атауларның мохалифләр кулына китүенә һич разый булмыйлар. Әгәр дә мохалифләр бу җирләрне сорый торган булсалар, сугышырга да хәзерләрдер. Гаскәр арасында да рух күтәрелде. Кабинет алмашынганны ишеткәч тә Чаталҗадагы гаскәрләр шенлекләр ясап (тантаналы рәвештә) бәйрәм иткәннәр. Гаскәрләр Мәхмүд Шәүкәт паша илә Әнвәр бәкне бик яраталар. Һәркаюсы анлар өчен җаннарын фида кыйлырга хәзерләрдер.

## Соңгы көн хатирәләре

Мина Истанбулдан сугыш башланыр көндә генә чыгып китәргә тугъры килде. Безнең пароходымыз кузгалып киткәндә сугыш башланырга сигез сәгать кенә калган иде. Шулкадәр аз вакыт калган булса да, Истанбулда зур тәбдил (үзгәреш, алмашыну) күренми иде. Фәкать тимер юл стансиясе тирәсендә генә гадәттәгедән артыграк хәят күренә иде. Чөнки бу көнгә кадәр Төркия сугыш өчен кирәк булган нәрсәләрнең һәммәсен алдан хәзерләп бетереп куйган, кирәк булган ризыклар вә сугыш яракларын Чаталҗа сугыш мәйданы илә Кәлибулигә җибәргән иде. Анатолия тарафындагы шәһәр вә стансияләрнең һәрберсендә запас гаскәр вә ризык бик күп булса да, бунлар—лазем булуларына карап кирәк кадәр урыннарына озату өчен хәзерләнеп куелган нәрсәләрдер.

Соңгы көннәрдә булган инкыйлабтан соң Истанбулның күренешләре хили үзгәрде, һәр җирдә гаскәрнең йөзендә бер җиддият һәм өмид галәмәтләре күренә иде. Төркия гаскәренең хәзерге команданларына инабәтләре (ышанычлары) бик зурдыр. Анлар бу сугышта үзләренең галиб булуларына ышаналар.

Әҗнәби гәзитәләр (чит ил газеталары) Чаталҗадагы гаскәрләрне йөз алтмыш мең генә дип күрсәтсәләр дә, төрекләр гаскәрләренең ул микъдардан күп артык икәнлеген дәгъва кыйлалар. Бу дәгъваның хаклы булуын да уйларга мөмкин. Чөнки бу көнгә кадәр Истанбулдан Чаталҗага һәркөн бер поезд яңа пешерелгән икмәк җибәрелеп торадыр иде. Поездны егерме вагоннан гына һәм һәр вагонда ун мең укадан гына (бер ука өч кадак) икмәк фарыз кыйлсак та, Чаталҗада ике йөз мең кеше булганлык күренеп торадыр. Шул сәбәптән бундагы гаскәрнең ике йөз мең кешедән артык булуы ачык аңлашыладыр.

Төрекләр соңгы көннәрдә тәмам сугыш тарафдары булып әверелделәр. Үзләренең әзерлекләренә тәмам ышаналар. Һичбер солыхтан бәхәс кыйлган кеше юк. Сугыш акчасыз була торган нәрсә түгел. Аның өчен күп акча лазем. «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасенең комитетына якын адәмнәрнең ышандырып сөйләүләренә караганда, төрекләрнең хили заманнар сугышырга житәрлек акчалары бар имеш. Бер җәһәттән караганда бу сүзләрнең дә тугъры булуы уйланадыр. Чөнки кулларында акчалары булмаса, солыхны ясарга бу кадәр каршы тормаслар һәм үзләрен дә бу кадәр хәвефле юлларга сукмаслар иде.

Соңгы заманнарда төрекләр көн-төн туктамый Чаталҗадагы истихкямнәрне (хәрби ныгытмаларны, крепостьларны) ныгыту илә мәшгуль булганнар. Бу җирләрдә гаскәрләрнең истирахәтләре (ял итүләре) өчен лазем булган әсбабларны хәзерләгәннәр.

Соңгы заманнарда бу тирәләрдә һавалар бик начар булганлыктан, гаскәрләрнең рәхәте өчен лазем булган тәдбирләрне кыйлганнар. Шул сәбәптән,

һавалар никадәр бозык булса да, хасталыклар әүвәлдәгедән артык түгелдер.

Ләкин соңыннан килгән хәбәрләрдә болгарларның Чаталжадан бик күп эчкә чигенгәнлекләре күренәдер. Төрекләр, әлбәттә, артларыннан анларны тәгъкыйб итәргә (эзәрлекләргә) мәҗбүр булачаклардыр.

Арттан куып барганда ул истихкямнәрне ташлап китәргә тиеш буладыр. Бу эш, әлбәттә, төрекләр өчен җинел булмаячак.

* * *

Соңгы инкыйлабның гаскәргә ни рәвешчә тәэсир иткәнлеген югарыда язган идем. Бу эшләр гаскәрләргә гүзәл тәэсир итсә дә, төрекләрдән башка кавемнәргә агырырак тәэсир итте. Анлар солыхның тизрәк булуын телиләр иде.

Ләкин эш анларның теләгәннәренчә булып чыкмады. Төрекләр Әдернәне бирүгә һичбер төрле разый булмадылар. Төркия өчен нәкыс (кимлек) булган бу солыхны ясаудан үлү артыграктыр, диделәр. Соңгы көннәрдә булган кабинет алмаштыруга да халыкта булган шул рух һәм шул хис сәбәп булды.

Төрекләрдән башка кавемнәрнең тизрәк солыхны теләүләренең сәбәпләре дә бик мәгълүм, чөнки анларның әксәре сәүдә вә тиҗарәт (сәүдә һәм алыш-биреш) адәмнәредер, сугыш булу аркасында тиҗарәт торгын. Алыш-биреш начар, харижи тиҗарәтләр бик аз. Күп тиҗарәт фирмаларының шартлауларының сәбәпләре дә шуннандыр.

Мувәкъкать мосаләхә (вакытлы килешү) булу илә, үз ихтыярлары илә гаскәр уларак читтән килгән кешеләр, гаскәри киемнәрен чыгарып, үзләренең гади киемнәрен киенгәннәр иде. Солых киселгәнлек мәгълүм булгач та бунлар янадан гаскәр киемнәрен киеп, үзләренең хезмәт иткән полкларына китә башладылар.

Соңгы ике атна эчендә хастаханәләр бушаганнар иде, сугыш башланачагы мәгълүм булгач та, бик ашыгычлык илә янадан килүләре ихтимал булган мәҗрухларны кабул итү өчен хәзерлекләр башланды. Соңгы көннәрдә генә бушатылган җамигълар, әгәр кирәк булса, янадан хастаханәләргә әйләнделәчәкләрдер.

Кабинет алмашынганнан соң һәртөрле җәмгыять мөәссисләренең мөрәххәсләреннән (җәмгыять эшлекләре) гыйбарәт булган гомуми бер мәҗлестә Муафигы миллия (милләт кирәкләре) җәмгыяте тәэсис ителеп, һәйәтләр интилаб ителде (комиссия сайланды). Бу һәйәтләр һәркаюсы Төркияне коткару, аның мөстәкыйльлеген саклау өчен юллар эзләү вә аны вөҗүдкә чыгару өчен сумма хасыйл итү һәм җыелган сумманы милләтнең мохтаҗ урыннарына сарыф итү илә мәшгуль булачактыр.

Халыкның яңа вәзирләр вә яңа хөкүмәткә ышанганлыгы сугыш ихтыяҗы өчен иганәләреннән күренәдер. Яңа кабинет эш башына килү илә иганәләрнең микъдары ике өлеш артты.

*Текстны басмага* **Ә. Алиева** *һәм* **Р. Даутов** *әзерләделәр.*

*Язучы Кыям Миңлебаевка 70 яшь*

# ДӨНЬЯДА СҮЗ ҖИҢӘР...

Бу көннәрдә житмешен ваклап йөргән әдәби тәржемә остасы, «Бакый» романы авторы язучы Кыям Минлебаев замана кырыслыгына, жилдавылларга бирешмәскә, базар пычрагын жанына үткәрмәскә тырышып яши. Ул һаман да терекөмеш кебек хәрәкәтчән, аралашучан, өлгергән башаклары як-якка салынып төшкән көлтәдәй чәчләре сирәгәйсә дә, элеккеге көязлеген югалтмаган. Дөрес, йөзендәге нурлы елмаюы кебек үк, өстендәге кәчтүмнәре, бүрек-эшләпәләре, кыска кара туны болгавыр чордан элегрәк юнәтелгән кыйммәтләр, яшьлек хатирәләре.

Әйе, гомерләрен халык мәнфәгатенә багышлаган бик күп зыялыларыбызны аяусыз вә имансыз дәвер тормышның аргы ягына, төбенә чыгарып ташлады. Сер бирмәскә, эчке әрнүне күрсәтмәскә, дошманны шатландырмаска дигән милли-рухи таяныч кына аларны яшәтә, арканы туры тотарга мөмкинлек бирә. Әдәби тәржемә эшен шигъри югарылыкка күтәргән Кыям ага Миңлебаев шундыйларның берсе. Ачтан, гарыләнүдән җан тәслим кылса да, тәнендә ургылып аккан кыпчак каны аны почмакта симәнкә сатып утыру дәрәҗәсенә төшермәс. Шул хикмәтләр турында уйланганда, аны яратып «дәрвиш» дип атыйсым килде. Бу сүзнең ике мәгънәсе бар икән. Бер очракта ул фәкыйрь, ярлы адәм төшенчәсен бирсә, икенче урында бер шәйгә дә исе китмичә, тормыш-яшәеш ваклыклары дәрәҗәсенә төшмичә, югары дөньяви, дини, нисби хыяллар белән яши белгән кешене атыйлар. Хыялый-дәрвиши дөньяда сәяхәт итә белүе Кыям Миңлебаевның төп таянычы, рухи мәркәзе. Фаразымның янәдән бер таянычы бар. Кыяметдин Сәләхетдин улы Миңлебаев Татарстанның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында туып үссә дә, унбер яшендә әти-әнисе белән ул чорда Казанның ерак бер почмагында урнашкан Дәрвишләр—Дербышка бистәсенә күчеп килә, жидееллык мәктәпне тәмамлый, Кабан Күле буендагы 12-нче татар урта мәктәбенә йөреп укый.

Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, ике ел Сарман урта мәктәбендә урыс теле укыта һәм, Казанга кайтып, Татарстан китап нәшриятына эшкә урнаша, кырык елга якын шунда хезмәт итә. Тиз арада яшь, жилле, тырыш егет күнеленә аеруча хуш килгән әсәрләрне башка телләрдән тәржемә итү белән мавыгып китә һәм әдәбиятыбызны бөтен жиһанга танылган 20-30 китап исәбенә баету бәхетенә ирешә.

«Дәрвиш» булмаган кеше шулчаклы әсәрләрне, дөнья классикасын үз ана телендә яңгырата алыр идеме? Исемнәрне, әсәрләрне саный, атый башласаң, исең-акылың китмәле. Дөньяны бары тик сүз белән яулап буласын аңлап эш иткән Сәләхетдин абзый улы.

Тәржемә ижатының башында әкиятләр, балалар-яшьләр өчен язылган, мажаралы, жинел укыла торган әсәрләр тора: Цвирка П. «Сандугач», Семушкин Т. «Айвам мажаралары». Бу эшен Кыям ихластан башкара, ә күзе, зиһен угы дөнья әдәбияты бөекләре ягында. Беренче булып аның каләменә Лев Толстойның автобиографик трилогиясе килеп эләгә. Һәр елны бер повесть тәржемә ителә, басылып чыга («Балачак», 1955; «Үсмерчак», 1956; «Егетчак», 1957). Бу әсәрләрендә үк тәржемәченең ике телне дә нечкәлекләре белән үзләштерүе, ижади дәрте, киләчәктә ачылып китәчәк язучылык сәләте ачык күренә.

Өлкән каләмдәшләренең башыннан сыйпап, жылы сүз әйтүен көтеп торгандай, Кыям Минлебаев урыс әдәбиятының иң мәшһүр, ифрат катлаулы,

кара урман кебек алаштыргыч сюжетлы, көтелмәгән борылышлы, телнең бөтен байлыгын, куәтен үзенә алган В. Шишковның «Угрюм река» романына алына. Тәрҗемәче ифрат тәнгәл, хәтта оригиналдан да төгәлрәк әчтәлекле исем таба («Хәсрәт дәрьясы»), каһарманнарның телен, кырыс табигатьле, кешелексез дөньяны саф татарча янгырата. Тәрҗемә өлкәсендә ана чаклы хөкем сөргән калька, сүзгә-сүз әйләндерү алымына чик куела.

Ул чорда үзе дә тәрҗемә белән шөгыльләнеп, М. Шолоховның шундый ук катлаулы «Тын Дон» эпопеясын башка телдә яңгырату өчен татарчага «күчереп» яткан Г. Ахунов чордашының уңышына сөенеп, юл уңаенда тәрҗемә шөгыленең торышына кин тукталып, бәясен биреп, «Хәсрәт дәрьясы»ның татарчасы һәм тәрҗемә практикабыз турында» исемле мәкалә белән чыга. Утыз мең данә белән басылган «Хәсрәт дәрьясы» тиз арада таралып бетә.

Катлаулы психологик роман белән мавыгып китсә дә, К. Миңлебаев балалар һәм үсмерләр мәнфәгатен онытмый. Бер-бер артлы В. Катаевның шул чорда ифрат танылган «Ялгыз җилкән», Н. Носовның Белмәмеш (Незнайка) турындагы өч китаптан торган әкият-повестьлары туган телебездә басылып чыга. Бу әсәрләрнең югары сыйфатта тәрҗемә ителүе шул өлкәнең белгече, галим Рүзәл Юсуповны «Белмәмеш татарча сөйләшә» исемле фәнни күзәтү язуга рухландыра.



*Сәнгатькяр әдип һәр күргәзмәнең кадерле кунагы*

К. Миңлебаевның теш кайрап, үзен шуңа әзерләп йөргән, димәк ки, рухына, фикерләү рәвешенә якын тагын бер язучы бар икән. Ул—совет чорының күренекле сүз остасы граф Алексей Толстой. Әүвәл ул аның туып килгән фашизмны фашлаган «Инженер Гаринның гиперболоиды» исемле хыялый әсәрен татарча янгырата. Язучының төп әсәре, өч калын-калын китаптан торган «Хождение по мукам» («Михнәтле заман») эпосына өч ел гомер китә. Тәрҗемәнең югары кимәле телгә ифрат таләпчән Х. Сарьянны да битараф калдыра алмый, кулына каләм алып, «Алексей Толстой татарчада» дигән тәпле бәя бирүгә рухландыра.

Нигездә урыс язучыларын тәрҗемә итсә дә, Кыям Миңлебаев Э. Войничның «Кигәвен» романы белән дә татар язучысы танышырга тиеш дип саный. Латин Америкасы әдәбияты да игътибардан читтә калмый. Нобель премиясе лауреатлары Габриэль Гарсия Маркесның «Ялгызлык», Жорже Амадуның «Габриэланың

гыйшкы» исемле мәшһүр романнары татарча яңгырый.

К. Миңлебаев фикерләү рәвешләре, дөньяга карашлары, сурәт-күренеш, тел үзенчәлекләре җәһәтеннән, төрле-төрле сүз осталарын бер үк дәрәҗәдә, сыйфат кимәленә хилафлык китермичә тәрҗемә итә. Авторның фикри кыйбласын, кабатланмас үзенчәлекләрен, ачышларын саклаган хәлдә, ул әсәрне татар телендә мөмкин чаклы табигый яңгырату тарафдары. Тәрҗемә аның өчен көнлекчеләр һөнәре түгел, илаһилыкны, йөрәк җылысын, күңел хуплавын таләп иткән сәнгать. Ул тәрҗемә нәзарәтенә һәм гамәленә кагылышлы күп санлы мәкаләләр, бәяләмәләр язу белән генә чикләнми, озак еллар дәвамында университетта студентлар белән дәресләр, фәнни-әдәби түгәрәкләр алып бара, Татарстан язучылар берлеге каршында тәрҗемәчеләр остаханәсе белән җитәкчелек итә. Матбугатны, әдәбиятны үстерү өлкәсендәге фидакарь хезмәте өчен язучылар берлегенә әгъза итеп алына, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек була.

Кыям Миңлебаевның гомере буенча йөрәк түрендә йөрткән икенче сере дә бар. Анысы—сынлы сәнгатькә мәхәббәте. Ул бу катлаулы, күпләрнең теше үтми торган өлкәгә багышланган язмаларында татар рәссамнарын күтәрә, аларның казанышын халыкка ирештерү рухы белән яши. 1982 елда ул татар халкының бөек улы, мактанычы, гали зат Бакый Урманченың сынлы сәнгать, нәкышь, графика өлкәсендәге казанышларын яктырткан төсле альбом эшли, аңа тәфсилле кереш сүз яза. Остазының, өлкән дустының иҗатына булган олы хөрмәте аны язучылык юлына алып чыга. Олуг рәссамның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган «Бакый» романы туа. Әсәрдә татар теленең төрле катламнарын, эчке куәтен, сурәтлелек мөмкинлекләрен яхшы белүе өстенә, кешенең рухи дөньясын, аң төпкелен ачуда урыс һәм дөнья әдәбиятлары тәҗрибәсен яхшы үзләштерүе сизелеп тора. Бу—интеллектуаль роман үрнәге. Нечкә зәвыклы, тылсымлы өслүб белән язылган бу әсәр матбугатта төрле фикерләр уятты. Берәүләр аны Урманченың якты истәлегенә багышланган эчтәлекле, психологизм алымнарына киң таянган әсәр дип бәяләсә, икенчеләре анда бөек рәссам образын бозып күрсәтү табып, каһарманны тормыш-көнкүреш ваклыклары эчендә эретеп калдыруда гаепләделәр. Тәнкыйтьнең күп өлеше нигезсез, дәлилсез һәм шәхси иде.

Романга килсәк, иң мөһиме шул: ул даһи Бакый Урманчены яратып, үзе ничек аңлаганча, күңел күзе ни рәвешле күргәнчә сурәтли. Әмма аның мәхәббәте уйдырма, төче түгел, ихласлы, вакыты белән тәнкыйди. «Бакый» әсәрендә аның дәрвишлегенең илаһи, хыялый канаты чагылды. Кыям Миңлебаев сәнгатькә, гомумән матурлыкка мөкиббән шәхес. Шунда аның көче, шунда аның Ахиллес үкчәсе.

Урманче кебек күп яклы, гаҗәеп сихри талант иясенең тәгәлләнгән образын бер әсәрдән, бер иҗади заттан гына таләп итү шулай ук дөрес түгелдер. Тукаебыз турында дәрья хәтле әдәбият яши. Мәгәр халык шагыйренең тәрҗемәи хәле, иҗаты һәръяклап ачылды дип раслауга җөрьәт итүче табылмас.

«Бакый» романы К. Миңлебаевның иҗат казанышы, Урманче шәхесен ачу юлында беренче җитди адым. Менә шундый ул дәрвишрәк дигәнебез Кыям Миңлебаев! Озын, бәхетле, иҗади гомер телик аңа! Ул шуңа лаеклы.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*академик*

# ФАТИХ КӘРИМИ МИРАСЫНА ЯҢА СӘХИФӘЛӘР

XX гасыр башы татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышында эз калдырган атаклы журналист, әдип һәм педагог Фатих Гыйльман улы Кәриминең (1870—1937) тууына йөз егерме биш ел тулу датасы 1995 елда беренче мәртәбә җәмәгатьчелек тарафыннан зурлап билгеләп үтелде. Бу гасырның 30-50 елларында хөкем сөргән мәрхәмәтсез тоталитар режим Фатих Кәримине дә әйләнеп узмады. Аның гомере вакытсыз өзелде. Галимнең мирасы һәм истәлеге әле 1980 елларгача эзәрлекләнүгә дәвам итте.

Шуңа да карамастан, татарның алдынгы карашлы кешеләре Фатих Кәримине, аның әсәрләрен, ул чыгарган «Вакыт» газетасын онытмадылар, саклап килделәр. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы Мирасханәдә аның фондына материаллар 1960 елның июленнән башлап тупланып килә. Бу эшне Хавва ханым Сайманова башлап җибәргән иде. Шул вакыттан бирле Мирасханәдә Фатих Кәрими мирасы фонды (25ф.) акрынлап тулылана килде. Аның фондын баетуда аеруча аның бертуган сеңлесе Закирә ханым Шәрәфнең (1884—1984) хезмәте зур булды. Ул күп еллар дәвамында Фатих Кәрими мирасына бәйле документларны, истәлекләрне туплап килде. Шулай ук репрессиягә эләккән галимне реабилитацияләү юлында да тырышлык куйды.

Фатих Кәрими фондындагы кызыклы документлар байтак. Әйтик, анда 1898—1913 еллар арасында мадьяр галиме Герман Вамбери тарафыннан төрекчә катыш татар телендә язылган 15 берәмлек хатның фотокүчермәсе саклана. Бу хатларда Г. Вамбериның Фатих Кәримигә, гомумән, татар халкына карата тирән хөрмәте чагыла. Мадьяр галиме татар әдәбиятын укып, күзәтеп барган; ул аның 1905 елдан соң бер-ике ел эчендә көчле һәм матур күтәрелеп китүенә соклана. Хатларда 1912 елгы Балкан сугышы мәсьәләләре буенча да фикерләр бар.

1995 елның март ахырларында гына Закирә Шәрәфнең оныгы Эльмира Әминова безнең Мирасханәгә әбисенең Фатих Кәрими тормышы һәм эшчәнлеге буенча тупланган 165 битлек ксерокопияләр тапшырды. Алар арасында документлар, хатлар, истәлекләр, мәкалә текстлары бар. Закирә Шәрәф тарафыннан үзе исән чагында беркадәр хатлар, документлар, истәлекләр Мирасханәдәге фондка тапшырылган иде инде. Яңа материаллар фондны тагын да баетып җибәрделәр.

Аларның барсына да бу язмада тукталу мөмкин булмаганлыктан, кыскача күзәтү ясау һәм кайбер кызыклы текстлар белән укучыларны таныштырып үтүне кирәк санийбыз.

Документларны эчтәлекләре буенча түбәндәге төркемнәргә берләштереп карарга мөмкин.

**Беренче төркемгә** Фатих Кәриминең әтисе һәлак булгач (1902 ел, 6 июнь) килеп туган көнкүреш проблемалары, патша жандармериясенең Фатих Кәрими һәм Тимерша Соловьев өстеннән килгән доноска мөнәсәбәтен чагылдырган циркуляр, галимне реабилитацияләү процессына кагылышлы документлар, Сара Борһан кызы Шәрәф (1912—1992) тарафыннан язылган Фатих Кәриминең тәрҗемәи хәле кулъязмасы керә.

**Икенче төркемгә** Оренбург кешесе Тәуфикъ Сабитов һәм Закирә Шәрәфнең Фатих Кәрими хакындагы истәлекләре теркәлә.

**Өченче төркем** материаллар Закирә Шәрәф язган хатларга Фатих Кәриминең замандашлары җибәргән җаваплардан гыйбарәт. Бу язышучылар арасында

күренекле татар зыялысы, педагог, сүзлекләр һәм дәреслекләр авторы Сахиулла Зәкәрия улы Рәхмәти (1894—1979) тарафыннан 1962—1968 елларда язылган хатлары кызыклы. Аларда 1937 ел дәһшәтләре, Галимҗан Ибраһимов, Афзал Таһиров, Фатих Кәримиләргә кагылышлы кызыклы хәбәрләр сакланган.

Сәхи Рәхмәти тарафыннан 1968 елның 3 августында Закирә Шәрәфкә язылган хатта Фатих Кәрими турында җылы сүзләр һәм матур истәлекләр китерелә:

«... Февраль революциясе булгач, «Кәрвансарай»да булган зур бер митингта карагруһлар Фатих абзыйга һөҗүм итеп, «үтерергә кирәк, бөтен дөньяны айкатучы шул Фатих»,—дип кычкыргач, Фатих абзый трибунага чыгып, башындагы эшләпәсен салып: «Җәмәгать! Минә бу чәчләр нигә агарган?»—дип, бик батыр нотык сөйләгән иде. Менә бу сүзләр минем Хәй Хисмәтуллинга язган истәлегемдә юк».

Моннан соң хатта сүз Фатих Кәриминең тууына йөз ел тулу юбилеен уздыру мәсьәләсе тирәсендә бара.

Сәйфи Кудашның 1969 елның 10 февралендә, 1970 елның 31 гыйнварында һәм 22 июлендә Закирә Шәрәфкә атап язылган хатларында да Фатих Кәримигә кагылышлы күп сүзләр бар.

Яңа кергән Фатих Кәримигә кагылышлы материалларның **дүртенче төркемен** әдипнең күренекле галим һәм язучы Ризаэтдин бине Фәхретдингә атап язылган ике хаты һәм 1919 елда «Эшчеләр дөньясы» исемле газетаның 2 апрель санында басылган «Көрәшче эшче» дип аталган мәкаләсе тәшкил итә.

Фатих Кәриминең әлеге хатлары XX гасыр татар иҗтимагый тормышы тарихы өчен гаҗәп әһәмиятле фактларга ия булып торалар, шунлыктан аларның икесен дә бу очракта тулысынча күчереп үтәбез.

## Беренче хат

*Петербург. 6 март, 1900.*

Газиз кардәшем Ризаэтдин абзый.

Мин хәзер Петербургта, кырымлы Ильяс мирза Бураганский типографиясендә торам. Типографиячелек эшләре белән бераз танышырга башладым. Күпме торуым әле хәзергә билгеле түгел. Өч айлап торырга ниятем бар. Мәскәүдә гарәп хәрефләре белән дә баса торган «Гирбек» атлы бер карт немецнең типографиясе бар. Шунда хәреф тезүче, яки корректор булып хезмәткә керергә теләсәм дә, бездә мөселманча эшләр аз була, эшләп торырга кешебез бар дип, мине алмады, шунлыктан монда килдем.

Бураганский мине бик яхшы кабул итте. Саф күңелле, яхшы табигатьле бер адәм күренә. Шәрекъ телләре укытыла торган бер рус мәктәбендә дәрес тә укыта һәм шәрекъ телләрендәге китапларны карый торган цензор Смирновка могавинлек (ярдәмчелек) тә итә икән. Шунлыктан, бу Бураганский аркылы цензурада карала торган китаплар турында бераз мәгълүмат алырга мөмкин булса кирәк. «Европага сәяхәтнамә»мне язып бетереп Мәскәүдән цензурага җибәргән идем. Әле каралып чыкканы юк. Мидхәт әфәндедән хатын бастырырга рөхсәт алу өчен цензурага бирергә ярамаганлык монда килгәч яхшы аңлашылды. Хәтта аны цензурага күрсәтүдән зарар киләчәге беленде.

«Шул хатыгызны һәм миссионер Смирнов рисаләсенә каршы язган җавабымызны Истанбулда үзегез бастыра алмассызмы?»—дип, Мидхәт әфәндедән үзенә хат язган идем, җавап килгәне юк әле. Рәшит казыйның 3, 4, 5 кисәк «Миръат»ләре дә байтактан бирле цензурада яталар икән.

Исмәгыйль бәй Гаспринский («Тәрҗеман» газетасының редакторы) килгән иде, күрешеп сөйләштек. Мидхәт әфәнде минем адресымны белмәгәнлектән, үзенең миңа язган хатын анар җибәргән вә миңа тапшырырга үтенгән икән. Ул аны миңа җибәрмәде. Копиясен алдырып кына сезгә җибәргән икән. Мондый эшләргә катнашудан куркып, шулай иткән булса кирәк. Мин ул хатны яратмадым. «Безгә акыл өйрәткәнче, хәлифә мәмләкәте булган Төркиянең үзендә шундый голяма хәзерләргә тырышсыннар»,—ди.

Бураганский типографиясендә басылырга дип җибәргән «Таң йолдызы»

---

Кәрвансарай—Оренбург шәһәрендәге атаклы татар мәчете бинасының исеме.

атлы әсәрегез цензурага ике мәртәбә кереп, каралып чыккан. Күп урыннары бозылган, төзәтелгән. Шул көенчә Бураганскийның китаплары арасында ята. Укып чыктым, миңа бик ошады. Цензура тарафыннан бозылмый калганнары гына басылса да, яхшы булыр иде. Бураганскийның сезгә зур хөрмәте бар. Ләкин әсәрегезне үз хисабыннан бастыра алмастыр. Чөнки кулы киң булмаска охшый. Шунар күрә, бу әсәрегезне анардан соратып алып, башка берәр җирдә бастыру чарасында керешүенез муафикъ булыр, дип беләм. Тагын берничә татарча цензурадан чыккан әсәрләр дә Бураганскийның китап киштәсендә ята бирәләр икән.

Типографисен бөтенләй сатарга да Бураганскийның нияте юк түгел икән. Үзенә иптәшкә уртак кабул итәргә дә разый. Типографиям унбер мең сумлар тора, ди. Типографиядә Петербург ахуны Гатаулла Баязитовның да өч мең сумлап пае бар икән. Ул шул акчаны алып, Бураганскийдан аерылырга тели. «Аның белән эш йөртеп булмый, ышанычлы кеше булса да, бик ялкау, вәгъдәсез бер адәм. Заказчикларның берсе дә үзеннән рази түгелләр. Аккуратность дигән нәрсә анардан һич юк. Акчамны биреп мине ширкәттән чыгармаса, типографияне торгидан саттырып, хакымны алачакмын»,—ди. Бураганскийның үзенең дә бурычлары күп булганлыгы аңлашыла. Һәрхәлдә бу типографияне зур авырлык белән алып барганлыгы аңлашыла. Пайтәхеттә Ильяс мирза кебек зыялы бер мөселман кулында типографиянең дәвам итүе яхшы иде. Хәллерәк мөселман сәүдәгәрләрен акча белән катнаштырып, типографияне Бураганский кулында дәвам иттерү мәсьәләсен өйрәнергә кирәк булыр дип беләм, бәлки бер нәрсә чыгар.

Рәшит казый Невский проспектта айга сиксән сумга биш-алты бүлмәле зур бер фатир алды. Һәр атнада шимбә көннәрне мондагы укымышлы мөселманнар, төрле мәктәпләрдә укучы мөселман студентлар шунда җыелып, танышып, сөйләшеп утыралар. Киләчәктәге «Татар клубы»ның беренче нигез ташы шушы булса кирәк.

Мәскәүнең юридический факультетын бетереп, Уфага кайтып киткән Искәндәр Солтанов (мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның улы), анда кайткач, татар-башкорт халкын агарту, алга җибәрү турында җин сызганып эшләргә сүз биреп киткән иде, вәгъдәсендә торамы икән? Хатлары бик сирәк килә. Оренбургтан килгән бер хәбәргә күрә, Гани бай Хөсәенов алдагы җәйдә Каргалы курсларын тагын ачып, хәлфәләр укытырга хәзерләнә һәм Париж выставкасына барып кайтырга тели икән.

Төркиядә ун мең христианның поплары белән бергә мөселманлыкка чыгулары һәм чиркәүләрен мәчеткә әйләндерүләре турында «Петербургские ведомости»ның беренче март номерында бер хәбәр басылып чыкты, белмим нинди хәлдә. Сәлам вә хөрмәт белән кардәшенез Фатих Кәрими».

## Икенче хат

*1901, 12 декабрь, Оренбург.*

Газиз кардәшем Ризаэтдин абзый!

Тарафыңыздан җибәрелгән «Асмә» адлы хикәягез тапшырылды. Элек үзем укыдым, аннары атама бирдем. Ул да укыды, ни хәтле дә яраттык, әйтеп бетерү мөмкин түгел. Теле ни чаклы гүзәл булса, мөндәриҗәсе *(эчтәлеге)* шулай ук яхшыдыр. Безгә бу әсәренез бик ошады. Милләтебез эчендә шундый матур әсәрләр язарлык кешеләр булуы, чын күңелдән шатланырлык бер хәлдер. Мондый әсәрләрнең кадерен, кыйммәтен хәзер белмәсәләр дә, киләчәктә белерләр. Бу әсәреңездәге шигырьләрне сөйләгән Закир Верхеуральск янында алтын казытучы Закир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиевдер. Бу шигырьләрне мин үз авызыннан да ишеткән идем. Төрекчә, русча телләрне яхшы белүче, гыйлем, мәгариф яклы, киң карашлы, ачык фикерле бер кеше, яхшы гына шигырь көче бар. Яшьлегендә бераз вакыт Истанбулда торып, әдипләр, шагыйрьләр белән катнашкан, татарча телне бигүк яхшы белә. Истанбулдан кайткач, төрекчәдән тәрҗемә кайбер хикәяләр үзендә чыгарып, берничә шигырьләр язып караган. Аларны бастыручы булмаган, кулларда укылып йөрелгән. Ахырында һәр нәрсәгә борыннарын тыга торган гөмбә башлы вәрәсәтел-әнбия (муллалар) тарафыннан үзенә кяфер пичәтләре басыла башлагач, язудан ваз кичеп, кәсепкә керешкән. «Кайбер татар җөмләләре»

исемендә миңа җибәрелгән бер-ике битлек язуын китаплар арасында куеп, сезгә җибәрдем. «Асмә»нең цензордан исән котылуы мәсьәләсе иң мөһим вә җитди бер мәсьәләдер. Борынгы Ислам мәдәниятын искә төшерү, кавем-кабилә берлеге турында сүз ачу, хосусан башкортларны онытмау, ысуле җәдидә алга китүен теләү цензор Смирнов бабаның һич тә кәефенә килмәгән нәрсәләрдәндер. Аның кызыл карага манган каләме «панисламизм», «пантуркизм» пичәтләре басарга хәзер тора. Күп җирләре бозылмыйча цензурадан чыгуына күп шөбһәм булганлыгы шикелле, бөтенләе белән алып калуын да ихтимал тотам. Шундыйрак мәсьәләләр катнаштырып язылган үземнең ике-өч рисаләмне кайтармыйча алып калды.

Тагын башка берничә кешенең әсәрләрен дә кайтармыйча калуын беләм. Шагыйрь Мөхәммәдсадыйк Рәхимкуловның «Котыб йолдызы» адлы әсәре дә кайтканы юк әле. Моннан соң кайтуы да бик шөбһәле. Алла бәласен йимерсен бу цензорның. Мондый әсәрләрне цензурага җибәрмәстән элек копияләрен алып калырга кирәк. «Асмә»нең копиясе үзеңездә бармы? Булмаса, мин монда күчереп алырмын. Ни булыр, ни булмас, бәлки бер көн килер, болытлар күтәрелер, кояш чыгар.

Цензурадан рөхсәт кайту белән, әлбәттә, үзебез басарбыз. Асыл басылачак һәм таратылачак әсәрләр—шушындый әсәрләрдер.

Берничә ел элек Гомәр хәлфә[1] «Сәлимә»не[2] укыгач: «Кулында мондый көчле каләме, башында мондый матур исәпли алу куәте булган бер кешегә,—башка һәртөрле эшләрен ташлап, бөтен гомере буенча шундый әсәрләр генә язып тору кирәк иде. Үзе дә бәхетле булыр, милләтне дә бәхетле итәр иде»,—дигән иде. «Асмә»не укыгач, минем дә шул сүзләрне әйтәсем килә. Һәрничек булса да, шуның кебек әсәрләрне күбрәк язуыгызны күңлем бик тели.

Сезгә укыр өчен бер ящик белән китаплар җибәрәм. Исемнәре аерым кәгазьгә язылган. Боларның кайсыларын үзегез сораган идегез. Кайсыларын үзем сайлап йибәрәм. Сездә үзегез теләгәнчә торсыннар. Миңа ашыгыч кирәк түгелләр. Шул китаплар белән бергә, сезгә, үземә килгән берничә хатларны да йибәрдем. Арада Госман Нури хатлары да бар. Кырымда Акчокраклы карьясеннән булган бер егет, элек Бураганский типографиясендә корректорлык иткән. Хәзерендә Петербургта гаскәрлек хезмәте итә. Әйбәт язучы, аң-белем иясе, яхшы тәрбияле вә кешелекле адәмдер. «Нәнкәҗан ханым төрбәсе», «Шагыйрь Пушкин» адлы бик матур әсәрләре бар.

Петербурда Азия музәсе эчендә Шәрекъ вә Ислам дөньясы турында бик төрле вә сирәк була торган китаплар бар икән. Европа сәяхәтенә китешли шул китапларның исемнәре язылган каталогның биш-ун битләрен күчереп алган идем. Хәзер шуны да Сезгә йибәрәм. Русия музәләрендә нинди гыйлем хәзинәләре булганлыгын күрерсез. Граф Толстойның Синодка каршы язган озын, бик кызык җавабы бар, моны бастырырга рөхсәт итмиләр, кулдан-кулга күчерелеп йөри. Мин шуны татарчага тәрҗемә иткән идем. Ләкин, хәзер үземдә түгел иде, йибәрә алмадым, киләчәктә йибәрермен. Рәшит казый мөселман мәктәп-мәдрәсәләре турында бер проект язган. Шуны, министрга тапшырдым,—ди. Кәсимдәге миссионерлар җәмгыятенең башлыгы Даронкин дигән бер поп «Ачык хат» исемендә бер рисаля язып, мөселманнарны чукынырга өндәгән. Рәшит казый шуңа каршы җавап язган. Үтенүе буенча, шуларның барысын тәрҗемә итеп, дүртне бай Хөсәеновка тапшырдым. Йөз меңнәр белән сату-алуларын бер якка куеп, шундый нәрсәләр белән шөгыльләнүдән тәм таба. Йә исә Русиядә төрле фикердәге, төрле милләттәге кешеләрнең күбрәк булганы яхшыдыр. Юкса, дөньяда яшәү бик күңелсез булыр, эч пошар иде, һәм фанатик русларга каршы фанатик мөселманнар булуы бик табигый бер халдер.

Оренбургның архивный комиссиясе үткән ноябрьнең 16 сында булган җыелышында мәшһүр гарәп сәяхе «Ибн Фазлан»ның башкортлар хакында язган язуларын латинчадан русчага тәрҗемә иттерергә карар бирде. Башкорт хакында

1. Гомәр хәлфә Дәүләтьяров Оренбург янындагы Каргалыда сату итеп тора, ләкин урысча, терекчә яхшы белә, күп укый, тирән мәгълүмат иясе бер кеше иде.
2. Ризаэтдин абзый тарафыннан язылып... елда басылган матур бер хикәяттер. (Фатих Кәрими искәрмәләре.—М. Ә.)

русча язылган бер хикәя китабын миңа бүләк итеп йибәрүе өчен мөфти хәзрәтләре Солтановка тэшәккеремне ирештерүенезне үтенәм. Үзем дә хат язарым һәм берәр китап бүләк итеп йибәрермен дип торам.

Атам үзе Сезгә бер хат язды, шул китаплар арасындадыр. Бәлки мине өйләндерү мәсьәләсе турында да бераз язгандыр. Ул турыда атам-анам борчылалар. Алар күптән бирле инде мине өйләндерәселәре килә. Монар үзем дә каршы килмим. Ләкин бу эш мәйданга килә тора, һәмишә кичегә бара. Әлбәттә, сәбәпләре бар, һәм бер түгел, берничә сәбәпләр бар. Боларның иң беренчесе, дөньяга вакытсыз килүебездер, йә бераз элегрәк, яки бераз соңрак киләсе калган. Мин хәзер европалы да түгел, азияле дә түгел, икесе арасында калганмын. Дөрес тәрбия-тәгълим күреп, дөнья гыйлемләре укылган бер кыз миңа килергә теләмәс. Ул доктор, инженер, офицерга барырга телә. Хәтта шундый бер бәндә табылып, миңа килергә разый булса да, аны алырга ярамас. Чөнки, андый бер кешене тәрбия итеп, канәгатьләндереп тору безнең кулыбыздан килмәс. Бер дә укымаган, гыйлем-тәрбия күрмәгән кеше безнең өчен тагын да бик муафикъ булып житмәс.

Без бай да түгел, ярлы да түгел. Бай түгел, чөнки капиталыбыз юк. Барлык капиталыбыз кулдагы каләм белән баштагы теләк вә хыялдан гыйбарәт. Тормышыбыз бик гади, ярлылар дәрәжәсендә киенеп, ярлылар дәрәжәсендә ашап-эчеп, үзебез эшләп көн күрәбез. Әткәй үзе чыгып кар көри, ишек алды тазарта, тирес түгәргә бара. Иң ярлы кешеләр белән бик рәхәтләнеп, бертуган шикелле сөйләшеп утыра. Әнкәй идән юа, кер юа, аш пешерә, кәрзин күтәреп әйбер алырга базарга йөри. «Ул кадәр ватылмагыз, хезмәт өчен бер малай яллыйк»,—дисәм дә, әткәй разый булмый,—үз кулыңнан килгән эшне, ник кешедән эшләтергә,—ди, һәм расход күп булудан курка.

Ярлы түгелбез, чөнки бурычыбыз юк, тамыгыбыз *(комсызлыгыбыз)* юк, намусыбыз бар, эшләп яшәргә һәм дә эшебез бар. Менә шуңар күрә мин өйләнгәндә,—безгә шундый, үзебез төслерәк бер кеше туры килсә икән, дибез. Андыйны ничек табасың, кайдан туры китерәсең. Егетләр белән кызлар арасында электән күрешеп танышу гадәтләре булмагач, бер-береңә муафикъ кеше белән очрашулар ике як өчен дә бер бәхеткә генә терәлеп кала.

Болардан башка тагын да бер нәрсә бар: мәгълүменездер ки, безнең әткәй бик тә туры сөйләргә ярата, үзе бик хөррият яклы. Монда (Оренбурга) килгәч тә каршысындагы кешенең дәрәҗәсен, кем икәнлеген игътибарга алмыйча, төрле мәсьәләләр турында ачыктан-ачык сөйләшеп, мөселман халкының артта калуына зур сәбәпләрнең берсе—мөселман кызларының укытылмавы мәсьәләсен, хатыннарның качып-бөркәнеп йөрүләре икәнлеген, боларны шулай иткән нәрсә надан муллалар, ахмак руханилар булганлыгын туры килгән бер җирдә әйтә бирде. Шуның өчен Оренбургта Каргалының барлык муллалары вә игътибарлы кешеләр дип саналган надан, фанатик байлары вә сәүдәгәрләре—барысы да, безгә начар күз белән карый торган булдылар. Монда мулласыз бер нәрсә дә эшләнми. Муллалар вә «могътәбәран» (ягъни *«хөрмәтлеләр»*) исә һәр турыда безгә каршы фикердәләр. «Шәкерт белән студент» вә «Җиһангир мәхзүм» рисаләләре дә бу турыда алар кулында зур корал булды. «Диннән көлгән, комганга тигән, голяманы мыскыл иткән андый кешеләрне ислам арасына кертмәскә кирәк»,—дип, Фатих ахун Гайнетдинов мәҗлесләрдә ачыктан-ачык агитация ясый: «Гыйльман ахун булган мәҗлескә мине чакырмагыз»,—ди. Байлар вә сәүдәгәрләр кашында гыйлем, мәгърифәт, мәдәният дигән нәрсәләрнең кыйммәте өлкән бәрән тиресенең кыйммәте чаклы да тормаганлыктан, тәүфикъ истикамәт *(дөреслек, туры юл)* дигән нәрсәләр алар кашында бөтенләй башка мәгънәдә йөргәнлектән, без алар кашында тәүфикъсыз, истикамәтсез кешеләрдән саналабыз. Шуның өчен бу мохит эчендә минем өйләнә алуым шул бәһаледер.

Кырымда укытып торган вакытымда мине өйләндереп, шунда алып калырга теләгәннәр һәм иптәшлек өчен муафикъ адәмнәр дә күрсәткәннәр иде. Ләкин мин Кырымда бөтенләй калырга теләмәдем. Алар кызларын кияүгә биреп, ерак җирләргә җибәрергә теләмиләр иде. Шунлыктан бу эш анда да булмый калды. Аннары Европада йөргән вакытыбызда Бельгиянең бер васыйл *(ирешкән)* шәһәрендә мөгаллимәлек итүче бер француз кызы миңа кияүгә чыгып, Русиягә килергә бик теләгән иде. Аңлашдыкына күрә, тәгълим-тәрбиясе, әхлак вә табигате

дә безгә туры килерлек күренә иде. Иптәшем Шакир Рәмиев тә шуның белән өйләнеремне муафикъ күреп, юл расходларына һәм монда кайткач, мәгыйшәтне корып җибәрергә матди ярдәм итәчәген дә аңлаткан иде. Укыган, яшь, тәрбия күргән бер кешене монда алып кайтып, шундый наданлык, фанатизм эчендә коллыкта, хурлыкта яшәтүгә күңлем разый булмады. Ахырында тәкдирдә, язмышта ничек булса, шул булыр, дияргә кала.

Бу мәсьәлә турында Сезгә болай озын язуымның сәбәбе—ата-анамның моңар зур әһәмият биреп борчылуларындандыр. Юкса, минем үз фикерем бу мәсьәлә белән артык мәшгуль түгел. Бу хакта артык исәпләмим дә, ни булса—ул булыр, дип карыйм. Мөселманчамы, русчамы бераз укыган, әхлак вә табигате төзек булган, көн күренешләре безнең дәрәҗәдәрәк булып, тук вакытта шөкер итә, ач вакытта бергә эшләп көн күрә торган бер бәндә туры килә калса, мин шуның белән гомерлек иптәш булырга разыймын. Кем белер, бәлки туры килер әле, Ходайның дөньясы киң бит. Бу мәсьәлә турында атама хат яза калсагыз, аны бераз тынычландырырлык рәвештә язуыгызны үтенәм.

Монда артык ят хәбәрләр юк. Элек Сызрань каласында мулла булып торган Мозаффар Мөштәриев дигән бер кеше (бер казый углы икән) Оренбургта хосусый русский класс ачып, мөселман балаларын русча укытырга мәктәпләр директорыннан рөхсәт алган. Сөләйман ахун углы Әхмәтфәез мәхзүм белән бергә эш күрәчәкләр икән. Мәктәпләр караучы директор Әхмәт бай Хөсәенов мәдрәсәсенә еш-еш килеп тикшеренеп йөри, нинди дәреслекләр, укытуы, укытучыларның кемнәр, кайда укыган кешеләр булуы турында мәгълүмат ала тора. Ни дә булса борын тыгып мәдрәсәгә бәйләнергә, тырнак астыннан кер эзләп маташа булырга булса кирәк.

Бу хатымны Сезгә бик озын яздым, Сезне бик якын күрүем сәбәпле. Хат яза башлаганда күңелемдәге бөтен нәрсәләр үз-үзеннән агып, каләм очына килә баралар.

Сезгә күп хөрмәт вә сәлам белән кардәшенез Фатих Кәрими».

Фатих Кәриминең сеңлесе—Закирә Шәрәф тарафыннан язылган истәлекләр дә бөек мәгърифәтче-галимебезнең тормыш сәхифәләрен тәшкил итәләр. Аларның күләме 91 битле дәфтәрне тутыра. Закирә Шәрәфнең «Казан утлары» (1968, № 6) журналында басылган Зариф Бәшири истәлекләре уңае белән язылган озын хаты да бик мөһим фикерләргә ия һ. б.

Санап үтелгән текстларның һәм китерелгән чыганакларның әһәмияте бер Фатих Кәрими шәхесе белән генә чикләнми. Бу чыганакларда татар халкының XX гасыр башындагы бөтен иҗтимагый-мәдәни проблемалары чагыла. Аларда Ризаэтдин Фәхертдинов, Рәшит казый (Ибраһимов), Дәрдмәнд (Закир Рәмиев), Мидхәт әфәнде, Смирнов (цензор), Ильяс мирза Бураганский, Госман Нури Кырыми, Гомәр хәлфә Дәүләтъяров һ. б. тормыш һәм эшчәнлекләре буенча мәгълүматлар бирелгән. Ул мәгълүматлар, материаллар татар тормышының XX гасыр башындагы елларда динамик үсештә булуын күрсәтәләр.

Татар әдәбияты, тарихы, эстетикасы, фәлсәфәсе буенча эшләүче галимнәр өчен яңа табылган сәхифәләрнең кыйммәте зур.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

*Фән*

# ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ТӨЗЕЛСӘМЕ?!..

Газиз халкының яшәү рәвешенә даимән яктылык сирпеп, аның рухи сәламәтлеген, акыл көчен һәм хис-тойгы байлыгын гәүдәләндереп торган шәхесләр була. Андый асыл затларга ихласи мәхәббәт гомер сулары агу белән дә сүнми, тормыш юллары, иҗат эшчәнлекләре белән кызыксыну, аларны тулырак, тирәнрәк аңларга теләү бервакытта да кимеми. Мондый төр ихтыяжны ничек канәгатьләндерергә соң? Теге яки бу жанрдагы әдәби әсәрләр, аерым проблемаларны үзәккә куйган, монографик характердагы фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр генә укучы күңелендә туган һәм туачак төрле-төрле сорауларга җавап биреп бетерә алмый. Әйтергә кирәк, әлеге ситуациядән чыгу юлы инде табылган: бу—энциклопедияләр, энциклопедик сүзлек-белешмәләр төзеп бастыру. Соңгы ике-өч гасыр эчендә күп илләрдә, шул исәптән Россиядә дә, андый китаплар бертомлык булып та, күптомлыклар булып та нәшер ителә тора. Якын заманда, 70—80 елларда, хәзер Бәйсез дәүләтләр берлегенә кергән илләрдә дә үз халыкларының бөек язучыларына багышланган энциклопедияләр дә төзелә һәм дөньяга чыга башлады. Мәсәлән, Украинада Шевченко сүзлеге, Казакъстанда Абай энциклопедиясе дөньяга чыгып өлгерделәр дә инде. Кайбер мәгълүматларга караганда, Низами, Нәвоиларга багышланганнары да чыгып килә.

Бездә дә Тукаебызның «шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән» гомер юлын, гаять бай эчтәлекле иҗат мирасын, халкыбыз күңелендә сүнмәс йолдыз булып яшәвен чагылдыра алган махсус энциклопедия (энциклопедик сүзлек-белешмә) төзү мәсьәләсе күптәннән күтәрелеп килә. 80 елларда Әбрар Кәримуллин, Нил Юзиевләр, соңрак Флүн Мусин гыйльми көчләребезнең бу әһәмиятле, әмма авыр, катлаулы эшкә җиң сызганып тотынырга тиешлекләрен әйтеп чыктылар. Тик Татарстаныбызның суверенитеты игълан ителеп, бераздан исә үз Фәннәр академиясе гамәлгә куелгач кына, мондый персональ энциклопедияне төзү буенча беренче адымнар ясала башлады. 1993 елда Фәннәр академиясе Президенты Мансур Хәсәнов һәм академиянең гуманитар фәннәр бүлеге академик-секретаре Мирфатыйх Зәкиев күрсәтмәсе нигезендә Нил Юзиев җитәкчелегендә бер төркем әдәбият галимнәреннән вакытлы хезмәт төркеме оештырылган иде. Вакыт-вакыт эшләп алып кына булса да, 1996 елның ахырына Н. Юзиев, М. Әхмәтҗанов, Р. Ганиева, Ф. Яхин һәм З. Рәмиевләрдән торган бу төркем әлеге энциклопедик сүзлектә урын алырга тиешле табылган мәкалә һәм белешмәләрнең исемлеген төзүне тәмамлады. Танылган әдәбият галиме, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Нил Гафур улы Юзиевнең 1996 елның сентябрендә дөньядан китүе, билгеле инде, бу эшне дәвам иттерүне кыенлаштырды. Шулай да 1997 елда энциклопедик сүзлекнең исемлеген яңа материаллар исәбенә тагын да тулыландыра төшеп, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы Азат Әхмәдуллин һәм бу юлларның авторы тарафыннан редакцияләп бастырып чыгарырга мөмкин булды. Шулай итеп, Тукай персональ энциклопедиясен төзүнең иң беренче, чагыштырмача җиңелрәк этабы тәмамланды дияргә ярый. Хәер, эш барышында бу исемлеккә шактый өстәмәләр, төзәтмәләр кертелер.

Хәзер инде бөтен гыйльми көчләрне бергә туплап энциклопедияне әзерләүнең гаять тә җаваплы дәверен—әлеге исемлектә исемнәре һәм күләмнәре (шулай ук иллюстрация яисә портрет бирү очраклары да) күрсәтелгән 3000 мәкалә һәм белешмәләрнең үзләрен язу эшен башлап җибәрү кирәк. Энциклопедияләргә язуның төп үзенчәлеге шунда: андагы мәкалә һәм белешмәләр кыска күләмле, җыйнак, шул ук вакытта фикергә бай, тыгыз эчтәлекле булырга тиеш.

Габдулла Тукай энциклопедик сүзлек-белешмәсен төзүдә төп максат—шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен, иҗат мирасын, традицияләрен төрле яклап өйрәнүдәге

казанышларны системага салып чагылдыру, дип уйлыйм. Гомум күләме 100 басма табак тәшкил итәр дип уйланылган сүзлек-белешмәнең якынча 15 табагында, ягъни 360 битендә, Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы (кыскача), иң мөһим гыйльми әдәбият исемлеге, шигырь һәм поэмаларында кулланылган рифмалар сүзлеге, Тукай теленең ешлык сүзлеге урын алыр дип фараз ителә.

Бу зур хезмәтнең 85 табагын, гадәти китап битенә күчереп хисапласак, 1300 битен, энциклопедик сүзлек-белешмәнең төп өлешен тәшкил итүче мәкалә-белешмәләр биләячәк. Берничә сүз белән аларның нинди эчтәлеккә ия булачагы, үзәккә нинди тема, нинди проблема куелырга тиешлеге турында әйтеп китик.

Исемлектән күренгәнчә, бар биреләчәк материал сигез тематик төркемне (юнәлешне) тәшкил итә.

Болар арасында иң күләмлесе—билгеле инде, Тукайның үз әсәрләре турындагы мәкалә һәм белешмәләрдән торачак беренче юнәлеш. Җиде-сигез елдан артмаган иҗат гомерендә ул 400 ләп шигырь, баллада, поэма, 350 ләп фельетон, публицистик мәкалә, әдәби тәнкыйть язмасы, рецензия, балалар өчен прозадагы миниатюра язып бастыра. Аларның гомуми саны, бүгенгә җыелган мәгълүматлар буенча, шулай итеп, 750 гә җитә. Берара Тукай әсәре сыйфатында басылып йөртелеп тә, ахыр чиктә анык булып чыкмаганнар турысында да, Тукайга нисбәт ителеп кенә йөртелә торган текстлар хакында да сүз әйтелергә тиештер. Тукай әсәрләренә карата фәнни фикер 1910—1980 еллар арасында татар әдәбияты тарихын тикшергән хезмәтләрдә булсын, шигърият, проза, публицистика, сатира һәм юмор, балалар әдәбияты журналистика өлкәсендәге тикшеренүләрдә булсын, күп әйтелде, күп язылды. Билгеле ки, энциклопедиягә керәсе мәкалә-белешмәләр шактый дәрәҗәдә боларда тупланган бай фикри һәм фактик материалга нигезләнеп язылачак. Әмма шунысы да бар, Тукай иҗатын без төрле заманда төрлечәрәк кабул иттек. Хәзер исә бөтенләй яңа дәвергә аяк бастык шикелле. Өстә, баш очында идеология кылычы тормый. Димәк, Тукай феноменының асылына якынаю мөмкинлеге бар. Эзлән, тикшер, тирәнлеген ачарга омтыл. Әйе, энциклопедиягә керәсе мәкалә-белешмәләрне язу—ул электә әйтелгән, заманасы өчен шактый кыю, дәлилле булып күренгән фикерләрне, фәнни фикер-концепцияләрне эзләп табып, бер тирәгә җыйнап бирүгә генә кайтып калмастыр. Һәр мәкалә-белешмә Тукай әсәрләренә яңача караш белән үтәдән-үтә сугарылуга ирешү—аларны язучы автор-тикшеренүчеләрнең галимнәрнең намус эше. Мондый мәкаләләрдә сүз әсәрләрнең иҗтимагый тормыш, реаль чынбарлык белән бәйләнешен чагылдырган аерым сурәтләр, образлар, детальләр турында гына бармаска, аларның сюжет-композициясенә, поэтикасына, сәнгати эшләнешенә кагылышлы гомумиләштерелгән күзәтүләр дә урын алырга тиешледер. Аларда шулай ук әсәрнең кулъязмасы, автографлары, беренче мәртәбә басылышы, язылу вакыты турында да мәгълүматлар китерелә, әсәрләрне музыкага салган композиторлар, яисә иллюстрацияләгән рәссамнарның исемлеге бирелә.

Икенче тематик төркемгә керәсе мәкаләләрдә Тукай иҗаты әдәбият теориясенә, иҗтимагый фикер тарихына караган проблемалар яктылыгында (һәрбер әсәре аерым-аерым түгел), гомумән алып тикшереләчәк. Аларның саны—әлегә 140 данә чамасында. Кайберләре, мәсәлән, «Җырлар», «Реализм һәм романтизм», «Поэзия», «Эстетик идеал» кебек аерата җитди проблемаларны яктыртасы мәкаләләр чагыштырмача зуррак мәйдан сорый (якынча өчәр битле).

Өченче, «Туганнары, дуслары, замандашлары» дип исемләнгән тематик төркемгә караган мәкалә һәм белешмәләрне язу да, моңа кадәр тупланган фактик материалны чагылдыру белән генә канәгатьләнмичә, күптөрле эзләнүләр алып баруны таләп итә. Чөнки сөекле шагыйребезнең замандашлары, туганнары, дуслары белән мөнәсәбәтләрендә ак таплар, томанлы урыннар, ачыклауга мохтаҗ моментлар бар әле. Әйе, бу төркемдәге язмалар бик күп фактик мәгълүматларга таянып кына тудырыла ала. Аларда Тукайның башка шәхесләр белән төрле-төрле характердагы һәм катлаулы бәгъләнышларын, гасыр башында яшәгән кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен унга-сулга тайпылмыйча, шомартмыйча, шәхесләрне кимсетмичә аңлату кирәк. Бүгенге көнгә җыелган мәгълүматлар буенча (билгеле ки, алар эш барышында тагын да тулылана төшәр) мондый төр мәкаләләрнең саны 400 гә җитә яза.

Чама белән шул ук сандагы мәкаләләрдә—дүртенче бүлектә Тукайның меңъеллык татар әдәбияты тарихында урын алган әдипләр—шагыйрь, прозаик, драматург һәм публицистлар белән бәйләнешләре ачылачак. Шулай ук шагыйрьнең әсәрләре нәшер

ителгән, яисә аның тормышы, иҗаты, башка әдәбиятларга, иҗат әһелләренә йогынтысы хакында төрле рухтагы язмаларны урнаштырган газета һәм журналлар, китаплары чыккан нәшриятләр дә игътибардан читтә калмастыр. Татар әдибе турындагы мәкалә иҗатының күпкырлылыгына, байлыгына, сәнгати дәрәҗәсенә карап түгел, бәлки Тукайга бәйлелек дәрәҗәсенә карап языла, аның күләмен дә бары тик шул нәрсә билгели. Сүз дә юк, Ф. Әмирхан, М. Гафури, С. Рәмиев, З. Бәшири, С. Хәким, Н. Исәнбәт, Г. Ахуновлар иҗатында Тукай белән бәйләнешле яклар шактый күп, шуна күрә алар турындагы мәкаләләр икешәр-өчәр битле үк булачак.

Исемлекнең бишенче бүлеге «Тукай һәм татардан тыш дөнья» дип исемләнгән һәм ул 250 мәкалә атамасын эченә алган. Бу тематик юнәлештәге материалларда Тукай әсәрләрен башка милли телләрдә, мәсәлән, рус, башкорт, казакъ, үзбәк, әзербайҗан, төрек, чуваш, мари, каракалпак, украин, уйгыр, комыкча яңгыраткан тәрҗемәчеләргә, бу милләтләрнең Тукай тормышы, иҗаты, традицияләре турында әдәби әсәрләр, фәнни хезмәтләр, фәнни-популяр мәкаләләр бастырган язучылары, галимнәре, җәмәгать эшлеклеләренә лаеклы бәя бирелер дип уйланыла.

Тукайның тәрҗемәи хәле, әсәрләре, иҗтимагый эшчәнлеге, Тукай образы татар сәнгатенең барлык төрләрендә, жанрларында (музыка, балет, опера, концерт, рәссамлык, театр, кино, телевидение, курчак театры, мультипликация) чагылыш тапты. Энциклопедик хезмәттә сәнгатькярләребезнең бу юнәлешләрдәге иҗат җимешләре турында да җитди сүз алып барылачак. «Габдулла Кариев», «Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская», «Бакый Урманче», «Фәйзрахман Әминев», «Салих Сәйдәшев», «Тукай һәм музыка» кебек мәкаләләрне язу өчен фактик мәгълүматлар шактый бай. Гомумиләштереп бирү өчен таяныч булырдай фикерләр, күзәтүләр дә фәнни әдәбиятта беркадәр тупланган инде.

Татарстанда, Россиядә Тукайның тормышы, иҗат эшчәнлеге белән бәйле җирләр, төбәкләр турында бер сүз дә дәшми узу мөмкинме соң?! Казан артының Кушлавыч, Сасна пучинкәсе, Өчиле, Кырлай кебек авылларында, Җаек, Казан, Петербург, Уфа, Әстерхан, Мәкәрҗәләрдә Тукайның булуын, гомер юллары узуын, аларның шагыйрь иҗатында үзенчәлекле төсмерләрдә чагылышын күрсәтү энциклопедик хезмәттә үзеннән-үзе соралып тора. Шулай ук әсәрләрендә теге яки бу очрак белән телгә алынган географик объектларга: кыйтгалар, илләр, мәмләкәтләр, шәһәрләр, авыллар, төбәкләр, елгаларга нәкъ менә Тукай күзаллавыннан чыгып бәя бирү кирәк, моның ише мәкаләләрдә аларны телгә алуның рәвеше, сәбәбе ачыла күрсен иде.

Энциклопедик сүзлек белешмәгә керәсе 380 мәкаләдә шагыйребезнең тәрҗемәи хәлен, иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлеген өйрәнүнең торышына кагылышлы материаллар, фикерләр тәфтишләнәчәк, бу эшкә хәл кадәренчә өлеш керткән галимнәр, язучылар, тәрҗемәчеләрнең хезмәтләренә, гамәлләренә бәя биреләчәк. Тукайның кыска гына иҗат гомерендә төрле-төрле жанрдагы әсәрләрен бастырган чакта бик күп—70 ләп имза кулланганлыгы мәгълүм. Аларның һәрберсе хакында да энциклопедиядә сүз булыр.

Кабатлап әйтәбез, бу зур, фундаменталь хезмәттә аерым шәхесләрнең (Тукай туганнарыннан тыш) биографияләре бирелми, бары тик реаль тормышта нинди һөнәр иясе, белгеч буларак урын алганлыгы гына бер-ике сүз белән генә хәбәр ителә (әдип, язучы, журналист, композитор, рәссам, әдәбиятчы-галим, тарихчы, дин эшлеклесе һ. б. ш ). Мәкаләләрдә атаклы, күренекле, мәшһүр, танылган, бөек кебек эпитетлар кулланыла калса, субъектив моментлар урын алыр иде, шунлыктан аның ише бәяләмәләрдән баш тартырга туры килә. Премияләр, орденнар, медальләр белән бүләкләнү, мактаулы исемнәр бирелү дә искә алынмаячак. Бары тик шагыйребезнең үз исемен йөрткән премиягә—Тукай бүләгенә лаек булуга гына игътибар ителергә тиешле кебек. Һәр мәкалә һәм белешмәнең азагында аларда яктыртыла торган проблемага, вакыйгага яисә шәхес эшчәнлегенә кагылышлы фәнни әдәбият исемлеге дә китереләчәк.

Милли җанлы бер генә татар кешесен дә Тукаебызга багышланган энциклопедияне төзү эше кызыксындырмый калмас. Фәнни оешмаларда, югары уку йортларында гуманитар гыйлемнәрнең төрле тармакларында, юнәлешләрендә җитди, бик мөһим тикшеренүләр белән мәшгуль галимнәребез исә бөек шагыйребезне—шәхесен, иҗатын ихтирам итүләрен сүздә генә түгел, бәлки шушы энциклопедияне гамәлгә куюга актив катнашулары белән дә расларлар дип уйларга кирәк.

**Зөфәр РӘМИЕВ,**

*Энциклопедияне төзүнең иҗади төркем җитәкчесе*

*«Казан утлары» архивыннан*

# ТАРИХКА КАЛГАН МИЗГЕЛЛӘР

Без, гадәттә, тарихны ерак узганнар белән бәйләп күзаллыйбыз. Ә баксаң, үзебез дә яшәвебез, эш-гамәлләребез, тормышыбыз белән тарихка яңа сәхифәләр өсти торабыз икән ләбаса.



Шагыйрь Хәсән Туфан елмаюы.— Бу рәсемне шулай дип атап булыр иде кебек. Әчке нур бөркелеп торган бу елмаю шагыйрьнең кешеләргә карата ихлас ярату хисен, милләтебезнең киләчәге— яшьләргә соклануын, аларга баглаган өмет-ышанычын бик ачык чагылдыра. Фотограф Мидхәт Шакиржанов аны язучы Афзал ага Шамов белән Казанның Мехчылар клубындагы әдәби кичәдән соң төшереп алган. (70нче еллар).



Фронтовик-шагыйрь Әнвәр абый Давыдов белән исә бу рәсемгә 1965 елның апрель аенда, төгәлрәк әйткәндә, Габдулла Тукай туган көнне уздырылган традицион Шигырь бәйрәмендә төшкән идек. Әнвәр абый поэзиядә фәлсәфи фикер, яңа шәкелләр эзләү тарафдары булгангамы, аны яшь шагыйрьләр аеруча үз күрәләр, күбесе үзләренең остазы саный иде. Әнә бит, аның тирәсендә—инде хәзерге вакытта зур шагыйрьләр, журналистлар, галим һәм җәмәгать эшлеклеләре булып җитешкән шәхесләр: Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Фарсил Зыятдинов, Фирая Зыятдинова, Мөхәммәт Садыйков, Миргасыйм Гаскәров, без фәкыйрегез һәм башкалар. Уртада—Әнвәр Давыдов.



Бу фоторәсемнең тарих өчен төшереп алынуына үземә дә шаһит булырга туры килде. 1985 елның февралендә Татарстан рәссамнарының иң уңышлы картиналарыннан күргәзмә оештырылган иде. Анда, гәзит хәбәрчесе буларак, мин дә катнаштым. Күргәзмәне карап йөргәндә рәссам Валерий Скобеевның бер картинасы янында тамашачыларның озаграк тукталуларына, кызыксынып карауларына игътибар иттем. Картинада күренекле композитор Нәжип Җиһанов иҗатташ дуслары арасында тасвирланган. Ул бик илһамланып, пианинода уйный. Муса Җәлил либреттосына иҗат иткән «Алтынчәч» операсы белән таныштыра бугай. Арада шагыйрьнең дә булуы шуңа ишарә ясый шикелле.

Шул вакыт бер төркем яшьләр картина янына житәкләп Нәжип ага Җиһановның үзен алып килделәр һәм бергәләп фоторәсемгә төшүен үтенделәр. Фотокорреспондент Мидхәт абый Шакиржанов шул арада төшереп тә алды. Объективка мин дә эләктем.

*Фоторәсемнәрне журналга тәкъдим итүче*—**Шамил МАННАПОВ.**

*Котлыйбыз!*

## Дамир Гарифуллинга 60 яшь



Сарман районында туы-үскән, әле дә шунда яшәп ижат итүче каләмдәшебез Дамир әфәнде Гарифуллинның олуг юбилеен республикабыз матбугаты бик зурлап билгеләп үтте. Һәм бу табигый да: балалар өчен матур-матур шигырь китаплары бастырган шагыйрь үзенең «Чыгарсынмы каршы алырга» (Валерий Әхмәтшин көе) жыры белән татарлар яшәгән һәр төбәккә мәгълүм дип беләбез. Робагыйлар да яза ул—«Мен дә бер робагый» дип исемләнгән китап кулъязмасы нәшриятта басылуны көтеп ята; хикәяләр дә ижат итә. Һәм, иң кыйммәтлесе: ул—олуг фән эшлекләләре, хәтта ки академиклар да санлаша торган күптәнге галим, китапчы (жөмләдән, Мөхәммәдъярның сирәкләрдән сирәк «Төхфән Мәрдан» әсәре кулъязмасын табуын гына искә төшерик!), авыллар тарихын язучы, атаклы кешеләрнең шәжәрәсен өйрәнүче, төзүче дә (мәсәлән, соңгы вакытта ул сөекле жырчыбыз Илһам Шакирның нәсел агачын өйрәнеп, шәжәрәсен эшләде...). Гали Чокрый, Акмулла, Утыз Имәни ижатларын, аларның бүгенге варисларын өйрәнүдә дә матур өлеше бар әдипнең.

Дамир Гарифуллин—Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Сарман һәм Зәй районнарының Сөббух Рәфыйков исемендәге премияләре лауреаты.

Каләмдәшебезгә янадан-яна ижат уңышлары телибез!

## *Укучы сүзе*

* * *

Татарстан китап нәшриятында Мөршидә ханым Вильданова-Хәкимова һәм аның улы Рафаэль әфәнде Хәкимов тарафыннан төзелгән «Таныш өянкеләр» дигән матур гына җыентык дөнья күрде. Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимгә багышлап язылган 295 битле бу китапта төрле буын язучыларының истәлекләре тупланган. Аның нәкъ менә хәзерге чорда басылып чыгуы бик тә вакытлы, хикмәтле. Чын мәгънәсендә, әдәбиятыбыз күгендә балкыган асыл бер күренеш булды ул.

Чөнки бу мәҗмуга ярдәмендә без, «Сибгат Хәким» феномены белән беррәттән, авторларның үзләрен дә, иҗат кешеләре буларак, яңабаштан ачабыз кебек. Дөресрәге, алар үзләре ачылып китеп, яна фән термины белән әйтсәк, әдәби-культурологик анализ ясыйлар. Фикерләре кызыклы, саллы, уйландырырлык.

Әйтик, чорыбызның күренекле әдибе Әхсән Баян үзенең хатирәләрендә: «Аның (ягъни С. Хәкимнең—Р. Н.) урыны әле дә буш»,—дигән фикерне алга сөрә. Бу—хак сүз, әлбәттә. Һәм автор, моның сәбәбен ачыклау максатыннан чыгып: «Үзеңне телән, Әдәбият һәм Халык хакына яши алу»,—дип, дөрес диагноз куя. Шуннан соң күнелдә: «Нигә соң әле башкалар—бездәге зур күпчелек!—шушы «рецепт» буенча яшәми, бары тик аерым шәхесләр генә—Халык һәм Әдәбият мәнфәгатьләрен кайгыртып—тирә-юньне яктыртып янган шәм-учак кебек, үзләрен корбан итәләр?»—дигән бик тә урынлы сорау туа.

Әгәр дә бу сорауны теге яки бу фән кешесенә бирсәң, ул шунда ук бу очракта мөмкин булган берәр системалылык күренешен эзли башлар иде. Төптәнрәк уйласак, без дә андый системалылыкны таба алабыз. Мәсәлән, «Габдулла Тукай белән Сибгат Хәким системасы»н. Нәрсә берләштерә соң бу ике бөек затны бер системага? Әлбәттә, әлеге дә баягы хикмәтле күренеш—«үзең телән, Әдәбият һәм Халык хакы өчен яши алу» рәвеше.

Кайдан килә икән соң кешегә мондый сәләт, мондый изгелек? Моңа философиянең яна бер төре—экзистенциаль философия җавап бирә ала. Ул нәкъ менә кешенең эчке дөньясы белән кызыксынучы юнәлеш. Һәм шушы фәлсәфи белемнең «атасы» саналган Серен Кьеркегорның (1813-1855), мәсәлән, мондый фикере мәгълүм: «Тумыштан кеше нинди генә сәләтле булмасын, ул әле дөньяда үзенең урынын тапмый торып, беркем дә була алмый» *(С. Кьеркегор. Или-Или. М., «Актогея», 1993, 217 б.).*

Һәм бу мәшһүр философ шушы ук әсәрендә бераз алдарак болай дип дәвам итә фикерен: «Моның өчен кешегә яңадан туу кирәк (ягъни, дөньяда үзенең чын-чынлап урынын табу өчен—Р. Н.)». «Кеше кинәт бер мәлдә үзенең мәңгелек әһәмиятен искәрсен өчен ул бик көчле рухи тетрәнү кичерергә тиеш»,- дип тә өсти бу философ (248 б.).

Ниһаять, күктән җиргә төшеп, сорау куйыйк—Г. Тукай белән С. Хәким кичергәннәрме мондый тетрәнү халәтен? Әлбәттә, алар икесе дә мондый халәтне кичергән шәхесләр. Мәсәлән, Г. Тукай хәрби хезмәткә каралу комиссиясендә: «Сез яшәмәячәксез, хөрмәтлем...»—дигән үтә дә авыр сүзләр ишетә һәм шуннан соң шагыйрь берничә көн үз бүлмәсеннән чыкмыйча бикләнеп ята. Шагыйрьнең нечкә күңеле ни генә кичермәгәндер ул көннәрдә!?. С. Хәкимнең дә, сугыштан соң, 1946 елда, инде җаны чыгар чиктә Казанга кайтып егылгач, шундый ук халәт кичергәнен беләбез.

Нәтиҗә ясап, татар халкының олуг бу шәхесләре үзләренең «мәңгелек әһәмиятен һәм бурычын» иң тирән дәрәҗәдә аңлаган кешеләр дип уйларга кирәк. Һәм аларның кабатланмас иҗат феномены да нәкъ шушында булырга тиеш. Димәк, моннан соң инде башка иҗат кешеләре дә, бу ике асыл затыбызның дәрәҗәсенә ирешү өчен, шушындый ук «җан тетрәнү халәтен» кичерергә тиеш булачак. Күренә ки, бу—җиңел эш түгел. Ә халкыбызның уллары һәм кызлары арасында гомерләрен башкалар өчен, Ил өчен, мәдәниятебез өчен багышларга теләүчеләр бүген дә бар икән, моңа сөенергә генә кирәк.

«Таныш өянкеләр»не укыганда шушындый уйлар килә һәм шуңа этәргеч хисләр туа диясе килә. Гомумән, бу китапка карата тагын да тулырак фикерне махсус белгечләр әйтерләр әле. Минем максатым—бу китапны язучылар һәм бастыручыларга хәеррәхмәтемне белдереп, үземдә туган бер генә фикерем белән уртаклашу иде.

**Рәмзи НОГМАНИ,**
*профессор-культуролог.*
*Казан шәһәре*

# *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## ТУКАЙ РУХЫН ЗУРЛАУ

Елдагыча, быел да халкыбызның сөекле шагыйре Г. Тукайның туган көне (113 еллыгы) Татарстанның төрле шәһәр-авылларында һәм башкалабызда зурлап билгеләп үтелде.

26 апрель көнне иртән Тукайның Яңа Бистә зиратындагы кабере һәм аның исемен йөрткән мәйдандагы һәйкәле итәге чәчәк бәйләмнәренә күмелде—киң җәмәгатьчелек вәкилләре, милләтебез зыялылары шулай итеп олуг шагыйрьгә үзләренең тирән ихтирамнарын белдерделәр.

Аннары Ирек мәйданында, опера-балет театры янәшәсендәге Тукай һәйкәле янында шигъри митинг башланып китте. Митингны ачып җибәреп, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев Җөмһүриятебезнең Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган яңа лауреатлар турында ТР Президенты Указын игълан итте. Быел алар икәү—күренекле язучы Әхсән Баян һәм танылган композитор Анатолий Луппов.

Шигърият бәйрәмендә Лондоннан кайткан Р. Бохараев, Мәскәүдән-күренекле шагыйрә Л. Щипахина, Төркия кунагы Һарун Бәйрәм-оглы, Өфедән—М. Кәримов, Казаннан татар шагыйрьләре Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, К. Латыйп, Р. Әхмәтҗанов, Р. Вәлиева, Р. Мингалим, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Л. Шагыйрьҗан, Х. Әюп, Ж. Дәрзаман, Р. Җамал, Ш. Җиһангирова, Р. Зәйдулла, Л. Лерон, И. Гыйләҗев, Р. Газизов, Ф. Исмәгыйлова, Ф. Мөслимова, Илгөлем һ. б. чыгыш ясады. Тамашачылар Ф. Вәлиәхмәтов, И. Биктаһиров, И. Айнатуллов һ. б. башкарган җырларны да яратып тыңладылар.

Бәйрәмне Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, шагыйрь Ә. Гадел алып барды.

* * *

Г. Тукайның башкалабыздагы әдәби музее (Тукай урамы, 74 нче йорт), Татарстан Язучылар берлеге һәм «Тукай җәмгыяте» белән берлектә, ел саен апрель аенда «Тукай укулары» уздыра. Быел ул музей бинасында җиденче мәртәбә үткәрелде. Әлеге укуларда «Тукай җәмгыяте» президенты Т. Галиуллин, музей директоры Ф. Яхин, галимнәрдән Р. Нәфыйков, Н. Хисамов, Р. Ганиева, З. Рәмиев, Д. Заһидуллина һ. б. чыгыш ясады.

«Тукай укулары»нда катнашкан язучыларның һәм галимнәрнең чыгышлары киләчәктә махсус җыентык итеп бастырылачак. Быел аның беренче томы дөнья күрде инде.

* * *

Татар дәүләт әкият-курчак театры 20-26 апрель көннәрендә, Г. Тукайның туган көненә багышлап, «И туган тел, и матур тел!» дигән исем астында татарча спектакльләр атналыгы уздырды. Спектакльләр алдыннан язучылар, драматурглар һәм композиторлар белән очрашулар үткәрелде.

## ЭСТОНИЯДӘ БУЛУ

16-19 апрель көннәрендә Татарстан Дәүләт Советының парламент делегациясе, Эстония парламенты җитәкчелеге чакыруы буенча, эш визиты белән әлеге илдә булды. ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Р. Харисов, икътисадый үсеш һәм реформалар мәсьәләләре комиссиясе рәисе М. Галиев, Татарстан Дәүләт киңәшчесе В. Нуриәхмәтов составындагы делегация парламент депутатлары белән эш очрашулары уздырды, бу очрашулар барышында «Халыкларның хокуклары декларациясе» проекты тикшерелде.

Казаннан килгән кунакларны парламент скиперы Томас Сави кабул итте. Р. Харисов Сави әфәндегә аның өчен уңайлы вакытта Татарстанга килергә ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәмммәтшинның чакыруын тапшырды.

## «ЯЛКЫН»НЫҢ НУРЛЫ БӘЙРӘМЕ

21 апрельдә «Казан» милли мәдәният үзәгендә «Ялкын» журналының 75 еллык юбилей кичәсе гөрләп узды. Журналны (баш мөхәррире—Э. Закирова) нурлы бәйрәме белән Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасары З. Вәлиева, ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, Мәгариф министры Ф. Харисов, Яшьләр оешмалары советы рәисе И. Гыйльметдинов, Татарстан Язучылар берлеге

идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова һ. б. котлады.

### ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Казан дәүләт университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең конференцияләр залында татар халкының күренекле тарихчысы, археолог, этнограф, телче һәм педагог Гайнетдин Нәҗметдин улы Әхмәровның тууына 135 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды. Аны Казан дәүләт университеты, Татарстан Фәннәр академиясенең тарих институты, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үткәрде.

Конференциядә катнашучылар галимнәр һәм студентлар өчен Г. Әхмәров исемендәге стипендия булдыру һәм Казан шәһәренең бер урамына аның исемен бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә кирәк, дигән карарга килделәр.

### «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ» КУНАКЛАРЫ

Түбән Кама шәһәрендәге «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе әгъзалары 26 апрель көнне башкалабызда булып, Г. Камал театрына килгән күпсанлы тамашачыларга үзләренең күңел байлыкларын, осталыкларын күрсәттеләр. Әлеге очрашуга 1981—1999 еллар дәвамында «Җидегән чишмә» кичәләренең кунаклары булган мөхтәрәм шәхесләр, милләтебез заялылары чакырылган иде. Мәшһүр җырчы И. Шакиров, күренекле шагыйрьләрдән Р. Фәйзуллин, Р. Вәлиев, танылган рәссам Ә. Фәтхетдинов, атказанган галим А. Зыятдинов, тынгысыз әдип Р. Хисмәтуллин (ул әлеге берләшмәнең беренче рәисе дә!) һ. б. үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

Кичәне берләшмәнең бүгенге көндәге рәисе Р. Галиев һәм нәфис сүз остасы Г. Галиева алып барды.

### Ш. ХАММАТОВНЫ ИСКӘ АЛУ

4 майда Матбугат йортында күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим һәм журналист, озак еллар «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасының баш мөхәррире булып эшләгән Шәмси Хәбибулла угылы Хамматовның тууына 80 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе үткәрелде. Анда Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, ТР Журналистлар берлеге рәисе, «Татар-Информ» мәгълүмат агентлыгы генераль директоры Р. Ратникова, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Г. Шәмсетдинов, Казан дәүләт университетының журналистика, социология һәм психология факультеты деканы Ф. Әгъзамов, Шәмси аганың улы—«Татар иле» газетасының баш мөхәррире Ш. Хамматов һ. б. чыгыш ясадылар. Ветеран журналистлардан М. Шакирҗанов, Г. Шәрәфетдинов, Р. Вәлиев, М. Әһлиуллин, М. Гәрәев һ. б. үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

### БЕРТУГАН КОМПОЗИТОРЛАРГА БАГЫШЛАП

Сабада район хакимияте һәм «Татарстан» телерадиокомпаниясе бертуган композиторлар Аллаһияр һәм Хөснул Вәлиуллиннарга багышланган кичә уздырды. Аны үткәрүдә Казаннан килгән бер төркем сәнгать әһелләре—Р. Үтәй җитәкчелегендәге оркестр, Р. Еникеев, К. Тажиева, К. Хәйретдинова, Р. Үзбәкова, М. Галиев, Г. Ибушев һәм композиторларның туганнары да катнашты.

Кунаклар иң элек бертуган Вәлиуллиннар яшәгән йорттагы мемориаль такта янына чәчәкләр куеп, шунда чыгыш ясадылар. Аннары Вәлиуллиннар исемен йөртүче Сәнгать мәктәбендә очрашу булды, район мәдәният йортында композиторларның әсәрләре башкарылды.

### УЕН КОРАЛЛАРЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

Татарстанның берләштерелгән дәүләт музеенда дөнья халыкларының XIX—XX гасырларда эшләнгән уен коралларыннан торган үзенчәлекле күргәзмә ачылды. Уен кораллары дәүләт музее фондларыннан, Казан дәүләт университетының этнография музееннан, шәхси коллекцияләрдән алып куелган иде. Зур күләмдә тупланган уен кораллары Казанда гына түгел, гомумән, Идел буе төбәгендә беренче мәртәбә күрсәтелә.

Күргәзмәне ачу тантанасында А. Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры чыгыш ясады.

### БАЯНЧЫ-АККОРДЕОНЧЫЛАР КЛУБЫ

17 апрельдә Казан шәһәренең музыка сөючеләре өчен шатлыклы вакыйга булды. Бу көнне башкалабызның К. Маркс урамындагы 26 нчы йортында баянчы-аккордеончылар клубы ачылды. Клуб президенты—Татарстанның халык артисты, М. Җәлил премиясе лауреаты Владимир Федотов җитәкчелегендә үткән тантанада Рәгъдә Халитов, Виктор Киреев, Леонид Сонц кебек халыкара күләмдә танылу алган музыкантлар, Рафаэль Ильясов, Лилия Чугунова кебек халык мәхәббәтен яулаган җырчылар катнашты. Концерт-тамашаны нәфис сүз остасы Елена Крайнова алып барды.

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

ТР Мәдәният министрлыгы, рәссамнарның иҗади осталыкларын үстерү, аларның уңышларын тәгъдир итү йөзеннән, Бакый Урманче исемендәге премия булдырган иде. Бөек рәссам-сынчының туган көнендә беренче лауреатларның исемнәре мәгълүм булды. Хәнәфи Нәфыйковка «Бәйбарс» хезмәте өчен (нәкышь), Фәридә Хәсьяновага «Ак бүре» китабын рәсемнәр белән бизәгәне өчен (графика), Наилә Кумысниковага гамәли-декоратив сәнгать әсәрләре өчен Б. Урманче премиясе бирелде.

* * *

8-11 апрель көннәрендә Башкортстан Республикасының Бәләбәй шәһәрендә «Илһам чишмәләре» дигән исем астында халыкара шигърият фестивале булып үтте. Аның эшендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Әхмәт Гадел һәм Мамадыш районының Кече Кирмән урта мәктәбе директоры Рафаил Газизов та катнашты.

Әлеге фестивальдә фронтовик-шагыйрь Фатих Кәрим исемендәге бүләккә, Башкортстаннан Динис Бүләков (үлгәннән соң), Чувашстанның халык язучысы Порфирий Афанасьев, Пермь өлкәсеннән рус язучысы Игорь Тюленев белән берлектә. Татарстаннан шагыйрь Әхмәт Гадел лаек булды.

* * *

«Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе баш мөхәррире Фәрит Аги Иделлегә Бөгелмә төбәгенең күренекле галим-мәгърифәтчесе Һади Атласи исемендәге «Мәгърифәтче» иҗтимагый фонды премиясе бирелде. Яңа лауреат мондый мәртәбәгә аткалы шәхесләребездән Р. Фәхретдин, Г. Исхакый һәм Кырым татарлары хокукларын яклап көрәшкән П. Григоренко турындагы тапшырулары өчен лаек булды.

## ЮБИЛЕЙЛАР

12 майда Чаллы шәһәренең «Энергетик» мәдәният сараенда «Аргамак» журналының баш мөхәррире урынбасары, язучы-эзтабар Мансур Сафинның 50 яшьлек юбилеена багышланган әдәби-музыкаль тамаша булды.

* * *

13 майда Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында, «Шәһри Казан» газетасының бүлек мөдире, күренекле шагыйрь Госман Садәнең 50 яшьлеге уңаеннан, әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

## «АКЧАРЛАКЛАР» КАНАТ КАГА

22 апрельдә Ш. Камал музеенда яшь һәм башлап язучыларның «Акчарлаклар» әдәби берләшмәсен (җитәкчесе—Р. Әймәт) тәгъдир итү мәҗлесе үткәрелде. Әлеге очрашуда Казан шәһәр хакимиятенең мәдәният идарәсе җитәкчесе Р. Төхвәтуллин, шагыйрьләр Р. Гатауллин, Л. Шагыйрьҗан, М. Әгъләм һ. б. чыгыш ясап, иҗатчы «акчарлаклар»га талмас канатлар, биек кинлекләр теләделәр.

## ТУЙМАЗЫ АРТИСТЛАРЫ—КАЗАНДА

Башкортстан Республикасының Туймазы Татар дәүләт драма театры артистлары 1-6 апрель көннәрендә Казанда булып, Г. Камал театры сәхнәсендә үзләренең иң яхшы спектакльләрен күрсәттеләр. Театрның кече залында балалар һәм аларның әти-әниләре өчен оештырылган көндезге спектакльләр дә зур уңыш белән узды. «Җиктереп пар ат...» дип исемләнгән театрлаштырылган концерт та тамашачыларның күңелләренә хуш килде.

Театр сәнгате һәм мәдәният өлкәсендәге уңышлары өчен, Туймазы театрының баш режиссеры И. Гәрәевка, ТР Президенты Указы нигезендә, «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Театр коллективы Татарстан Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## БАШКАЛА АЛКЫШЛЫЙ

28-30 апрель көннәрендә Казанда—«Чулпан» кинотеатрында, Г. Камал исемендәге театрда һәм Химиклар мәдәният сараенда Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты, җырчы-тальянчы Фән Вәлиәхмәтов концертлары зур уңыш белән үтте. Концертта танылып килүче җырчылардан Бәширә Насыйрова, Рисәлә Мостафина, Фәнир Галимовның да катнашуы нур өстенә нур булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Шагыйрь һәм галим Нурмөхәммәт Хисамов.
*Рәссам (әдипнең улы) Айдар Хисамов эше.*



**Татар һәм дөнья әдәбияты зур югалту кичерде. 99 нчы яшендә Татарстан халык язучысы ГОМӘР БӘШИРОВның йөрәге тибүдән туктады.**

Гомәр Бәшир улы Бәширов 1901 елнын 7 гыйнварында Казан губернасы Арча волосте, хәзер Арча районынын Янасала авылында крестьян гаиләсендә туа.

Гомәр Бәширов әдәби ижади эшчәнлек белән 1932 елдан шөгыльләнә башлый. Ул башта «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә—хәбәрче, аннары хатлар бүлеге мөдире булып эшли.

1936 елдан Гомәр Бәширов—«Совет әдәбияты» журналынын җаваплы секретаре, 1938 елдан—Татарстан китап нәшриятынын нәфис әдәбият секторы редакторы. Анын әсәрләре Казан, Мәскәү һәм СССРның башка шәһәрләре газета-журналларында даими басылып килә. Г. Бәшировнын Гражданнар сугышы вакыйгаларына багышланган «Сиваш» повесте киң танылды.

Бөек Ватан сугышы чорында Г. Бәширов «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы булып эшләде.

60 нчы еллар башыннан Гомәр Бәшир улы—профессиональ язучы. Ул заман сулышын нечкә тоемлады. Язучынын үзенчәлекле таланты, халык күнеленен тирән катлауларын ачудагы осталыгы «Намус» романында аеруча ачык чагылды. Бу роман өчен Гомәр Бәширов СССР Дәүләт премиясенә лаек булды. Бу әсәр дөньянын дистәләрчә теленә тәрҗемә ителде һәм дөнья рухи мәдәниятенен алтын хәзинәсенә кертелде.

Ул үзенең «Туган ягым—яшел бишек», «Җидегән чишмә» кебек автобиографик әсәрләрендә халыкнын иң яхшы традицияләренен, гореф-гадәтләренең борынгыдан килгән чыганакларын, югары рухи, әхлакый сафлыгын, туган халкынын ирек һәм хезмәт сөючәнлеген бик оста сурәтләп бирде.

Үтә заманча язылган «Сарут» новелласы һәм кешенен җәмгыять алдында һәм үзе алдындагы җаваплылыгы турында 70-80 елларда иҗат ителгән хикәяләре өчен Гомәр Бәшировка Татарстан Республикасынын Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Гомәр Бәшир улы халык иҗаты әсәрләрен җыю, эшкәртү һәм пропагандалау буенча мавыгып һәм нәтиҗәле эшләде. Ул җыйнаган һәм эшкәрткән фольклорнын иң яхшы үрнәкләре шулай ук дөнья халыклары телләрендә кат-кат басылды.

Г. Бәширов һәрвакыт тормыш эчендә кайнап яшәде, җәмәгать эшчәнлегенә күп көчен бирде. Ул ике тапкыр СССР Югары Советы һәм Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты булып сайланды.

Г. Бәшировнын күпкырлы таланты һәм җәмәгать эшчәнлеге Ватаныбыз тарафыннан югары бәяләнде. Ул Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнде. Ана шулай ук Татарстан Республикасынын халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде.

Татар халкынын күренекле язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе турындагы якты истәлек безнен күнелләрдә мәнге сакланыр.

**М. Ш. Шәймиев, Р. Н. Миннеханов, Ф. Х. Мөхәммәтшин, Ә. С. Гобәйдуллин, И. К. Хәйруллин, Р. М. Харисов, М. Х. Хәсәнов, К. Ш. Исхаков, М. М. Таишев, И. Н. Сабиров, С. Ф. Мөхәрләмов, Р. С. Мөхәммәдиев, Р. А. Җиһаншина, Р. Ф. Кәлимуллин, Ә. Н. Еники, Г. А. Ахунов, Ш. Г. Галиев, И. Г. Юзеев, В.В. Корчагин, Т. А. Миннуллин, Р. Г. Фәйзуллин.**

Индекс 73210



Нурмөхәммәт Хисамов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)